Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты

*Галимҗан Баруди*

# ХАТИРӘ ДӘФТӘРЕ

## 1920 елның октябреннән алып 1921 елның ноябренә кадәр

Казан – 2018

УДК 82-94
ББК 63.2(2Рос=Тат)
Б 23

*ТР ФА Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты
Гыйльми советы карары нигезендә басыла*

**Фәнни мөхәррир:**
ТР ФА академигы, тарих фәннәре докторы
*Радик Салихов*

**Җаваплы мөхәррир:**
Киров өлкәсе мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе,
мөфти *Зөфәр хәзрәт Галиуллин*

**Китапны басмага әзерләүчеләр:**
*Айдар Гайнетдинов*,
*Руслан Хәбибуллин*

Б 23 ***Баруди Г.*** **Хатирә дәфтәре: 1920 елның октябреннән алып 1921 елның ноябренә кадәр** / Басмага әзерләүчеләр *А. Гайнетдинов, Р. Хәбибуллин*. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2018. – 272 б.

ISBN 978-5-94981-299-0

«Хатирә дәфтәре» – мәшһүр дин галиме, җәдитче, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог Галимҗан Барудиның көндәлек дәфтәре. Анда төрле тарихи вакыйгалар тасвирланган, галимнең кызыклы карашлары, кыйммәтле фикерләре, акыллы киңәшләре чагылыш тапкан. Китап татар халкы тарихы, дини мирас белән кызыксынучы укучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-94981-299-0

УДК 82-94
ББК 63.2(2Рос=Тат)

© ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2018

## Кереш сүз

Галимҗан Баруди (1857–1921) – мәшһүр дин галиме, дини реформатор, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, педагог, нашир, журналист. Ул 1857 елның 17 февралендә хәзерге Биектау районы Кече Кавал авылында туган, Казанда үскән. 1862 елда үсмер Галимҗан Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсенә укырга кергән. 1875 елдан ул укуын Бохарада дәвам иткән. Андагы уку йортларында схоластика, обскурантизм, фанатизм, мистицизм белән сугарылган дин өйрәтелсә дә, Г. Баруди, Бохарадагы укуы белән канәгатьләнмичә, 1882 елда ул Казанга кайткан һәм бишенче мәхәллә мәчетенә имам итеп билгеләнгән. Тиздән 1882 елда җәдитчелек ысулындагы атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен оештырган һәм шунда укыткан. Шулай ук ул актив рәвештә дәреслекләр төзеп бастырган. 1906 елда Казанда Г.Баруди мөхәррирлегендә «Әд-дин вәл-әдәб» («Дин вә әхлак») журналы чыга башлаган. 1908 елда, кадимчеләрнең яла ягуы аркасында, Г.Барудины панисламизмда гаепләп, ике елга Вологда губернасына сөргенгә җибәргәннәр. Шул вакытларда чит илләргә сәяхәт кылып, Истанбул, Каһирә, Мәдинә, Мәккә кебек шәһәрләрдә булып, үзенә кирәкле гыйлемнәр туплаган. 1917 елда күпчелек тавыш белән Уфадагы Русия мөселманнарының Диния нәзарәте мөфтие итеп сайланган. Г.Баруди 1921 елның 6 декабрендә вафат булган. Кабере Казанның Яңа татар бистәсе зиратында. Ташының тексты түбәндәгечә:

1) «Мәшһәдүл-гаалим-
2) -ил-фәәдыйли
3) хаадимил-гыйльми
4) вәд-диини
5) Галимҗан
6) бине Мөхәммәдҗан
7) әл-Баруди
8) рахимәһүмәәллааһү
9) рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе: «Хөрмәтле галим, гыйлем һәм дин хадиме Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди. Аллаһ аларның икесен дә киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Узган ел аның иске кабер ташы яңага алыштырылды. Кызганычка каршы, иске ташын, зиратта калдырмыйча, алып киткәннәр. Аның урынына мәрмәрдән эшләнгән яшькелт төстәге яңа кабер ташы куелып, түбәндәгечә сүзләр язылган:

1) «1857 / 1273 – 1921 / 1340

2) Галимҗан хәзрәт Мөхәммәдҗан углы

3) әл-Баруди (Галийыф)

4) мәшһүр дин галиме, ишан җәмәгать эшлеклесе

5) Мөхәммәдийә мәдрәсәсенә нигез салучы күренекле мөдәррис

6) Русийә мөселманларының Динийә нәзарәте мөфти»[1].

Мондагы текст та гарәп графикасында язылган, тик тел галимнәре белән киңәшләшмичә ясатылганга күрәдер, кайбер орфографик һәм пунктуацион хаталар күзгә чалына.

Г. Баруди турында без күп ишетсәк тә, кызганычка каршы, галимнәр, белгечләр тарафыннан галимнең бөтен хезмәтләре халыкка кайтарылды, дип әлегә әйтеп булмый. Кайберләре һаман үз чиратын көтеп ята. Мәсәлән, шундыйлардан «Хатирә дәфтәре» (кульязма рәвештә сакланан).

Г. Барудиның дүрт көндәлеге билгеле. Беренчесе – «Истанбулга сәяхәтем». Ул 1907 елда Төркиягә барган сәфәрендә күргән вакыйгаларны тасвирлауга багышланган булып, 1908 елда «Әд-дин вәл-әдәб» журналында басылып чыккан иде[2].

Икенчесе – 1918 елда язылганы – Төркестан һәм Казакъстан якларына оештырылган сәяхәтенә багышланган. Г. Баруди шул сәфәрендә Кызылъяр, Троицк, Чиләбе, Омск, Күкчәтау һ.б. шәһәрләрдә булып, үзенең күргәннәрен, теге яки бу мәсьәләгә карата фикерләрен язган. Әлеге көндәлек КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана[3]. Ул гарәп графикасыннан кириллицага күчерелеп, 2004 елда басылып чыкты[4].

---

[1] Ахыргы өч юлы ташның аскуймасында язылган.

[2] Баруди Г. Истанбулга сәяхәтем // Әд-дин вәл-әдәб. – 1326/1908. – № 1. – 22–25 б.; – № 2. – 57–60 б.; – № 3. – 86–90 б.; – № 5. – 149–152 б.; – № 6. – 184–187 б.; – № 7. – 209–214 б.

[3] КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге китапханәнең кульязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 1682 – Т.

[4] Галимҗан Баруди. Кызылъяр сәфәре. – Казан, 2004. – 167 б.

«Хатирә дәфтәре» дип аталган өченче көндәлек 1920 елның 12 июненнән алып шул ук елның сентябрь ахырына кадәр язылып барган. Монысы да КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә[5] һәм тагын бер нөсхәсе, төгәлрәк әйткәндә, Ш. Шәрәф тарафыннан күчереп язылганы, шәхси кулларда саклана. Өченче «Хатирә дәфтәре»нең яртысы «Казан» журналының 1997 елгы саннарында[6], рус теленә тәрҗемәсе параллель рәвештә «Казан» журналының 1997 – 1998 елгы саннарында басылып чыкты[7], шулай ук «Иман» нәшриятында шул ук өлешләре китап рәвешендә ике телдә дөнья күрде[8]. 2017 елда Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты тарафыннан югарыда искә алынган «Хатирә дәфтәре»нең өченчесе тулы рәвештә диярлек басылып чыкты[9].

Бәхеткә каршы, Г. Барудиның әле дүртенче көндәлеге дә сакланып калган һәм ул 1920 елның октябреннән алып 1921 елның 18 ноябренә кадәрге чорны үз эченә алган. Шуннан соң берничә атнадан соң Галимҗан хәзрәт бакыйлыкка күчкән. Ул үзенең озакламый вафат булуын сизеп торган кебек, чөнки февраль аенда ук түбәндәге сүзләр язып калдырган: «Аллаһ янына барыр вакытым ирешкән, дөньяны куеп, асыл ватанга кайту вакытым җиткән. Хисап дәфтәремә карасам, ахирәт азыгы булырдай һич эшемне күрмим, таяныч булырлык бер гамәл таба алмыйм. Тик тәүхид [бераллалык] иясемен, Коръән иясемен, Коръәнгә мәхәббәтем бар. Рәсүлуллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) юлына керүне һәм аның сөннәте белән эш күрүне тиешле күрәм. Коръәнне һәм хәдисне аңларга, аңлаганча гамәл кылырга, кешегә дә шулай аңлатырга

---

[5] КФУ каршындагы Лобачевский исемендәге китапханәнең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге: 1604 – Т.

[6] Баруди Г. Хатирә дәфтәре // Казан. – 1997. – № 10–11. – 71–89 б.; – № 12. – 118–158 б.; – 1998. – № 1. – 21–48 б.

[7] Баруди Г. Памятная книжка // Казань. – 1997. – № 10–11. – 71–89 б.; – № 12. – 118–158 б.; – 1998. – № 1. – 21–48 б.; – № 2. – 66–86 б.

[8] Әл-Баруди Галимҗан. Хатирә дәфтәре / Галимҗан әл-Баруди. – Казан: «Иман» нәшрияты, 1428 / 2007. – 106 б.; Баруди Г. Памятная книжка / Г. Баруди. – Казань: Изд-во «Иман», 2007. – 130 с.

[9] Баруди Г. Хатирә дәфтәре: 1920 елның 12 июненнән алып сентябрь ахырына кадәр / Басмага әзерләүче А. Гайнетдинов. – Казан: ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2017. – 236 б.

максат һәм бер дәрәҗәдә тырышлык сарыф итәм. Бу юлны үземә мәсләк [итеп] тотам».

Әлеге соңгы «Хатирә дәфтәре» дә Ш. Шәрәф тарафыннан күчереп язылып, хәзерге көндә шәхси кулларда саклана. Шәһәр Шәрәф (1877–1938) заманында Г. Барудиның 1920–1921 елларда язылган көндәлекләрен пөхтә итеп күчереп язган булган. Хәзерге көндә әлеге «Хатирә дәфтәре» шәхси кулларда саклана. Безгә Ш. Шәрәф күчергән нөсхәнең фотокопияләренә ия булу бәхете татыды. Дин галиме, язучы, педагог, тарихчы, җәмәгать эшлеклесе Ш. Шәрәф хәзерге Буа районы Аксу авылында туган, 1897–1919 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыткан, «Әд-дин вәл-әдәб» журналында эшләгән, Казанда имам-хатыйб вазыйфаларын үтәгән, Диния нәзарәтендә дә хезмәт куйган. Ул Г. Барудиның иң яхшы шәкерте булып хисапланган.

Хатирә дәфтәре»ндә Г. Баруди байтак дини мәсьәләләргә карата, мөфти буларак, үзенең акыллы фәтваләрен биреп, аңлашылмаган яки бәхәсле дини мәсьәләләрдә ачыклык керткән һәм дәлилләп, тәфсилләп аңлаткан. Бүгенге көндә дини гыйбадәтләрнең уку рәвеше хакында күп бәхәсләр, тарткалашулар барган заманда аның бу фикерләре бик актуаль яңгырый. Шунысын да әйтергә кирәк: Г. Баруди байтак дини мәсьәләләрдә хәнәфи мәзһәбенә иярмәгән, иҗтиһад кылып, үзлегеннән Коръән һәм хәдисләрдән җавап табып, дөрес хөкем чыгара белгән. Шуңа күрә аны мөҗтәһид галим дип санарга тулы нигез бар.

XX гасыр башында Г. Баруди тарафыннан күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль, әйтерсең лә, ул көндәлегендәге фикерләрен хәзерге заманда яшәүче милләттәшләребезгә юллаган, шуңа күрә дә аның әһәмияте әйтеп бетергесез. Ул безгә тарихның билгесез һәм караңгы якларын ачкан, күп кенә авыр ситуацияләрдән чыгу юлларын күрсәткән, милләтне һәм динне саклау ысулларын өйрәткән.

Һәр кеше «Хатирә дәфтәре» белән үзлегеннән танышып чыга алмый. Бу инде аңлашыла да, беренчедән, ул гарәп графикасында язылган, икенчедән, иске татар телендә, ягъни хәзерге телдән шактый аерыла торган рәвештә язылган. Шуңа күрә без Г. Барудиның «Хатирә дәфтәре (1920 елның октябреннән алып 1921 елның ноябренә кадәр)» дип аталган көндәлек дәфтәрен кириллицага күчереп, аңларга уңайлы булсын өчен, барлык архаик грамматик формаларны хәзерге әдәби тел нормаларына салып

эшләргә булдык, ягъни максималь дәрәҗәдә хәзерге гамәлдәге телгә җайлаштырдык, якынайттык. Шактый күп очраган гарәп телендәге җөмләләр татар теленә тәрҗемә ителде, аңлашылмаган сүзләргә яки терминнарга җәяләр эчендә аңлатма бирелде. Тоташ гарәп яки фарсы телендә язылган шигырьләрне, катлаулы дини гыйбарәләрне, борынгы гарәп-фарсы китапларыннан алынган цитаталарны төшереп калдырдык.

Г. Баруди – һичшиксез җәдитчелек хәрәкәтенең күренекле вәкиле. Ул тышкы кыяфәте белән гади әһелләре кебек булса да, үзенең эчке рухи дөньясы, дини карашлары белән алардан нык аерылып торган, бөтен көчен милләтебез, динебез өчен сарыф итеп, армый-талмый хезмәт куйган, халыкны аң-белемгә, иҗтиһадка (шәригать мәсьәләләрен үзлектән тикшереп, мөстәкыйль фикер йөртүгә) чакырган һәм схоластикадан, тәкълидтән (мәзһәбләргә сукырларча иярүдән) арынырга өндәгән.

Кызганычка каршы, үзебезнең җирлектә туган галимнәребез Г. Баруди, Г. Курсави, Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, М. Бигиев, Г. Буби, З. Камали, Ш. Шәрәф тарафыннан язылган хезмәтләр, әйтелгән фикерләрне санга сукмау кебек күренешләр дә күзәтелә. Әгәр дә без бу шәхесләрне онытсак, алар өйрәтеп калдырган сүзләр белән гамәл кылмасак, артларыннан иярмәсәк, милләтебезнең хәле бик аяныч булачак. Иманыбыз камил, арабызда Г. Баруди кебек фикерләүче шәхесләр булса, җәдитче галимнәребезнең юлыннан читкә тайпылмасак, данлыклы дини реформаторларыбызның хезмәтләрен туплап, алар буенча гына дини мәгарифебезне үстерсәк, тиз вакыт эчендә динебездә экстремистик һәм радикаль карашлар, агымнар юкка чыгар, мөселманнар арасында тынычлык-иминлек урнашыр, милләтебезнең киләчәге матур булыр иде. Шул сәбәпле, мәгърифәтчеләребезнең мирасын халыкка кайтару эшендә галимнәргә, җиң сызганып, армый-талмый хезмәт кую гаять зарур һәм актуаль.

***Айдар Гайнетдинов,***
филология фәннәре кандидаты

*БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ*

## Диния нәзарәтенең кулланылуы һәм киләчәктә фарыз ителгән чаралары

Шура хөкүмәте дәвам итсә, Нәзарәтнең дәвам итүе шөбһә астында булып калачак. Диннең бөтен нигезләрен инкяр итүче булганлыктан, динне куәтләү сәбәпләрен бөтенләй бетерергә тырышачаклар.

Бу мәсьәләдә мөселманнар өчен ике юл күренә:

Берсе: Диния нәзарәтенә нык багланып, матди һәм мәгънәви мөнәсәбәтләрен куәтләп, бөтен халык аның кирәклеге турында үзара карарлар чыгарып, форсат һәм урыны килгән саен Мәркәзгә мөрәҗәгатьләр ясый торырга тиеш. Мөмкин кадәр Нәзарәтнең әһәмиятен сүз һәм эш белән күрсәтә тору, аның дини мәркәз икәнен, динне саклау өчен мәҗбүри икәнен белдерә тору тиеш. Нәзарәт үзе сәясәттән тәмам читтә торып, хөкүмәтнең сәясәтенә каршы хәрәкәтләрдән саклану, кайбер шәригать шәриф һәм сәламәт вөҗдан сыйдырган кадәр булышуларда һәм ярдәмләшүләрдә булырга тиеш ки, бөтенләй ябу һәм туктату өчен ачык кыйммәт күренмәсен, бер дәрәҗә файда кылгандай булып торсыннар. Нәзарәт тарафыннан булган булышуларны тиешенчә аңлатып һәм игълан итеп торырга, хөкүмәтне һәм халыкны бу эшләрдән хәбәрдар итеп торырга тиеш. Бу рәвештә халыкның хөкүмәт белән мөнәсәбәте һәм аңа карашы бер дәрәҗәдә урта фикердә булачак. Теләгән кешеләргә диннәрен саклар өчен ярдәм итүчән булып күренгәнлектән, халык байтак хөррият өйрәнәчәк. Хөкүмәтнең халык хөкүмәте булып игълан ителүенә ачык каршы бер сәясәт күрмәячәк.

Икенче юл: Нәзарәтнең бөтенләй ябылуы – рәсми рәвештә аңа соңгы чик һәм азак бирелүе. Бу рәвеш ачык булса, хөкүмәт моннан бөек зарар күрәчәк, халыкның йөрәкләрендә һәм рухларында бөек нәфрәтләрен тудырачак, шәрыкъ мәсьәләсенә дә бөек тукталыш булачак. Мөселманнардан гыйбарәт булган шәрык халкы бу мәсьәләне дини бер мәркәзне бетерү, ислам шәехлеге ишеген бикләү, халыкны дини оешмадан туктату, дини һәм әхлакый тәрбиядән мәхрүм итеп, хайваннар кебек буш ташлау дип караячаклар. Бер кечкенә мәсьәлә ки халык өчен кирәк һәм тормышыннан да

артык дәрәҗәдә кирәксенелә. Хөкүмәтнең нигез эшләре өчен бер дә зарары булмаган бер оешманы ябудан һәм туктатудан торачак нәрсә халык өчен дини афәт, хөкүмәт өчен бер сәяси хата булачак.

Әгәр дә бу хәл була калса, мөселманнар өчен тиешле тормыш һәм диннәрен саклау рәвеше:

1. Һәр кайсы даирәдә булган өстенлекле галимнәрне – мөхтәсибләрме, башкача галимнәрме – әмма муллалар үзләренә үрнәк итеп танып, халыкка да шулай танытып, кирәкле булган гыйльми һәм дини чараларда аларга мөрәҗәгать итәргә тиеш. Бу мәсьәләдә байтак әхлакый фидакярлек кылырга тиеш булыр.

2. Имамнар һәм халык мөмкин кадәр бердәмлектә булып, мәктәп һәм мәдрәсәләрне ахыргы көч җиткәнчә алып барырга тиеш. Әгәр дә мәктәп һәм мәдрәсә исемендә кулларында бернәрсә дә калмый икән, мәчетләрдә, йортларда, хәтта очраган җыеннарда, базарларда укытулар, дини нәсыйхәтләр, тормыш кисәтүләре ясарга кирәк. Изге сәләфләр [борынгы изге кешеләр] вакытларында һичбер мәдрәсә булмаган хәлдә, мәчетләрдә укытып, шәкертләр һәм башка адәмнәр дәрес һәм вәгазь түгәрәкләрендә булып, гыйлем алмашалар, динне саклау рәвешләрен, әхлак төзәтү ысулларын һәм юлларын өйрәнгәннәр.

3. Халык бу вакытта элекке заманнан артыграк мал иганәләрен майданга кую, бөек-бөек акчалар туплап, халыкны укыту мәсьәләсендә фәкыйрь һәм гаҗиз шәкертләрне, ятимнәрне тәрбияләп, аларның дин галиме булулары мәсьәләсендә мал сарыф итү тиеш ки, алдагы көн өчен дини әзерлек булыр. Чын иганәнең вакыты кулда калган булса, байлыкның файдасын күрә торган заманы килгән булыр.

4. Шулай ук дин галимнәренең, яхшы имамнарның кадер-хөрмәтләрен белеп, тормыш мәсьәләсендә яхшы иганәләр хаҗәт булыр ки, алар тормышлары җәһәтеннән куркусыз булып, яхшы тырышырлар. Дин мәсьәләсендә халык матди ярдәмнәрен кызганмаганнары кебек, болар да мәгънәви ярдәмнәрен кызганмасыннар.

5. Мөмкин кадәр һәркем – галим һәм җаһил, бай һәм фәкыйрь, олы һәм кече, яшь һәм карт дингә сарылып, нык һәм төгәл ябышырлар. Дингә каршы хәрәкәтләр куәтләнгән вакытта яклау һәм кешелеклелек бигрәк артып, каршында фидакярлек итеп, тырышырлар. Ничек Романовлар вакытында миссионерларның начар хәрәкәтләрен вакытында халыкта яклау һәм гайрәт кузгалып, диндә ныклык арткан иде.

Динне өйрәнү, саклау турында безнең сәләфләребез, Рәсүлуллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен), хөрмәтле сәхабәләр (Аллаһ алардан риза булсын) башлап, табигыйн [сәхабәләрне күргән мөселманнар], тәбгы табигыйннар [табигыйннарны күргән мөселманнар], аннан соңгы изгеләр һәм яхшы диндар мөселманнар ничек тырышканнар, ни кадәр фидакярлекләр иткәннәр, малларын аямаганнар.

Диндар адәм өчен дин иң кадерле нәрсә булганлыктан, аның турысында һичнәрсәне дә аямаска тиеш тә була. Шул рәвешле динне саклау заманы, тырышлык белән тоту заманы инде киләчәк һәм килә дә башлады. Шәхси максатлардан китеп, кыямәт көнен күз алдында тотып, Аллаһның динен югалтмаска һәм торгызырга тырышу безнең чиратка төшсә, авырлыклар күтәрергә туры килсә дә, безгә дөньяда һәм ахирәттә хөрмәт булачак. Иншалла, чиксез әҗер һәм савап булачак. Шул хәлне ганимәт итеп белеп, һәркайсы тәкъдирдә дә тырышу һәм кулыбызда булган кодрәтебезне сарыф итү тиеш. Шул рәвешле, милләт тырышса, аларның башларында булып, галимнәр һәм имамнар яхшы юллар, фидакярлекләр күрсәтеп торсалар, өметләнәм ки, уңыш табарбыз, уңышка ирешербез.

Менә ахыр чиктә бердәнбер Мәхкәмәи шәргыябез ябыла, бетерелә икән, без, иншалла, дини гайрәтебез һәм төрки дәртебез белән тырышып, динебезне сакларбыз, шул мәсьәләдә һәр бар нәрсәбезне фида итәрбез. Аллаһ насыйп итсен. Мәрхәмәтен һәм кайгыртуын безгә юлдаш итсен. Амин!

## Диния нәзарәте дәвам итсә, аның киләчәге өчен идарә итү рәвеше һәм чара

**Әгъзалары.** Казакларныкыннан башка Нәзарәт өчен бары дүрт әгъза кирәк: мөфти, өч казый. Болар һәркайсы аңлы һәм диндар галимнәр арасыннан алты елга бер сайланып куелырлар. Уртача яшьтә, уртача фикердә, җитди, милли эшләрдә кайгыртучан, тәрҗемәи хәле билгеле, дин мәсьәләсендә үзенең эше һәм тормыш юлы белән галимнәргә һәм башка мөселманнарга яхшы үрнәк булырдай адәмнәрдән булуы тиеш.

**Тәэмин ителүе.** Милләт тарафыннан тиешле юллары белән боларның, билгеле булганча, бик яхшы дәрәҗәдә булырлык тормышлары тәэмин итлергә тиеш ки, юк-бар тар юлларга керергә, үз

әсбап һәм җиһазларын югалтырга, үзләренең элекке байлыкларын сарыф итәргә мохтаҗ булмасыннар.

**Мәхкәмәи-шәргыянең хезмәтләре**.

I. 1. дини мәдрәсәләр, кирәкле ысул һәм яхшы тәртип алганча, имам, мөдәррис һәм мөәзиннәрне урта программа белән имтихан кылыр.

2. Имтиханда һәркайсы сыйныфтан Коръән укый белү, дөрес уку һәм язу, дин гыйлеме, пәйгамбәр тормыш юлы маддәләренә әһәмият бирелер, имам һәм мөдәррис булучыларда бу мәсьәләләр артык рәвештә әһәмият бирелер.

3. Имтихан булачак кешеләрнең дин һәм әхлагына әһәмият белән игътибар ителер. Үзе нык диндар әһеле булмаган кеше, халыкның дине өчен кайгырмас, киләчәк көннәрдә дин һәм милләт эшләрендә артык эш күрү имамнар вазыйфасы булып, бу мәсьәләдә имтихан вакытында да аеруча дикъкать ителми.

4. Бу маддәләр өстенә акыл фәннәреннән (хисап, милли һәм гомуми тарих, география һәм башкалардан) хәбәрдар булу таләп ителә. Табылса, болар дини вазыйфалар өчен дә артык итеп тотылырга тиеш.

Искәртү: Аксай, Сибирия һәм Хаҗитархан кебек озак җирләрдә Мәхкәмәи-шәргыя хаҗәт күрсә, аерым вакытлы комиссия билгеләп, имтихан мәҗлесе ачар һәм аларның имтихан шәһадәтнамәләрен рәсми рәвештә танып, шуның буенча указ бирер.

5. Имтиханның һәр вакытта булуы Мәхкәмә өчен кулайсыз, шунлыктан имтихан өчен ике вакыт билгеләнер: 1) май, июнь айлары; 2) сентябрь-октябрь айлары.

II. Мәхкәмәи-шәргыянең икенче хезмәте – ярлык бирү хезмәте.

1. Бу мәсьәләдә элекке кагыйдәләргә игътибар ителер. Мәхәллә халкының өчтән икесе риза булуы, имам һәм мөәзиннең тормышларын җитәрлек кадәрле тәэмин итәргә килешүләре, майданда искә алынган кешеләрнең шәригатьтә һәм сәясәттә гаепләре булмавы кебек шартларга игътибар ителер.

2. Мәхәллә кечерәйтергә мөмкин кадәр каршы торырлар. Тик элек Милләт мәҗлесе карарынча, һәрвакыт мәхәлләнең һәркайсы ике йөз йорт булуын шарт күрү – үтәве авыр булган шарт. Бәлки йөз кадәр йорт булып, мәчет һәм мәктәпне имам һәм мөәзинне тәрбия итәрлек булганда мәхәллә торгызу яраса кирәк.

3. Бер мәхәлләгә икенче имам алу да шулай ук урынына күрә үтәлергә тиеш. Зарурлык булмаганда, икенче имам алынмас, ләкин

дини яки иҗтимагый зарурлык булганда, алырга мөмкин булыр. Мәсәлән, әүвәлге имам имамлык эшендә чикләнгән була торып, укыту мәсьәләсендә йомшаклык күрсәтсә яки фикере түбән булганда, халык тәрбияләвенә көче җитмәгәндә, укыту мәсьәләсен яхшы ачу өчен икенче имам алу мөмкин булыр. Элекке карар буенча, әүвәлге карт имамның имамлык хезмәтен башкара алмау дәрәҗәдә картлыгы маддәсенә генә хас булмас. Моның кебек зарурлыклар булганда, Мәхкәмәи-шәргыянең үз фикере һәм саклануы белән икенче имам кую мөмкин булыр.

4. Ике имам булганда, хөтбә сөйләүче һәм имам гает, җомга хөтбәләреннән башка вазыйфалар үтәүдә, никах һәм талак, исем кушу һәм җеназа маддәләрендә бертигез булырлар. Бу тиешле эшләрдә хөтбә сөйләүченең артыклыгы булмас. Бары дәфтәрләр хөтбә сөйләүче кулында булыр.

III. Өченче төр хезмәте – метрика әзерләү (гаилә дәфтәре җитештерү). Элек бу хезмәтне Мәхкәмәдән тәмамлап чыгаралар иде, ләкин Мәхкәмә өчен байтак мәшәкатьле эш. Үзе кирәкле эш булса да, зур, мөһим эш түгел. Шунлыктан бу эшне Казан кебек матбагасы күп җирдә мөхтәсибләр аркылы яки аерым бер комиссия аркылы эшләтү мөмкин булыр. Искә алынган комиссия тарафыннан дөрес рәвештә эшләтеп, шуннан ук кирәкле урыннарга таратылыр. Таратканда һәр өлкәнең мөхтәсибе аркылы таратылса, яхшырак булыр. Ләкин имамнардан күчермәләрнең (копияләр) барысы да Нәзарәттәге архивка тапшырылыр. Мәхкәмә барчасын кабул итеп, тикшереп, тиешле урынына куяр.

IV. Мәгариф эше.

1. Башлангыч, урта укулар барчасы Мәхкәмәи-шәргыядә төзеләр.

2. Һәр мәхәлләдә дини укыту өчен мәктәп яки мәчет, я башка бер өй торгызылыр.

3. Имамнар, куәтлерәк мөәзиннәр укытырга мәҗбүр ителер. Кирәк булса, дингә мөнәсәбәтле хәлфәләр куелыр. Хәлфәләр билгеләгәндә Мәхкәмәи-шәргыя дә ярдәм итәр.

4. Укыту мәсьәләсендә вакытына яраклы дәрес программасы һәм китаплары билгеләнер. Китапларны мөмкин булган кадәр хәзерләргә тырышыр.

5. Бу мәктәпләр ахуннар һәм алардан өстен мөхтәсибләр карамакларында булып, рәвешләреннән, хәлләреннән хәбәрдар булыр-

лар. Кирәк вакытта мөхтәсибләр Мәхкәмәи-шәргыягә хәлне бәян итәрләр.

6. Хәҗәт вакытта Мәхкәмәнең үзе тарафыннан да тикшерүче йөреп, әхвәлләреннән хәбәр алыр һәм Мәхкәмәне дә хәбәрдар итәр.

**Дини мәдрәсәләр.** Зур шәһәрләрдә, өстенлекле урыннарда мулла-мөәзин җитештерер өчен дини мәдрәсәләр торгызылыр.

1. Мәдрәсәләр мәсьәләсе бүленеш рәвешенчә хәл ителергә тиеш. Кечкенә шәһәрләрдә, гыйльми мәркәз булып хисапланып килгән авылларда урта белем дәрәҗәсендәгеләр беренче өлешне тәшкил итерләр.

2. Зур шәһәрләрдә – Казан, Оренбург, Хаҗитархан, Троицк, Уфа кебек шәһәрләрдә – урта белем дәрәҗәсе өстенә югарырак дәрәҗәдә укыту төзеп, имамлык дәрәҗәсенә лаек булырлык программа белән төзелер.

3. Имамлык дәрәҗәсенә хәзерләү мәдрәсәсе бер шәһәрдә берничә булмаска тиеш. Бәлки ул шәһәрдәге күп санлы мөдәррисләр бер дәресханәгә тупланып, бер программада һәм бер даирәдә булып, дәресләргә бүленеш ысулынча уртак укыту тиештер.

4. Әгәр Хода насыйп һәм мәрхәмәт итеп, мәдрәсә һәм шәкертләр күбәеп китсәләр дә, һаман мәңгегә уртак һәм бердәмлек белән бер даирәдә булып укыту тиеш булыр. Христианнарда төрле даирәләрдән Казан академиясенә җыелып, шуннан чиркәү башлыклары булып чыгалар. Бу тәкъдирдә, күп санлы мәдрәсәләр Бохара һәм Истанбул мәдрәсәләре кебек, ялгыз тора торган урын һәм укуханәсе булып, ул мәдрәсәнең мөдәррисеннән мөдәррис булу сыйфаты белән дәрес уку мәҗбүри булмас. Мәсәлән, Казанның дәресханә даирәсе һәм дәрес идарәсе шәкертләрне дәрәҗәләренә күрә яраклы мәдрәсәгә урнаштырыр. Дәрәҗәсенә яраклы һәм дәресләренә күрә укыячак урынын һәм мөдәррисен билгеләр. Бер җирдәме, ике җирдәме – тиешенчә билгеләнер. Торган җирнең кануны буенча тормыш итәр, куелган программа буенча дәресләр укыр.

5. Мөдәррисләр һәм могаллимнәр идарә тарафыннан билгеләнгән тәртип белән дәресне дәвам итәрләр, үзләре билгеләнгән дәресләрне көчләре җиткәнчә тырышып укытырлар.

6. Һәркайсы урында булган көчле кешеләрнең укыту эшендә катышуына, көче җиткән кадәрле тырышуына Мәхкәмәи-шәргыя тарафыннан кайгыртылыр. Мөхтәсибләр аркылы күзәтелер һәм

хәбәр алыныр. Кайбер вакытта Мәхкәмәнең үзе тарафыннан әгъзаларның кайбеләнренә тикшерү хезмәтләре йөкләтелер.

V. Мәхкәмәи-шәргыя гаилә низагларын карап, дошманлыкны туктатыр.

1. Бу мәсьәләдә элек бер гаилә нәсыйхәтнамәсе таратыр, имамнарга да бу мәсьәләдә әхлакны саклау өчен халыкны вәгазьнәсыйхәт кылырга һәм тиешенчә тырышырга боерыр ки, эшнең тоткасы низагны тудырмауда.

2. Низаг туса, мөмкин кадәр мәхәллә имамы туктатырга, килешүләр белән бетерергә тырышыр, һич мөмкин булмаса, мөхтәсиб низагны туктатырга тиеш. Иң соңгы дәрәҗәдә генә югары Мәхкәмәи-шәргыягә җиткерелер, мөхтәсибләр яки имамнар аркылы дәгъваны бетерер.

3. Гаилә дәгъвалары турысында бу кагыйдәгә таяныр: ислам динендә һичкемнең хокукы югалмас. Бу мәсьәләдә олы кагыйдә: «Ирләр – хатынга әдәп, тәрбия бирү өчен кайгыртучы. Аллаһ бар ителгәннәрнең кайберләрен кайберләреннән артык кылу белән, ирләр акылда, куәттә хатыннардан өстен булды һәм малларын хатыннарга сарыф итү белән дә ирләрнең дәрәҗәсе өстендер. Изге хатыннар Аллаһка һәм ирләренә итагать итәрләр, ирләре өйдә булмаганда Аллаһ саклавы белән малларын һәм үзләрен сакларлар, һичбер хыянәткә бармаслар. Әгәр хатыннарыгыз итагатьсез булып азуларыннан курыксагыз яки берәр яман эшләрен белсәгез, аларны вәгәзьләгез, итагатьсезләргә Аллаһның ачуы һәм газабы бар икәнлеген белдерегез. Вәгәзьләгәннән соң төзәлмәсәләр, түшәкләрендә ялгыз калдырыгыз, ягъни якынлык кылмагыз. Моннан соң да төзәлмәсәләр, аларга сугыгыз. Әгәр хатыннарыгыз сезгә итагать итсәләр яки явызлыкларыннан соң төзәлсәләр, алар зарарына юл эзләмәгез, ягъни хаксыз җәбеләнмәгез. Әлбәттә, Аллаһ бөек һәм олы булды. Әгәр ир белән хатын арасында фетнә һәм дошманлык туса, шул вакытта тормышлары бозылудан курыксагыз, гаделлек белән тикшереп араларын төзәтү өчен, ирнең якыннарыннан бер гадел кешене һәм хатын ягыннан бер гадел кешене билгеләгез. Әгәр билгеләнгән кешеләр, ир белән хатын арасын чын күңелдән төзәтергә теләсәләр һәм төзәтү өчен бөтен чараларны кылсалар, Аллаһ тәүфыйк биреп, ир белән хатын арасына дуслыкны салыр. Дөреслектә, Аллаһ кешеләрнең гамәлләрен белүче һәм күңелләрендәге теләкләреннән хәбәрдар булды» (Ниса сүрәсе, 34–35). Бу ике аять күп урында гаиләне төзәтү өчен файда бирәчәк. Хатыннар-

ның хокукларын саклау белән бергә, алар – иярүче, ирләрдән түбән дәрәҗәдә, ирләренә шәригать кушкан даирәдә итагать итәргә тиешлеләр һәм бурычлылар. Әгәр дә ир гаиләне туендыра алмаса, аңа билгеләнгән вазыйфаларны үтәмәсә, өмет тә киселсә, хатыннарның теләкләре белән хокукларын саклап, яхшылык белән аерылырга тиеш.

VI. Васыятләрнең шәригатькә туры килүен яки туры килмәвен тикшерү, кирәгенчә мирас бүлү кәгазьләре бирү, җавап соралган мәсьәләләрдә шәригать һәм гадәт белән фәтвалар бирү, ул фәтваларны игълан итү. Бу хезмәтләр казыйлар арасында электәге кебек эшләрне бүлү рәвешенчә бүленеп, күндерелер.

Мәхкәмәи-шәргыянең рәсми хезмәтләре өчен һәрвакытта хезмәт итәрлек бер хокук галиме (юрист-консул) булырга тиешле. Сәркятип кенә бу хезмәтләрне үтәп бетерә алмый. Юрист-консул һәрвакытта хөкүмәт даирәләре белән эш күрергә, Мәхкәмәи-шәргыянең шәригать хокукларын сакларга тиешле. Бу вәкилнең Мәхкәмәнең башка хезмәткәрләре һәм вәкилләре кебек һәрвакытта Мәхкәмәдә торуы мәҗбүр ителмәс. Читтә торып, үз эше белән дә мәшгуль булырга мөмкин. Бары Мәхкәмәнең рәсми эшләреннән хәбәрдар булып, хаҗәт вакытта башкаручы, үтәүче булырга тиешле. Бу кешегә хезмәтенә күрә яхшы хезмәт хакы бирергә тиешле.

**Диния нәзарәтында имтихан**. Бу Нәзарәттә имтихан, мәдрәсәләрнең өмет ителгәнчә камиллеккә ирешмәүләреннән, бердәм рәвештә, яхшы тәртип һәм низамга куелып җитмәгәннән, зарурлык белән, Нәзарәттә үтәлә. Юкса, мәдрәсәләр тәртипле һәм ысуллы булсалар яки бу Нәзарәт химаясе астында имам һәм мөдәррис әзерләү өчен христианнардагы элекке академия кебек, бер генә булса да зур мәдрәсә булса, шуның имтиханы җитәрлек булыр иде. Бу рәвешле эш хәзер дә булмаганга, кайбер мәдрәсәләрдә дәрес һәм имтихан ысуллары сугыштан элек булган юлына куелса да, гомуми булмаганлыктан, ул мәдрәсәләрнең имтиханнары өстенә бер дәрәҗәдә күздән үткәрү сурәтендә генә җиңелчә имтиханнар булып килде. Сугыш һәм төрле фетнәләр белән мәдрәсәләргә гомуми зур зәгыйфьлекләр ирешеп, тиешле рәвешенчә имтихан янә Диния нәзарәтендә калырга һәм анда кирәгенчә эш ителергә тиеш булды. Ләкин хәзер заман хәлләре артык борчылуда, имамнар арасында тиф белән вафат булучылар күп, [эшен] дәвам иткән мәдрәсәләр юк яки юк хөкемендә, бик аз. Электән сәләтле булган шәкертләр төрле хезмәтләрдә (укыту, гаскәри һ.б.) таркау булганга, Диния нәзарәте имтихан эшләрендә хәлләрнең

күтәрүенә күрә карарга, эш күрергә мәҗбүр. Шулай булса да, халыкның гыйлемгә, әхлак төзәтү юлында яхшы юлбашчыга ихтяҗлары куәтле булганга, яраксыз кешеләрне урнаштырудан сакланып, яраклы кешеләрне тикшерергә, имтиханда да халыкның хәле, замананың һавасы йөкләгән кадәр җентекләп тикшерергә тырыша һәм тырышырга тиеш.

Милади 1918 елда яшьрәк, дәртлерәк казыйларның тәэсире белән минем Сибириядә сәяхәтем вакытында укучыларны шәригать гыйлеме, яңа фәннәргә кызыксындыру нияте белән, юл күрсәтү булсын дип, бер имтихан расписаниесе һәм программасы төзелгән иде; ләкин бу көнгәчә һичкайсы мәдрәсәләрдә укытылмаган, гыйлем һәм фәннәргә кергәнлектән, эшне үтәү мөмкин түгел. Булса [да], аптырату нияте белән генә булган имтихан төсен алса кирәк. Бу расписание төзелгәннән бирле, имтиханыбыздан һич мөдәррис үтмәгән, тик Фәхрелбанат бинте мулла Сибгатулла Сөләйманиягә һәм казый Мөхлисә бинте мулла Габделгалләм бу бәягә хатын-кыз галәменә мәрхәмәт күрсәтү һәм башкаларны өндәү нияте белән, бер дәрәҗәдә гарәп телен белү һәм өйрәнүләре булу белән, минем сәфәрем вакытларында мөдәррислек дәрәҗәсе бирелгән.

Бу имтихан расписаниесен үзгәртү һәм яхшырту [турында] кайбер казыйлар белән сөйләшенеп килсәк тә, бу көнгәчә гамәли үзгәртү белән канәгать булып йөрдек. Имтиханда, минем уйлавымча, бу заманда каралырга тиешле маддәләр түбәндәгеләр:

1. Халыкта, гомумән, галимнәрдә һәм гади кешеләрдә Коръән уку, хәтта тану зәгыйфь.

2. Шулай ук азан, камәт бик зәгыйфь. Мөэзиннәрнең уннан берсе яхшы үтәми. Элек Мәхкәмәдә бу мәсьәләләр кайгыртылмаганлыктан, бу кимчелек һәм бозулар таралган иде[10]. Шунлыктан һәркем имамлык өчен булсын яки мөәзинлек өчен булсын, төзәтүе һәр мөселманга мәҗбүри булган бу ике маддәдән (Коръән, азан һәм

[10] Элек Сәлимгәрәй һәм Мөхәмәдьяр мөфтиләр вакытларында имтихан кылыначак шәкерт имтихан ахырында гына күңелдән «Фатиха» сүрәсен яки башка өйрәнгәнне укып, имтихан ахырында «Фатиха»сын укырлар иде. Казыйлар арасында Коръәнне дөрес һәм яхшы укучы адәм булганы бер дә ишетелмәде, Уфа шәһәреннән читтә дә Коръәнне дөрес укучы бер яхшы кари булдырмадылар. Шунлыктан Коръәнне дөрес уку фәне турысында гомум халыкта бер уяну булмады.

камәт) имтихан кылынырга тиешле, төзәтү юлларын күрсәтеп, үтәргә тиешле. (Бу рәвеш хәзер күп очракта кайгыртыла).

3. Аңлау сәләте таләп ителергә тиеш. Мөәзиннәр иң азы төрки китапларны дөрес һәм җиңел укып, эчтәлеген аңласыннар, аңлаганнарын аңлата алсыннар. Имамнар исә, гарәпчәне дөрес укып, аңларлык булырга тиешләр. «Мохтасар әл-викая» кебек артык кыска китапны яхшы аңламасалар да, «Төхфәтел-мөлек», «Мохтасар әл-кодури» кебек җиңел китапларны гарәп кагыйдәләренә нигезләнеп укып, өйрәнә белсеннәр, эчтәлеген бәян итә алсыннар.

4. Боларның (имам һәм мөэзиннәрнең) һәркайсы дөрес яза белергә тиеш, тик мөәзиннәр дөрес язсалар, язулары матур булмаса да, канәгать ителергә мөмкин. Имамнар, әлбәттә, дөрес һәм яхшы имля өстенә, матур язу, инша иясе булулары, рәсми язуларны (дәфтәр, гариза, вакыйгаларны) яхшы үтәрлек һәм язарлык булулары мәҗбүри.

5. Яхшы әхлакка ия булулары, халыкның диннәренә һәм әхлакларына яхшы тәэсир итүләре өчен үзләре, фигыльләре белән дә яхшы үрнәк булырлык дәрәҗәдә булулары таләп ителә. Бу максат өчен дәүләттән алган шәһадәтнамә[11] өстенә, стазыннан яки якынында булган мөхтәсибтән шәһадәтнамәсе булырга тиеш. Бу мәсьәләдә гаделлек дәрәҗәсе булса, җитә. (олы гөнаһлардан тыелу, кече гөнаһлар эшләүдә ныклык күрсәтмәү кадәр хәл нигез була белер).

Бу искә алынган биш маддә – беренче дәрәҗәдә мәҗбүри күренәчәк имтихан маддәләре. Мөәзиннәр өчен игътикад һәм гыйбадәт әдәбеннән хәбәрдарлыгы белән, бу кадәре җитәрлек тә булыр.

Имамнар өчен тагын шулары:

6. Игътикад һәм гыйбадәттә яхшы хәзерлеге, шулай ук гаилә мәсьәләсендә мәгълүматы, казый эшендә хәбәрдарлыгы таләп ителер.

---

[11] Элек хөкүмәт имамнарның сәясәт мәсьәләсендә чамалы булуларын, җинаять эшләреннән пакълекләрен кайгыртканлыктан, рәсми рәвештә моңа караган шәһадәтнамә белән канәгатьләнәләр иде. Мөфти Солтанов вакытында дини әхлак мәсьәләсендә остазыннан бер язу сорала башлаган иде, ләкин бу соңгы маддә – иң әһәмиятле маддә. Әмма әхлакның кайсысы яхшы, кайсысы яман – имтиханы әһәмиятсез.

7. Фарыз гамәлләрдән, хисап ысулынча, мәсьәләләрне яхшыртуга көче җитмәсә дә, бөек Коръәндә искә алынган хәлләрне белүе тиешле тотылыр.

8. Пәйгамбәр (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) тормыш юлы, тугры хәлифәләр хәлләре, пәйгамбәрләр һәм алардан соң килгәннәрнең тарихы, ислам тарихыннан кыскача булса да, мәгълүматлы булырга тиешле.

9. Хисап, география, медицина кануннары, төркичә риторика, вәгазь сөйләү куәте кебек гүзәл эшләр яхшы күрелер.

10. Имам һәм мөәзиннәрнең дәрәҗәләренә күрә, сабыйларны укыту маддәләрендә, укыту ысулларыннан хәбәрдарлыгы кирәк булыр.

Искәртү:имтихан маддәләренең кайбеләнре, аеруча соңгы өч маддә бүгенгәчә гомуми рәвештә мәдрәсәләрдә укытылып килмәгәнлектән, шәкертләрнең күбесендә ул маддәләрдә хәзерлек юк. Шунлыктан алдагы көндә бу мәсьәләләрдән хәбәрдар булулары, мәхәллә хезмәтләренә керешсәләр дә, кирәксенеп китап укулары, ул фәннәрне өйрәнү теләгендә булулары таләп ителеп, искәртелер. Шул искәртү юлынча гына имтихан кылулар булмас.

Моның өстенә, мөдәррисләр өчен тиешле булыр:

11. Югары маддәләрдә яхшы хәзерлеге өстенә, риторикадан хәбәрдарлыгы, Коръән, хәдис аңлау юлларын[12] белүе, игътикад һәм фикыһта да хәзерлеге кирәк. Болар өстенә, гарәп телен белүе, өйрәнү куәте, саклану куәте яхшы булырга тиеш. Бу кадәр белән мөдәррислеккә лаеклылык шәһадәтнамәсе бирелергә тиеш. Тик мөдәррисләргә яңа гыйлемнәр мәсьәләсендә хәзерлек күрү, шәкертләргә юл күрсәтү мәсьәләсендә эш искәртелер.

Шулай ук шәкертләрне гыйлеме, яхшы тәрбияләре өстенә, диндарлык һәм әхлак мәсьәләләрендә да күзәтчелек итү, төпле киңәш бирү дә соралыр.

Шулай ук һәр кайсы указ (ярлык) алучыларны гүзәл хезмәтләре, дин һәм милләт өчен хәерхаһлы булып, тырышулары мәсьәләсендә киңәш һәм нәсыйхәт әйтеп күндерелер. Валлаһү

[12] Тәфсир аңлау юлы борынгыдан килгән тәфсирләрне күзәтеп, фәкать фикер, уй буенча гына тәфсир итмәү тиеш. Хәдистә шулай ук күпчелек шәрех кылучыларның өйрәтүләре буенча барып, һәркем үз фикеренә алданмаска тиеш.

йәһди мәй-йәшәъә илә сыйратыйм-мүстәкыйм (Аллаһ кемне тели, шуны туры юлга күндерә).

## Нәзарәттә яңа комиссиянең эшкә керешүе

([Һижри] 1339 елның 17 сәфәрендә) 1920 елның икенче октябрендә шимбә көн яңа комиссия булып, Диния нәзарәтенең әгъзасы эшкә керәште. Аллаһ Тәгалә хәерле кылса иде. Мәҗлес башында бу сүзләрне сөйләдем:

«Съездда яңадан сайланып, халыкның ышанычын казанып, әманәтләрен йөкләп калдык. Алдыбызда дини һәм милли бөек эшләр тора. Халыкның дини реформаларга ихтыяҗлары элекке заманнарга караганда арткан. Шунлыктан без бердәмлек белән, һәр мәсьәләдә хәерлек һәм хаклыкны тикшереп, тырышлык белән хезмәт итүебез мәҗбүри. Халыкның яхшы уйлары да бушка чыкмасын. Бу хезмәт белән Аллаһның ризалыгын тапсак иде. Шәхси теләкләрдән сәламәт булып, милләтнең дини һәм гыйльми файдаларын күзәтеп, яраклы эшләргә ирешсәк иде». «Фатыйха» сүрәсе белән мәҗлес тәмамланды.

Урыннар: минем йөрәгем тарафында Ризаэтдин бине Фәхретдин казый, аның янында Мөхәммәдсабир бине Мөхәммәджан Хәсәни казый, уң тарафымда Кәшшафетдин бине Кауваметдин Тәрҗеман казый, аның янында Мөхлисә казый мулла Габделгалләм кызы билгеләнде. Рәсми кәгазьләрдә имзалар: миннән соң Ризаэтдин, Кәшшафетдин, Сабир Хәсәни, Мөхлисә Бубия имза куячаклар.

## Шәһәр Шәрәфнең имамлыгы

Шимбә көн икенче октябрьдә Казаннан беренче октябрьдә Сәйдәшев имзасы белән бирелгән телеграмма алдым, язылган: «Шәһәр хәлфә сайланды».

Элекке Казан сәяхәте өлешендә язылган иде ки, Казанның Ак мәчетенә бертуганым мулла Габдрахман мәрхүм урынына, миңа ярдәм итәр өчен имам сайлау мәсьәләсендә мин искә алынган Шәһәр хәлфәне тәкъдим итсәм дә, кайберәүләрнең чуалулары булып, әдәпле-әдәпсез сүзләр киртә була язып калган иде. Арада Әхмәджан хәлфә Мостафинның да таләп итүе кысылып, Оренбург имамы Таһир хәлфәнең мәдрәсәдә элекке яхшы хезмәтен тәкъдир итеп, аны теләүчеләр бар иде. Таһир хәлфәнең гаиләсе артыннан

Казанга кайтуында мәхәллә халкы мөрәҗәгать итеп карасалар да «Мин ул мәхәлләгә яхшы карасам да, дамелланың күркәм ризалыгы булмаганлыктан, алдымда Шәһәр хәлфәләрнең исемнәре булып торганда, кабул итә алмыйм» дигән җавапны алганнар.

Әхмәджан хәлфәгә мөрәҗәгать итүләрендә: «Халык теләсә, мин кабул итәм», – дигән. Шәһәр хәлфә дә, киңәшләшкәннән һәм истихарә намазы укыганнан соң, каршы түгеллеген белдергән. Ул октябрьдә җомгада яшерен тавыш белән имам сайлауга карар бирүләреннән хәбәр алган идем. Бу телеграмма, шул җомгада сайлау булып, Шәһәр хәлфәгә ризалыкларын белдерә. Аллаһ хәерле итсен!

Таһир әфәнденең элекке заманнан бирле остаз белән шәкерт мөнәсәбәтен кайгыртучан, тиешле әдәпне җиренә җиткерергә тырышучан булганлыктан, халыкка аның кабул итмәячәген белдергән идем. Икенчедән, хәзер тормыш ягы алда тотылу тиеш күрелгәнгә, аның Оренбурда калуы икътисадый җәһәттән, дини һәм дәрес җәһәтеннән дә хәзер Казанда артыклык күренми. Шунлыктан аның ихтыяр итмәве дөрес фикер. Аллаһ аның эшләренә бәрәкәт бирсен!

Әхмәджан хәлфә исә халыкның хәлләреннән хәбәрсез, үз фикерендә нык, фикеренә каршы булган бер эшне дә кеше хәтере яки хокукын кайгырту юлынча кабул итмәс, үз фикеренә алданган адәм.

Бу маддәдә халыкның күпчелеге тарафыннан кабул ителмәве мәйданда бик ачык иде. Кем дәлил китерсә дә, ихтималлы түгел иде. Шулай да бер-ике хуш кешенең гадәтләренә алданып, үзен игълан итүе яхшы чарадан түгел иде. Әгәр мөмкин булса иде, мин үзем дә аны тәкъдим итүдән тартынмаган булыр идем. Ни булса да, Аллаһ ахырын хәерле итсә иде. Шәһәр хәлфә сайлаулары тәмам булса, Әхмәджан хәлфә үзенең хөрмәтен үзе югалтмаса, Шәһәр хәлфә тарафыннан тарлык күрмәячәк.

## Нәзарәттәге эшләр бүленеше

Янә 2 октябрьдә Нәзарәтнең дүрт казые арасында эш бүлү мәсьәләсе карарланды. Шулай ки:

Беренче бүлек мөдире казый Ризаэтдин Фәхретдин улына тапшырылды. Эшләре: беренче бүлемендә мәхәлләләр төзү, дини җәмгыятьләрне тәртипкә китерү, мәчет эшләрен башкаручылар комиссияләренә күзәтчелек итү, мәчет төзү һәм төзәтүгә рөхсәт бирү, имам һәм мөәзиннәрне раслау, эштән китүләрен кабул итү, мөсел-

ман гаскәрләренең дини хәлләренә һәм хастаханәдә булганнарның хәлләрен күзәтү, гаскәрләргә мөмкинлек булганда имам билгеләү, руханиларны хәрби хезмәттән коткару чараларын күрү, алар хакында мәгълүмат җыю хезмәтләре. Икенче бүлемендә дәфтәр һәм архив эшләре. Мәхәлләләргә дәфтәр җитештереп, тарату һәм җыеп алу, кирәк урыннарга дәфтәрләрдән шәһадәтнамә бирү, архивта яхшы, тәртипле рәвештә саклау, Диния нәзарәтендәге китапханәне саклау һәм шуның ише эшләр.

Икенче бүлек – юстиция бүлеге – казый Мөхәммәдсабир Хәсәнигә тапшырылды. Вазыйфалары: мөхтәсибләрне сайлату һәм раслау, руханилар өстеннән килгән шикаятьләрне карау, руханиларның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү, кичектерүләр бирү, Диния нәзарәтенең хезмәткәрләрен күзәтү, вәкыф, бүләк кебек дини эшләрне башкару, зиратларны карау, Нәзарәт милкен саклау, хөкем эшләре җыентыкларын төзү.

Өченче бүлек – гаилә бүлеге – Мөхлисә Бубига тапшырылды. Вазыйфалары: никах, талак һәм аңа мөнәсәбәтле мәсьәләләр, ата-ана хокуклары, мирас, васыятьнамә төзү кебек гаилә мәсьәләләре, ислам динен кабул итүчеләрне тиешле мәхәлләләргә билгеләү кебек эшләр.

Дүртенче бүлек – мәгариф бүлеге – казый Кәшшафетдин Тәрҗеманга тапшырылды. Вазыйфалары: мәхәлләләргә дин хезмәткәрләре җитештерү, мәктәп һәм мәдрәсәләр торгызу, хаҗәт булганда вакытлы дини дәресханәләр ачу, имтихан кылу, Коръән һәм аның кисәкләрен дөресләп бастыру, кирәк урыннарга дини китаплар тарату, мал эшләрен карау, казначы эшләренә күзәтү, бәйрәм һәм каникул расписаниеләрен төзү, вакытлы бер дини журнал төзү һәм шуның ише эшләр. Башка бер чара күренгәнче бу рәвешле эшләр күреләчәк.

## Съездга килгән докладларда игътибар итәрлек нәрсәләр

Съездда тирә-яклардан килгән мөхтәсибләрнең докладларында төрле эчтәлекләр бар иде. Съездның комиссия вәкилләре сайлау вакытында кайберләнрен төшереп, кайберләнрен кыскартып һәм әһәмиятсез рәвештә генә теркәп, кайберләнрен игътибар белән теркәп, мәҗлескә тәкъдим иттеләр. Шулар җөмләсеннән Бүздәк мөхтәсиблегеннән дүрт эчтәлекле доклад килгән:

1. Тәмәке бик таралып, бала-чага, хатын-кыз галәменә кадәр таралганлыктан, бер дару булмасмы, дип, аның хәрамлыгы турында Диния нәзарәтеннән бер фәтва тарату.

2. Гарәп теле гыйлемен һәм дин гыйлемен саклау, ныгыту яки иң башта галимнәр, фикерләре һәм гамәлләре белән тырышу тиешле булган хәлдә, үз балаларын гарәп теле гыйлемен, дини гыйлемне укытмыйча, русча укытырга бирүләре, күпчелек белән, бу юлда хәрәкәт һәм алга баруларына каршы килү.

3. Халыкның ислам әдәбен, милли мәрасимнәрне кайгыртуларында бу съезд бер төрле чара булса икән. Халкыбыз ифратлык һәм чиктән ашу ягына китеп, кием-салымга, зарурлык булмаган рәвештә, чит милләт кешесенә охшау; кешеләр галәме белән ябынып йөрүләре фарыз, катгый булган зиннәт урыннарын ачу; намаз, ураза, зәкят мәсьәләләрендә җиңелчә караулар таралуга каршы бердәмлек белән шәригать буенча дөрес һәм гадәт ителгән хәрәкәт булса иде.

4. Мөфти һәм казыйлыкка, элекке комиссия карары белән, Гайсә пәйгамбәрнең иңүенә ышанмаучыларның мәңге җәһәннәмдә булуларына һәм әһле сөннә вәл-җәмәгага иярүчеләрнең сүзләрен инкяр иткән бидгатьче адәмнәр катыштырылмаса иде, дигән.

Беренче мәсьәлә съездга бөтенләй тәкъдим ителмәде, комиссия каршында файда күрмәгәннәр. Халык бәласе булган мәсьәлә, зур галимнәр арасында да каршылыклы, соңгы галимнәрнең күпчелеге хәләллеге белән фәтва биргәннәр. Хәрам, хәрамга якын мәкруһ булуына баручылар булса да, куәтле дәлил хәләллеге тарафында. Шәех суфи Габделгани ән-Нәблүси хәзрәтләре «Шәрх әт-тарикат әл-мөхәммәдия»дә дә һәм махсус бер китапта хәләл булуын ачык бәян иткән. Сәед Мөхәммәдәмин бине Габидин хәзрәтләре дә «Тәнкыйхү фәтәвә хәмидия»дә һәм «Радд әл-мүхтәр»дә яхшы аңлаткан. Хәдис белгечләреннән Сәед Сиддыйк Кануҗи да хәләл булуын ысуллы рәвештә бәян иткән. Бары шул күренә, һәр зарарлы нәрсә ислам кагыйдәләре буенча тыелган булганга, бер адәмнең исәнлегенә, нервларына зарар итәрдәй булса, аңа тыелган, куллanудан саклану важиб. Әмма бер адәмгә зарар ихтималы юк яки зарарсыз дәрәҗәдә аз куллана икән, тыю юк. Тик бу соң заманда тәмәке заты аз һәм бик кыйммәт булып киткәнлектән, аның урынына башка төрле ышанычлы табиблар тарафыннан зарарлы табылган нәрсәләрне куллану, әлбәттә, тыелган. Дөрес, сәламәт һәм хөр табигатьнең бер нәрсәгә зарурлыксыз әсир булуы күркәм эш түгел,

аеруча, табигате зәгыйфь яки үсү яшендә булганнар өчен мөмкин кадәр саклану, сак эш итү мәҗбүри. Гореф-гадәт һәм медицина җәһәтеннән начар күренүе шәригать тарафынан да шулай булуы бик ихтимал. Шунлыктан бу мәсьәләнең мәҗлескә тәкъдим ителмәве гаеп ителмәслек мәсьәләләрдән.

Икенче мәсьәлә исә бик мөһим. Бу мәсьәлә тәкъдим ителсә дә, тиешенчә фикер алышуга куелмады. Күбесенең гыйлем әһелләре булуыннанмы, башка сәбәптәнме, кыскартып үткәрделәр, дин галимнәре балаларының дини дәресләрдә булуы яхшы күренү кадәр белән генә үтте. Ләкин бу мәсьәлә яхшырак каралырга тиеш иде. Бу мәсьәләдә имамнар зур җаваплылыкта. Гамәлләре һәм эшләре белән халыкны гарәп теле гыйлеме һәм дин гыйлеменнән нәфрәтләндерүдә, мөнбәрләрдә һәм михрабларда искә алынган гыйлемнәргә өндәүләре фәкать икейөзлелек, чын рия, ясалмалык. Байтак имамнарда бу хәл бар, муллалыктан нәфрәтләнәләр. Муллалык бер теләнчелек дип аңлатып, әмәл тапсалар, үзләре дә башка юлга керәләр, балаларын башкача тәрбиялиләр. Бу мәсьәләдә беркадәр мәхәллә әһелләренең дә кимчелекләре бар. Руханиларны тәрбия һәм ихтирам итүдә аларның гаепләре бар. Муеннарына йөкләнгән хокукны үтәмиләр, ләкин надан халыкның бу хәлләренә карап, имамлыктан нәфрәт юлын тотмаска тиешләр. Безнең илебездә дин саклау, гыйлем тарату, яхшылыкка чакыру, начарлыктан тыю тик имамнар вазыйфасы булып килгән. Башка юл белән бу мактаулы хезмәтне булдыру читен, мөшкел. Шунлыктан имамнар иманлы һәм ышанычлы булсалар, әлбәттә, бу эшне игътибарга алып, сабырлыкһәм өсләренә йөкләү белән могамәлә итәргә тиеш. Аллаһтан ризык юлларын сорап, үтәп, бу имамлык хезмәтен олыларга кирәк. Хәзер бер имам эшендә теркәлгән булса, тиешле дини вазыйфаларын яхшы үтәсә, халык белән пәйгамбәрдән мирас булган яхшы холык белән могамәлә итеп, туры юл күрсәтү юлында дәвам итсә, ач-ялангач булмый, ризык тарлыгына калмый, сабыр һәм канәгать итәрлек тормыш әсбапларына ия була. Киресенчә, эшенә бәйләнмәгән, фәкать яшәү өчен, дөрес ниятсез имамнар төрле авырлыклар күрәләр. Имамнар, әлбәттә, дин эшләрен үз өсләренә алып, имам булгач, эшләренә бәйләнеп, динне якларга, мөмкин кадәр дини укуөйрәнүне булдырырга бурычлы. Шунлыктан балаларын дин гыйлеме юлыннан аерып, рәсми гыйлем өчен рус мәктәпләренә тапшыру, дөньяви максатларны алда тотулары тырышудан һәм вөҗданлыктан түгел.

Рәсми гыйлем укучылар, һәртөрле канун һәм низамнарны өйрәнүчеләр дә булырга тиеш. Хөкүмәт хезмәтләрендә эшләрлек кешеләребез дә булырга тиеш. Ләкин болар күбрәк башка төркемнән булырга, имам балаларыннан булсалар, дин һәм шәригать гыйлемнәрен яхшы укыган булып, бөтен яхшы сыйфатларны да туплаган булырга тиеш.

3 нче мәсьәлә дә бик әһәмиятле булса да, мәҗлестә фикер алышуга куелмады. Бары җомга көн вәгазендә минем тарафтан вәгазь һәм искә төшерү юлы белән генә әйтелеп үтте.

4 нче мәсьәлә дә фикер алышуга кертелмәде. Зур низаг һәм бәхәсләргә сәбәп булачагын уйлаганнардыр. Фикер алышынмаса да, эчтәлеге белән гамәл ителде. Бозык гакыйдә белән гаепләнгән адәмнәр башка рәвешләр белән юк булдылар. Аллаһ ахырын хәерле кылсын.

Искәрмә: кешенең гакыйдәсен тикшерү, йөрәгендә булган мәзһәбенә ризасызлык белдерү вөҗданлыктан түгел, ләкин мәйданда беленеп торса, ачыктан иясе тарафыннан игълан ителсә, халыкның нәфрәте һәм саклануы дөрес хисаплана. Чөнки бидгатьче булып җитсә (бу – озын сүз), аңа иркен юл кую, аңа ихтирам һәм игътибар күрсәтү дөрес түгел. Бу мәсьәләдә күп кешеләр фикер хөрлеге исеме белән җиңел күрсәләр дә, тиешле җиңеләйтү түгел. Яшерү хуплана, ләкин ялагайлану начар эш.

Уфа ягында начар гакыйдә һәм бидгать белән телгә алынучы – Уфаның икенче мәхәллә имамы Зыя Камали. Бу кешенең кайбер нәшриятыннан, халык арасында чыккан фикерләреннән, үзеннән күчергән кайбер ышанычлы кешеләрнең бәяннәреннән, Гайсә пәйгамбәрнең (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) «Алар аны [Гайсәне] үтермәделәр һәм асмадылар, ләкин аларның бер юлдашы аларга Гайса сурәтендә күренде» [Коръән, 4:157] дигән хөрмәтле аятен күп әсәрләр, дан-шөһрәтенең мәңгелеге белән ялгыш аңлаткан. (Бу фикердә Муса әфәнде дә аңа кушылган).

Ахырзаманда күктән иңүен, дөрес хәдисләр белән нык булса да, инкяр итү һәм ялганга санау, хәтта аның атасын, барлыгын инкяр итү, җәннәт һәм җәһәннәмнең хәзер яратылган булуларын инкяр итү, мигъраҗны фәкать рухани бер төштән гыйбарәт кебек бидгатьләр нисбәт ителә. Тәсаувыф хакында әдәпсезлеге, көчле инкяр итүе анык.

Бичара тырыш кына, гыйлем көче бар, эшлекле, мәгълүматлы адәм булуы белән кирәгенән артык дин фәлсәфәсен тикшергән

булып, исламны Европа гыйлеменә (ахыр чиктә христианлыкка) якынлаштыра, аларның начар карашларын бетерергә теләп, килештерергә булган. Артык дини фәлсәфәне тикшерүе дөрес эш түгел. Изге китап, пакъ сөннәт кә туры килгәнчә игътикад һәм иманны ныгытканнан соң, дини хөкемнәрнең хикмәткә һәм яхшылыкка муафыйк булуын, акыл ирешмәс дәрәҗәдә серләрнең эчендә булуын «Ихъя гулүм әд-дин», «Хүҗҗәтүллаһ әл-бәлига» китаплары юлларынча аңланса, файдалы. Әмма ярым-йорты гыйлем белән мондый тирән диңгезгә керү – зур һәлакәткә атылу. Бу кеше артык үзе теләгәнчә эш итүче, үз фикеренә гаҗәпләнүче булганлыктан, остазы Хәйрулла әфәнде Госманнан да кыерсытылган, кире кагылган булган, ризалыгын ала алмаган. Соңра шәех Зәйнулла әл-Нәкышбәнди хәзрәтләренә үзенең кайбер фикерләрен сөйләргә теләгәндә, шәех хәзрәт өеннән сөргән. Остазларны тыңламаудан һәм изге шәехләрнең ачуыннан Аллаһка сыенам.

[...].

Муса әфәнде бу адәмгә күп дәрәҗәдә хөрмәттә булган хәлдә, имансызларның мәңге җәһәннәмдә булуларындагы мәңгелекне, кайбер сәләфләрдән күчерелгәнчә, озак вакыт дип аңлатуы, югарыда ишарә ителгәнчә, кайбер ялгыш аңлатуы, хәрәкәтендәге дуамаллыгы, сәясәттән, уйлап эш итүләрдән ераклыгы кебек кимчелекләре халыкның карашында нәфрәткә сәбәпче булган.

Докладлар эчендә 1) Коръәнне төрки телгә тәрҗемә итү (бер төркичә Коръәнне мәйданга кую; 2) Нәзарәт өстендә бер гыйльми шура төзү; 3) бер тикшерү комиссясе төзү бар иде. Бу өч мәсьәләгә форсат аз булганлыктан, халык тарала башлаганлыктан, фикер алышынмады. Комиссия рәислеге тарафыннан өч мәсьәлә бар иде, ләкин форсат булмаганлыктан, фикер алышынмый калды, дип белдерелде. Халык ризалык күрсәтеп, мәҗлесне яптылар. Искә алынган өч мәсьәләнең аңлатуы һәм нидән гыйбарәт икәнлегенең бәяне түбәндә.

## Коръән тәрҗемәсе мәсьәләсе

1. Коръән тәрҗемәсе күп еллардан бирле мәйданда, кайбер яшьләр тарафыннан куелган мәсьәлә иде. Моның кирәклеге: имеш, гарәпчә белмәгән, белергә дә теләмәгән мөселманнар төркичә Коръән булса, аннан динне аңлап, диннең гүзәллегенә ирешерләр иде, мөселманлыклары да куәтләнер иде. Мондый халыкның

һәвәскәрләре тарафыннан да бу сүз әйтелә, кайбеләнре русча тәрҗемәдән караштырып маташалар, ләкин русларның тәрҗемәләренә ышанып булмый, шунлыктан бер ислам галиме тарафыннан төрки теленә тәрҗемә ителүне тиеш күрәләр. Мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов заманында Муса әфәнде төрки тәрҗемәсен Казан матбагаларыннан берсенә басу өчен тапшырган иде. Казан халкыннан кайбеләнре мөфтигә шикаять телеграммасы биреп, мөфти матбагага басылмавы турында хәбәр җибәреп тукталып калган иде. Соңрак Зыя әфәнде Камали Коръәнне төрки телгә тәрҗемә иткәнен игълан итеп, бары басылуы хакында тик төркичә Коръәнне үзен генә бастыру яки битнең бер тарафына гарәпчәсен, каршысына тәрҗемәсен бастыру турында киңәшләшкән иде. Бу игълан газеталарда күренде. Җавап бирүче булдымы-юкмы – эш мәйданга чыкмады. Шул көннәрдән бирле бу мәсьәлә кайбер яшьләр арасында яхшы саналды, картлар, күпчелек галимнәр тарафыннан кире кагу һәм тәнкыйтьләү юлынча сөйләнеп килә. Ислам илләрендә дә бу мәсьәлә байтак заманнан бирле кузгалып, галимнәр тарафыннан, хәтта гыйлем һәм сәясәт хуҗалары тарафыннан кабул ителмичә үтеп киләдер. Мәрхүм Әхмәт Мидхәт әфәнде белән әңгәмәбездә яхшы дип тапмаганын әйткән иде. Истанбулдагы соңгы инкыйлабтан соң, анда бер табак басылганын күрдек, ләкин соңра тукталганын ишеттек. Бу мәсьәләдә шәригать карашы:

Коръән, хакыйкатьтә, коры мәгънәдән гыйбарәт булмыйча, тышкы төзелешенең һәм мәгънәнең җыелуына ия. Коръәннең Коръәнлеге гарәпчә төзелеше һәм шул гарәп тезмәләреннән аңлашылган мәгънәләрдә. Гарәп сүзе аңлаткан кадәр мәгънәне яки гарәп сүзе аңлаткан мәгънәне һичкайсы тел аңлата алмый. Гарәп сүзләренә, теленә хирыслыгы, зәвыгы булган кешегә бу мәгълүм әйбер. Тәрҗемәдә һәркем үз аңлаганына канәгать итүчән, чөнки һәркем үз акылына, үз белеменә таяна. Шунлыктан тәрҗемәдә Коръәннең тышкы төзелешеннән гыйбарәт [булган] нигезе югалган кебек, турыдан-туры нигезнең югалу ихтималы да юк түгел. Бер дәресебездә бу мәсьәлә буенча фикер алышу булганда, оста сүзле иптәшләребезнең берсе: «Элекке изге китаплар үзгәртелгән, Коръәнгә ничек үзгәртүләр керми дигәндә, кайчан төрки телгә тәрҗемә ителә башласа, үзгәртүләр керә башлар», – дип җавап биргәнен сөйләгән иде. Бу сүз – нигезле һәм җанлы сүз. Элекке изге китапларның бар үзгәртүләре дә, үзгәртү максаты белән эшләнгән

булмыйча, бәлки кайбеләнре тәрҗемәдәге хаталардан торган хата булырга мөмкин.

Имам Әбү Хәнифәнең Коръән мәгънәгә ия, шунлыктан башка тел белән укылса да, намаз дөрес, дип әйтүе сөйләнелсә дә, өммәт галимнәре тарафыннан кабул ителмәгән, бәлки имамның бу сүздән кайтканы анык күренә. Шунлыктан Коръәнне башка тел белән ниятләп укыса, бидгать белән хөкем ителер, бәлки динсезлеккә нисбәт бирелер, дигән сүз фикыһ китапларында күренә. «Һидая шәрхе кифая»дә күчерелә. Имам Мәхбуби әйткән ки: «Имам Әбү Хәнифә белән иярченнәре имам Әбү Йосыф, Имам Мөхәммәд арасындагы фикер каршылыгы гаепләнмәгән кемсә хакында ки: [әгәр ул] намазда бер сүзне яки артыгракны фарсыча укыса. Әмма бер кемсәнә фарсыча укырга гадәт итсә яки Коръәнне фарсыча язса, көчле тыю белән тыелыр. Шәех имам Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Фазыл[13] вакытында бер фәтва язып, искә алынган шәехкә җибәрелгән. Фәтвасендә әйткән: «Заманыбызда сабыйларга гарәпчә уку авыр, фарсыча укытсак, дөрес булырмы?» Җавабында, фәтва сораучыга кайтып торырга әйтеп, аның хәленнән сорашкач, бозык фикер белән гаепләнгән адәм икәнен аңлаган. Хезмәтчесенә бер пычак биреп: «Бу пычак белән фәләнне үтер, җавабын мин бирермен», – дигән. Шулай эшләгән. Шәһәр әмиренә хәбәр ирешкәч, шәех әмиргә барып әйткән ки: «Аллаһ китабын ялган итәчәк иде, шунлыктан үтерттем». Әмир рәхмәт белдереп, кыйммәтле өс киеме кидерткән.

Коръәннең мәгънәсен аңлау – әлбәттә, дин буенча, таләп ителгән һәм сөелгән нәрсә. Бу хөрмәтле әмергә ирешү өчен уку, өйрәнү тиешле. Дин кайгысын тоткан, ул юлда аз гына омтылышы һәм кызыксынуы булган кемсәнәгә өйрәнү мәшәкатен йөкләү мәҗбүри. Кайбер адәмнәрнең «Бу төркичә булса, аңлау ансат булыр иде» дигән теләкләрен сылтау иткән адәмнәр, ул теләүче адәмнәрдән үзләренең диннәрен аңлаганнары дини зарурлык турысында ныклыкларын беләләрме? Ул затлар катгый [рәвештә] мәгълүм булган дини хөкемнәрдә ник ваемсызлыкта булалар һәм йомшак карыйлар. Коръәнне аңлаган һәм аңламаганга хәтта һәр мөэмин һәм имансызга катгый [рәвештә] ислам баганаларыннан икәне мәгълүм булган намазда ничек саксыз булалар? Мондый адәмнәр һәркайсы телдә

[13] Бу Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Фазылдан искә алынган кеше җитәрлек итеп сөйләгән: «Коръәнне гарәп теленнән тыш башка телдә укыган кемсә я юләр (дәваланырга тиеш), яки динсез».

Коръәнне аңласалар да, намаз укулары өметлеме? Бу җавапсыз сорау булса кирәк.

Тәрҗемә юлы ачылса, һәркем үзе белгәнчә тәрҗемә итеп, каршылыклар туарга мөмкин. Һәркем үзенә канәгать булып, дөресен-дөрес түгелен Коръән эчтәлеге дип дәгъвада булса кирәк. Бу хәл куркыныч эшләрне күз алдына китерә. Тәрҗемә хатасы һәм андагы каршылык мөҗтәһидләрнең аңлауларындагы каршылыгы белән чагыштырылмас. Алар иҗтиһад шартларын бөтенләй җыйган булу ягыннан, хаталары булса да, хаталарын Коръәнгә нисбәт бирмиләр, бәлки үзләренең уйларынча аңлаганнарын Коръәннән чыгаралар. Әмма бу тәрҗемәчеләр хаталарын Коръәннең үзе дип мәйданга куячаклар. Бәйнәһүмә фәркуль-газыйм (болар икесе арасында зур аерма). Гарәп теленнән гыйлеме аз кемсәнәләр өчен Коръән астына язылган тәрҗемәләре һәм аңлатмалары җитә. Бу рәвеш яраклы табылды. Бу рәвештә гарәп тезмәсе сакланып барганлыктан, тәрҗемәгә игътибар икенче дәрәҗәдә калачак, гарәп теленең онытылмавына сәбәп булмаячак.

## Гыйльми шура мәсьәләсе

2. Гыйльми шура исә, югарыда әйтеп үтелгәнчә, төрле фикерләр һәм төрле аңлатучылар тарафыннан төрлечә фикерләр мәйданга куелса да, хәзер берничә мәсьәлә кебек мәҗлестә каралмавы хәерле булды. Аңларлык кеше дә аз. Берничә мәсьәлә, әлбәттә, кире кагылган булыр иде. Әмма бу мәсьәлә хакында уңай тавыш бирүчеләр күп булса, ихтимал иде. Уфа имамнары Нәзарәткә әгъза булмасалар да, аның өстендә бер Нәзарәт һәм бер хуҗа булуын теләүләре сизелә иде. Ләкин янә дөрес тәртип булмагач, хәерле нәтиҗә дә чыгачак түгел иде.

Бу мәсьәлә үзе кирәкле бер зур мәсьәлә. дөрес рәвеше Европадагыча бер академия рәвешенчә булырга тиеш: бөтен Русия, Кырым, Кавказ, Төркестан, Казакъстан, Татарстан һәм Башкортстанның мактаулы, аңлы дин әһелләре, милләтпәрвәр галим-шәехләреннән хөрмәтлеләре булып, сайланып алыныр лар. Болар елына бер мәртәбә җыелып, дини эшләрдә, дини эшләрне кайгыртып, мөшкел, авыр мәсьәләләрдә киңәшләшеп, бөтен халык өчен Нәзарәт һәм башкалар өчен кагыйдә булырлык карарлар, халык җан һәм күңел белән кабул итәрлек фәтвалар чыгарырлар. Боларның фәтвалары һәм карарлары Диния нәзараты эшләреннән өстен һәм

игътибарлырак булыр. Шул рәвешле бер гыйльми һәм дини шура төзелсә, бик яхшы, гүзәл булачак, ләкин хәзер бу съезд әгъзалары моңа әзерләнеп җитмәгәннәр, әзерләргә вакыт та булмады, шунлыктан калып торуы ят [нәрсә булып] күренмәде.

## Нәзарәтне тикшерү комиссиясе

3. Нәзарәтнең эшләрен тикшерү маддәсе кирәкле мәсьәлә иде. Съезд вакытында яхшы тикшерелсә дә, башка вакытта караулар зыянлы эш булмас иде. Ләкин съездның башка эшләргә вакыты күбрәк. Кайбер җитешсез эшләргә вакытны күп сарыф итү белән форсаты аз иде. Күп кеше китәргә ашыкты. Хәтта иң мөһим мәсьәлә – смета мәсьәләсе – дә кирәгенчә игътибар белән карый алмыйча үткәрделәр. Ахыры хәерле булсын!

## Съездның тәмамланмаган эшләре

Съездда тупланган кәгазьләрнең гадәти һәм гадәти булмаганы күп булып, президиум комиссиясе барчасын бертөрле исемлек һәм язма белән Нәзарәткә тапшырырга тиеш булса да, ашыгулары сәбәпле, алар да тәмамланмыйча, юлда калдырып киттеләр. Протоколлар, мәҗлестә сөйләгән сүзләр, әйтелгән карарлар байтак йомшак булган. Казый Ризаэтдин әфәнде әйткәнчә, үзебездән бер-ике язып баручы утырткан булсак, яхшы буласы икән. Комиссиягә ышанып калдык.

## Ибне Габидиннең «Сәбәт» нөсхәсе һәм хәдис гыйлемнәре

Мәхкәмә эшләреннән бушаган арада, китап күрү гадәтем булганга һәм кире кайтарып укуга керешкән «Сахих Мөслим»не укудан бушагач, Сәед Мөхәммәд Әмин ибне Габидин – «Раддел-мохтар» язучысының «Гукуд әл-ләли фил-әсәнид әл-гавәли» исемле «Сәбәт» нөсхәсен күргәләдем. Кереш сүзендә хәдис гыйлемен мактавында бу сүзләрне теркәгән:

[...].

Искә алынган «Сәбәт» Ибне Габидин исеме белән билгеле булган Шамның олуг галимнәреннән Сәед Мөхәммәд Әмин бине Сәед Гомәр бине Габделгазиз Габидин әл-Хөсәйни хәзрәтләренеке. Шамда [һижри] 1198 елда туган. Шәһәренең олуг галимнәреннән

мәшһүр гыйлемнәрне алган. Күбрәк дәресләре һәм тәрбиясенең күбесе шәех Мөхәммәд Шакир бине Гали Сәлим әл-Гакадтан. «Сәбәт»не һәм искә алынган шәехенең «Сәбәт»е буларак язган. Остазына зур мәхәббәтле һәм тугры булганлыктан, бу «Сәбәт»тә остазына күп хезмәт иткән.

Сәед Мөхәммәд ибне Габидин фикһ буенча күп китап язган. «Радд әл-мохтар хашия дөрр әл-мохтар» – иң олысы һәм мәшһүре. Аннан башка олы һәм кече кырык-илле кадәр матур әсәрләре бар. Хәдис һәм башка фәннәрдә үз чорының һәм Мисыр галимнәренең күбесеннән иҗазәт [алган гыйлемне башкаларга тапшырырга рөхсәт итүче шәһадәтнамә] алган. Иң мәшһүрләре: шәех Мөхәммәд Шакир Гакад, шәех Сәгыйд әл-Хәләби (1259 елда вафат), шәех Мөхәммәд бине шәех Габдрахман әл-Кәзиби (1221 елда вафат), шәех Әхмәд бине Гобәйдулла әл-Гаттар (1218 елда вафат), шәех Мөхәммәд Сәгыйдь әл-Хәмәви (1236 елда вафат), шәех Салих әл-Фүләни, шәех Мөхәммәд әл-Әмир әл-Кәбир әл-Мәгарри, шәех әт-Тарика шәех Халид әл-Госмани әш-Шәхрузи әл-Багдади һәм башкалар. Рахимәһүмүллаһү Тәгалә (Аллаһ Тәгалә аларны рәхим кылсын). Үзеннән дә күп кешеләр файда күргәннәр. Шәех Әхмәд Зыятдин Кәмәшханәви хәзрәтләренең шәехе Сәед Әхмәд бине Сөләйман әт-Тараблиси хәзрәтләре дә аннан иҗазәт алган. Шунлыктан минем тәрҗемәи хәле сөйләнгән кешегә тоташуы ике юл белән. Фүләни юлы белән Бохарины Рәсүлуллаһтан (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) тик 13 арадашчы белән күчерә. Минем 15 васита белән буладыр. 1252 елда 54 яшендә Шамда дөньялыктан күчте. Рахимәһүллаһү Тәгалә (Аллаһ аны рәхим кылсын).

## Муса әфәнденең доклады

Съездда Муса әфәнденең 70–80 кадәр номерлы доклады укылып үтсә дә, Шура идарәсеннән фикер алышуга куелырга рөхсәт булмады һәм ул фикер алушусыз калган иде. Башка докладлар рәтендә Диния нәзарәтенә дә тапшыруны тиеш күрмәде. Съездддан соң башка докладлар белән бер җыентыкта теркәлеп, төгәл, дөрес күренеп, нәшер итү өчен мөрәҗәгать ителсә дә, тапшырмады. Ләкин бу атна эчендә октябрьнең 5–7 ләрендә тагын хат җибәреп, Диния нәзарәтендә Уфа галимнәрен туплап, бөтен галимнәр алдында укып чыгачагын, мөмкин булса, тикшерү үткәннән соң, мәркәз хөкеменә

һәм башка ислам шәһәрләренә җиткерү, нәшер итү теләгендә булуын бәян итте.

Ләкин Диния нәзарәте рәсми мәҗлестә фикер алышуга ярдәм итә алмады. Аеруча җирле хөкүмәт тарафыннан съездда фикер алышуы булмаганлыктан, моңа рөхсәт тә булмаганлыктан, моның өстенә, соңгы көннәрдә бөтен Уфа вилаятендә гадәттән тыш хәл игълан ителүе бигрәк тә бер рәсми киртә булды. Алай да 8 октябрьдә җомга көн казыйлар алдында үзенең мөһим күргән өч маддәсеннән берсен (гомуми җиһад маддәсен) укыды. Нәтиҗәсе: саклану җиһады, бөек Коръән буенча, шәригатькә туры килә, килешү-антны бозып, җиһад хәрәкәте шәригатькә туры килми. Хәзерге хәлдәге кебек, Төркия дәүләте авыр хәлдә калып, залим дәүләтләр тарафыннан җәбеләнгәндә, килешүгә зарар килмәсә, аларга ярдәм итү тиешле. Ияртүче дәүләтсез белән Төркия арасында сугыш булганда дәүләт белән җимереп, ул сугыштан Русиядә булган мөселманнарның битараф калулары кебек яхшы маддәләрдән гыйбарәт.

Калган мөһим күргән маддәсе – «Ислам бердәмлеге өчен әзерләү» турындагы өлеше – форсат булмаганлыктан, укылмады. Алай да кыскартылып алынды. Җиһангир ахун Абызгильдин: «Хәзер бик вакыт, хөкүмәт киртә түгел, яңадан төзекләндерүгә тырышлык кирәк», – диде. Ләкин бу мәсьәлә хәзерге хөкүмәт каршында сөелми икәне, Шәрык мәсьәләсе мәйданга куелса да, ислам беләншмәсенең барып чыгуын гаять тә сак эш иткәннәре, панисламизм һәм пантөркизмнан бик ерак торырга тырышканнары бәян ителде. Муса әфәнде сугыш маддәсен дә, соңгы маддәләрен дә прессага чыгарырга, тәвәкәллек күрсәтергә тели, ләкин мәҗлескә килгән Җиһангир әфәндедән башкалар килешеп бетмәделәр. Казый Риза әфәнде: «Бу мәсьәләләр кырык-илле ел артыграктан бирле мәйданда язылды һәм сөйләнде. Сәед Җамаледдин әфәнде һәм шәех Мөхәммәд Габдүһ тә «Гурвәт вә сәкый» мәҗлесендә Мисыр газеталарыннан «Ән-Нәйл» һәм башкалар, Җәзаир һәм Тунис газеталарында, фәлән-фәлән һәм башка ислам дәүләтләре газеталарында кабатландылар. Хәтта кайбеләнре һәр телдә диярлек язды. Ләкин милләт бу эшләргә бер чара һәм юл тапмаганлыктан, эш күрсәтә алмадылар. Милләтнең бу эшләргә әзерлеге юк. Тиз генә булырдай мәсьәлә түгел», – дип каршы килде. Казый Кәшшаф әфәнде «Элек үк Австрия яклавы астында булган чехлар әзерлек күргәнлектән, немецларга каршы саклаган дошманлыкларын, славяннарга булган

дуслыкларын үткән сугышта Европада мәйданга чыгардылар. Күпчелеге фронттан Русия тарафына күчтеләр, соңра үзләренә хокук алып бәхетле булдылар. Ләкин аларның тәрбия һәм сәләтләре безнең халыкта юк. Шунлыктан бүгеннән бу игъланның яхшы тәэсире булмас» дигән мәгънәдә сөйләде.

Мин дә әзерлексездән мондый хәрәкәт һәлакәткә илтәчәк, житди рәвештә әзерлек күрү, милләт һәр кешесенә бу турыда мәктәп һәм башка юллар белән фикер, рух бирү кирәк икәнен, соңрак, әгәр дә безнең дәүләт белән Төркия арасында сугыш чыкса, кайчан булса да битараф калу чараларын күрү кирәк икәнен сөйләдем.

Муса әфәнденең язуларыннан аңлашылган мәгънәгә карата максаты:

Докладын Диния нәзаратыннан раслатып, халык арасында таратырга булганга охшый, ләкин минем аңа таләп ителмәгән язуым баргач, уен-фикерен әйтеп, Нәзарәт исеменнән һәм аның раславыннан таратуны теләмәдем, бәлки исә галимнәрдән юл күрсәтүне теләдем, диелә. Ахыры хәерле булсын!

Октябрьнең 14 ндә, беренче сәфәрдә Муса әфәндедән казый Кәшшаф әфәндегә түбәндәге хат килгән.

## Съезд хакында Муса әфәнде хаты, Заһид Шамвилнең вафаты

«Мөхтәрәм Кәшшаф хәзрәт Тәрҗемани җәнабләре!

Заһид әфәнде Шамвил җәнабләре сентябрьнең 25 ндә вафат булып, сентябрьнең 27 сендә җирләнгән[14]. Җеназасы зур ихтирам белән үз итеп оештырылган, сигез йөз мең җеназа йолаларына сарыф ителгән, имеш. Әнвәр бәк хәзрәтләре үз кесәсеннән ике йөз мең сум биргән, Төркия илчелеге, әфган илчелеге, бөтен Шәрык кунаклары җеназасында булганнар.

Бичара мескен йөгерде, сугылды, аһ-ваһ итте дә бөтенләйгә китте. Риваять дөрес булса, Әнвәр бәк мәҗлесендә Мәскәү мөселманарының нindидер хәрәкәтләреннән тынсыз булып, йөрәге зар-

[14] Иннә лиләһи вә иннә иләйһи раҗигун... (Чынлыкта, без Аллаһныкы һәм Аңа кайтачакбыз...). Вафат булучы яхшы милләт хадиме, дөрес ниятле, тугрылыкны сөюче, хөрмәтле, яхшы нәселле имамзадә Заһид бине Шафигъ бине әл-имам Шамвил иде. Гафәраллаһү ләһ (Аллаһ аны кичерсен)!

ланып үлгән, имеш. Заһид әфәнденең вафаты миңа да гаять тәэсир итте...

Дини дәресләр ачсагыз, мине арада хисапламагыз. Съезд көннәреннән бераз интрига хәрәкәтләре күрдем. Фетнә орлыклары да бераз чәчелде, начар нәтиҗәләре якында күренүе ихтимал. Фәлән кеше сайланса, Казан аерылачак, төгән кеше сайланса, Себер вәкилләре иганәләрен бирмәячәк, кебек фетнә орлыклары начар нәтиҗәләрен, җимешләрен якында, бәлки, өлгертер. Нәзарәт әгъзаларының мондый интригаларга килешүләре дә тиеш түгел иде[15]. Тикшерелсә,ниләр сөйлим: мондый интригаларда минем гөнаһым юк. Нәзарәт әгъзаларын начар сүрәттә тәнкыйтьләгән берничә мөхтәсиб әгъзаларын да күрсәтмәдем. Башка вакытларда да Дини нәзаратына тарафдарлыгым бар иде. Җитди иде, дөрес иде, чын иде. Докладымда байтак маддәләр Диния нәзаратына олы тарафдарлык иде. Болай була торып та, Нәзарәт әгъзаларының минем хакта һәм докладым хакында хәрәкәтләре муафикъ хәрәкәтләр түгел иде. Җомгадан соң булган мәҗлестәге хәрәкәтегез дә әдәп хәрәкәте түгел иде[16]. Ихтирам белән мөрәҗәгать иттем, ихтыяҗым түгел иде. Заман әһәмияте дә, мәсьәлә әһәмияте дә бар иде. Казыйлыкка да, мөфтилегегездә күзем юк иде (кызыкмый идем – *А.М.*)[17], нәфесем

---

[15] Әлеге интригаларга Нәзарәт әгъзаларының катнашы юк. Алардан булырга тиеш сүз дә түгел. Казан маддәсен казанлылар, Сибирия маддәсен янә үз әһелләре сөйләсә сөйләгәндер. Рәшит Ибраһимнан ишеттем: «Шәһәрем Тара халкы миңа дусларча һәм ихлас караган хәлдә, Муса әфәнде турында һич ышандыра алмадым. Мине вәкил итеп сайлау җыенында: «Мөфтилеккә Муса яки Зыя сайлансалар, иганә акчабызны, бирмичә, алып кайтырсың», – диделәр. Халык фикеренә ничек тә каршы килү мөшкел эш», – диде. Минем мөфтилеккә омтылышым юк иде. Бу вазыйфадан китүем җитди һәм чын иде, ләкин килгән вәкилләр үзләре һәм дә югарыдагылар телләреннән көчләп диярлек дәрәҗәдә үтенделәр. Бичарадан ни чара – кабул иттем.

[16] Әдәпсез хәрәкәт булмагандыр, бары, гадәттән тыш хәл игълан ителгәнлектән, Уфа муллаларын туплауны тиешле күрмәдек. Көнендә иде. Җыелгач, Һади мулла өеннән: «Гадәттән тыш хәл вакытында ник җыелдыгыз», – дип, төрмәгә илтеп яптылар. Саклыкны тиешле күрәбез, диелде. Укыган кадәрлесен казыйлар белән тыңладык, җомга ирешкәч, кузгалдык.

[17] Вәллаһү әгъләм бис-савәб (Дөресен Аллаһ белүчерәк). Бәлки, шулайдыр.

юк иде. Тырыштым, съезд вәкилләре – яшьләре дә, картлары да – шәһадәт бирер. Тик «комиссия калмаса, яңа комитет сайланса, Дини нәзараты харап» дигән сүзендә яки хыялыгызда минем эшем юк[18]. Мәскәү мәҗлесендә дамелла Галимҗан хәзрәт җәнабләренә моны ачык сөйләдем. Зыя әфәндегә ул кадәр каршылык[19] итмәсәгез дә ярар иде. Нәзарәтнең үзенә, әгъзаларына, моннан соң зарарымнан, начар сүзләремнән, орышуларымнан, гаепләүләремнән Нәзарәтне дә, әгъзаларын да тәэмин итү [ягъни ирештерү] юлында шул хатны яздым. Миннән һәр яктан имин булыгыз[20]. Якын араларда, иншалла, сәфәргә чыгармын. Нөсхәсе бер генә, докладымны бирә алмам[21], сезнең өчен әһәмияте дә булмас. Зур эшләр хозурында тәмам зәгыйфьлекме – таныдым. Килешенгән хәрәкәтләрне – бөеклекме, юкмы – дәгъва иттем. 13 октябрь, 1920 ел. Муса Җарулла. Уфада».

Бу хат үзе дә бер төр интригадан туган хат. Нәзарәт әгъзалары сайлап алу турысында бер кешенең дә зарарына хәрәкәт итмәгән кебек, үзләренә дә хәрәкәттә булмадылар. Бары халыкның җитди теләкләренә, халык фикерен күздә тотып, ризалык күрсәттеләр. Ни сәбәптәндер, бу кадәр хәл хат иясенә авыр тоелган кебек сизелә.

---

[18] Бу хыял безнең хыял түгел, яла ягу. Вәкилләр арасында булган, үземә дә: «Син кабул итмәсәң, халык тарафыннан иганә булмаячак, Мәхкәмә дәвам итә алмаячак», – диючеләр булды. Валлаһү хәсәбәһүм (Аллаһ алардан хисап алыр).

[19] Ул кадәр каршылыгыбыз юк, бары Мәскәүдә Габделвәдүд ахун өендә дүрт кеше идек. Мин эштән чыгуымны аңлатып сөйләдем, мөфти сайлавы турында фикер алыштык. «Зыя әфәндене халык теләмәс», – дигәч, мин исә: «Ничектер халыкның бер өлеше аның гакыйдәсендә шөбһәләнәләр, кызыллык белән дә сөйләп хурлыйлар», – дидем. Соңра Зыя әфәндened миңа бер ышанычлы кеше ирештерүенә күрә, Муса әфәнде аңа ирештергән: «Мөфти сине имансыз һәм коммунист», – диде. Бу сүзгә гаҗәпкә калдым. Муса әфәндегә бу кадәр ялган катыштырып, сылтап калдырасым килми. Аптырап калып торам. Үзләре белән әңгәмәгә вакыт юк. Муса әфәнде ул мәҗлестә минем сүземә каршы: «Инде сезнең эшсез торуыгызга күрә, Зыя әфәндедән туган начарлыкның зарары кирәк булыр», – диде.

[20] Югарыда әйтелгәннәрдән зыян ирешер дип курыкмыйбыз. Съезд әгъзалары арасында булганнар хакыйкатьне аңлап киттеләр бугай.

[21] Съезд кануны, законнар җыентыгы буенча бирү, беренче нөсхәне күчереп алу мәҗбүри иде.

## Сүзлек иясенең бер вакыйгасы, сәләфләрнең хәдис укулары

Бу кәгазьләрдә мөнәсәбәтле-мөнәсәбәтсез сүзләр туплыйм. Хатирә дәфтәре дә шулай була торгандыр. Менә бер мөнәсәбәтсез нәрсә язам:

Бер көндә, бер җирдә «Укъянус»ның беренче өлеше кулыма очрап, керешендә сүзлек иясенең тәрҗемәи хәле өлешендә, ул мөхтәрәм галимнең камиллек иясе булуыннан соң, хәер һәм бәрәкәт теләп, бер остазы алдында өч көндә бөтен Сахихе Мөслим китабын укып чыгуын яза. Моны тәрҗемә итүченең Шамда, ишекләр арасында шәех Мөхәммәд бине Җәһбәл янында булуын үзенең бәетендә аңлата. Шигырь:

[...].

Изге галимнәрнең гыйлемнең хөрмәтен белеп, бер китабын теләп, ихтирам һәм тәбрикләү йөзеннән башканың янында укып, чылбыр хасил итә килгәннәр, китапларын дөресләгәннәр, үзләренең өйрәнү куәтләренә алданып, мәхрүм калу юлына кермәгәннәр. Вә фиһим ләнә үсвәтүн хәсәнәһ. Рахимәһүмүллаһү Тәгалә (Алар – безнең өчен яхшы үрнәк. Аллаһ Тәгалә аларны рәхим кылсын).

«Ә-сәбәт» иясе мәшһүр бөек әмир Мөхәммәд әл-Мисыри сөйләвенә күрә, Хафиз бине Хаҗәр әл-Мисыри хәзрәтләре шәех Әбү Таһир Мөхәммәд бине Мөхәммәд бине Габделлатыйф бине әл-Көеки янында «Сахихе Мөслим» дүрт мәҗлестә укып чыккан. Соңгы галимнәрдән хәзрәт шәех Шаһ Вәлиулла Дәһләвинең шәехе шәех Мөхәммәд Әбү Таһир бине шәех Ибраһим әл-Көрди әл-Күрәни әл-Шәһрузи хәзрәтләре остазы һәм шәехе шәех Хәсән бине гали әл-Гаҗими әл-Мәккәидән аз-аз заманнарда хәдис китапларын укыган. Шулай ки, «Мүвәтта»ны унбер мәҗлестә 1101 елның 17 рәҗәбендә «Сахихе Бохари»ны 19 көндә аз гына җире калып 1111 елның 28 рәҗәбендә укыган. Шәехенең мәҗлес буе көченнән гаҗәпләнә, кояш чыкканда утырып, икенде алдында мәҗлес тәмамлана. Өйлә намазына гына кузгалып ала идек, ди. «Сүнән Әби Дауд»ны өч битеннән башкасын 14 көндә 28 мәҗлестә укыган 1112 елның 28 рәҗәбендә, бу арада икенде дәресе булу белән «Хәсаигый күбра» да укыган. «Сүнән Тирмизи»не 7 көндә 21 мәҗлестә тәмамлаганнар, 1112 елның 20 рәҗәбендә. «Сүнән Нәсаи»ны шул елның 11 рәҗәбендә башлап, шәгъбан башында тәмамлаган. Бу вакытта кайберсендә Тирмизине дә укыган була. Шәех Әбү Таһирнең

бу укуларын үзенең кайбер иптәшләренә 1123 елда язган иҗазәтнамә нөсхәсеннән күчердем. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә хәдис шәехе хәзрәтләренә аерым куәт һәм көч биргән. Мин Истанбулда шәех Әхмәд Зыяддин әл-Көмешхәнәви хәзрәтләре даирәсендә «Сүнән Тирмизи»нең яртысы кадәрле, югарыда искә алынган хәзрәтләренең хәдистәге әсәре «Рамүз-әл-әхәдис» китабын 15 көндә өйрәнү һәм төзәтү белән тәмамлап укып чыгуымда да хаста була язган идем. Янә күп шөкер итүемә яраклы булдым 1307 елда.

## «Әмин» сүзе хакында

Бу вакытлардагы гадәтемчә, «Нәвави шәрехе» белән «Сахихе Мөслим»не өйрәнгәндә, «Иршад әс-сәри фи шәрх әл-Бохари»да тәэмин итү мәсьәләсендә «әмин» сүзенә мондый бәян очрады:

[...].

Тел һәм фикыһ галимнәре фикеренчә, хата һәм ялгышу булып хисапланган «мим» тәшдиде белән «әммин» сүзен искә алынган дөрес юл иясе Хәсән Басри Җәгъфәр әс-Садыйкка, Хәсән бине әл-Фазылга нисбәт иткән. Үткән заман максатында булган «әммә» сүзеннән исме фәгыйль булып, «нәхнү касыйдүнә нәхвәк» тәкъдирендә булачак. Хәзерге китап авторлары догаларында кыскартулар ишетелә. Электән үк бу мөбарәк сүзнең китап ияләрендә булуы, кайбер хәдисләрдә, яһүдләр, мөселманнарга «әмин» сүзе бирелгәч, көнләшүләре искә алынуы Нәвавинең «Тәһзиб»тә Гатиятел-Гуфидан риваять иткәнчә, бу сүзнең борынгы яһүдичә яки ассирияле булуына ачык дәлил.

## Совет-Польша килешүе

Ничә айлардан бирле Польша хөкүмәте Шура хөкүмәтен сугышлары белән борчып, әле җиңеп, әле җиңелеп килә иде. Бу хөкүмәт үзе кечкенә булса да, артында Антанта торып, төрле корал һәм кешеләр белән, рәсми рәвештә булмаган ярдәм итеп торганлыктан, күңеле күтәрелеп, шатлыгы артып, бу соңгы айларда җиңеп, Шура хөкүмәтен вакытлы килешү, солых сорарга мәҗбүр итте.

Көньякта янә Антантага сыенган Врангель исемле җитәкче белән Шураның сугышы да житди кәсеп итә барганлыктан, болар белән килешү, әлбәттә, тиешле күрелгән иде. Кыш якынлашты. Гаскәр күп булса да, ялангач һәм башка әсбабларга да житеш-

мәүчәнлек бар, быел Эчке Русиядә иген булмавы да бик начар тәэсир бирәдер. Троцкий никадәр каһарман сугышчы булса да, никадәр зыянлы һәм хаталы булса да, ирексез, сугышны тиешле тапкан булса кирәк, берәр атнадан бирле сөйләнеп һәм язылып килгән килешү бүген 15 октябрьдә игълан ителде. 18 октябрьдән сугыш тукталып, янә 21 көнгә туктатылачак, солых шартлары буенча да фикер алышу булачак. Бу солыхта Шура хөкүмәтенә бик авыр маддәләр куелмый, Шураның да шуларны кабул итүе ихтимал икән. Бүген игълан ителде: 14 нче елдан бирле Польша мәмләкәте (хөкүмәте һәм халкы) һәртөрле сугышларда никадәр зарар күрсә, барчасын Шура хөкүмәте түләячәк икән. Янә шуның кебек зарарлы һәм хурлыклы шартлар, бәлки, бардыр. Халык файдасын күз итүеме, хөкүмәтнең үз файдасын күз итүеме, шулай йөкләтелә икән. Ләкин бу кадәр түләү, әлбәттә, халык өстенә йөкләнми мөмкин түгел. Аллаһ ахырын хәерле итсен. Нинди олы хәсрәт.

## Килешүләр, бармак хисабы

17 октябрьдә (4 сәфәрдә) иптәшебез казый Ризаэтдин Фәхри кайбер балалары турында хикәят сөйләде: кайбер профессорлар көрдләрнең бармаклар белән зур хисаплар күргәнен, гимназия дәресендә булса кирәк, сөйләгән. Казый әфәнде тәшәһһөдтәге имән бармак белән ишарә итү хәдисләрендә бармак очлары белән санауга ишарәләрне күрсә дә, ни өчендер бу хисапны ят нәтиҗә кебек күргәнлектән, әйттем: «Шәрех мулла Җаминең сүзне аңлатуында дүрт функцияне санагандагы «төен»нәрне ни дип белә идегез?» «Бармак төеннәреме, дөрес аңлап укылмаган», – диде. Чыннан да, үзебез дә иптәшләребез белән дөрес аңламый укыганбыз. Мөгаллимебезнең санау төймәсе дигәне хәтеремдә калган. Хәер, бу аңлату «төеннәр» сүзенә бик туры килмәсә дә, дүрт функция кебек (сүз булмыйча мәгънәгә дәлил булган нәрсәләргә) мисал булырга лаек. Соңра мәҗлесебездә әйттем: «Бармак очлары белән «төеннәр» – хисапта бер фән, Гали әл-Кари «Мишкят» шәрехендә ишарә хәдисләрендә сәхабәләр арасында бу гыйлемнең таралганлыгын бәян итеп китә, һинд һәм әфган халкы арасында да таралган. Минем математика остазым мулла Миршәриф Сәгати Хисүб хәзрәтләреннән өйрәнгән идем. Ун бармак белән ун меңгәчә хисап йөртелә. Мәүләви Җаминең әйткәне шушы булса кирәк».

Хөрмәтле казыйларның барысы да килгән иде, бу кадәр ишетеп калдылар. Бу җирдә шул фәнне кыска гына язып үтүне муафыйк күрдем:

Бу фәндә ун бармак белән ун меңгәчә санала, шулай итеп: уң кулдан чәнчә бармак, атсыз бармак һәм урта бармак төрле рәвештә тугыз, имән бармак һәм баш бармак белән тугыз унлыклар санала. Сул кулдан имән бармак белән баш бармак тугыз дәрәҗә йөзлек төеннәре, чәнчә бармак, атсыз һәм урта бармак меңлек төеннәре өчен. Уң кул бармакларыннан бердән тугызгача ишарә рәвешләре, сул бармаклардан бер меңнән тугыз меңгәчә ишарә булыр. Мәсәлән, уң урта бармак өчен учка кую бишкә ишарә, сул урта бармакны сул учка кую биш меңгә ишарә итә. Уңнан туксан галәмәте, сулдан тугыз йөз галәмәте булыр. Бу хисапта бармакларда унтугыз төрле рәвеш һәм галәмәтләр күздә тотыла. Шулай итеп: 1 – бер саны өчен уң кулдан чәнчә бармакны үз төбенә аз гына бөгәр. 2 – ике өчен янына шул рәвешле атсыз бармакны кушар. 3 – өчкә боларга уртадагыны кушар. 4 – дүрткә чәнчә бармакны күтәрер, атсыз бармак белән уртадагыны үз хәлләрендә калдырыр. 5 – бишкә атсыз бармакны да күтәрер, уртадагы гына бөгелгән хәлдә калыр. 6 – алтыга уртадагыны күтәрер, атсыз бармакны учның уртасына төшерер. 7 – җидегә аны күтәреп, ялгыз чәнчә бармакны беләзек тарафына учка бөгәр. 8 – сигезгә чәнчә янына атсыз бармакны кушар. 9 – тугызга боларга уртадагыны кушар. 10 – ун өчен имән бармакның тырнак очын баш бармак янына куеп бер түгәрәк төзер. 20 – егерме өчен имән бармакның уртадагысына тоташтырып, баш бармак тырнагына куялар[22]. 30 – утыз өчен баш бармакны торгызып, имән бармакның очын баш бармак очына бөгәләр. 40 – кырык өчен баш бармакны эчке тарафыннан имән бармакның төп уемы аркасына тоташтырылыр. 50 – Илле өчен имән бармакны тик тотып, баш бармакны имән бармак буенча учка куелыр. 60 – Алтмыш өчен баш бармакны бөгеп, тырнагы өстенә имәннең урта буынын куялар. 70 – Җитмеш өчен имән бармакның урта бармакка якын эчке буынын баш бармакның тырнагы янына кушылыр, ләкин тырнагы калдырылыр. 80 – Сиксән өчен баш бармакны торгызып, буыны аркасына имән бармак тарафына үткәрәләр[23]. 90 – Туксан өчен имән бармакның тыр-

---

[22] Егермегә имән бармак белән баш бармакны икәвен сузуны галәмәт иткән. Утызга имән бармак белән баш бармакны галәмәт иткән.

[23] 80 өчен имән бармакны баш бармак тырнагына куюны тәгаен итә.

нак очын баш бармакның урта буынына куелыр[24]. Инде унсигез төрле рәвеш бәян ителде, тугызы чәнчә бармак, атсыз, урта бармаклар ярдәмендә, тугызы имән бармак һәм баш бармак белән үтәләр. Башта кереш сүз белән бәян ителде, уң бармаклар белән бергә генә ишарә ителсә, сулдан ул бармаклар шул рәвеш белән бердән тугызгача ишарә ителә. Уңнан кайсы белән 10, 20, 90 гача билгеләр күрсәтелсә, сулдан бу рәвешләр белән 100, 200, 900 гә ишарә ителер. Шул рәвешле ун бармак белән бердән тугыз йөз туксан тугызгача ишарә итеп була. Ун мең өчен баш бармак очын имән бармакның икенче буыныннан учына таба сузылыр, хәтта икәвенең тырнаклары бәрабәр булырлар.

Бу бәян иҗазәт биргән шәехебез Сиддыйк бине Хәсән Кануҗи Бәһупали хәзрәтләренең «Һидият әс-саил илә әдилләтил-мәсәил» китабыннан күчерелде. Хашиядә Шиһабетдин әл-Кыйлубинең[25] «Шәрхү минһәҗ лил-мәхәлли» хашиясендә булган исемлегеннән кайбер каршылыклар булган җирләренә ишарә ителде.

## Заһид Шамил тәрҗемәи хәле

20 октябрьдә Мәскәүдән 30 сентябрдә язылган Дивишев имзасы белән телеграмма алдым: 27 сендә Заһид Шамвил (Шамил) вафат, 29 ында күмелде. Милләт хадиме, эчкерсез, юмарт, галиҗәнап, һәр аптыраганга ярдәмче, яхшы кеше иде. Һәр мәсьәләдә халык юксынырлык һәм сагынырлык әмирзадә иде. Аллаһ рәхмәтенә алган булса иде. Телеграмма ашыгыч булса да, бик озак килгән. Хөкүмәтнең хезмәтләре бик арткан булса кирәк, өч көннән бирле Уфадан һичкайсы төрле гади һәм шәхси кешеләрдән хәбәрләр кабул итмиләр. Аллаһ ахырын хәерле кылсын. Риваятькә караганда, искә алынган шәехнең, артык борчылуы сәбәпле, йөрәге бозылып вафат булган. Халыкның төрек башлыкларын корбан бәйрәме мөнәсәбәте белән кунак итү турында ике мәхәллә арасында аз гына каршылык орлыгы мин Мәскәүдә вакытта ук беленгән иде. Шул җәһәттәнме, башка сәбәпме, аз гына кызыксыз вакыйга булып

---

[24] Йөз өчен сул чәнчә бармакны үз төбенә бөгүне тиеш күрә, ләкин (?) кулның барын ачуны йөзгү тиеш күрә, чөнки остазы мулла Миршәрифтән (?) ике кулны бөтенләй ачуны ун меңгә тиң дия иде.

[25] Бу мәсьәләне тәшәһһөдтә булган ишарә мөнәсәбәте белән искә алган.

(дөрес булса, татарлар белән төрекләр арасында сүз булып), бичара, намуслы нечкә хисле Заһид бәк бик тә кәефсезләнеп кайтып, йөрәгем бозылды, өч көннән артык тормам, дигән икән. Шул вакыйганың өченче көнендә вафат булган икән. Гафәраллаһү ләһү вә рахимәһ (Аллаһ аны кичерсен һәм рәхим кылсын). Нечкә хисле кешеләрнең шул сәбәпле кинәт үлүләре булгалый. [Коръәннең] җиде төрле укуын, гарәп телен белгән имам Әбү әл-Хәсән Гали бине Хәмзә әл-Кәссәи әл-Күфи белән гарәп теле остазы һәм гарәп синтаксисы имамы Әбү Бәшәр Гамру бине Госман Сибәвәйһ әл-Фарси әл-Басри бәхәсләреннән соң, Сибәвәйһ зәгыйфьләнеп, тиздән вафат та булган[26].

Вакыйга: бу ике имам Һарун Рашид янында җыелып, әңгәмәләре вакытында Кәсәи бер мөнәсәбәт белән гарәпчә: «Зәнбур кигәвен – төклетура кебек агулы чебен, бал корты», – дип әйтүендә Сибәвәйһ: «Алай түгел, бәлки «фә-изә һүвә һия», – дигән. Арада бәхәс өзелеп, чүл гарәбеннән (мәдәни кешеләргә катышып, теле бозылмаган гарәптән) – саф һәм дөреслекне белгән кешедән – сорарга теләп, чын гарәп Сибәвәйһ әйткәнчә сөйләгән. Кәсәи Һарун Рәшид улы Әминнең мөгаллиме булгач, өстен чыгарга теләп, әлеге гарәпне: «Фә-изә һүвә әйәһә», – дип әйттерергә теләсәләр дә: «Минем телем алай бармый», – дип, хаталы сөйләргә риза булмаган. Бары бер кешене, вакыйганы сөйләп: «Ике имамның кайсысының сүзе хак», – дигәч, «Кәсәинең», – дип әйтергә күндергәннәр. Сибәвәйһ, бичара, золым кылынган, мескен булып чыккан. Кәсәи моның артынннан: «Моның йөрәге янды, яшәве чикле, түзмәс», – дигән. Вакыйга озакламады, ул дөньядан китте. Рахимәһүллаһ (Аллаһ аны рәхим кылсын).

22 октябрь җомга көн Сибирия мосафирларыннан Мәгъсүм Зарифзадә Фәләнев Петропавел өлкәсеннән Становой исемле казакъ авылы имамы бер мәзәк, гыйбрәтле хәл сөйләде. Бер рус коммунист оратор, халыкны җыеп, коммунизмга чакырып, нотык сөйләгәндә, әйткән: «Гайсә пәйгамбәр коммунизмны өйрәнгән иде. Аның тәгълиматы Мөхәммәд пәйгамбәр килгәнче дәвам итте. Мөхәммәд килгәч, аның куелган кагыйдәсен барын да утка якты». Мөселманнардан Зариф исемле кеше сүз алып әйткән: «Мөхәммәд пәй-

---

[26] Кәсәи имам Мөхәммәд бине Хәсән ән-Нәсибани белән бер көндә Рий шәһәрендә [һиҗри] 189 елда вафат булган, Сибәвәйһ [һиҗри] 180 елда вафат.

гамбәрнең коммунизмны ягуы дөресме?» «Дөрес», – дигән. Өч мәртәбә кабатлатканнан соң, халыкка әйткән: «Без Мөхәммәдне пәйгамбәр дип таныган, аңа ышанган кешеләр, коммунизмны яккан булгач, инде бу мәҗлестә аны тыңлап торырга да кирәкми, дип ораторны оятлы иткән. Халык та көлешеп таралган.

Бу Сибирия мосафиры Колчак гаскәренең хәлләренә байтак тукталу күрелде. Бу гаскәрнең кызылларга каршы яхшы сугышмавы турында әйтә: «Колчак Сибирия халкының кызылларга каршы теләкләре куәтле икәнен белеп, бөтен көче белән сугышуны теләмәде. Сибирия халкы кызыллар белән яхшы танышмыйча, каршы тору файдалы түгел, танышканнан соң эш күрелер, дигән фикердә һәм сүздә булдылар». Вәл-гыйльмү гыйндәллаһ (Гыйлем Аллаһта гына).

Казаннан бишенче мәчеткә минем яныма икенче имам итеп Шәһәр Шәрәфнең сайлауларыннан рәсми протокол иреште. Шуның белән бердә бу нөсхә бар иде: «1920 елның 12 июлендә Шәһәр Шәрәф хакында төзелгән приговорга имза куела башланган булса да, элек мәхәллә оешмасының (общинаның) мәслихәт күрүе буенча 5 нче мәчеткә имам булачак затны яшерен тавыш белән сайларга карар биреп, беренче октябрьдә җомга көн Әхмәтҗан Мөхәммәдкәрим улы Мостафин белән Шәһәр Шәрәфне яшерен записка ысулы белән сайлап, Әхмәтҗан Мостафинга 102, Шәһәр Шәрәфкә 112 записка булып, Шәһәр Шәрәфкә тавышның күбрәк булуы сәбәпле, 8 октябрьдә җомга көн рәсми приговорга имза куярга карар бирелде. Моның өчен яңадан приговор язылмыйча, бәлки 12 июльдә башланган приговорга имза кую дөрес булып, 5 нче мәхәллә халкы югарыда искә алынган Шәһәр Шәрәфне имам итеп сайладылар. Бу югарыда язылган кәгазьне, приговор нөсхәсенә кушып, Диния Нәзарәтенә җибәрелде. Нәзарәткә кәгазь һәм рәсми приговоры 24 октябрьдә иреште. Эш гамәлгә чыкса кирәк.

## Татарстан җөмһүрияте рәисе Сәедгалиевкә ату

24 октябрьдә Башкортстан җитәкчеләреннән Спас кантоны Урбагар авылыннан Камал Фәхри әфәнде Казаннан минем туганнан туган сеңлемә – Кәшшафетдин казыйның балдызына – өйләнеп килде.

Казан хәлләреннән күңелсезлекләр сөйләде, Җөмһүрият рәисе Сәхибгәрәй Сәедгалиевне атканнар, кулына гына тиеп сәламәт кал-

ган. Ләкин эшкә әһәмият биреп, милләтчерәк булган коммунистларны һәм башка гайрәтле кешеләрне кулга алганнар икән. Укуларына күрә, Сәедгалиевтә милләт рухы бер дә булмыйча, чын коммунист булуына гына бу эшнең килеп чыгуын уйлыйлар икән. Бу хәлне тикшерү өчен мөселман гаскәре идарәсе рәисе Мирсәет Солтангалиев Мәскәүдән Казанга килгән. Чөнки шул арада военная коллегиядән дә кулга алынган кешеләр булган икән. Бу эш сылтавы белән байтак мөселманнарны урыннарыннан чыгарып, алар урынына чын милләтсез, халыкка чит татарларны яки русларны урнаштырганнар.

Искәрмә: «Сәедгалиев тә электән үк милләткә карамый, чын коммунизмны куәтли, Җөмһүрият хезмәтләрендә үзенә яраклы адәмнәрне генә туплый, аз гына милләт рухы сизелгән кешеләрне куа, берәр сылтау табып, еракка җибәрә» дигән сүзләр бар иде. Мәркәздә дә, бәлки, шулай кушу яки фәрман бардыр. Ләкин бу рәвеш, бу сәясәт яхшы чара түгел. Аеруча Казан кебек милләтче һәм динче җирдә хөкүмәт урнаштыру, яңа Җөмһүриятне аякка бастыру өчен акрынлык юлын күрү, халыкка аз гына милләт төсен күрсәтү кирәк иде. Һәркайсы яңа хөкүмәтнең аякка басуы һәм дәвам итүе өчен, кискен алмашынулар булмыйча, халыкның ияләнгән нәрсәсен акрынлап бетереп, үзенә ияләндерү, үзен халыкка җирәнгеч итеп күрсәтмичә, якынрак күрсәтү, хәтта мөмкин кадәр сөйдерергә тырышу тиешле. Шунлыктан Җөмһүрияттә, кирәк рәис булсын, кирәк әгъзасы, коммунист булсалар да, коммунизмда бик көчле рәвештә ныклык күрсәтмичә, йомшаклык белән хәрәкәт итүләре теләгән нәрсәләренә ирешер өчен файдалырак булыр иде. Шулай да ату, үтерү кебек җинаятьләргә батырчылык итү файдалы түгел. Әҗәл җитмәгәч, Сәедгалиев, бары азрак кулы җәрәхәтләнеп кенә калган, үтерелгән булса да, араларында дошманлык кына артыр, башкасы аның мәсләген эзәрлекләгән булыр иде.

Бу арада күп адәмнәргә зыян тигән, гөнаһсыз адәмнәр җәза күрәләр. Барчасының да эшләре – яшьлек, тәҗрибәсезлек. Шөбһәсез хак һәм дөрес булган ислам ысулыннан гыйбрәт алу, аның тоткан сәясәтеннән сабак алу кирәк иде. Ислам барча халыкны бәхетле итүне максат итсә дә, һәркемнең ислам дине белән хөрмәтле булуын теләсә дә, йогынтысы астына һәм сәясәтенә керткән мәмләкәтләрдә көчле һәм кискен мөгамәләләр кылмый, һәр милләтне үз хәлләренә куя, бары һәркайсыннан дуслык һәм иминлек көтә, мөселман буламы яки бертөрле түләү белән калып, дуслык килешүен кыламы –

канәгатьләнә. Бу эш чит кешеләрнең көферлек һәм күпаллалык хәлендә калуларына риза булганлыктан түгел, бәлки ислам эчендә торып, яхшылыкларына төшенеп, яхшы ихтыярлары белән ислам динен кабул итәрләр, көферлек һәм адашудан котылырлар, дип, үз ихтыярларына калдыра.

Бу коммунистларга да шушы юл – яхшы юл. Үзләренең максатларына ирешер өчен, коммунизмны халык арасына таркатыр өчен, халык белән дуслашып, якынлашып, мәсләкләренең (булса) яхшылыкларын күрсәтеп, акрынлык белән мөгамәлә итсәләр, яхшырак булыр иде.

Бу тоткан катылыклары, кискен тәэсир итү һәм аулау фикерләрендә булулары халыкны биздергәнлектән, дошманнары өчен файдалы. Кем белер, кайбер сәясәтчеләрнең әйтүенчә, боларның эчләрендә бу, искә алынганча, халыкны нәфрәтләндерү һәм читләштерү максаты белән бу эшне эшләүче коммунизм мәсләгенең икейөзлеләре бар, шулар мондый хәрәкәттә булалар, дигән сүзнең дөрес булуы ихтимал. Дөресен Аллаһ белүчерәк.

Искә алынган Камал әфәнде Казаннан безнең Диния нәзарәте өчен ун төп юллы ак кәгазь китерде. Һәр тупасы 280 нән унҗиде мең сум, якынча табагы 35 сум чамасы буладыр. Госманлы каләме китерде, һәр данәсе илле сумнан. Бу бәһаләрне игътибар [итү] өчен яздым.

Искә алынган мосафир Камалның әйтүенә күрә, Казан юлында һәм тарафларында булган мөселманнар Уфада булып узган галимнәр һәм мәчет эшләрен башкаручылар съездына бик куанганнар. Диннең дәвам итүен һәм куәтләнүен чыгарып, Диния нәзарәтенә рәхмәт белдергәннәр. Бу куанычлы рәхмәтләр һәр җирдән ишетелә.

Халык элек бик өметсез булган. Хәбәрләшүләр кулайсыз булганлыктан, Нәзарәттән дә хәбәр ишетә алмый торган җирләр булган. Бу кадәр исбат итү тәмам хөррият белән киңәшмә, фикер алышулар, яхшы карарлар чыгару, элекке комиссия әгъзаларының янә хезмәт кабул итүләре диндар халыкның хушына киткән. Аллаһ Тәгалә ахырын хәерле итсә иде!

## Толстой хакында әңгәмә

Шимбә 26 октябрь, 12 сәфәр кичәсендә Йосыф хаҗи Дибирдиев һәм туганнан туган сеңлем Фатыйма ханым Шакулова өебездә

кунак булганнар иде. Йосыф хаҗи русча яхшы белә торган дин галиме, туганнан туган сеңлем русча күп укыган, аеруча мәшһүр Толстой әсәрләрен күп күргән һәм аңа ихласлы, хөррият тарафлы, дин фикерләрендә хөррият юлына куйган гыйлемле ханым. Искә алынган хатын кебек байтак адәмнәр дә Толстойга мәхәббәт урнашкан, аны бер хаклык эзләүче, бәлки, хаклыкка ирешүче дип әйтүчеләр бардыр.

Сүз арасында, Мәскәүдә күргән, гомеопатия табибы, шактый гадел, хикмәт иясе кебек холыклы Федор Бруштейнның кайбер хәлләрен хатирә дәфтәреннән укыдым. Аның Толстой хакында «Акыллы булса да, югары дәрәҗә сөю, шәһрәт сөю белән интеккән адәм иде. Чын хикмәт иясе һәм дөрес кеше булса, хатынының кайбер хәрәкәтләрен күтәрә алмыйча качып китмәс иде. Түзем, аеруча гаиләсенә авыр булса да, яхшы мөгамәләдә булырга тиешле» дигән эчтәлеген дә укыдым. Укучысы Фатыйма ханымга бу сүз хушсыз тоелса да, Йосыф хаҗига бик хуш күренде.

Сүз арасында, мин әйттем: «Толстой чын хаклык эзләүче адәм түгел, хәзрәти Мөхәммәдне (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) ишетте, аның дине хөрриятта таралганын белде, шунлыктан, ышанмаса да, тугрылыгын ихтимал тотып, мөселман галимнәренә мөрәҗәгать итеп, хәзрәти рәсүлулланың динен һәм тәгълиматын тикшерү һәм тоту Толстойга тиеш иде. Бу эшне кылмады, хаклыкны эзләмәде, бары үз Инҗиле белән канәгатьләнеп, шул иманы белән үлгән булса, үзен утта мәңге калучы итте».

Йосыф хаҗи да бу сүзне куәтләде. Арада ике туганнан туган кардәш арасында байтак фикер алышулар булып, Бруштейн сүзен хаҗи байтак куәтләп, «гаҗәпләнүе һәм горурлыгы белән дөньядан мәхрүм китте, туры юл тапмады» эчтәлегендә исбат итте, Фатыйма ханымның Толстой хакындагы ышануына һәм мәхәббәтенә байтак көчле һөҗүм ясады. Толстой христиан галәменә, аларның бозык ышануларына байтак тәэсир итте, икеләнү китерде, нигезләренең зәгыйфьлеген яхшы күрсәтте. Ислам галәме өчен дә бу эш файдалы булды. Ләкин үзен уңышка чыгара алмады, бары хәрәкәтсезлек заманында яраклы, күпаллалыктан сәламәт бер инҗили иман хасил итсә дә, тышкы яктан һәм әсәрләрендә күренгән хәленә күрә, хәзрәти Мөхәммәднең (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) килеп чыгуыннан соң тиешле булган иманны, уңыш бирүче булган ышануны кайгыртмады, эзләнмәде. Шул үзе Инҗилдән тапкан кадәр ышану белән дөньядан кайтты, китте, һәлак булды. Рәсүлуллаһның

(Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) миссиясеннән соң һәркемгә, кирәк яһүди, кирәк христиан, кирәк буддист, кирәк кем булсын, бер Аллага табынучы да булсын, аңа [Мөхәммәд пәйгамбәргә] ышану, исламны кабул итү мәҗбүри һәм фарыз. Ансыз иман хасил булмый, бер Аллага табынучы булса да, һаман кяфер хәлендә була.

## Совет мәктәпләренә балаларны җибәрү һәм дин дәресләре

Кайбер якларда Шура мәктәбенә балаларны җибәрмәү һәм укытмаулар, кайберләрендә Мәркәзнең «мәктәпләрне халыкка кайтару мөмкин» дигән сүзенә карап, иртәрәк кылынучылар, ишетелгәнгә күрә, бер мөрәҗәгатьнамә язып, канцеляриягә бирдем. Вакыты белән тиешле урыннарга нөсхәсе җибәрелер.

Мөрәҗәгатьнамәнең эчтәлеге: Совет (Шура) мәктәбендә укытуны, балаларны җибәрүне тыймаска тиешле. Ләкин дин дәресләренә дә әһәмият бирергә кирәк. Һәр ике төр дәресләрне, ике төрле укыту мөдирләре халыкның да теләкләренә карап, мөмкин кадәр практикада кулланырга, дәрес вакытларын киңәшләшү белән билгеләргә тиешлеләр. Шура дәресләрен бөтенләй ташлау зур бозыклыкка сәбәпче булуы ихтимал булганга, мөмкин кадәр практикада кулланып укыту яраклы.

Мәктәпләрне халыкка кайтару мөмкинлеген Мәркәздә әйтteләр, рәсми кәгазьдә дә искә алдылар. Ләкин ул эш әүвәл халык тарафыннан рәсми приговор белән, исбат ителеп, соралырга тиеш, шуннан соң ул мәсьәлә хәл ителер. Аңа кадәр мәктәпләрдә Шура вәкилләре таныштырып торалар. Дини дәресләрне төштән соң укыту мөмкин булса кирәк. Юнәтелсә, борынгы заманча таң белән укыту бигрәк яхшы булыр иде. Дини дәресләр өчен хәзер ике сәгать, бер ярым сәгать җитәчәк ки, язу таныту, яздыру Шура мәктәбендә үтәлә.

## Кояш-ай тотылу мәсьәләләре

27 октябрьдә чәршәмбе көн кичке сәгать биштән соң ай тотылу булды. Сәгать сигез булгач, ачылды. Ләкин һавада болыт булганлыктан, ай тотылуның үзе күренмәде. Фәкать караңгылык куәтле булды.

25 октябрьдә шәһәрдә игълан итеп, кәгазьләр ябыштырылган иде. Ләкин Казан обсерваториясеннән күчерелгән календарьдә сәфәр аеның бетүен 12 октябрьдә сишәмбе көн иртәнге 3 сәгатьтә 52 минутта күрсәтелгән. Моның буенча ай тотылу 26 [октябрьдә] сишәмбе көн кич булса кирәк иде. Обсерваториядән хата алынганмы – бер сәерлек бар.

Искәрмә: Ай тотылу, кояш тотылуның һәркайсы Аллаһ күренешләреннән бер күренеш, бәндәләр бу хәлдән курку, дулкынлану хәленә килеп, тәүбәгә килү, Аллаһка ялвара һәм сыена башларга тиеш ки, галәмгә күрсәтелгән зур алмашыну һәм дәһшәтле хәл. Сөннәттә дә кояш тотылганда җәмәгать белән озын намаз, хәтта башыннан ахырына кадәр барган намаз уку, ай тотылуда кичнең төрле вакытында барлыкка килеп торганлыктан, җәмәгать авыр булып, ялгыз-ялгыз намаз уку шәригать буенча билгеләнгән һәм гадәт итеп алынган. Ләкин бу заманда байтак адәмнәр, боларның сәбәпләрен белгән булып, куркынычсыз күреп, бер тамаша кебек итеп карап үткәрәләр. Дөрес, Аллаһ гадәтенә күрә, мәгълүм сәбәпләрдән хасил була торган хәлләр. Шулай да куркыныч, күк хәленең зур үзгәрүе. Куәтле җилләр, куәтле яңгырлар һәм карлар – барысы да тышкы сәбәп белән булсалар да, Аллаһның ачуы галәмәте булуларын, шуннан артык көчле хәлләрнең тууын ихтимал тотып, курку, Аллаһка кайту, тәүбә һәм ялваруга керешү тиешле. Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) иң баһадир һәм йөрәкле адәм булса да, мондый хәлләр туганда курка икән. Мөбарәк йөзендә сарылык сизелер, хәлләренә һәм хәрәкәтенә дулкынлану килеп, тиз үк Аллаһка ялвара һәм намаз укый башлар икән.

## Суфьян бине Гуяйнә һәм шәкертләре

Ибне Хәлләкән Суфьян бине Гуяйнә тәрҗемәи хәлендә әйтә: «Араларында бик яшь Яхъя бине Әксәм булган хәлдә, шәкертләре хәдис ишетер өчен [аның] кәефсезрәк вакытында килгәч, Суфьян бине Гуяйнә күңел тарлыгы белән әйткән: «Минем бәхетсезлегем [шул ки,] Әбү Сәгыйдь әл-Худригә иптәш булган Дамра бине Сәгыйдь белән, Гобәйдулла бине Гомәргә иптәш булган Гамру бине Динар белән, Әнәс бине Мәликкә иптәш булган Зүһри белән сөйләшеп утырган идем. Инде сезнең белән утырам. Шәкертләре оялгач, Яхъя бине Әксәм: «Әй, Әбү Мөхәммәд, инсафлык кыл», – дигәч, [Суфьян:] «Иншалла», – дигән. Соңра Яхъя әйткән ки:

«Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) сәхабәләренең иярченнәре синең белән сөйләшеп утыруда, синең безнең белән сөйләшеп утыруыңа нисбәт белән артыграк булганнар. (Аларның сиңа нисбәт белән булган хөрмәтләре һәм бөеклекләре синең безгә нисбәт белән булган хөрмәтең һәм бөеклегеңнән артык иде).

Имам Суфьян[27] югалып калып, Әбү Нәвәснең бу бәетен укыган:

[...].

Яхъя бине Әксәмнең батырлыгыннан һәм тиз арада җавап бирүеннән, халык, югалып калып, таралган. Имам: «Бу бала солтаннар белән сөйләшеп утыруга яраклы булыр», – дигән. Чыннан да, габбасилардан Мәэмүнгә бик яраклы булып, аның казые булып, нигъмәтләренә чумып яшәгән.

## Нәзарәтнең мөрәҗәгатьнамәсе

Бөтен халыкка тарату өчен 4 сәфәр /17 октябрь тарихы белән тәфсилле бер мөрәҗәгатьнамә язып, Уфа типографиясенә бирелгән иде. Басу вәгъдәсе идарәсеннән алынса да, басмый кайтардылар. Соңра югарырак даирәгә дә тәкъдим итеп күрелде, файда булмады. Хөкүмәтнең үз эше күп, дип, рәсми кәгазебезне, рәсми язу белән кайтардылар. 6400 кадәр мәхәлләгә тарату тиеш булган, үткән Съездның гомуми иктисади эшләре бәян ителгән һәм һәркайсы мәхәлләләр өчен белеп торуы яхшы сүз иде. Эчтәлеге:

1. Дини вә әхлакый вәгазь, диндә ныклык, үзара мәрхәмәт һәм шәфкать, дин укыту өлкәсендә тырышлык, балаларны яхшы тәрбия һәм шуның кебек эшләр.

2. Имамнар белән халык арасының, ирләр белән хатыннар арасының күркәм рәвештә булуы, һәркайсы тиешле хокукны кайгыртуы һәм бер-берен ихтирам белән мөгамәлә итеп, татлы тормыш юлында булулары.

---

[27] Имам Суфьян бине Гуяйнә – олы хәдис белгечләреннән, имам Шафигый кебек имамнарның хәдис остазы. Мәккәдә [һиҗри] 198 елда 91 яшендә вафат булган. Галим, гыйбадәт кылучы, аскет, җитмеш мәртәбә хаҗ кылган. Егерме яше тулмас борын Күфәгә килгәч, имам Әбү Хәнифә: «Гамру бине Динар гыйлемен ятлаучы килде», – дип, аны файдаланырга [кирәк дип] иярченнәрен кисәткән. *Әбү Хәлләкәннән [алынды]*.

3. Имамнарның балаларны яхшы укытулары, ирләргә һәм хатыннарга яраклы рәвешчә яхшы вәгазь әйтүләре.

4. Съездның карары буенча Диния Нәзарәте вәкаләтенә тапшырылган чыгымнар бәяне:

а) Нәзарәтнең үзенә махсус еллык чыгым ун өч миллион ике йөз мең сум (канцелярия, матбага, утын, ут су, зур ремонт өчен 4050000 сум, әгъза һәм хезмәтчеләр өчен 9150000 сум);

ә) мөхтәсибләргә (85 зат) яшәү чыгымы елга тугыз миллион алты йөз мең сум;

б) дин хезмәтчеләре, дин укытучылары җитештерер өчен ир һәм кыз балаларга аерым-аерым вакытлы дәресханәгә дүрт миллион өч йөз илле мең сум;

в) ерак җирләргә командировкага вәгазьчеләр йөртергә бер миллион сум, барысы 28150000 сум;

г) мәхәлләдәге мәктәпләргә китап белән ярдәм өчен ике миллион сум;

д) мәхәлләләргә гаилә дәфтәрләре хәзерләү өчен өч миллион биш йөз мең сум;

е) вакытлы дини журнал нәшере өчен ике миллион сум;

ж) һәртөрле программалар, гадәттән тыш хәлләр өчен бер миллион сум, бөтенесе буладыр утыз алты миллион алты йөз илле мең сум.

5. Искә алынган чыгымнар өчен, Съездның карарынча, өметле керемнәр:

а) 1919 ел башланган ихтияри иганәне бирмәгән җирләрнең тутырып бетерелүе өмет ителәдер;

ә) һәр мәхәллә кимендә елга 5748 сум иганә итәр;

б) изге шәригатьчә булган никахтан соң никах бүләге буларак мәһернең сумына бер тиен кадәр иганә итәрләр;

в) боларның өстенә аерым зур шәһәрләрдән аеруча иганәләр өмет ителәдер;

г) искәртелгән иде ки, съезд вакытында Нәзарәт кассасында өч миллион дүрт йөз туксан ике мең өч йөз ундүрт сум акча калган иде, декабрь башынача җитәр-җитмәс микдарындадыр. Аллаһ тәгалә эшләрнең ахырын хәерле кылса иде. Вә Һувә хәсби вә нигъмәл-Вәкил (Ул [Аллаһ] миңа җитә һәм Ул – Иң яхшы вәкил).

## ГубЧКга чакыру

3 ноябрьдә көндезге сәгать унда ГубЧКдан (Губернский чрезвычайный комиссиядән) чакыру кәгазенә юлыктым. Шул көннең сәгать 13:00 дә Казанский урамындагы 7 нче номерлы йортка, 19 нчы бүлмәгә, 94 нче эш дип, мине чакырткан. Эш беленми, бу вакытларда шәһәрдә аптырау ишетелә, тикшерүләр, туктатулар, хәтта үтерүләр булгалап, күбәеп тора. Азрак аптырау хасил булды. Хөкүмәт идарәләре арасында иң куркынычлы идарә – бу Губернский ЧК идарәсе. Монархия вакытында жандармский полковник иң куркыныч тикшерүче, көчле идарә иде. Шул ни дәрәҗәдә көчлерәк иде, хәзер бу идарә. 1920 елның 8 мартында Бирски, Бәләбәй сәяси хәрәкәтләре вакытында гадәттән тыш хәлләр идарәсе булу сылтавы белән, дүртенче мәчет имамы мулла Һади бине мулла Фәхреддин өендә дүрт казый (Ризаэддин, Кәшшафеддин, Нурмөхәммәд, Гыйнаять) белән кунак булганда, җыелып җитү белән, дәһшәтле рәвештә латыш түрәләре килеп, тоткарладылар һәм шул ЧК йортына, идән астындагы иң кадерсез, тар, чиксез тыгыз бүлмәгә япканнар иде. Мине бер кичәдән, башкаларны өч атнадан бер айга кадәр төрмәдә тотып, чыгарганнар иде. Ул вакытта җитәрлек сорау алсалар да, янә шул мәсьәләне кузгатып, миннән сорау алырга дип, чакырган икән. Тормыш иптәшем Гайшә минем белән бергә барды, бүлмәсен эзләп таптык. Кечкенә генә бүлмәдә яшь кенә егет чакыручы икәне беленде. Тормыш иптәшем бүлмә ишегенә кадәр килсә дә: «Русча аз беләм, хатыным тәрҗемә [итәр] өчен хәҗәт», – дисәм дә, кабул итмәде. Ахырда кайбер җөмләләрдә буталу булганлыктан, [хатыныма] керергә рөхсәт ителде. Сораган маддәләре – үткән марттагы вакыйгалар һәм сораулар. Башта гомуми сорау алуларда яшь, гаилә, кәсеп, сыйныф, тормыш рәвеше, кайда уку сорауларын тәмамлагач, мондый рәвештә сорады:

– Военное положение вакытында рөхсәтсез Фәхреддин йортында киңәш мәҗлесе төзегәнсез, шул турыда үзеңне гаепле дип беләсеңме?

– Хәер, гаепле [дип] белмим. Мәҗлес киңәш мәҗлесе түгел иде, фәкать дини бер дога мәҗлесе иде. Һичтөрле киңәш булганы юк. Бары бер ваемсызлыгым булган – мине чакырганда, гадәттән тыш хәлләр идарәсе булу мөнәсәбәте белән, хөкүмәт идарәсеннән рөхсәт алуын сорамаганмын. Мөселманнарда дога мәҗлесе күп була, ул мәҗлестә бер дә андый-мондый сәяси сүзләр булмаганлык-

тан, хөкүмәт идарәләре дә һәр җирдә моны белгәнлектән, һичвакытта бу көнгәчә бәхәс һәм каршылык булмаганлыктан, бу сорау хәтеремә килмәгән.

– Мәмлиев бар идеме?

– Бар иде.

– Ни сөйләде, чиркәүне хөкүмәттән аерылуы турында сөйләмәдеме?

– Сөйләмәде. Минем баруым да соң гына булды, хатыннарыбыз белән барган идек. Берәр хатынның килүен көтеп, дога һәм аш башларга гына торганда тоткарландык.

– Башка вакытта Мәмлиевтән ни булса да ишетмәдеңме?

– Ишетмәдем, сәясәттән сүз сөйли торган кеше дип белмим.

– Сиңа дошман түгелме?

– Юк, дошманлыгын бер дә белмим.

– Мәмлиевне Мәскәү съездында ник казый итеп сайламаганнар?

– Ачык белмим, мин съездда булмадым. Шулкадәр бар ки, сайланган адәмнәр элек тә аз-маз яхшырту һәм баш күтәрү тарафында, кызыллык белән танылган адәмнәр булган, элекке казыйлар хезмәттә битараф торган кешеләр иде.

– Элек (мартта) «аны баш күтәрү тарафлы түгел» дип җавап биргәнсең.

– Элек әйткән җавабым: баш күтәрүгә катышмаган, битараф кеше дидем.

Искәрмә: бу урында элекке сорау алучы, Мәмлиев фатирында торганлыктан, araларында кайбер каршылыклар, үпкәләр булдымы – ни сәбәптәндер, Мәмлиев турысында, гаепсез булса да, гаеп табарга тырышкан кебек тоелды. Минем сүземне дә, үз максатларында кулланып, язган. Аның хакында сорау алучының: «Иске фикерле (старый режим)», – диюенә каршы мин: «Асылы – тәрәккыйпәрвәр, учитель булган кеше, иске фикерле адәм түгел», – дисәм дә, аны кагәзенә язмаган. Мәмлиевтән җавап алганда, үзен әрчер өчен: «Мөфти синең хакында «иске фикерле кеше» диде, шул сәбәпле, эшең артык сузылды», – дип, араны бозарлык сүзләр әйткән иде.

Фәхреддиновта нинди мәҗлес булганын кабат сораганда, әүвәлгечә әйттем: «Бер дога мәҗлесе иде, үлгән анасы өченме, туган көне идеме, догадан элек чыгарылуыбыз сәбәпле, ачык күңелемдә калмаган», – дигәч, «Дога мәҗлесе генә булгач, ни өчен булган, дога булса да, әһәмияте анда түгел», – дип сүзне тәмамлады.

Язып, миннән имза куйдырды. Хәзерге хәл өчен бер дәрәҗәдә тынычланып кайттык. Ләкин ахыры Аллаһның рәхимлегенә һәм юмартлыгына бәйле. Аллаһ хәерлегә әйләндерсә иде.

## Мирас бүлүдә Нәзарәт кәгазе

Уфа мәмләкәтенең юстиция министрлыгыннан мөселманнарның шәригатькә туры китереп мирас малын бүлүләренә каршы Диния нәзарәтенә түбәндәге эчтәлектә мондый язу килде:

«Мөселманнар торган районлагы халык судларының белдерүенчә, гаиләдәге бүленүләр һәм мирас хокукларын билгеләүләрне мөселманнар муллалар ярдәме белән шәригатьчә эшләүдә дәвам иткәннәре күренә. Бу мөнәсәбәт белән Губернский юстиция бүлеге бөтен гражданнарның, милләтләрнең төрлелегенә карамый, милек һәм гаилә хокуклары фәкать Үзәк совет идарәсе тарафыннан бирелгән декретлар белән генә ныгытылганлыгын һәм дә, ни шәригать, ни җирле гореф-гадәтләрнең милек хокукы даирәсендәге мөгамәләләрдә кулланырга көчләре юклыгы хакында аңлатуны тиешле таба. Муллаларның, гомумән, руханиларның бу эшләргә катышырга бер хаклары да юк. Шуның өчен аларның һәрбер катышырга теләүләре җирле идарә мәхкәмәләре тарафыннан каты рәвештә туктатылырга тиешле».

Асыл нөсхәдә имза куйганнар: Юстиция губотделының мөдире Налидов, гомуми подотделның мөдире өчен Черепанов, секретарь Миронов дөресләде, секретарь ярдәмчесе, имза. Асыл нөсхәгә яраклы милләтләр Губотделының секретаре имза.

Моңа каршы Диния нәзарәтендә төзәтү мөшкел булганлыктан, хәзергә ишетелеп хаҗәт вакытында мөмкинлегенә күрә хәл ителер өчен калдырылды. Бәла килгәндә әйтелә торган аять: «Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун» (Без Аллаһыныкы һәм Аңа кайтачакбыз) – укылачак мәсьәлә.

## Нәзарәтнең архивын алулары

5 ноябрьдә Губерна регистрация рәислегеннән Нәзарәтнең архив ишегенә архивны (бинасын) әлеге идарә алганлыгын, башкаларның рөхсәтсез керергә хакы юклыгын аңлаткан кәгазь ябыштырдылар. Моның асылы: бөтен метрикаларга бәйле гомуми хәлләр (туу, вафат, никах, талак) хөкүмәт идарәсендә теркәлә. Боларда тер-

кәлгәннән соң гына имамнар гаилә дәфтәренә теркиләр. Бу гомуми регистрацияләре һәр җирдә гамәлгә куелган. Уфа шәһәренең мөселманнар эшенә көчләп кереп, безнең Нәзарәт бинасында бер бүлмәне алып, җиде-сигез ай кадәр торганнар иде. Үткән октябрьдә чыктылар. «Яңа казыйлар өчен бүлмә кирәк, бина бөтенләй үзебезгә тапшырылды, бүлмәне бушатыгыз» дигән язу бирелгән иде. Шул сәбәп булдымы яки эшләре азлыктан аерым чыгымнар тотмас өчен руслар белән бер җирдә эш күрергә булдылармы? Ләкин безнең бинада торган вакытта ук Нәзарәтнең архивчысы Арслан Еникеевны үзләренә архив хезмәткәре итеп куйганнар иде. Аңа күптән түгел генә «Архивка башканы кертмә» дигән язу биргәннәр иде. Нәзарәтнең архивта ничә яктан ихтыяҗлы һәм зарури эшләре булса да, бу арада туктап тора. Октябрьдә бу турыда Исполкомга гариза тәкъдим ителсә дә, һаман җавап ала алмыйбыз. Ахыры ни булып калыр? Бу тапкырда 6 ноябрьдә жилищный отделга гариза җибәрелде, «Безнең архив бинасы буш бина түгел, сезнең ордер бирүегез тиешле түгел» дигән эчтәлектә язылды, ни мөгамәлә итәрләр?

Бу көннәрдә Нәзарәт урамында өч-дүрт йортта тикшерү булачак икән, дигән хәбәр ишетелеп тора. Шул исәптән Нәзарәт бинасында да булачак икән. Була калса, байтак борчулы эш, каты мөгамәлә, рәсми һәм рәсми булмаган конфискацияләре була, булмаса да, борчуы һәм һөҗүме авыр, Аллаһ үзе сакласа иде.

Бәлки донослар була торгандыр. Юкса сәүдә һәм сәясәт белән шөгыльләнмәгән идарәдә тикшерүләр булмаска тиеш иде.

## Остаз, ата, каенаталарны һәм хатынның ирен исеме белән атавы хакында искәрмә

Бүген 6 ноябрьдә Йосыф хаҗи бине Әмин Диберди белән озак чәй мәҗлесебез булып, кайбер кызык хәлләр сөйләнеп узды. Кайбер олыларның, бигрәк тә каената, каенананың исемнәрен атамау, шул исемдәге кешегә башка бер исем белән генә мөрәҗәгать итү гадәтләре искә алынды. Борынгы карчыклар бу мәсьәләгә бик әһәмият биргәннәр. Йосыф әфәнденең каенагасы Рәхмәтулла исемле булган. Бер карчыкның намаз сәламен сөйләде. Шулай ки, карчык намаз сәламендә: «Әс-сәламү галәйкүм, каенага, әссәламү галәйкүм, каенага», – дип сәлам бирә икән. Тирә-янындагы азрак укымышлы гаилә балалары: «Бу ярамый, «әс-сәламү галәйкүм вә рахмәтуллаһ»

дияргә кирәк, намазыңны бозасың», – дисәләр дә, һич кабул итмәс икән. «Каенагамның исемен атамыйм», – дияр икән.

Янә үзе күргән-белгән, яхшы тәрбияле, укымышлы Диберди гаиләләрендә бүген дә бер карчыкның каенанасы исемен атамаганын сөйли. Шулай ки, каенанасы Зәгъфрән исемле икән. Кайбер хасталыкларда зәгъфрән белән табак язарга боерганда: «Сары кара белән халык яздыра торган рәвешчә язсыннар», – дип кенә, зәгъфрән сүзен теленә алмый икән. Бу гадәт надан суфиларда да күренә. Нигезсез мәхәббәт – мәхәббәттә чиктән ашу диярлек гадәт.

Шәех Зәйнулла хәзрәт Казанда бер мәҗлестә Камчылы ишан дип танылган Габдессаттар хаҗидан: «Хокандта шәехегез кем, ни исемле?» – дип сорагач, бик каушады: «Хәзрәт ишан вә фәлән, исемен телебезгә алып кимсетмибез», – дип, бөтен мәҗлес халкын туңдырырлык салкынлык күрстәкән иде. Бервакыт әлеге кешенең шәехеннән миңа әлеге хаҗины яклавым мөнәсәбәте белән рәхмәт әйтеп язган хаты ашамы белгәнемә күрә, дамелла Ташмөхәммәд дип шәех Зәйнулла хәзрәтләренә әйттем. Шәех дамелла Ташмөхәммәд мөдәррисләрдән булып, Ташкенттан шәех Мәҗзүб, шәех Әхмәд, мәхдүм Караташ хәзрәтләренә ияреп, тарикать таратып, байтак күп кешене файдаландырды, дип ишетелә иде. Язуы күркәм, тәртип һәм иншасы яхшы, гыйлемле иде. Рахимәһүллаһ (Аллаһ рәхим кылсын).

Исемне искә алмау безнең төрки халыкта һәр ыругда бар. Казан халкында да бик таралган. Хатыннар мотлак каената вә каенана исемнәрен искә алмаслар. Нинди зарурлык булса да, символ һәм ишарә белән чикләнәләр. Безнең Болгар төркиләрендә электән бирле калган гадәт шул. Якын күрелгән олыларның исемнәренә яраклы исемле кешене адаш абзый дип атыйлар. Бер балага бер исем әйтелсә: «Юк хәзрәт, минем бабам яки әби шул исемле, ярамый», – дип, хәтта башка түбәнрәк якыннарына яраклы булса да, инкяр итәләр. Бездә бу бер наданлык гадәте, аны алмаштыру һәм ул гадәтне ташлату тиешле.

«Ихтирамлы олы кешегә, бала ата-анасына, хатын иренә, шәкерт остазына мөрәҗәгать итеп, исеме белән эндәшмәсен, әй, фәлән, дип исеме белән кычкырмасын», – дигән сүзләр әдәп бүлегенә керә, әхлак китапларында искә алына. Ләкин хаҗәт вакытта артында сөйләгәндә дә, аның исемен әйтмәү, исемдәшләренә дә исемен әйтмичә, адаш дип үз алдына тагын бер исем тагу әдәп китабына, әхлак бүлегенә кергән нәрсә түгел, ә сөннәт һәм пәйгамбәр тормышына каршы булган салкын һәм чиктән чыккан бер йөкләмә.

Моның каршысында хәзерге яшьләр арасында бер кимчелек гадәте таралып бара. Хатыннар ирләренә мөрәҗәгать иткән вакытта да исем белән атыйлар. Менә бу рәвеш тиешле түгел, ислам әдәпләренә каршы килә. Яшь егетләр рус тормышына авышып, күбрәк әдәпне дә шул рус тормышыннан гыйбарәт [дип] белеп, шул юлны күргәннәр. Хатыннарга иркенлек бирәбез, кадер-хөрмәт итәбез, дигән булып, һәр эштә шәригать үлчәвенә карамыйча, кайберләре артыклык кылып һәм чиктән чыгып, шәригатьне үзенә буйсындырырга маташудан, хатын-кыз галәменә тулы хыянәт итәләр, аларның оят һәм әдәпләренә җинаять кылалар. Аларның күбекләре сыегаймаслык рәвешчә кызыктырып, мөгамәләдә булалар, бу күз алдыбызда күренеп торган хәл.

## Исем кушу рәвешләре хакында искәрмә

Бү көннәрдә исем кушу мәҗлесендә туган кыз баланы өстәл өстенә алдыма китереп куйгач «Нинди исем телисез», – дидем. Атасы: «Флория», –диде. Ошатмавымны күрсәттем. Яшьләрдән чит һәм мәгънәсез исемнәргә кызыгучылардан кайберләре [шуларга] мөрәҗәгать итәргә булдылар. «Төрекләрдә бар, бер чәчәк исеме икән вә фәлән», – диделәр. «Элек хатын-кызлар йөзләренә сирәк кисея ябып, исемен «флёр» дияләр иде, кеше исеменә яраклы түгел», – дидем. Берсе: «Алайса, хиҗапка юрап булса да, ярамасмы?» – диде. Әйттем: «Бик зәгыйф, чыдамсыз нәрсә, яхшы юрау юк», – дигәч, атасы анасы янына чыгып, Фәһимә исеменә ризалык алып керде. Бу исемне яратып, утырган җиремдә уң колагына (чыннан да колагына) азан, сул колагына камәт укып: «Рабби инни сәммәйтүһә Фәһимә вә инни үгыйзүһә бикә вә зүрриятәһә минәш-шәйтанир-раҗим» («Раббым, мин аны Фәһимә дип атадым һәм аны да, аның нәселен дә ләгънәт кылынган шайтаннан сиңа сыендырам»), – дип әйттем. Фәһимә исемле булды дип шунда булучыларга игълан иттем. «Аллаһүммә әнбитһә нәбәтән хәсәнә» («Йә, Аллаһ, аны яхшы итеп үстер») күркәм җөмлә белән дога, һәм тәүфыйклы, бәхетле, гомерле булсын [дигән] эчтәлекле сүзләр белән тәмамладым. Бу исем кушуда гадәти булмаган берничә маддә бар:

1. Сабыйның якыннары әйткән һәрбер исемне кушмау, бу эш – әлбәттә, галимнәрнең вазыйфасы. Халык, ят исем булсын, кызыклы исем булсын кебек, тиешсез юллар белән әсәрләнгән һәм сөннәт булган исемнәрдән ераклашалар, хәтта мәҗүсиләр исемнәренә

кызыгалар. Электән калган Шәйхелислам, Фәхрелислам, Хәернас, Имамагзам, Галләмәитафтазани, Сорургаләм, Маһисорур, Фәхригаләм, Галимәтелбанат кебек шәригать буенча үзгәртелүе мәҗбүри булган арттырылган, олуг мактаулы исемнәр белән атыйлар. Мондый мәсьәләләрне имамнар яхшы белергә тиеш һәм яхшы белгәннәре ялагайланмыйча халыкка аңлатырга тиеш. Мактауны аңлаткан исемне Рәсүлүллаһның (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) үзгәртүе хәдис китапларында искә алына.

Бу мәҗлестә казый Ризаэддин әфәнде баштан үткән бер вакыйганы сөйләде: кечкенә энеләренә Салих исемен биргәннән соң, еракта калган карендәшләре: «Карт исем, күңелсез исем куйганнар», – дип, аталарына йомшак кына каршылык та белдерткәннәр. Соңра шул исем халык тарафыннан яхшы күрелеп, авылларында таралып киткән.

2. Баланы исем кушучы алдына куеп, ике колагына азан һәм камәт укылу. Бу мәсьәләнең асылы – туган баланың туган вакытында колагына азан-камәт укылу тиешлеге. Исем кушу шартларыннан түгел. Туганнан соң азан-камәт укылмый калуы ихтимал булганга, тәэмин ителә. Укылган булса да, янә баланың колагына Аллаһны мактау сүзләре ишеттерү ярамаган эш түгел, шунлыктан һәр мәмләкәттә бу эш таралган.

3. Бу азан-камәт чынлыкта ни рәвешле баланың колагына әйтү тиеш? Гореф-гадәттә таралган булган рәвешчә, бала җирдә, исем кушучы аягүрә баланың уң һәм сул тарафына борылып кына укылса, бала колагына, дип әйтү – ерак нәрсә, бик кыланышлы мөрәҗәгать итү. Сөннәттә бер күчерелгән рәвеш нык булмаганлыктан, хакыйкать белән гамәлдән тыючы нәрсә юк. Бохарада олы остазлардан казый дамелла Габдешшәкүр хәзрәтләренең утырган җирендә баланы алдына алып исем биргәнен күргән идем. Мәдинә галиме сәед Гали бине Заһир әл-Витри хәзрәтләре дә Казанда алдына куелган балага утырган җирендә генә колакларына азан һәм камәт укып исем кушкан иде. Бер рәвеш сөннәт китапларында ачык күренмәгәнлектән, һәркайсы рәвешне дә бидгать вә фәлән дип юкка чыгарылмаса, әлеге рәвешне яхшырак һәм дөреслеккә якынрак дип күрәбез. Таралган рәвеш белән исем кушудан сакланабыз.

4. Исем кушу гыйбарәсендә һәркем бер җөмлә уйлап яки сайлап алган. Минем иптәш муллам Йосыф ахун Сәгыйдь аяк өстендә азан-камәтне тәмамлагач, баланың йөзен ачып «Сәммәйнә бифәлән» («Фәлән исем куштык, тәүфыйклы, бәхетле, гомерле бул-

сын»), – дия иде. Дога кылган сүзләре дөнья һәм ахирәт файдаларын җыйган күркәм җөмлә булганга, югарыда әйткәнемчә, ул кадәрлене мин дә кабул иттем. Бохарада вакытымда Коръән укыган вакытымда хәзрәти Мәрьям (Аллаһ аннан риза булсын) исем биргәндәге аятьне укыгач, күчереп алу өчен яравы йөрәгемдә урнашкан иде. исем кушу хезмәте ирешкәч, шулай башлыйсы идем. Соңра шәех Шиһабеддин Мәрҗани исем кушуына очрап, искә алынган аятьне кулланып, исем кушканда, шулай яхшы туры килүгә Аллаһка мактау булсын, дип шөкер иттем.

## Минзәлә мулласы Шаммазовларның съезды

6 ноябрьдә Минзәлә мулласы Бинеямин Шаммазовтан Нәзарәт исеменә рәсми язу алынды. Язуның эчтәлеге: Минзәләдә быел декабрьдә коммунистлар катыш голяма шурасы дип аталган бер съезд (4 нче съездлары) төзергә булганнар. Шул съездга Диния нәзарәтеннән бер вәкил чакыра. Вакытлы рәис Шаммаз дип имза куйган. Бу фирка һәркемгә әхлагы һәм тормышы белән мәгълүм Шакирҗан Хәмиди йогынтысы астында элек Бубида, икенчесе Сарапулда, өченчесе 1920 елның июлендә Минзәләдә төзелгәннәр иде. Максатлары – коммунистлар белән оешып, аларның тәэсирләре астында бертөрле уңайлык юнәтү, дини укуларны вә хөкемнәрне (исемен) үткәрү икән.

Беренче һәм икенче съездларында ук Диния нәзарәтенә караш мәсьәләсен бер маддә [итеп] хисаплап, башта бер дәрәҗәдә таләп итү һәм әрләү белән үткәреп, икенчесендә Диния нәзарәтенә, аеруча мөфтигә нәфрәт игълан иткәннәр иде. Нәфрәт иглан итүләре хөкүмәт газеталарында игълан ителгән иде.

Шакирҗан Хәмидинең ничектер Диния нәзарәтендә имамлык эше кичегүен мөфтидән күреп, шәхси үпкәсен һәм нәфрәтен белдереп килә иде. Элек монархиягә якынаю юлларын күзәтеп йөрсә дә, бу соңгы елларда Шура хөкүмәтенә бер төр якынаюны мәсләк [итеп] тотып һәм шуңа таянып, юашрак кешеләр арасында йогынты күрсәтеп йөри. Ләкин тиз белерләр, хәл һәм табигате Кур-батырның: «Барырымны ел белер, кунарымны сай белер» дигәне кебек.

Бу эштә (бу съездка катышу турында) искәрмә маддәләре:

1. Үзәк тарафыннан Диния нәзарәтенә сәясәткә катышмау шарты белән дәвам итәргә мөмкинлек бирелде. 1918 елның апрель аенда төрле милләтләр идарәсе рәисе Сталинның 165 нче номерлы

телеграммасы белән һәм бу 1920 елның 21 августында шул ук идарәнең 211 нче кәгазе белән шул ук эш аңлатылды һәм расланды. Шунлыктан бу сәясәт катыш съездга Диния нәзарәте катышырга тиешле булмый.

2. Муллаларның мондый сәясәт катыш съезд ясап йөрүләре тиешлеме, юкмы – бер теоретик мәсьәлә. Диния нәзарәтенә сәясәткә катышмау шарт ителгән икән, аның карамагында булган имамнарның да барчасы бу шарт астында гына яшәргә тиешле. Нәзарәт боларга бу эштә үзенең мәсләген яхшы аңлатырга бурычлы.

3. Муллаларның мондый съезд ясап йөрүләрендә ни файда бар? Безнең карашыбызча, Шура хөкүмәте мондый кечкенә съездларның, гади муллаларның ярдәмнәренә мохтаҗ түгел һәм боларның мондый хәрәкәтләреннән хөкүмәткә игътибар итәрлек файда да туачак түгел, бәлки коммунистлыкка бер төр әдәпкә чакыру һәм йөкләү дип карап, халыкның рухын кузгату гына булачак. Җирле Шура идарәләре дә бу турыда җитди карый алмаганлыкка охшыйлар. Арада йөргән муллалар үзләренә өлешчә файда булуын уйлап, ахырына карамыйча, хәрәкәт итәләр кебек тоела. Шура хөкүмәте өчен иң файдалы рәвеш – мондый чакыру һәм йөкләүне тыйдыручы хәрәкәтләрдән ваз кичеп, халык өркердәй кагыйдәләрдә бер дәрәҗәдә җиңеллек күрсәтеп, халыкны үзенә иярәштерү. Шуннан башкасы халыкның нәфрәтен тудырачак.

## Намаз укыганда игътибар ителгән сөннәтләр

Байтак еллардан бирле «Фатиха» белән сүрә арасында «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип укуны гадәт иткәнмен. Коръәннең тышкы ягына карау шуны сорый. Хәнәфиләр каршында, сурәдән бер өлеш булмаса да, бисмилланың, нигездә, Коръәннән булуы таныла, сүрәләр арасындагы язылышы бүлү өчен дисәләр дә, тышкы хәлгә карап, укуда зыян күрмим, бәлки яхшы күрәм. Коръәндә языла торып, асылы Коръәннән икәненә иҗмаг [өммәтнең бердәм фикере] була торып, калдырып китү нәфрәт төсен алган кебек тоела. «Һидая» авторы яшерен укуны яхшы дип үтә. Тахтави «Дөрре мохтар» хашиясендә «Бисмилләһ» шәрехендә әйтүе мөстәхәб (күркәм) булган урыннардан санап үтә. Әбү Хәнифә каршында яхшы – Ибне Һөмам белән шәкерте Хәләбинең шуны өстен иткәнен бәян итәләр. Ахырда «Бәхрер-раик»тан бердәм рәвештә мәкрүһ түгел дип тә куелган. Мин, кешене өндәмәсәм дә,

бу эшкә дәвамлык кылам. Ишеткән кешеләр сорасалар, мәсьәләсен әйтәм.

Бер заман янымда ияреп укыган бер кеше: «Бу намазда синнән дүрт ят нәрсә сиздем: 1) имам басып Коръән укыганда оеп, «Сәнә» укымадың, икенче рәкәгатькә баскач, имам Коръән укырга керешкәнче укыдың; 2) яшерен укылган рәкәгатьтә имам артында «Фатиха» сүрәсен укыдың; 3) Сөннәттә булса кирәк, «Фатиха» белән сүрә арасында «Бисмилләһ» әйттең; 4) соңга калгач, имам сәламен көткәндә, салават укыдың», – дип сораган иде.

Соравы гыйлем алу максаты белән булганга, махсус шулай укыганымны, шулай тиеш санаганымны аңлатып җавап бирдем.

Боларның тиешлеге байтак эзләнү һәм төпченүдән соң үз канәгатьлегем буенча. «Сәнә» мәсьәләсендә, хәнәфи китапларында көчле риваятькә күрә, имам кычкырып укыган намазга ирешсә, «Сәнә» укымас, яшерен намазда укыр. Соңга калган кеше имамга ияргән чакта укымаган булса, намазның калган өлешен казага керешкәндә «сәнә» укыр, соңра «әгүзү-бисмилләһ» белән Коръән укыр, дигәннәр. Минем эшләвемчә, имам белән укый башлаган кеше беренче рәкәгатьтә укымый калганда, икенче рәкәгатьтә имам Коръән укырга керешкәнче уку риваяте хәтеремдә ачык булмаса да, укуны өстенрәк күрәм. Сөннәт буенча укылырга тиешле урында гозер белән укылмый калганны икенче рәкәгатьтә имамның укуыннан элегрәк укуда начарлык күрмим. Соңга калган элек укыган булмаса, калганын казага керешкәч укыр, дигәннәр.

Имам артыннан «Фатиха» уку – күп мөҗтәһид һәм хәдис белгечләре тарафыннан тикшерелгән, тиеш икәне анықланган мәсьәлә. Хәнәфиләрдән дә хәдискә әһлият бирүчеләрдән байтак кешеләр укуны ихтыяр иткәннәр. Бохариның «Хайрел-кәлам фил-кыйраәти хәлфәл-имам» китабы – бу мәсьәләдә җитәрлек китап.

Соңга калган кешенең, имам сәлам биргәнне көткәндә, салават укуы да яхшырак күренә. Хәер, хәнәфи галимнәре шәһадәт кәлимәсен кабатлар яки, «әттәхият»не акрын укып, имамның сәламенә туры китереп бушар, дигәннәр. Боларның бу икегә бүлүләре: «Беренче әттәхияттә утырганда, салават уку сәбәпле, өченче рәкәгатькә басу кичегә, кичектерелгән рөкен була», – дип әйтүләренә күрә, беренче әттәхияттә салават укудан качып өйрәнүләреннән булса кирәк.

Хәер, хәтеремдә кайберләренең «Яки салават укыр» дигәне дә бар. Кайсы китаптан икәнен хәтерли алмыйм. Мин үзем ул

мәсьәләдә бераз урталыкта булам. «Аллаһуммә салли галә Мөхәммәд» микъдарында салават укыйм, бер урында Рәсүлүллаһ исеме искә алынып та, салават укымыйча калдыруны яраклы дип күрмим. Кайбер хәнәфиләрдән дә бу кадәрне укырга рөхсәт бар. Булса, булмаса – мин кыскача уку тарафында. Шунлыктан соңга калган вакытта, имам сәламен көткәндә, рәхәтләнеп укыймын. «Шәрех төхфәтел-мөлек» китабында өч ихтималны искә алгач, салават укуны беренчерәк күрә, намаз тик тору урыны түгел дип тә, кабат әттәхиятне дә дөрес күрми.

## Кайгылы вакыйга

9 ноябрьдә сишәмбе көн иртән борынгы бай гаиләдән хаҗи Хәмзә бине Тимербулат бине Хурамша Акчуринның гәүдәсе Уфаның Малый Казан һәм Аксак урамнары чатында табылып, полиция идарәсенә китерелгән. Төнлә театрда булып, кайбер дуслары белән аннан чыкса да, юлда бүленеп калган, соңра нинди вакыйга булуы беленми тора. Бүген (10 ноябрьдә) рәсми тикшерү һәм сорау алулар булачак.

Егет 24 яшьтә, аклар тарафыннан гаскәри хезмәткә алынып, ахырдан Уфага кайткан иде. Акларның гаскәри идарәләреннән, аеруча Колчакның мөселманнарга карашыннан риза түгел иде. Уртача төрки һәм рус [телләрен] белә, соңгы елларда университетка кергән иде. Кешелекле егет иде, Аллаһ ярлыкасын. Анасы Зөһрә ханым тарафыннан хатыным Гайшәгә карендәш. Пәнҗешәмбе көн икенде вакытында, җеназасы минем имамлыгымда үтәлеп, җирләнде. Шәһит хөкемендә [дип] игътибар ителеп, госел алынмады. Юылмавы «Һидая» китабының: «Вә мән вүҗидә катилән фил-мисъри гусилә иллә изә гулимә әннәһу кутилә би-хәдидәтин зулмә» («Шәһәр эчендә үле килеш табылса, тимер белән золымлык кылып, үтерелгәне беленгән очрактан тыш, госел кылыныр»), – дигән риваятенә нигезләнде. Мескенне ярдылар, карадылар. Артыннан атканнар, бик якыннан булмаганга, пуля күкрәгеен тишсә дә, күлмәк эчендә калган. Золымлык белән үтерелүе беленсә дә, тәфсилле рәвеше беленеп җиткәне юк. Хәзер һаман сорашу һәм тикшерү дәвам итә. Хөкүмәт җитдилек белән, чынлап тикшерсә, беленердәй галәмәтләр бар икән. Аллаһ ахырын хәерле кылса иде!

## Борынгы галимнәрнең акыл һәм шәригать гыйлемнәренә мөнәсәбәтләре һәм акыл гыйлемнәренең файдасы хакында

Бер караш: борынгы галимнәрдән хикмәт фәннәре белән мәшһүр булган затларны күп кешеләр, фәкать фән галиме, акылга нигезләнгән гыйлемнәр иясе, дини гыйлемнәрдән, бигрәк тә, Коръән һәм хәдис гыйлемнәреннән хәбәрсез һәм өлешсез, дип уйлыйлар. Бер мөнәсәбәт белән кайбер дустыбызга: «Мулла Җәлал Дүвани «Сахих Бохари» укыган, «Нәмүзәҗел-голүм» китабында сәнәдләрен искә алган, болар акыл фәннәре белән шөһрәт тапкан булсалар да, хәдис гыйлемнәренә дә әһәмият биргәннәр. Бу гыйлемнәрне ысуллы рәвештә алганнар», – дигән идем, бер дә хушланмады: «Мәхәббәтем юк», – дип, гомерен югалткан кешеләрдән санаганын аңлатып, начар кабул итте. Байтак кешеләрнең бу ышануда булуы мөмкин. Акыл фәннәрендә әсәрләре булса да, Коръән белән хәдис гыйлемнәрендә китап язмаганнар яки китаплары мәйданга чыкмый калган. Кайбер кешеләрнең ялгыш фикеренә күрә, хикмәт фәннәрендәге шөһрәтлек дин гыйлеменең зәгыйфлегенә дәлил [булып] күренә. Бу да – бер ялгыш, мантыйксыз хөкем.

Хакыйкатьтә исә, акыл гыйлемнәре һәм хикмәт фәннәре дә куәте, осталыгы һәм дөрес куллана белүе булган кеше фикерләү көче урталыкта һәм акыл көче саф һәм яхшы куллана белүче булганга, дини гыйлемнәргә караса, башкаларга караганда, яхшырак һәм артыграк аңласа кирәк. Тәнкыйть сәләте көчәйтелгән булганга җәрех-тәгъдил [хәдис күчерүчеләргә начар яки яхшы дип бәя бирү], тикшерү, анализлау гаделрәк булса кирәк. Мәсәлән, Ибне Һөмам кебек акыл фәннәрен тикшерүченең хәдис аңлаудагы карашы ни дәрәҗәдә бөек икәнен «Фәтхел-кадыйр» китабын укыган кеше яхшы белә. Безнең заманыбызда һәм бераз элекгрәк булган Болгар илебез галимнәре Әбен-Насыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани акыл фәннәрен яхшы һәм сыйфатлы белүләре белән дини гыйлемнәргә яхшы аңлаучан карашлы, дөрес тәнкыйтьле һәм яхшы дөреслеккә ирешүче булып мәйданга чыктылар.

[Һиҗри] 1314 елларда «Мәсабих»тән бер борынгы нөсхә артында беренче галим исеме белән танылган Котб Ширазинең бөтен «Җәмигыль-усул фи әхадисер-расүл» китабын янында укыган бер олы имам улы булган шәкертенә [һиҗри] 759 елда ураза гаете кичәсендә Тәбриз мәчетендә язган иҗазәтнамәсеннән [һиҗри] 777

елда язылган бер нөсхә күреп, күчергән идем. Иҗазәтнамәсендә шәех Садреддин Кунәви хәзрәтләре янында әлеге китапны башыннан ахырына кадәр укыганын язган. Бу шәех Шәрәфеддин Ягъкуб бине Мөхәммәд әл-Мәусыйли аркылы автор Мәҗдеддин Әбүс-Сәгадәт бине әл-Әсир әл-Мәусыйлидән күчергән.

Бу көннәрдә Гариф Җами мәүляна Габдрахман хәзрәтләренең шәехләр дәрәҗәләре һәм изгеләр өстенлекләре турындагы матур әсәре булган «Нәфәхател-инс мин хадаратил-Кодс» дигән китабында шәех Садреддин Кунәви биографиясендә күрдем, әйткән: «[...]».

Котб Ширази хәзрәтләренең өстән генә караганда «дини гыйлемнәргә гомерендә һич өлеш бирмәгән» диярлек дәрәҗәдә фәнни әсәрләре күп һәм, чынлыкта, хәдискә никадәр хезмәт иткән. Бөтен «Көтебе ситтә»не («Җәмигыль-усул»ны) үзе язып, тарикать әһелләре шәехләреннән тәмам укып һәм аны шәкертләренә тәмам укыткан. Аллаһ аны рәхим кылсын һәм Аллаһ аңа гыйлеме һәм галимнәр исеменнән хәерле бүләк бирсен! Шулай башка ислам галимнәре, хәкимнәре хакында да дини гыйлемнәре ягыннан яхшы уйларга тиешле.

* * *

Эстәрлетамак өлкәсендәге Эстәрлебаш дигән мәшһүр авылның халкы бу законсыз хөрриятгән файдаланып, берьюлы ике мәчет торгызып, авылларын өчкә бүлгәннәр. Салынган мәчетләренә рәсми рөхсәт алу өчен, мөхтәсиб раслаган хәлдә, приговорларын Диния нәзарәтенә тәкъдим иткәндә, мәчетләрен танып, ләкин җомганы фәкать элекке зур мәчетләрендә сөннәткә, шәригатькә һәм дин фәлсәфәсенә туры килгәнрәк күреп, яңа мәчетләрен фәкать биш вакытлы итү фикерендә булдым. Чөнки борынгы мәчетләре бик зур, бөтен авыл халкы өстенә биш алты йөз шәкерт булган заманнарда да барчасын сыйдыра иде. «Авыл эчендә елга, су кебек нәрсәләр дә юк, зарурлыксыз җомга арттырмыйк, фәтвагә караганда, берничә җомга дөрес булса да, каршылыклы мәсьәлә булганга, гозерсез һәм зарурлыксыз җомга аттырмау яхшырак», – дисәм дә, казыйлар кабул итмәделәр. Һәркайсын җамигъ мәчет итүдә казый Ризаның үҗәтлеге булып, башкалар аның белән ризалаштылар. Мин ялгыз аерым фикердә калдым. Мөфти бер тараф, барча казый бер тараф булып, фикердә аерылышуның беренче очрагы. Соңра бу хәлне

рәсми дәфтәргә кертер өчен, бу карамалының нөсхәсен мәҗлескә тапшырдым[28].

## Муллаларның Нәзарәткә мөрәҗәгате

15 ноябрьдә Бирски имамнарыннан Диния нәзарәтенә 14 ноябрьдә язылган нөсхәне алдым. Бирски ягында Калмык волосте, Кызылъяр волосте, Борай волосте, Мәскәү волостендә беркадәр имамнарны тотып, Уфа ГубЧКсына китергәннәр. Гөнаһларын үзләре белмиләр. Хат китергән кешене кыстагач кына, театрга балаларны җибәрмәү турында икән, дип аңлаткан иде. Гади халыктан да иптәшләре бар, хәтта күп икән, дигән. Хатта 1) икенче як мөхтәсибе Шәехгаттар Имәкәев, 2) Кәнгилдедән Әхмәдфәиз Камалетдинов, 3) Сыйласад имамы Миңлетаһир Муллаяр улы, 4) Булаҗ авылыннан имам Мөхәммәдҗан бине Мөхәммәдшакир, 5) Ишбулдының Әхмәтсафа Рәемиев, 6) Әче Елгадан Васфымөхәммәд Фәтхеддинов, 7) Кызылъярдан Мөхәммәдгата Шаһбиков, 8) Борайдан Әхмәднәби Мортаза, 9) Мәскәү авылының Сәлимҗан Гыйльван улы имзалары бар. Котылулары өчен Диния нәзарәтеннән ярдәм көтәләр. Эш рәвешләрен аңлагач, мөмкин булган хәрәкәтне кылырга тиешле булыр. Аллаһ Тәгалә хәерле ахыр бирсә иде!

## Мәүлиден-нәби (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) тарихы

Мәүлиден-нәби 12 рабигыль-әүвәлдә дип бөтен дөньяга билгеле, һәркем тарафыннан кабул ителеп, шуңа нигезләнеп, бәйрәм итәләр. Мәккә-Мәдинә, Мисыр, Төркия һәм Төркестан өлкәләрендә дә шуңа нигезләнеп эш итәләр. Бу дата дөрес булса да, азрак хаталы булса да, максат пәйгамбәрне хөрмәт итү, шәригатьчәме, сәясиме, миллиме бер бәйрәм төзү булганга, бу кадәр өчен дата билгеләүнең күп, зур әһәмияте юк. Шулай да гыйльми җәһәттән дөрес туган көнен белү, чын йолдыз хисабы белән вакытын билгеләү – тиешле бер гыйлем һәм әдәп вазыйфасы. Бу тарихны «Әд-дин вәл-әдәб» журналындагы икенче өлешендә тәфсилләп язган идем һәм бәйрәм итүнең нигә нигезләнүе ачыкланган иде.

---

[28] Моннан соңра да моның чиста нөсхәсе язылганлыктан, бу урында каралама нөсхәсе күчерелмәде.

Бу датаның дөрес рәвештә чыгарылуын соңгы астрономнардан мисырлы Мәхмүд паша, киң һәм тирән эзләнүләр һәм хисапларга таянып, туу көненең милади 571 елның 20 апреленә туры килгән 9 рабигыль-әүвәл базар иртәсе (дүшәмбе) булганын ун-унике дәлил белән исбатлады. Әлеге дәлилләрдән берсе – чөнки Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе булсын) әфәндебез, Юпитер белән Сатурнның Чаян йолдызлыгында булган кушылу елында һәм кушылудан бераз соңрак дөньяга килүе, рабигыль-әүвәлнең беренче яртысында базар иртәсе көне икәне каршылыксыз булып, әлеге кушылуның исә милади 571 ел мартының утызынчы яки егерме тугызынчы көне булуы тиеш килүен хисаплаганнан соң, аны чиратлашып кергән элек рабигыль-әүвәлнең җыелу вакыты) апрельнең 10 нчы көне, Мәккә сәгате белән ярты төн узгач, 9 сәгать 41 минуттан соң булып, ә ай күрү исә 11 апрель кичендә мөмкин килүе ачык булуы сәбәпле, апрельнең 12 нче базар көне рабигыль-әүвәлнең беренче көне булуы ачыкланып, әлеге айның беренче яртысындагы базар иртәсе (дүшәмбе) исә икенче һәм тугызынчы көннәр булган булыр. Тарихчылар фикеренчә, туу көне хакында шикле булган ягы башлыча 8, 10, 12 рабигыль-әүвәл булып, әлеге хисап исә боларның һичберсе базар иртәсе булмавын, фәкать 9 рабигыль-әүвәлнең базар иртәсе булуын күрсәткәнгә, менә бердәм урыны 9 рабигыль-әүвәл булуы тиеш килү, 8 рабигыль-әүвәл тарафдарлары, риваят кылучылар бу айның башы бер көн соңрак булуына, ягъни аның башы базар иртәсе икәнен әйтүче булалар, чөнки ай башлану хакында һәрвакыт һәр җирдә ашыгу яки кичектерү бик табигый икәнен белдертергә ихтияҗ юк.

## Вакытлы курслар дәресләре

Уфада һәм башка җирләрдә имам әзерләү өчен вакытлы курслар торгызу тиеш күрелә. Галимнәр һәм мәчет эшләрен башкаручылар җыены да моны кирәкле дип күргәннәр иде. Шунлыктан Уфада ноябрьдә бу курслар ачылачак иде. Хат һәм хәбәр белән генә игълан ителсә дә, шәкерт тупланып җитмәде. Шулай да, дүрт-биш кешегә 15 ноябрьдә дәрес башланды. Бу килгән кешеләр имамлык һәм мөәзинлек өчен имтиханга килүчеләр булганга, мин, хәлләренә туры килгәнчә, Коръәнне дөрес уку гамәли фәнен яхшыртуны һәм Коръән тәрҗемәсен башлаттым. Һәркөн иртәнге намаздан соң җамигъ мәчеттә укытам. Көндез беренче җамигъ мәчет имамы мул-

ла Җиһангир ахун, дүртенче җамигъ мәчет имамы мулла Һади Фәхри ислам тарихы белән гарәп телен өйрәтәләр. 22 ноябрьдән соң үз теләкләрен игътибарга алып, «Мохтасарел-викая» укыта башладым. Һәркөн ахшамнан соң бер дәрес бирергә булдым. Бу кешеләр гарәп морфологиясен һәм синтаксисын укыган булсалар да, хәтерләрендә әсәре калмаган, китап укыган кешеләр түгел. Шунлыктан «Мохтасарел-викая» түгел, «Төхфәтел-мөлек» укулары яхшырак иде. «Төхфәтел-мөлек»не яхшы аңлап, укып тәмамлаган кеше гади авылларга – башкорт авылларына – имам булырга ярый. Ләкин мондый рәвешле адәмнәр бик аз очрый. Электән килгән мөдәррис һәм мөгаллимнәрнең начар укытуларыннан – бала-чагага, гарәп телләре дөресләнеп бетмәгән буй үстергән шәкертләргә «Мохтасарел-викая» укытып, файдасыз укыту юлын ачканнар. Аз гына гарәпчә укырга булган шәкерт хәзер «Мохтасар» укый башлый. Язу карасын, дөрес укытыр өчен хисле һәм сәләтле мөгаллимнең башын байтак вата, мең җафа белән бер-ике фасыл укысалар, «Мохтасар» укыдык [дигән] исемен йөртәләр. Бу рәвешкә Диния нәзарәтенең электән калган игътибарсызлыгы бар ки, гарәпчәдән имтихан дәрәҗәсенә килсәләр, шәкерт кулына «Мохтасарел-викая» тоттыралар. Рәсми имтихан «Мохтасар»дан була дип белеп, һәркем шуның белән маташа башлый, сәләтенә карамыйча, хәлфәләре дә, үзләре дә яхшы белмәсәләр дә, укыта башлыйлар.

Вафат булган мөфти Мөхәммәдьяр Солтанов вакытында бу турыда үзем һәм Казан имамнары исемнәреннән гомуми язып карадык. Имтихан өчен күп белү барлыгын аңлау өчен, «Мохтасарел-Кодури» яхшырак булыр иде. Гарәп теле төзек, шул ук уку көче белән укыла торган китап, үзе дә башкалардан артык һәм мөбарәк күренгән, хәнәфи мәзһәбендә кабул ителгән язма, дип язылган иде. Үз гамәлләре белән канәгать булган һәм алданган казыйларга дөрес булмаган булса кирәк, колак салмадылар. Башта әлеге мөфти бөтен имтихан тәртибендә мөрәҗәгать иткән булса да, тәкъдимнәргә карый алмады.

«Мохтасарел-викая» – бик яхшы китап, «Һидая» мәсьәләләренең күбрәген җыйган, ләкин башлап фикыһ өйрәнү өчен түгел. «Мохтасарел-Кодури», «Кәнз», «Һидая» кебек кыска һәм озын китаплардан фикыһны өйрәнгәннән соң, вак мәсьәләләрне хәтердә саклар өчен, галим кешеләрнең ятлавы яки төгәллеге өчен туры килгән бер мөбарәк китап. Аз гына мөнәсәбәт белән бу җөмләне монда яздым. Кыскасы, үз мәсләгемә туры булмаса да, мәҗбури

буларак, «Мохтасарел-викая»ны бу җитешмәгән кешеләргә укыта башладым. Ни булса да, анадан туган адәмнәр, эчтәлеген аңлап укыйлар, китаптан күп файда алмасалар да, аңлатудан шаять файда алырлар.

Искәрмә: халыкның галимнәргә ихтыяҗы гадәттән артык, ләкин хис юк, сәламәт вөҗдан юк, дин кайгысы юк. Нәтиҗә, ул да юк, бу да юк, юк та юк. Гади халыкта гына түгел, югары сыйныф исемен алган имамнарда һәм мөдәррис исеме хөрмәтен күтәргән затларда да бу хәл таралган. Һәркайсы белгәненә канәгатьләнгән, йөрәгендә бер камиллек көтми, үзен файда алу дәрәҗәсеннән күптән үткән итеп күрә. Шунлыктан гыйлем артмый, дин төзәлми, көннән-көн наданлык, азгынлык артып тора. Бу бозык әмернең әсәре: искә алган рәвешчә намаз артларында дини дәресләрем, Коръән укуны төзәтү, намазда укылачак сүрәләрнең тәрҗемәләре, тәһарәт һәм намаз бүлегеннән байтак мәсьәләләр укытыла торып, читтән килеп, имтихан өчен укучы затлардан башка имам, мөәзин, гади халыктан бер адәм булсын, дәрескә килүче булмый. Ә бөтенесе укуга, төзәтүгә, тәрбиягә мохтаҗ, һәркемгә ваҗиб булган «Фатиха» сүрәсен өйрәнү бурычыннан котылмаганнар. Кешелек сыйфатына ия булган кешегә шикаять кылу тиешле – ул я юатыр, я көлдерер, я синең белән кайгырыр.

## «Сахих Мөслим» китабын уку,
## Нәвави, Әбү Дауд, Тирмизи

Төрле фетнәләр, төрле афәтләр төпләнүе һәм төрле золымлыклар сәбәпле, мәүлид мөнәсәбәте белән 1338 елның рабигыль-әүвәл башында имам Әбел-Хөсәен Мөслим бине әл-Хәҗҗаҗ әл-Кушәйри хәзрәтләренең «Сахих» китабын Нәвави аңлатмасы белән укырга, өйрәнергә керешкән идем. Бу китапта булган хәдис шәрифләрне уку һәм өйрәнү белән бу динсезләр заманында үземне юата һәм байтак ял иттерә идем. Аллаһның рәхмәте һәм юмартлыгы белән тәртип белән укыдым. Шәрехен яхшы гына тикшердем. Аллаһка моның өчен мактау булсын! Бу 1339 ел рабигыль-әүвәленең унбишенә каршы җомга төнендә тәмамладым. Элек тә бу китаптан файдалануым күп булса да, тәртипле рәвештә уку-укыту насыйп булмаган иде. Быел күп шөгыльләр арасында һәм байтак язуларым арасында бер ел эчендә укып чыктым. Аллаһка моның өчен күп, пакь, мөбарәк мактау булсын.

«Сахих Мөслим» китабы – Аллаһ китабыннан соң иң дөрес китап саналган ике китапның берсе. Бары «Сахих әл-Бохари» белән чагышытыру арасында, хәдис галимнәре һәм сөннәт шәехләре арасында төрле фикер бар. Күпчелеге Бохарины өстен күргәннәр. Кайберләре, бигрәк тә көнбатыш тарафы (Фәс, Тунис, Җәзаир) галимнәреннән кайбеләре «Сахих Мөслим»не [яхшырак] күрделәр. Имам Мөслим, китабында бүлек исемнәрен куймаса да, һәр бүлеккә туры килгән хәдисләрне бер җиргә җыйган, бер бүлекккә мөнәсәбәтле төрле юлар белән күчерелгән хәдисләрне бер урындарак искә ала. Кайбер хәдис гыйлеме галимнәре фикеренә күрә, Мөслимнең артыклыгы шушы яктан икән, ә хәдиснең дөреслеге ягыннан – Бохари артык икән. Хәдис галимнәренең күпчелегенең карары шушы.

Имам Мөслим хәзрәтләре Әбел-Хөсәен Мөслим бине әл-Хәҗҗаҗ бине Мөслим ән-Нишапури [һиҗри] 206 елда туган. [Һиҗри] 261 елда 55 яшендә Нишапурда вафат булган. Гыйлем артыннан сәфәрнең бик авыр вакытында күп сәфәр иткән. Хиҗаз, Мисыр, Шам, Гыйрак тарафларына барган. Зур галимнәрнең каймакларыннан [булган] Әхмәд бине Хәнбәл, Исхак бине Раһәвәйһ, Яхъя бине Яхъя Нишапури, Мөхәммәд бине Исмәгыйль әл-Бохари («Сахих» китабы авторы), Даримидән («Мөснәд» авторы) гыйлем алган. Бу «Сахих» китабын өч йөз мең хәдис эченнән сайлап алганын үзеннән күчерәләр. Кыскасы, Сахих Мөслим китабы, ислам галәмендә Аллаһ китабыннан соң беренчелек дәрәҗәсен алмаса да, Сахих Бохаридан кала башкадан өстен һәм иң яхшы китап икәненә галимнәрнең бердәм фикере бар. Аллаһ андыйларны күбәйтсен. Бу китапка көнбатыш галимнәреннән һәм башкалардан байтак [кешеләр] шәрех вә аңлатмалар язып, хезмәт иткәннәр.

Мәшһүр хәдис галиме Мөхьеддин Яхъя бине Шәрәф бине Мөрри бине Хәсән бине Хөсәен бине Хизам ән-Нәвави әш-Шами хәзрәтләре[29], Мәризи, казый Гыяздан, «Мәгалим әс-сөнән» авторы Хаттабидан[30] күп күчереп, «Минһаҗ» исемле мәшһүр шәрехен яз-

---

[29] [Һиҗри] 631 елда туган, 676 елда вафат. Шамда «хәдис йорты» дип билгеле булган мәдрәсәдә аскетизм һәм намус белән укыган. Бүген дә укыган урыны билгеле.

[30] «Мәгалим әс-сөнән» – «Сөнән Әби Дауд» шәрехе. Ләкин нөсхәсе сирәк. Мисыр китапханәсендә дә фәкать икенче томы бар икән. Хаттаби (Аллаһ аны рәхим кылсын) бу китабында, «Игъләм әс-сөнән» исемле

ган. Нәвави шәрехе мәйданда таралып, Мәризи һәм казый Гыяз китаплары онытылып калганнар. Юкса бу ике кешенең әсәрләрендә күп гыйлем җыелган булган. Нәвави шәрехенең төп эше бу икесеннән һәм Хаттаби китабыннан диярлек. Нәвави хәзрәтләре бик файдалы һәм эчтәлекле итеп бу шәрехен дөньяга чыгарган. Үз заманыннан бирле галимнәр һәм шәкертләр бу шәрехтән файдаланып киләләр. Аңа һәм ул файдаланылган кешеләргә мөселманнар исеменнән Аллаһның хәерле бүләге ирешсен.

Нәвави дини гыйлемнәрдә, аеруча хәдис фәнендә, фикыһта яхшы хезмәт иткән. Аның әсәрләреннән вәгазь китабы «Риядъ әс-салихин» китабы бик яхшы. «Кырык хәдис» китабы исә бөтен дөньяга таралган, һәркем тарафыннан яхшы кабул ителгән, файда алына торган мөбарәк китап. Фикыһта «Минһаҗ»ы, хәдис күчерүчеләр турында әсәрләре, «Хильят әл-әбрар» исемле зикерләр китабы да мөбарәк, бик файдалы китап. Үзенең мәзһәбе булган Шафигый фикерләренә дә күп хезмәт иткән. Бөек хәдис галиме булуы беләң бергә, мәзһәб галиме дә. Аллаһның сыйфатлары хакында булган мөтәшәбиһ [төрлечә аңларга мөмкин булган] аятьләре һәм хәдисләре мәсьәләсендә борынгы һәм соңгы галитмнәр фикерен бәян итеп үтсә дә, аңлату барышында, соңгы галимнәр фикерләренчә аңлату тарафына авышуы тоела. Нәвави бу «Мөслим» шәрехендә хәдис күчерүчеләр исемнәрен теркәп, аңалшылмаган хәдисләрне аңлатып, хәдисләрдән нәтиҗәләр чыгарып, хәдис укучы шәкертләргә һәм башка шәрехләүчеләр өчен яхшы юл күрсәтеп калдырды. Аллаһ аңа хәерле әҗерен бирсен.

1339 ел 15 рабигыль-әүвәлдә «Сахих Мөслим»не тәмамлаганнан соң, сөннәт китаплары арасыннан «Сөнән Әби Дауд»ны тәкъдим итеп һәм сайлап алып, укырга һәм өйрәнергә керештем. Нөсхәм Һиндстанның элекке яхшылап төзәтелгәнче басылган нөсхәләреннән булганга, көчем җиткән кадәр төзәтеп баруны өстемә алдым. Тик башында булган «Миркат әс-согуд» белән «Сөнән Әби Дауд» исемле Сөютыйның шәрехен, чагыштыру өчен нөсхә юклыктан, игътибар итәргә ярдәм итмәслек дәрәҗәдә хатала-

---

Бохари шәрехендә хәдис гыйлеменә һәм хәдис шәрехенә караган күп гыйлем язган булса кирәк ки, соңгыларга чыганак булган. Хаттаби хафизнең [тулы исеме] – Әбү Сөләйман Әхмәд бине Мөхәммәд бине Ибраһим бине әл-Хаттаб әл-Бүсти. Вафаты [һиҗри] 388 елда. Әлеге имам Хаттабидан мондый шигырь китерелә: [...].

ры күп булганга, дөресләүне өстемә алмадым. Аллаһтан өмет итәм, бу «Сөнән Әби Дауд» ны тынычлык белән укып чыккач, «Сөнән Тирмизи», соңра «Сөнән Нәсаи», соңра «Сөнән ибне Мәҗәһ»не укысам һәм яхшы өйрәнеп гыйльми һәм гамәли яктан файдалансам икән! Ул [Аллаһ] – Рәхим, туры юлга күндерүче.

Искәрмә: дүрт «Сөнән» китаплары эчендә элек уку өчен «Сөнән Әби Дауд»ны сайладым. Чөнки Әбү Дауд – Тирмизи белән Нәсаинең укытучысы, хәдис галимнәренең аңлатуларына күрә, сөннәт һәм хөкемнәргә караган хәдисләре күбрәк. Хәнәфи фикыһына нигез булган хәдисләре башка «Сөнән»нәргә караганда, күбрәк, хәдис галимнәре арасында да өстенлеге һәм үзенчәлеге күбрәк искә алынган.

Йәмәннең хәдис галиме Ибне Дәйбаг «Тәйсир әл-вөсул илә гыйльмил-усул мин хәдисир-расүл» китабында алты китап арасыннан авторларын искә алганда, Әбү Даудны беренче искә ала. Сәед Мөхәммәд бине Габидин үз китабында башкалардан өстенлеген яза. Шул сәбәпләрдән, «Сөнән Әби Дауд» белән башладым. Бу «Сөнән»нән мәктәпләр өчен «Кырык хәдис»ләр сайлаганда, Тирмизине тәкъдим иткән идем. Ул вакытта, Аллаһ белүчерәк, Тирмизинең хәдисләр тәртибендә күп бәян итүе өчен тәкъдим иткән булсам кирәк[31]. Барысы да – хәдис имамнары, туры юл имамнары, Аллаһ аларны мөселманнар исеменнән бүләкләсен.

---

[31] «Сөнән Әби Дауд» китабында берничә тоташу чылбырларым, күп хәдис шәехләреннән алынган иҗәзәтләрем эченнән берсен бу җирдә терким. 1327 елда Мәккә Мөкәррәмәдә Һинд галимнәреннән шәех Мөхәммәд Габделхак бине Мәүләви Шаһмөхәммәд Аллаһабади янында әлеге китапның башыннан һәм ахырыннан укып тәмамлаудан иҗазәт юлы белән тоташу чылбыры алган идем. Бу шәех күп шәехләрдән риваят итә. Җөмләдән «ган әш-шәех Габделгани бине әш-шәех Әби Сәгыйд әл-Фарукый вә һуә ган әш-шәех Мәүләви Исхак ган җәддиһи ли-әиммәти Габделгазиз әд-Дәһләви ган әбиһи Шаһвәлиуллаһ әд-Дәһләви ган әби Таһим Мөхәммәд бине Ибраһим әл-Көрди ган әл-Хәсән бине Гали әл-Гоҗәйми ган Гыйсә әл-Мәгърибы ган әш-Шиһәб Әхмәд әл-Хәфәҗи ган Бәдреддин әл-Хәсән әл-Кәрхи ган әс-Суютый ган Мөхәммәди каблә әл-Хәләби ган әс-Саләх бине әби Гамр әл-Мәкъдиси ган әби әл-Хәсәни Гали әл-Бохари ган мөснид гасриһи Әби Хафс Гомәр бине Табразәд әл-Багдәди ган Әбил-Вәлид Ибраһим бине Мөхәммәд әл-Кәрхи вә әби әл-Фәтх Мослих бинӘхмәд әр-Руми киләһүмә ган әл-хафиз әби Бәкер әл-Хатыйб әл-Багдәди ган әл-имам әл-казый әби Гамр әл-Касим би Җәгъфәр әл-

16 рабигыль-әүвәлдә «Сөнән Тирмизи»не укырга керештем. Бу китаплар белән төрле дулкынланулар арасында юанам. Бу китаплар бәрәкәтендә күп эшләремдә хәерлек күрәм. Аллаһның ярдәме булса иде.

## Уфа милләтләр бүлегенең Нәзарәт тәгълиматен күзәтү хакындагы кәгазе

1920 елның 28 ноябрендә Уфа Исполком милләтләр бүлегеннән Г. Дукаев имзасы белән Диния нәзарәтеннән мөхтәсибләргә, ахунларга һәм имамнарга җибәреләчәк рәсми фәрманнарның башта милләтләр бүлегенә күрсәтелүен сорапп язган рәсми язу килде. Бу эшләре белән зур деспотизм күрсәтмәкче булалар ки, Мәхкәмәишәргыяне күзәтмәкче булалар. Бер дә нигезсез һәм искә алырга лаеклы бер шөбһә кермичә, хуҗалык итмәкче булалалар. Дин хөкүмәттән аерым игътибар ителүенә күрә, бер төрле сәяси шөбһә күрмичә торып, мондый күзәтү рәвешендә тыгылмаска тиеш иде. Бу турыда янә үзләренә мөрәҗәгать белән ачыклау соралыр.

Бирски ягында кулга алынган имамнарның кайберләреннән 15 ноябрьдә алынган хәлләре югарыда язылган иде. Боларны хәлләрен бераз аңлагач, сәбәпсез, ялгыз донос белән туктатылуларына дөресрәк уй хасил итеп, 29 ноябрьдә азат ителүләрен сорап, Уфа ЧКсына үтенү кәгазе җибәрдем. Өч-дүрт мулла хосусый тырышлыклары аркасында котылганнар икән.

Соңра ишетелде, Калмык авылыннан мөхтәсиб мулла Шәехгаттар Имәкәй белән Борайдан мулла Мөхәммәднәби Мортаза әфәнделәрне, 1918 елда акларга ярдәм иткәннәр, дип нигезсез яла ягу сәбәпле, өч ел төрмәгә хөкем иткәннәр. Аллаһ аларны тиз арада коткарсын.

## Нәзарәт алдындагы курсларның дәресләре

Уфада Диния нәзарәте чарасы итеп 15 ноябрьдән бирле дини дәресханә ачылганлыктан, мин көн саен иртәнге намаздан һәм ахшам намазыннан соң ике дәрес йөкләдем. Дәрес укучылар ике сыйныф булып, беренчедә Коръәнне дөрес уку фәнен, кайбер

---

Һәшими ган әби Гали Мөхәммәд әл-Луәлуәи ган әлмосанниф әби Дауд әс-Сиҗистәни рәхимәһүмүллаһу Тәгалә».

сүрәләрнең тәрҗемәләрен, «Мохтасарел-викая»дан «Тәһарәт бүлеге»н укыганнан соң, әлеге китапның авырлыгы сәбәпле, «Төхфәтел мөлек» укыта башладым. Гарәп морфологиясе һәм синтаксисы белеме юк яки аз шәкертләргә бу китап та авыр булса да, хәлләренә туры китереп, башка китап мәйданда күренмәгәнгә, укытыла. «Төхфәтел-мөлек» китабы – белеме аз имамнар өчен дә җитәрлек мәгълүматны җыйган яхшы китап. «Мохтасарел-викая» кебек өйрәнергә читен түгел.

Икенче сыйныфларга тәрҗемә һәм аңлату белән Коръән дәресе, тәһарәт бүлегеннән «Мишкәтел-мәсабих» башланды. Бу кешеләрнең күбесе имамнар, бер дәрәҗәдә белемнәре бар. Бер бит кадәр «Мишкәт»не аңлап укыйлар. Бу курсларны Education Диния нәзарәте, теләгән рәвештәрәк булуын кертеп, рәсми дини дәресләр җәдвәле белән укытуны көтсә дә, хәзер шәкерт аз, бары 15–16 кадәр шәкерт күренеп тора. Болар өчен Нәзарәт зур чыгым йөкли. Зур чыгымнар булса да, халыкның гыйлемгә ихтыяҗы көчле булганлыктан, Милләт съезды, яраклы күреп, чыгымнарны йөкләгән иде. Булган имамнар да зәгыйфь, яхшы тәрбия күрмичә, урнашканнар. Имтихан өчен әзерләнүчеләргә укырга җир юк, булса, тәртипсез, шунлыктан укучы аз булган хәлдә, бу курслар тиешле дип табылды. Мин үзем, казыйлардан Кәшшаф һәм Сабир әфәнделәр дә укытырга булганнар иде. Бу көннәрдә Кәшшаф әфәнде укытырга керсә дә, Сабир казый һаман вакыт таба алмый тора. Һәркайсы сыйныф көн саен дүртәрбишәр төрле дәрес укып торалар. Билгеләнгән дәрес җәдвәле мондый рәвешчә иде: *(бу урында бер биттән артыграк ачык калдырылган, җәдвәл язылмаган).*

## Намазга керешкәндә тел ниятенең бидгать булуы, күңел ниятенең әһәмияте

«Төхфәтел-мөлек» дәресенең «Ният бүлеге»ндә «Бишенчесе – ният, ул исә күңел белән намаз укырга теләү, ә әйтү сөннәт» дигән гыйбарәт белән искәртеп үткәрдем. Шулай ки, тел белән әйтү турында галимнәр төрлечә әйтәләр. «Һидая» авторы: «Тел белән әйтү саналмый, карарын ныгыту өчен бу яхшы», – дип әйтә. «Мохтасарел-викая»: «Тел белән әйтү яхшырак», – ди. «Мохтасарел-кодури» белән «Кәнзер-ракаик»та бөтенләй искә алынмаган. Фикыһ китапларына һәм фәтваларга карасаң, элегрәкләрдән ниятне тел белән әйтү күренми, соңгылар төрлечә кызыктыру сурәтендә искә алган-

нар. «Төхфәт» авторы, арттырып җибәреп, сөннәт дип куйган. Хафиз Ибнел-Каййим «Зәд әл-Мәгад фи һәдйи хайрил-гыйбәд» китабында: «Ниятне тел белән әйтү Рәсүлүллаһтан (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен), сәхабәләрдән, тәбигыйннардан, дүрт имамнан бөтенләй күчерелмәгән, шуңа күрә бидгать», – ди. Аның сүзен Ибне Һөмам «Һидая» шәрехендә күчерә һәм кабул итеп, «Һидая»нең «карарын ныгыту өчен», сүзен дәлил итмичә, «бу яхшы» җөмләсенә бәйләп, юнәлтә. Бу юнәлтүе авырлык һәм каршылык булса да, хатадан яхшырак. Мәгънәсе: карары һәм теләге таркалганда җыю, котырту белән шикләндерүне бетерү өчен – хаҗәт булса – яхшы димәкче була. Ягъни шундый вакытта гына зарурлык булганга кулланылыр дигән мәгънәдә булып калыр.

Имам Раббани Әхмәд Сирһинди бер мәктүбендә бидгать дип ачык әйтеп, гади халык тиешле ниятне бу тел нияте дип белеп, чикләнә, күңел ниятеннән гафил булып, ниятсез намаз үтәүләре һәм, чынлыкта, намазсыз калулары ихтимал икәнен бәян итеп, куркыткан. Мулла Габделхәй әл-Һинди «Һидая» китабы битләренең читендә: «Бу мәсьәләдә кайбеләре «бидгать», кайбеләре «сөннәт», кайбеләре «мөстәхәб», кайбеләре «мәкруһ» диделәр. Дөресрәге: ул – яхшы бидгать», – дип чыгарган. Яхшы дигән сүзне язмаган булса, яхшы булыр иде.

Мин бу мәсьәләдә Ибнел-Каййим һәм «Мәктүбәт» авторы имам Раббани бәян итүләре белән канәгатьләнәм. «Сөннәт» һәм «мөстәхәб» дип әйтүне тиешсез сүз дип беләм. 20 елдан бирле артык шикләнү булып, йөрәгемне җыю һәм төгәлләтү авыр булганда гына, бик аз вакытта гына, телгә ияртеп ният итәм. Шафигыйларда, аеруча мисырлылар да бу гамәл бик артып киткән. Хәтта кайбеләрендә котыртуга дучар булып, имамның рөкүгына кадәр намазга керешә алмый торганнары була. Котыртуга юл бирсә, шайтан көлкесе булу бик тиз. Аллаһ сакласын.

## Намаз башлау тәкбирендә сөннәткә каршы булган кыскача бер сүз

Соңгы галимнәрнең китапларында, баягы мәсьәлә кебек, төп шәригатьтән тыш нәрсәләр кереп, байтак бозыклыкка илткән.

Икенче мисал: «Мохтасарел-викая» һәм аннан соңгыларда намаз башлау тәкбирендә кул күтәрү мәсьәләсендә «Баш бармаклары белән колак йомшакларына тигән хәлдә» дигән гыйбарә белән арттырган-

нар. Асыл сөннәт: куллар колак турысына яки җилкә турысына [хәтле] күтәрелә. Һәркайсы сөннәттә бар. Хәнәфиләр колак турысына, Шафигый һәм күпчелек хәдис галимнәре җилкә турысына кадәр күтәрүне сайлаганнар. Ләкин: «Баш бармаклары белән колак йомшакларына тигән хәлдә», – дигән шарт һичбер мәзһәбтә юк, элекке галимнәрдән күчерү дә юк. Кул күтәрүдә колак йомшагына кадәр күтәрүне белер өчен колак йомшагына тидерү дип арттырганнар. Гади халык, бу мәсьәләне дәрәҗәсеннән арттырып, фарыз гамәл хөкеменә ашырып, чиктән тыш арттырганнар. Шул колак тотуны тиешле күрәләр. Шуның белән бу гамәл бидгать гамәл булып китә. Боларның мисаллары бар. Шунлыктан бер галим фикыһ китапларыннан бер кыска нәтиҗә чыгарса, асылсыз мәсьәләләрне һәм коллар бүлекләрен төшереп калдырып, бер китап язса, яхшы булыр иде.

## Эстәрлебашта җамигъ мәчет төзүгә мөфтинең каршы булуы һәм рәсми хаты

Ноябрьдә җамигъ мәчет арттыру турында Диния нәзарәтендә рәсми мәҗлескә игълан иткән фикеремнең Мәхкәмәнең рәсми вакыйгалар дәфтәренә теркәгән фәтванамәмнең нөсхәсе мондый:

1920 елның ноябрендә Эстәрлетамак ягындагы Эстәрлебаш авылында кинәт бер мәхәлләне өчкә бүлеп, яңадан ике мәчет торгызуларын Диния нәзарәтенә рәсми игълан ителеп, рәсми ярдәм сорадылар. Диния нәзарәтенең күбрәге белән бу яңа мәчетләрнең җомгалы булуларына фәтва бирсәләр дә, мин мөфти вә Нәзарәтнең рәисе Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди бу эшкә риза булмыйча, аерым фикердә калдым.

1. Диния нәзарәтенең өстенә шәригать тарафыннан динне тергезү һәм Сөннәтне тарату йөкләтелгән. Гомуми милләт тарафыннан да бу изге хезмәт аеруча таләп ителде. Бу принципны Диния нәзарәте һәр өлкәдә мөмкин кадәр үзенә беренче дәрәҗәдә төп канун итеп тотарга тиеш.

2. Бер шәһәрдә, бер авылда берничә җомга уку, өстен күргән сүзгә күрә, дөрес булса да, бөек мөҗтәһид имамнар тарафыннан зарурлык кадәр генә рөхсәт ителә. Бу мәсьәләдә җомганың җәмәгатьләрне җыючы булуындагы шәригать серен үтәүдән һәм тиешенчә эшләүдән гозер сәбәпле генә рөхсәт иттеләр.

3. Дин галимнәре һәм мәзһәб мөҗтәһидләреннән борынгылар һәм соңгылар әсәрләрендә язылган риваятьләрнең текстларыннан

һәм рухларыннан бу мәсьәлә ачык күренә. Бу мәсьәләдә «Раддел-мохтар хашиятү әд-Дөррил-мохтар»да җитәрлек риваять язылган.

4. Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) заманында, хөрмәтле сәхабәләр һәм табигыйннар вакытында зур-зур җәмәгатьләр белән җомга намазы бер урында гына укылып килгән. Алардан соң гына халыкның ифрат дәрәҗәдә күбәюе сәбәпле, Багдад, Мәрв, Шаһҗиһан шәһәрләрендә башланган берничә мәчет төзү күренешен, дин имамнары белән ризалашып, түбәндә искә алыначак сәбәпләргә күрә, дөрес күрәбез. Диния нәзарәте һәм бөтен мәхәлләләр халкы шул сәбәпләрнең булуы тәкъдирендә, рөхсәтләре һәм гамәлләре өчен, шаять, гөнаһлы булмаслар, дип уйлыйм: 1) җәмәгать бер мәчеткә сыярлык булмас, 2) арада йөрергә мәшәкать китерерлек, күперсез бөек елгалар һәм сулар булыр, 3) гадәт буенча бару мәшәкатьле булырлык, ерак ара булыр. Шуның кебек гозерләр булганда берничә мәчет рөхсәт ителә, зарурлык кадәрен билгеләп, бердән артык җамигъ мәчет төзү дөрес булса кирәк. Мондый шәригать буенча дөрес гозер булмаганда, халыкны җомгада бер мәчеткә туплап, башкаларны биш вакыт намаз мәчетләре итү тиешле. Хәтта җамигъ мәчет итеп, рөхсәт алынган мәчетләрдә халык аз булса, бер җиргә тупланып укулары мөмкин булганда, халык тиешсез фанатизмнарын Аллаһ ризалыгы өчен ташлап, бер җиргә тупланып укулары тиешле.

5. Берничә мәчет булган авылларда һәр мәхәллә үз имамы, үз вазыйфалары, үз дәфтәре буенча мөстәкыйль булыр. Хәтта җомга намазы үтәүдә хөтбә сөйләүчеләр чират белән җомга укытырлар. Иркен һәм киңрәк булган мәчет җомга өчен һәммә хөтбә сөйләүче арасында уртак булып торыр.

6. Мәсьәлә маддәсе булган Эстәрлебаш авылында иске мәчет гадәттән тыш зур, гади мәчетләрдән дүрт-биш тапкыр киң. Авыл эчендә бердәмлекне авырайтырлык бер сәбәп тә юк. Шунлыктан яңа мәчетләрнең биш вакытлы булып, җомганы бу элекке мәчетләрендә авыл халкы барысы да җыелып укулары тиеш икәнлекне белдерәм. Бу фәтвамны җирле мөхтәсиб аркылы бу авыл халкына ирештерүем өстенә, Диния нәзарәтенең рәсми вакыйгалар дәфтәренә теркәү өчен, бу кәгазьне мәҗлескә ирештерәм. Аллаһ дөреслекне белүчерәк.

Имза: 8 декабрь 27 рабигыль-әүвәл.

Бу тәкъдимемне мөхмәрәм казыйларга укып, рәсми вакыйгалар дәфтәренә теркәү өчен нөсхәне бирдем. Алар бераз кәефсез булды-

лар. Мәхкәмәдә фикер каршылыгы булса да, читкә чыгару Мәхкәмәнең хөрмәтенә зарар итә, авылның үзенә игълан ителмәве яхшы иде, диделәр. Бигрәк тә казыйлар шәехе Ризаэддин әфәнде байтак борчылды.

Мин әйттем: «Гади эшләрдә шулай вак каршылыклар булса да, күпчелекнең карары буенча эш үтәлер. Төрле фикерләр вакыйгалар дәфтәрендә генә калыр. Ләкин моның кебек мәсьәләләр зур бер дини мәсьәлә булганга, фәтва юлынча иглан итү тиешле, имамнар һәм гади халык өчен, шаять, кисәтү булыр. Бу Эстәрле маддәсе моның игълан ителүе өчен иң кулайлы маддә булганга, игълан ителүен тиешле күрдем».

## Кәс, чынаякларга язылган гарәпчә шигырьләрнең хаталары. Сәләх хәзрәтнең искәртүе

Җәра каләмул-казаи бимә йәкүн фәсиййәнит-тәхәрруку вәс-сукуну

Җөнүнүн минкә ән тәсга лиризкыйн вә йурзәку вә гашәвәтиһил-җәнину

[Язмыш каләме киләчәкне язган инде, шуңа хәрәкәт тә, тик тору да бертигез.

Ризык артыннан чабу – синнән юләрлек, ана карынындагы яралгы да ризыклана].

Бу тиклегә бәйле ике юл Ибне Халләкән күчерүенә күрә, Әбел-Хәер әл-Васитый шигыреннән. Тыштан күренгәнчә, кәсеп итүне ташлау һәм ялкаулык өчен әйтелгән түгел. Бәлки артык хирыслыкны, мал җыюда һәлак булуны һәм дини бурычларны калдырып, ризык өчен тырышуны инкяр итү өчен. Кәсеп юлына кереп тә, хәерле нәтиҗә юнәтә алмаганда, артык борчуга төшмичә, юатылган булу өчен дә файдалы. Сабый вакытымда әткәм мәрхүм бу бәетне һәм мондый бәетләрне: [...] «Китабел-хайван» китабында күреп, бер каләмле шәкерттән нөсхә яздырып, чынаякларга яздырып, тараткан иде. Ләкин нөсхә хаталы булган. Минем дә ул вакытта гыйльми көчем дөресләүгә җитәрлек булмаган. Остазларга күрсәтелмәгән. Фабрикадан эшләнеп килгәч, остаз Сәләхеддин Сәгыйдь хәзрәтләре күреп, кисәтсә дә, эш узган иде. Гыйльми эшне киңәшсез таратуның зарары һәм безгә калган ядкяре булды. Әтием мәрхүм мәдрәсәдә яздыргач, гыйлем йортыннан төзәтелеп чыгарылыр, дип уйлавы дөрес булып чыкмаган.

## Имам Бохари һәм Рифагыйның кайбер хәлләре

Шәех Касталаниның «Сахих Бохари»га кереш сүзенә өстән-өстән генә карап алган вакытымда имам Бохари хәзрәтләренә нисбәт ителгән мондый бәетләрне искә алырга туры килде:

Игътәним фил-фәраги фадла рукугин фәгасә ән йәкүнә мәүтүкә бәгътәтән.

Кәм сахихин раәйтә мин гайри сукмин зәһәбәт нәфсүһүс-сахихәту фәлтәтән.

[Буш вакытта намаз укы, бәлки, үлемең кинәт килер.

Күпме сәламәт кешенең бер авырусыз сәламәт җаны кинәт китеп барды].

Хафиз Габдулла бине Габдрахман әд-Дәриминең вафат хәбәре ирешкәч, әйткән:

Ин гыйштә тәфҗагъ бил-әхиббәти куллиһиму

Вә бәкау нәфсикә лә әбә ләкә әфҗәгу

[Озак яшәсәң, барлык сөеклеләреңне югалтырсың.

Ә берүзең генә исән калу тагын да куркынычрак].

Имам Бохари хәзрәтләре ураза гаете кичәсендә [һиҗри] 256 елда, 62 яшенә 13 көн җитмичә, дөньядан кайтты. [Әбҗәд системасы белән] вафат датасы – «Нур» сүзе, туу датасы – «Сыйдкъ», яшәү дәвере «Хәмид» сүзләре белән теркәлгән. Кабере Сәмәрканд вилаятендә Дәһбид ягындагы Хәртәнк исемле авылда. Минем туганым Газизҗан, Эстәрлебаш кешеләреннән Хәбибулла бине Харис бине Нигъмәтулла Тукай, Гобәйдулла бине Зәйнулла Галикәй белән 1297 елда, Бохарадан барып, зиярәт иткән идек. Бу көннәрдә әлеге авылны Хуҗа Исмәгыйль исеме белән йөртәләр. Максатлары – Мөхәммәд бине Исмәгыйль, димәк. Кабере гади генә ихата эчендә. Янында кечкенә генә күләгәлек бар. Тарикать шәехләре каберләре белән чагыштырганда, кадер-хөрмәттә. Аллаһ аны рәхим кылсын һәм китаплары безгә файда бирсен.

Касталани хәзрәтләренең [тулы исеме] – Әхмәд бине Мөхәммәд бине Әбү Бәкер бине Габделмәлик бине Әхмәд бине Мөхәммәд бине Хөсәен бине Гали. [Һиҗри] 851 елда туган, [һиҗри] 923 елда солтан Сәлим Госманның сугыш белән Мисырны яулап алу көнендә вафат. Аллаһ аны рәхим кылсын.

[...].

Бу күркәм шигырьләрне Мәүләви Габдрахман әл-Җами «Нәфәхат әл-әнс»тә сәеде Әхмәд әр-Рифагый Рифагыя тарикате

башлыгы хәзрәтләренә нисбәт иткән. Хәтта бу шигырьләрне ишеткәч, дөньядан китүен риваять иткән. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Мәүләви хәзрәтләре Рифагый хәзрәтләренең тәрҗемәи хәлендә мондый көчле гыйбарәне искә ала: «Бөек дәрәҗәләр, сөөнәт юлы хәлләре иясе, Аллаһ аңа бик күп гадәттән тыш хәлләр күрсәтә, әйберләрне үзгәртә, гаҗәп хәлләр чыгара. Ләкин яраннары арасында төрлесе бар иде, кайберләре утка керә, еланнар белән уйный иделәр. Бу шәехтә юк иде, аның изге иптәшләрендә дә юк иде, шайтаннан Аллаһка сыенабыз. 578 елда вафат булды». [...].

Әлеге шәех нәселеннән Исламбулда солтан Габделхәмид II гасырында офыкларга билгеле сәед Әбел-Һөда хәзрәтләренә [һиҗри] 1327 елда юлыккан идем. Ният турындагы хәдисне ишетеп, тоташу чылбырын алдым. Бу кеше бик акыллы һәм хисле, даһи адәм иде. Солтанны буйсындырган һәм госманлы мәмләкәтендә булган вазыйфаларда абруйлы иде. Инкыйлабтан соң күтәрә алмады, [һиҗри] 1328 елда булса кирәк, вафат булды. Аллаһ рәхим кылсын.

## Уфа милләтләр бүлегенә Нәзарәт тәгълиматы, мәртәбәләре һәм архивы хакында мөрәҗәгать

Декабрьдә Уфа милләтләр бүлегенә, 28 ноябрьдә Габделхәй Дәүкәев имзасы белән җибәрелгән фәрманнарына каршы, язу җибәрелде. Эчтәлеге: «Сезнең бу әмерегез нинди сәбәпкә нигезләнгән, нинди ният белән яздыгыз?», – дигән мөрәҗәгатьтән гыйбарәт.

Декабрьдә архив турында «Ноябрь башыннан Мәхкәмәнең эшләренә кимчелек килүе, архивта дәфтәрдән, Мәхкәмә өчен кирәклеләрдән тыш, уннан артык төр рәсми кәгазь барлыгын әйтеп, Мәркәздән катгый бер мөгамәлә булганча, үз ихтыярыбызга бирелсен» дигән эчтәлекле бер рәсми кәгазь исполкомга Мәхкәмә исеменнән җибәрелде.

## Уфа имамнары белән коммунистлар арасында дини бәхәс

28 декабрьдә башкорт-татар идарәсеннән: ««Диннәр тарихы һәм коммунизм» турында 31 декабрьдә җомга көн сәгать биштә фикер алышу булачак, үз тарафыгыздан ике кеше җибәрегез», – дип рәсми чакыру килде. Чакыру кәгазен китерүче ике кеше, тиз җавап

[бирүне] сорасалар да, кәефем дә җирендә булмаганга, кәгазь Мәхкәмә исеменә булганга: «Хәзер җавап бирә алмыйм, бер сәгатьтән мәҗлесебез булачак, шунда ирештерермен, иртәгә шушы вакытта җавап җибәререм», – дидем. Үзара аз фикер алышудан соң: «Казый Кәшшаф Тәрҗемани белән ахун Җиһангир Абызгилдинне җибәрү ничек булыр, шаять, лаек булырдар», – дип сөйләшсәк тә, иртәсендә 29 декабрьдә Уфа имамнары чакыртып, киңәшләшү сурәтен үтәп, соңгы карар мондый рәвешчә булды: «Бу фикер алышу – тик Уфа коммунистларының үзлегеннән генә чыгарылган бер фикер алышу мәҗлесе. Элек руслар христиан голямасын, шулар эчендә епископны да чакырып, бәхәсләшсәләр дә, алар тик җирле даирә әһелләре. Диния нәзарәте исә – ул дәрәҗәдән югары, гомумрусия мөселманнары өчен бердәнбер олуг Мәхкәмә. Шунлыктан бу җирле фикер алышуга, үзлегеннән катышмыйча, карамагында булган җирле имамнарга тапшыру дөресрәк күренә». Чакыруга каршы шулай җавап язылды: «3285 номерлы 1920 елның 29 декабрендә сезнең 671 номерлы чакыру кәгазегез Диния нәзарәтендә яхшы каршы алынып, җирле дин галимнәренә ирештерелде. Фикер алышулар да әдәп белән булганда, һәр тарафка тигез сүз форсаты бирелгәндә, дин галимнәренең бу фикер алышуга катнашуларына Диния нәрзарәте ярдәм итә. Ләкин алдан тема-мәсьәләләр тәфсилләбрәк белдерелсә иде».

Коммунистларның бу фикер алышу һәм бәхәс мәҗлесе төзүләре, үз фикерләренчә, хөкүмәт фикере дә булганлыктан, гади халык арасында сөйләп, көчләренә халыкны ышандырырбыз, [дигән] хыялында төзелгән булса кирәк. Юкса хаклыкны эзләү һәм аңа ияррү максаты белән түгел. Мондый бәхәсләшүгә уңай карамау дөрес булса да, төрле начар уйлардан саклану максаты белән уңай җавап бирелде. Мәхәллә имамнары үзләре тарафыннан беренче мәхәллә имамы Җиһангир бине Тальхә Абызгилдин белән икенче мәхәллә имамы Зыятдин (Пәрваз) Камалине билгеләделәр. Зыятдин әфәнде, кайбер мәсьәләләрдә хосусый фикерләре булса да, мондый гомуми мәйданда хосусый фикерләрен куеп, күпчелек мөселманнар фикере буенча хәрәкәт итәчәк булды. Хәзерлек күрер өчен форсат аз булса да, хаклык тарафыннан сөйләячәк кешенең йөрәге, әлбәттә, нык булганлыктан, бу ике әфәнде, кыюлык белән барачак булып, карар бирделәр. Чыннан да, җомга көн милади елның соңгы көнендә Галия мәдрәсәсен тәмамлаганнардан коммунист Фәйзи Вәлиев идарәсе астында кичке биштә мәҗлес ачылган. Зур җәмгыятьтә

коммунистлар тарафыннан Һади Килдебәк сүз башлаган. Бер ярым сәгать кадәр сөйләгән сүзенең эчтәлеге илаһиятне инкарь итү, диннәрнең барысы да – кешеләрне тоту һәм бәйләү өчен ясалма бер тәртип һ.б. кебек бозык маддәләрдән гыйбарәт. Элекке хикмәтияләре вакытында ук мәйданга чыгып, илаһият хикмәт ияләре тарафынан ук кире кагылып һәм юкка чыгарылып, көле көлгә очырылган сафсата фикерләр. «Шифа» һәм «Ишарәт» кебек Ибне Сина китапларында аерым бүлек белән «Барлыкның хисләр белән чикләнүне юкка чыгару» дигән темада бу фикерләр юкка чыгарылды. Исламга кадәрге чор вакытындагы вәхши фикерләр эчендә булып үткән уйлар. Боларга каршы, динне яклап, Зыятдин әфәнде сөйләде. Бер-ике маддәсен санамаганда, сүзе яхшы чыкты, коммунага яхшы һөҗүм бирде, диярлек сөйләде. Ләкин яһуди һәм христианлык турында кирәгеннән артык, кайбер әдәптән чыгып, бу мәҗлестә яһуди һәм христианлыкны байтак ясалма икәнен күрсәтте. Мәрьямне (аннан Аллаһ риза булсын) бер еврейка (яһүди), Гайсә галәйһиссәламне 2 аршин 4 вершоклы еврей малае дип әйтү кебек кабәхәт гыйбарәләр дә булды. Бу сүзләрдә максаты, яшьләрнең яһүди һәм христиан сурәтләгән илаһка нәфрәтләнеп караганга, исламча илаһ башкача, дип әйтүе. Исламча илаһне бөтен бар ителгән нәрсәләрне электрик көч кебек чолгап алган бер көч кебек күрсәтте. Гүя ки, аңа коммунистлар мондый илаһны без инкяр итмибез, диярләр, имеш. Бу безнең Зыя мулла шул яңалыгы белән исламны коммунизмга якын күрсәтергә була. Аллаһ сакласын. Динне фәнгә туры китерү максаты белән, күпчелек яшьләр уйлауларынча, фәннең һәр кагыйдәсе катгый, шуңа динне һәм Коръәнне фәнгә туры килерлек итеп аңлатырга кирәк, диюләренә ялагайланып, ерак аңлатуларга кереп китте. Җөмләләреннән берсе – Адәм белән Хәва аерым шәхесләр түгел, туфракта пәйда булган кеше җенесе, Кабил белән Һабил дигәннәре дә яхшылык куәте белән начарлык куәтеннән гыйбарәт, дигәннәре кебек ялгыш аңлату юлына кереште. Җәннәтнең мәгънәсен сораганда: «Бу галәм искереп, кояш галәме бетү хәленә килеп, яңадан бер җир шары төзелеп, сөт һәм бал елгалары агар дәрәҗәдә мәңге, һәр ләззәтләре камил һәм нигъмәте тулы булачак. Шул җирнең исеменә җәннәт диеләчәк», – диде. Язылган кайбер әсәрләрендә бу бидгатьләре артыгы белән искә алына.

Сүз ахырында бер коммунист та хосусый үзенә: «Ислам исеменнән хосусый үз фикерегезне сөйләдегез, гомум мөселманнар фикерен сөйләмәдегез», – диде.

Мөселманнар тарафыннан мулла Кәшшаф казый Тәрҗемани һәм мулла Сабир казый Хәсән дә азрак сөйләделәр. Кайбер дини мәсьәләләрне хәл итәргә керешсәләр дә, коммунистлар боларга бик аз вакыт биргәнлектән, тикешенчә аңлата алмадылар.

Үз ораторларына иркен вакыт куеп, мөселманнарга аз гына вакыт бирүләренең хикмәте – ачык бер мөгамәлә.

Нигъмәт бине Хәким исемле бер коммунист Зыя әфәндедән соң, аңа каршы булса кирәк, бераз сөйләмәкче булса да, халык чыгып китә башлаган. Ахырда корал көче белән халыкны туктатып, көчләп, аның сафсатасын ишеттергәннәр. Шулай да, халыкка коммунистлар зур тәэсир итә алмаганга охшый. Читтән тыңлаган битараф кешеләр: «Коммунистлар җиңелеп калдылар, динне никадәр бозарга тырышсалар да, морадларына ирешә алмадылар», – дип сөйләделәр. Ачык хакыйкатькә каршы ачык ялганның нинди тәэсире булсын. «Әйт: хаклык килде һәм ялган юкка чыкты, ялган юкка чыгучан». [Коръән, 17:81].

## Дини бәхәскә әзерлек

Киләчәк җомгада икенче мәҗлес булачак икән. Бу мәҗлеснең темасы «Дин вә фән» исемендә булып, киләчәк [мәҗлес] «Ислам вә коммунизм» исемендә булачак икән. 1921 елның 2 гыйнварында кич белән минем бүлмәмдә Уфа имамнары җыелып, киләчәк мәҗлес өчен кайбер каршы тору сүзләре турында фикер алыштылар. Үткән вакыйгалар турында да азрак сүз булды.

Бишенче мәхәллә имамы Хаҗиәхмәд әфәнде: «Сөйләячәк кешеләр билгеләнсен дә, сөйләнәчәк сүзләр (коммунизмга каршы катгый кире кагулар, ислам һәм коммунизмны практик куллану чараларына тыгылмыйча) төзелеп, бер гыйльми дини комиссиягә тәкъдим ителсен, һәркем үз сүзләре белән мәйданга чыкмасын», – диде.

Алтынчы мәхәллә имамы Хәбибулла Әхтәм: «Социализм хәзер бер фән дәрәҗәсенә ирешкән, кире кагуга керешү яраклы булмас, бары исламны яклап сөйләргә кирәк», – дип әйтте.

Казый Сабирҗан Хәсән: «Фән диелгән нәрсәгә каршы сөйләү гаеп түгел, фәннең математикасы катгый булса да, башкаларының барысы да катгый түгел, үзгәреп торганнары да аз түгел, шунлыктан социализмның фән дәрәҗәсенә килүе каршы тормауны тиешле итми», – диде.

Мин әйттем: «Безнең вазыйфа – исламны яклау, исламны дөрес рәвештә бәян итү һәм аның шөбһәсез хак һәм дөрес икәненә иман һәм ышану булганлыктан, җиңүгә ышанып, кыюлык белән кагыйдәләрен һәм нигезен исбат итүгә керешү тиешле. Ислам кагыйдәләренең кайбеләре белән коммунизм җимерелсә, җимерелсен, бик яхшы. Кайбеләре туры килә икән, аннан да качмыйбыз, кире какмыйбыз. Ләкин баш хәрәкәт сызыгын билгеләргә кирәк, хосусый фикерләргә нигезләмичә, бәлки Китап һәм Сөннәттә тапкан кагыйдәләр белән эш кылыныр. Мөселманнарның иманнарын саклау, коммунизмга авышуларына каршы тору тиешле. Сөйләнәчәк сүзләр гомуми рәвештә үз мәҗлесебезгә күрсәтелеп үтсен, соңыннан үзара каршылыкка сәбәп булмасын».

Кайберәүләр тарафыннан коммунизмга каршы ачык сөйләү мөмкин булмас һәм фәлән-төгән дигән шөбһәләр әйтелүенә каршы, мулла Кәшшаф казый: «Диспут мәҗлесе булгач, ярдәм булырга тиеш. Һәр тараф оппонентын юкка чыгара һәм кире кага алырга тиеш. Хөкүмәтнең бу турыда тарафдарлыгы юктыр», – дип җавап бирде.

Зыятдин әфәнденең янә сөйләргә теләге күренде. Коммунистлар белән йолкышып хәбәрләшүе һәм диалогы да беленде. Коммунистларның күпчелеге аның шәкертләре булганлыктан, бәхәс мәҗлесендә башка имамнарның катнашуын тиешрәк күрүләрен, үзеннән бераз курыкканнарын да аңлатты. Зыя әфәнде, табигый, үз шәкертләре белән, коммунист булсалар да, авырлыксыз дустанә мөгамәлә итә булса кирәк. Аларның да хәлфәләре белән шулай риясыз сөйләшүләре булгалый икән.

Сабир казый янында булган бер мәҗлестә укучыларыннан Фәез Вәли белән Галяү Ходаяр Зыя әфәндегә сөйләгәннәр: «Мәдрәсәдә безгә дин рухын бирә алмадың, торган саен динсезлегебез артты. Бәлки тәфсир уку башлагач, шаять, дингә мәхәббәтебез артыр, дип йөрсәк тә, капма-каршы фараз чыкты. Тәфсир укый башлагач, бигрәк диннән мәхәббәтебез сүнде», – дигәннәр. Зыя әфәнде «Минем вазыйфам – дини мәгълүмат бирү, гамәлегез һәм мәхәббәтегез минем вазыйфам түгел» дигән эчтәлектә җавап биргән.

Мәдрәсәсен дини «Галия» мәдрәсәсе исеме белән йөртсә дә, дин мәсьәләләрен азрак өйрәтсә дә, дин өйрәтү мәсьәләсендә тырышлык күрсәтә алмавы, шәкертләренең күбесендә күренгән динсезлек һәм ышанмаучылык тәрбиясенең әсәре булуы уйланыла. Бу

кадәр дин сөюче һәм дин әһеле булган гади мөселманнарның нәфрәте дә – бер хәвефле хәл. Йә Аллаһ, безне сакла.

Алтынчы гыйнварьда коммунистлар идарәсеннән «Һәр ике тарафтан берәр генә оратор нотык сөйләячәк» дигән хәбәрне язу белән белдерделәр. Мәҗлесләре дә дүшәмбе көн 10 гыйнварга калдырылган икән. Шул киләчәк мәҗлестә гомуми диннәр белән коммунизмның иҗтимагый хәлләргә кайсының яраклырак булуы сөйләнеп, булачак өченче мәҗлестә ислам белән коммунизм чагыштыруы булачак икән. Йә Аллаһ! Дингә ярдәм итүчегә ярдәм бир, динне ярдәмсез калдыручыны ярдәмсез калдыр.

## Зыя Камалиның дин хакындагы кайбер фикерләре

8 гыйнварда бер мәҗлестә Зыя Камали белән очраштык. Казыйлар һәм байтак мосафирлар бар иде. Мәҗлес турында сүз чыгып, Зыя мулла: «Үткән мәҗлестә аның каршысында әүвәлге диннәрнең дә асылда күктән иңгән дин булып, ул исә ислам булганын, соңыннан бозылып адашканнарын, «Иннәд-диинә гыйңдәллаһил-исләәм» [«Аллаһ каршында чын дин – ислам»] [Коръән, 3:19] аятен укып, каршылык күрсәткән мулланы гаепләде. Гүя ки, хата фикер һәм хата сүз белән каршылык күрсәтте. Элекке диннәрдә ислам булганы юк. «Ислам» һәм «мөселман» – тик Мөхәммәдкә иңгән дингә бирелгән исем һәм атама. Хәдистә килгәнчә, исламда китапларга ышану, илчеләргә ышану игътибарга алына. Адәм пәйгамбәр вакытында нинди китаплар һәм нинди илчеләр бар, бөтен ышанасы нәрсәләр аңлатылып беткәч, барчасына ислам диелгән һәм ышанучыга мөселман дип әйтелгән» дигән эчтәлектәге сүз сөйләде.

Җавап бирүче мулла үзе мәҗлестә булмаганга, мин, аның сүзен алып, бераз аңлаттым: «Шулай ки, күктән иңгән диннәрнең барысы да бертөрле бераллалык асылына нигезләнгән дин, Ибраһим пәйгамбәргә һәм аның иярченнәренә үк «мөслим» исеме бирелгән. Пәйгамбәрләрнең барысы да исламны акрынлап бәян иткәннәр. Һәр пәйгамбәр заманында, замандашларының әзерлегенә күрә, хөкемнәр арттырылып килгән. Расулулла (аңа Аллаһның сәламе һәм салаваты булсын) белән камилләшкән. Адәм галәйһиссәлам нигезен корган дин акрынлап Мөхәммәд галәйһиссәлам белән тәмамланган. «Бүген сезгә динегезне камилләштердем, нигъмәтемне тәмам итттем, һәм сезнең өчен исламннан дин буларак риза булдым» аяте [Коръән, 5:3] белән тәмам булуын белдерелгән. Дөрес хәдистә, исламны бер

бинага охшатып, һәркайсы пәйгамбәр кирпечләрен сала килеп, бер почмагындагы салынмаган һәм тулмаган җирен Рәсүлуллаһ (аңа Аллаһның сәлам һәм салаваты булсын) килеп тутыруы, шуның белән ислам һәм күк дине бинасы тәмам булуы искә алынган. Ягъкуб пәйгамбәр галәйһиссаләтү вәс-сәлам: «Әй, улларым, Аллаһ сезгә дин сайлады, шуңа күрә мөселман булган хәлдә генә үлегез», – дип васыять калдырган. Аятнең тулысы: «Ибраһим милләтеннән үзен акылсыз кылган кешедән башка кем йөз чөерер? Без аны бу дөньяда сайлап алдык һәм ахирәттә дә ул изгеләрдән булыр. Раббысы аңа әйтте бит: «Буйсын (мөселман бул)! Ул җавап бирде: «Галәмнәр Раббысына буйсындым (мөселман булдым)! Моны Ибраһим балаларына васыять итеп калдырды һәм Ягъкуб та: «Әй, улларым, Аллаһ сезгә дин сайлады, шуңа мөселман булган хәлдә генә үлегез» [Коръән, 2:130–132]. Бу аятьләрдән Ибраһим галәйһиссәлам һәм Ягъкуб галәйһиссәлам диненә «ислам» исеме һәм дин тотучыларына «мөслим» исеме бирүен Коръәннән ачык мәгълүм була.

Бу сүзләргә каршы: «Алардагы ислам бары «Әсләмту вәҗһи» мәгънәсендә булган. Безнең ислам башка, бөтен хөкемнәр бәян ителеп, шушы җыелмага бирелгән исем», – дисә дә, ләкин ислам бөтен очракта да «Әсләмту вәҗһи»дән алынган мәгънә белән. Соңгы термин буенча «яһүд галәме, христиан галәме, ислам галәме» диюгә карарга кирәкмәс, бу сүз аеру өчен, үзгәртелеп беткән диннәрнең капма-каршысы итеп искә алына.

Ислам галәме дип әйтүебез, чынлыкта, күктән иңгән динне саклаучы, илаһи канунны үзгәзртмичә, бозмыйча алып баручы булганлыктан, безгә бу хөрмәтле исем лаеклы булган. Яһүд һәм христиан исә, үзгәртүләре сәбәпле, илаһи канунны тиешенчә сакламаганнар, бигрәк тә Рәсүлуллаһ (аңа Аллаһның сәлам һәм салаваты булсын) турындагы шатлыклы хәбәрләрне һәм аның сыйфатларын үзгәртеп, бозып, исламнан читтә калганнар. Пәйгамбәрләренә бирелгән исламны, рәхмәтле булмыйча, ташлаганга, пәйгамбәрләре ышанган хәзрәт Мөхәммәд галәйһиссәламгә ышанмаганга, бу исемнән мәхрүм калып, ялганнарына ишарә итүче яһуди һәм христианлык исемнәре белән калганнар.

Сүз арасында шәригатьнең ачык хөкемнәренә каршы башка сүзләре дә булды. Әлеге мәҗлестә булган җавапларына каршы халык тарафыннан һәм коммунистлар тарафыннан аңа әйтелгән: «Син мөселманнар тарафыннан сөйләмисең, бәлки үзең корган дин һәм үзең читкә чыгып аңлаган ислам буенча җавап бирәсең». Бу диалог-

та да шул сүзләр яңадан әйтелде. «Мин халыкның саташкан диннәре буенча җавапка керешмим, аларның ышануларын акларга керешелсә, төгәлләве мөшкел булачак», – диде.

Мин әйттем: «Коммунистлар халыкны адаштырмакчы булалар. Шунлыктан халыкны котыртудан саклау, ышануларына зарар китермәү тиешле. Халыкның иманы һәм ышануы – ачык Коръән һәм дөрес хәдисләр. Шуның буенча аклау һәм яклау тиешле. Китап һәм Сөннәткә ябышу белән оппонентка каршы торучы зур таянычка таянган, ахырдан, җиңүче булачак, аннан курку кирәкмәс», – дидем.

Бу адәмнең язучы фәрештәләр турында да чит фикере барлыгы аңлашылды. Читтә бер дустына сөйләгәне ишетелде: «Халык ышанганча, Сур [быргысына] өрергә бер фәрештә, фәлән эшкә бер фәрештә һәм шул рәвешчә. Болай күп вак илаһларга ышанып, Аллаһны баш илаһ, дип әйтү була», – дигән сүзе колагыма керде. Ләкин мәҗлестә бар сүзенә, бигрәк тә мәйданга куймаган сүзләренә каршылыкны күтәрә алмаганга, башка вакытка калдырылды. Бу мәсьәлә өчен җитәрлек каршы сүз шул: Аллаһ Тәгалә дөнья һәм ахирәтне мөстәкыйль Бар итүче һәм Хикмәтле идарәче булганы хәлдә, дөнья эшләрен ачык сәбәпләргә бәйләп, барлыкка китерүен һәм идарә итүен үзенә гадәт иткән. Падишаһлар кую, мәгънәви төзеклек өчен пәйгамбәрләр җибәрү һәм болардан түбән дәрәҗәлерәк вәкилләр кую ысулын өйрәтүе күркәм идарә һәм бөеклекне күрсәтү һәм дәлил китерү өчен. Шулай ук мәгънәви эшләрдә һәм күренми торган галәмдә бөек фәрештәләрне хөзмәтче итүе – кешеләрнең Аллаһтан турыдан-туры тәгълимат алуга әзерлекләре юклыгы һәм илаһи идарәне күтәрә алмаулары сәбәпле. Җан алу өчен Газраил, Сурга өрү, җил җибәрү өчен Исрафил, гыйлем ирешетерү өчен Җәбраил фәрештәләрне, суларга, диңгезләргә һәм тауларга һәм башкаларга махсус фәрештәләр булулары – Аллаһның солтанлыгын һәм бөеклеген күрсәтүче эшләр, илаһилыкка, бераллалыкка каршы нәрсәләр түгел. Һәркайсы – изге аятьләрнең эчтәлеге, дөрес хәдисләрдә килгән сүзләрнең мәгънәсе.

## Икенче мәртәбә дини бәхәс

10 гыйнварда дүшәмбе көн янә икенче диспутлары булды. Бәхәс темалары «Диннәр һәм коммунизм» иде. Ярым-йорты белгән фәннәргә тотынып, күктән иңгән динне катгый булган фәнгә каршы, дип җимерү максатына керештеләр. Дин күктән һәм илаһтан

булмыйча, халыкның хәлләренә карап, арадан чыккан бер акыллы кеше тарафыннан куелган бер канун, дип күрсәтергә тырыштылар. Боларның динсезлекләре – бик элекке заманнан бирле килгән динсезлек. Иранда, Сасанилар дәүләтендә, Кикбар заманында пәйдә булып, улы Кихсроу Әнуширвән [тарафыннан] барча иярченнәре белән үтерелгән мәшһүр Маздак – бу коммунизм юлының бөек борынгы тарафдары. Ислам чорында Мөгътәсыйм билләһ заманында янә Иранда барлыкка килеп һәм күп кенә көч туплап, ислам дәүләтенә байтак борчу биргән Бабәк тә шул җөмләдән булды. Бәхәс мәҗлесләрендә дә шул фикерләрен көчәйтү максаты белән, фәкыйрьләрне яклау, халык арасын тигезләү, дөньяны һәм дөньяда булган нәрсәләрне махсус кешеләр өчен генә кылмыйча, бөтен кеше арасында уртак кылу максатында булып (фәкать телдә генә), сөйлиләр. Гомум халыкны, адаштырып, җәлеп итәргә телиләр. Кулларыннан килгәнчә ислам һәм башка диннәрне җиңү максатында булалар.

Мәҗлестә булучы дин әһелләренең бәян итүенә күрә, дин турында чиксез әдәпсез сөйлиләр, Аллаһ һәм илчеләре турында көферлек һәм динсезлекнең төрлеләреннән тартынмыйлар икән.

Имамнар тарафыннан билгеләнгән ораторлар Җиһангир Абызгилдин, Зыя Камали әфәнделәр яхшы сөйләгәннәр. Динне яклау һәм коммунизмга бәрелүдән, урыны белән, тар-мар итүдән курыкмаганнар. Зыя әфәнденең бу мәҗлестәге сүзләре чиктән чыкмаган, кыю булган.

### Дин белән фән һәм боларны куллану мәсьәләсе

Өченче мәҗлестә коммунизмны ислам белән чагыштырулары фаразлана икән. Гыйлемсез динсезләр Мөәссир, Мохтар, Фәгыйль, Кадир, Санигъ, Хәким булган Аллаһның барлыгына нигезләнгән исламны аңлый алмаган динсезләр һәртөрле сафсата, шөбһәләр кылып, күрерләр, күпчелеге фараздан гыйбарәт булган «табигыйлар», «материалистлар» тарафыннан мәйданга куелган фәнни кагыйдәләргә тулысынча таянып, дингә, ахирәт хәлләренә, пәйгамбәрләр могҗизаларына каршы килеп маташалар. Кайбер фәнгә авышкан имамнар ике юлны берләштерү өчен тырышсалар да һәм шул фикер белән яшьләрне дингә тарту теләгендә булсалар да, бу фикернең ахыры начар, куркыныч, өметсез.

Бер салкын өмет күренә. Динне хикмәт һәм фәлсәфәгә туры китерәм, дип, диннән саташкан, ышануыннан язган кешеләр элекке тарихта күп күренәләр. Бу заманнарда да современный фәннәргә туры килү теләге белән Коръән аятьләрен ялгыш аңлатучы һәм мәгънәсен бөтенләй үзгәртүче кешеләр юк түгел.

Элек могътәзилә фиркасы акылга артык бирелеп, дөрес хәдисләрне инкяр [итү] һәм Коръән аятьләрен ялгыш аңлату бәласенә очрап, байтак мәсьәләләрдә Сөннәт юлыннан читкә чыкканнар. Һәр заманда аларның мисаллары була килгән. Безнең бу илебездә Муса һәм Зыя әфәнделәр дә берничә мәсьәләдә фән бәласенә төшеп, динне Европада карар тапкан фәннәр буенча аңлыйбыз да, аларны исламга якынлатабыз, дип хатага төштеләр. Үзләренең читтән чыккан фикерләрен: «Дини текстлар, катгый дәлил булмаса, тышкы мәгънә буенча аңлана», – дигән кагыйдәгә яраклы булырга тырышып маташтылар[32]. Хәзер асыл төп Коръән аятьләрен аңлатырга максат итүләре, фәннәре математика кебек катгый бүлектән түгел, ә фаразлы кагыйдәләрдән, кемгәдер ияреп, кабул ителгән мәсьәләләрдән, Коръән аятьләрен тышкы мәгънәсеннән чыгарырлык сәламәт вөждан һәм туры йөрәк белән ышанырлык нәрсәләр түгел. Хәтта фикер, тәҗрибә үзгәрү белән алмашканнары да аз түгел. шунлыктан андый фәннәр чыккан саен Коръәнне ялгыш аңлату һәм аның мәгънәсендә үзгәреш ясау акыллы кеше эше, мөэмин гамәле түгел. Ихлас мөэмингә, тиешле гарәп теле фәннәренә, борынгыдан килгән тәфсирләргә туры китереп, Коръәнне аңлап, ул-бу шөбһәләргә бөтенләй колак салмыйча, чын иман һәм ышану белән нык йөрәкле һәм җәннәткә лаеклы (иншалла) булу тиешле. Әлбәттә, күркәм нәтиҗә шунда. Ахырдан, һәркайсы фән кешесе (инсафлы булу шарты белән) шул катгый һәм илаһи өйрәтмәләр булган Коръәнгә ышанырга мәҗбүр булачаклар. Без мөселманнарга мондый динсезләр тарафыннан һәм атеистлар тарафыннан китерелгән котыртуларга кулай туры килсә, фән, тарих белән җавап бирү яхшы, ләкин бу динсезләр үзләре дә чып-чын фән кешеләре һәм гыйлем әһелләре түгел. Аннан-моннан ишеткән, вак-вак китапчыклар, табигать белеме нөсхәләрен укыган белән генә фән дигән булып маташалар. Шунлыктан болар каршысында хакыйкый

---

[32] Боларның хаталарын юллы рәвеш белән Томски имамы мулла Хәмзә ахун яхшы бәян итеп китаплар язды, инсафлы кешеләр өчен канәгать булырлык дәлилләр торгызды. Аңа Аллаһның рәхмәте булсын.

бәхәс мөмкин түгел. Фәнни бер хәрәкәткә көчләнмичә, югарыда язылганча, ике кагыйдәне нигез [итеп] тоту тиешле:

1. Аллаһ һәрнәрсәне үз ихтыяры белән бар иткән, һәрнәрсә аның ихтыяры буенча, теләгенә туры килеп, үзенең вазыйфасын үти. Буу сәбәпләр галәмендә Аллаһның ихтыяры һәм теләге белән һәрнәрсә туры килгән сәбәбенә бәйле булса дә, Аллаһ аны башка бер яшерен сәбәпкә бәйләргә һәм гадәттән тыш рәвешенчә барлыкка китерергә мөмкин.

2. Мөхәммәд галәйһиссаләтү вәс-сәлам – Аллаһ тарафыннан, хатадан сакланган һәм шайтан явызлыгыннан, бозык фикердән һәм начар максаттан имин һәм сәламәт ителеп, җибәрелгән мөгаллим һәм туры юлга юнәлтүче. Аның Аллаһтан китергән Коръәне, илаһи ярдәм белән сөйләгән хәдисләре – барысы да хакыйкый хикмәт һәм нык фәлсәфә. Бер-ике кеше күчергән хәдисләре дә материалистлар нигезенә күрә, ышанычлы һәм документальлек ягыннан көчле һәм нык. Димәк, без бу ике нык крепостька кергән хәлдә, үзебезне сакларга тиешле. Динсезләр, канәгатьләнмәсәләр, канәгатьләнмәсләр, мондый сөйләшүләр белән туры юлда булмаган, хакны эзләүче булмаган кешеләрне файдаландыру мөмкин түгел. Үз җәмәгатебезне шулай сакласак, зур файда.

## 1920 елда булып киткән имтиханнарның кыскача җәдвәле

Имам, урта дини мөгаллим – 5 кеше, имам, башлангыч дини мөгаллим – 32, фәкать имам – 30, мөәзин һәм башлангыч дини мөгаллим – 28, мөәзин фәкать 85, бөтенесе – 180 була. Укыр өчен чыгарылганнар: имам – 27, мөәзин – 25, барысы – 52 була. Бөтен имтихан мәҗлесенә кергәннәр – 232 әфәнде.

## Вакытлы курсларның һәм мөгаллимнәрнең вазыйфалары

Уфада вакытлы курсларда тәфсир, хәдис һәм фикыһ укытып дәвам итәм. Көн саен ике-өч дәрес укытам. Иртән Мәхкәмә ачылганчы бер дәрес, ахшам белән ястү арасында күбрәк ике дәрес укытыла. Бу гыйнвар урталыгында мөгаллимнәргә Мәхкәмә тарафыннан айлык иганәләр өләшелде. Һәр дәрескә бишйөз сумнан билгеләнгәнгә күрә, шул хисап белән бирелде. Минем исә ниятем бушка укыту иде. Ләкин казна хөкемендә булган Диния нәзарәте

хәзинәсендә рәсми билгеләнгән айлыкларыбыз алына килсә дә, чыгымнарыбыз өчен җитәрлек булмады. Бөтен вакытыбыз Мәхкәмә хезмәтенә багышланганлыктан, аның хезмәте өчен бәйле булуыбыздан, заманасына күрә, җитешле микъдарга казнада хакыбыз бар иде. Бу тулысынча үтәлми, шунлыктан дәресем эш хакы өчен булмаса да, бу сылтау белән кайбер хокукым кулыма керсә, зыян итмәс. Алганым, чынлыкта, дәрес түләве булмас, ә ярдәм булыр. Шаять, шөбһәсез, дөрес һәм хәләл булса кирәк өмете белән, 70 дәрес өчен 35 мең сум (өч пот арыш оны бәясен) кабул итттем. Ләкин, Аллаһ Тәгаләгә мактау белән, укытуда ниятем акча түгел иде, бер тиен булмаганда да, максатым һәм карарым укытуда иде. Бугенгәчә илле ел кадәр бушлай укыта килдем. Бары шәкертләрдән һәм башкаларда бүләк юлы белән хасил булган нәрсәне кабул иттем. Аллаһ мине гафу итсен.

## Курслар эшендә начар вакыйга

Бу гыйнвар урталыгында мөгаллимнәр комиссиясеннән Уфа имамнары Җиһангир һәм Һади әфәнделәр дәрес башына биш йөз сумны азсынып, мең сум булмаганда укытмыйбыз, дип дәресләрен калдырдылар. Бу хәбәрне ишеткәнемнән соң, суфый кыяфәтле, җәдитлекнең күп эшләреннән качучы, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаучы Һади әфәндене яныма җәлеп итеп, сораштым. Мең сум сорап, ким булганда, дәресне калдырачагын, башка кәсеп белән шөгыльләнәчәген белдерде. Бу әфәнделәр башта да мең сум кирәк булыр, съезд 300 сум билгеләп, дөреслеккә туры килмәде, дисә дә, бераз сөйләшүдән соң 500 сумга риза булачакларын аңлаттылар. 1,5–2 ай чамалы укытудан соң мөгаллим юк вакытта төрле яктан төпләнеп, юк хәлләрен бар итеп, 30–40 мең сум айлык чыгым тотып, укып торган шәкертләрнең хәлләрен тар-мар итеп, бу рәвешле укытудан качу бу әфәнделәрнең дәрәҗәләренә яраклы түгел иде. Аларның хезмәтләренә ышанып ачылган курсларны болай борчылуга калдырмыйча, дәресләрен дәвам итеп, сатулашсалар да, макксатларына җитәрләр иде. Бу хәлдән чын ният һәм тырышлык юклыгы күренеп тора. Милләтнең насыйхәтче һәм вәгазьчеләренә яраклы булмаган рәвеш. Аллаһ безне һәм аларны Үз рәхмәте һәм юмартлыгы белән төзәтсен.

Соңра 18 гыйнварда рәсми мәҗлестә гыйнвар башыннан башлап теләгәннәренчә дәрес башына бер меңнән бирергә булдык. 19 гыйнварда дәрес укыта башладылар.

**Икътисади мәсьәлә**

1919 елда Эстәрле ягында Хәмзә утары авылының имамы мулла Гыймран Хәмзәзадәгә бодай икмәк өчен егерме мең сум акча биргән идем. Әлеге кеше туры ниятле, тырыш кеше булганлыктан, минем өчен бодай чәчкән, Аллаһ әмере белән 60 поттан артык бодай булды. Чәчү, уру, сугу кебек чыгымнары өчен орлыклары белән чыгымы туксан мең булды. Димәк, урынында һәр пот 1500 сумга торган. Бүген әлеге имам үзе кулыма дүрт пот бодай оны ирештерде. Бик ак, саф он, быел җыелган бодай оны. Уфа базарында бүген дә моның бәясе (вальцовка оны) утыз мең сум икән. Аллаһ Тәгалә бу кадәрдән һәм калганыннан хәерле файдаланырга тәкдир итсә иде. Утыз биш пот кадәрен, кәсеп төре юлы белән, игәр өчен калдырып, егерме пот кадәренә он итеп китерүне киңәшләшеп сөйләшенде. Аллаһ Тәгалә бу имамга да хәерле әҗер бирсен. 25 гыйнвар көннәрендә мулла Гыймран әфәнде янә дүрт пот кадәр он китереп шатландырды. Гошерен үтәп, файдалануына керешелде, шуңа Аллаһка шөкер булсын.

15–20 гыйнварларда башка шәһәрләрдәге кебек артык кыйммәтчелек булып китте. Арыш оны 15 меңгә, гади бодай 25, печән поты 4 мең чамалы, салам поты 2 меңнән артык, атланмайның кадагы 4 мең, елкы мае 3,5 мең, чәй кадагы 30 мең, бал 3,5 мең, тоз кадагы бер меңгә якын. Бер аршин ситса 4 мең, бер шешә сөт 2 меңгә иреште. Бу хәлләр алдагы көннәрдә янә зур куркынычлыкларны күрсәтәләр. Аллаһ, безгә мәрхәмәтле бул! Бөтен ягы урман белән капланган Уфа вилаятенең шәһәрләрендә бер колач (сажень) утынның 18–20 мең сум булуы һәммәдән гаҗәплерәк.

Бу хәлләр һәм моның килеп чыгуы халыкның исраф һәм башка гөнаһларына каршы Аллаһ тарафыннан гыйбрәт күрсәтү булса, кайбер изгелек ияләренең догалары бәрәкәтендә күтәрелүе, яхшылыкка әйләнүе ихтимал. Әгәр газап кебек булса, ахыры начар булу мөмкин. Олысы, кечесе бу хәлләрдән зарлана, ләкин чарасына керешмиләр. Коры шикаять файдасыз, сүз һәм зарлану белән юаналар. Чарасы халыкның үз кулларында, үз кесәләрендә кебек сизелә. Гыйбрәт алу, Аллаһка кайту, сынык күңел, яшьле күз белән чынлап

тәүбә итү, элекке исрафка корылган тормышлардан кайту, чын ислам һәм иман юлына керү тиешле. Шул тәкъдирдә, Аллаһтан өметтер ки, рәхмәтен иңдерер, төзәтер, һәрнәрсәне тиешле рәвеш юлына куяр. Юкса спекулянтлар үз эшләре белән алданыр, бу кадәр кыйммәтчелекне ганимәт дип белеп йөрсәләр, башкалар да тәүбәсез булып, ничек тә акча юнәтеп, егерме-утыз мең сумга бер кадак чәй алу теләгендә булсалар, сыйлану, назлану кайгысында йөрсәләр, йөрәкләрен, бөтен барлыкларын инсафлык һәм вөҗдан юлына кертәмәсәләр, өмет ерак күренә.

## Мәгарри һәм Муса, Зыя әфәнделәр

Берничә ел элек Әбел-Галяэ әл-Мәгарри [исемле] философ шагыйрьнең «Лузумият» китабы аның бердәнбер яратучысы Муса әфәнде Җарулла Биги кызыктыруы белән бастырылып, бу шагыйрьнең тәрҗемәи хәле мөстәкыйль бер китап булып, казый Ризаэтдин әфәнденең мактаулы каләменнән «Мәшһүр ирләр» сериясенә кертелгән. Заманында халык арасында байтак шау-шу булып, «Дин вә мәгыйшәт» журналы хуҗалары зур гына хәрәкәткә килеп, кире кагулар язып шөгыльләнделәр. Шул ук вакытта уфалы Зыя Камали, элек «Фәлсәфә» исеме белән язган һәм тараткан мәкаләләре өстенә, «Дини тәдбирләр» исемле бер китабын язып, чыгару юлына кереп, әдәпсез рәвештә мәйданга чыкты. Муса әфәнденең дә төрле урындагы мәкаләләре, «әһле сөннә вәл-җәмәгать» юлы булып танылган, Коръәннең ачык мәгънәсе һәм дөрес хәдисләрнең мәгънәләре булып урнашкан мәсьәләләр турында ят фикер күрсәтеп, мәйданга фикерләре беленеп, күп дулкынлануга китерде.

Мин электән үк бу ике зат (Муса, Зыя) турында ят фикергә тартым, һич файдасыз мәйданга бер нәрсә чыгару теләге сизә идем. Табигатьләрендә бертөрле читкә китүне күрә идем. Шунлыктан мәкаләләренә игътибар белән карарга вакыт бирә алмадым. Барча мөселманнарга, шаять, начар тәэсирләре булмас, дип ышандым. Риза әфәнденең исә Мәгаррине ихтирам итүе булса, фәкать гыйльми адәм, артык яки заманы өчен сирәк була торган кеше дип карап кына, халык арасыннан онытылып китмәсен, дип кенә кылган хезмәте. Бу фикерләр туган вакытта ук «Дин вә мәгыйшәт» журналында төрле мәкаләләр һәм күп кире кагулар язылса да, мин бу журналның һәртөрле кешегә урынсыз каршы чыгулары, гыйлемгә нигезләнмәгән бәрелүләре дә күп булганлыктан, аның сүзләренә күп колак

салмый идем. Низаглар күңелгә борчу салучан, мөселманнар хакында начар фикер тудыручан булганлыктан, андый мәсьәләләрдә актык зарурлык булмаганда, колак салучан түгел идем.

### Томски Хәмзә ахун китаплары һәм тәрҗемәи хәле

Әлеге бидгать фикерләргә каршы вакытында ук мулла Хәмзә бине Әмин әл-Хәмиди әт-Томи тарафыннан берничә китап язылды һәм матбугат мәйданына куелса да, бу көнгәчә укырга кулым җитмәгән иде. Быел [һиҗри] 1339 елның рабигыль-әүвәл аенда әлеге автор тарафыннан китаплары кулыма иреште. Болар шушы китаплар: «Тәнбиһел-әгъбия фи тәһарәти әнсәб әүлия»[33], «Изәләтел-әүһәм фи нөзули Гайсә галәйһиссәлам»[34], «Әд-дурарел-бәһия филгакыйдәтил-исламия»[35], «Фаслел-хитаб фи тәэйиди гакаидил-әсхаб»[36], «Тәнбиһел-габи вә тәдмиред-дәни фи ибталит-тәдбирид-дини»[37]. Бу китапларның бишенчесеннән [кала] башкасын укыдым. Коръән һәм дөрес хәдисләргә тотынып, яхшы бәян иткән. Инсафлы кеше канәгатьләнерлек [итеп] язылган. Аңа Аллаһның рәхмәте булсын.

Автор мулла Хәмзә ахун Кышкар шәкертләреннән, шул ук Кышкар мәдрәсәсендә байтак дәрес укытып, соңра Тара шәһәрендә дәрес биргән, мулла Рәхмәтулла бине мулла Йосыф Янгурази шәкертләреннән хөрмәтле бер кеше. Чыгышы Пенза вилаяте Җамбар ягы, Алты авыл исеменә кергән Решетино авылыннан булып,

---

[33] Мәгарринең Адәм балаларының нәсел-нәсәпләрен гомуми рәвештә гаепләү кебек тоелган шигыре мөнәсәбәте белән, Мәгарринең начар эшен, һәм аны яклаган казый Ризаэтдин һәм Муса әфәндегә каршы язуларны үз эченә ала.

[34] Муса Биги һәм иярченнәренең Гайсә галәйһиссәламнең иңүен инкяр итүләре сәбәпле, хакыйкатьне күрсәткән.

[35] Шул ук Бигинең һәркайсы кяфернең котылуы, Гайсәнең кадакланган, үтерелгән, иңмәс дип әйтүе кебек төрле хаталарына каршы яхшы дәлилле исбатлаучы китап.

[36] «Фаслел-хитаб» Муса Бигинең хаталарын, бигрәк тә Гайсә галәйһиссәламгә бәйле мәсьәләләрдәге хаталарын бәян итә, «Гакаид Тахави»ны тәрҗемә итә һәм башка темаларны да искә ала.

[37] Бу китап исә Зыя Камалиның «Дини тәдбирләр» исемле китабына каршы язылган. Бу китабы да яхшы файдалы, «әһле сөннә вәлҗәмәгать»нең ышануларын күрсәткән.

Себер мөһаҗирләреннән. Аң һәм сиземләве дөрес, акыл фәннәрендә оста, соңгы заманнарда дини гыйлемнәрдә дә яхшы белем хасил иткән.

Мәктәпләр һәм мәдрәсәләрне төзекләндерү ысулларын башлаганда, безгә яраклы хәрәкәттә булды. Мәхәббәт итеп, зур уллары Габдрахман белән Хөҗҗәтелисламны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә тапшырды. Бу фикердә булуына үз хисе өстенә, тарикать шәехе Зәйнулла Рәсүли хәзрәтләренең дә, бәлки, тәэсире булгандыр. Соңгы заманнарда яшь мөгаллимнәрнең чамадан тыш эшләре, мәктәп һәм мәдрәсә идарәләрен үз кулларына алып, дөрес һәм дөрес булмаган төрле нәрсәләрне иҗат итүләре, байтак кешеләрнең нәфрәтләрен уятты. Әлеге Хәмзә әфәнденең дә мөгаллимнәрдән, мәктәпләрдән аерылуына һәм кайбер яшь фикерле мәхәллә халкыннан бераз читтә калуына сәбәп булды. Шул арада «Дин вә мәгыйшәт» журналына нисбәтләнүе белән фикерсезлек, реформа дошманы исемен хаксыз күтәреп, фикер ияләренең начар карашларын җәлеп иткән иде. Хәтта 1917 елда Мәскәүдә булган зур съездда күпчелек тавыш белән указлары алынырга тиеш күрелгән 10 кешенең[38] берсе дә шушы зат иде. Соңгы Уфа Диния нәзарәтендә 1917 елның 15 июнендә мөдәррисләр һәм мөгаллимнәрдән төзелгән Шура мәҗлесендә дә Нәзарәт әгъзаларына шул мәсьәләне искә төшергәннәр иде. Моның өстенә, ул вакыттагы пайтәхеттә булган Шура тарафыннан да Мәскәү карарын үтәү өчен рәсми кисәтү ясалган иде. Ләкин Нәзарәт бу эшләргә кабул [итмәде] һәм яхшы караш белән карамады, эшеннән алырдай анык кимчелек булмады. Фикер төрлелеге, чыганак аермасы сәбәпле, җәзалау шәригать буенча да, мантыйк буенча да тиешле күрелмәде. Шунлыктан бу кешенең һичкайсына Диния нәзарәте (гәрчә араларында Нәзарәткә һәм кайбер әгъзаларына хосусый золымлы дошманлыклары булганнары булса да) зарар ирештермәде, һәркайсын яклады. Һәм бу эшендә нәзарәт хаклы булды. Алар ислах һәм тәрәккыйга зыянлы

[38] Буби имамы Габдрахман Кәримов, Түнтәр имамы Ишмөхәммәд Динмөхәммәдов, Оренбург имамы Мөхәммәдвәли Хөсәенов, Томскида Хәмзә ахун Хәмидов, Чиләбе өязендә Аксак ишан улы Габделхәй Корбангалиев, «Дин вә мәгыйшәт» журналының мөхәррире Галләмеддинхан Исламов, Чиләбе өязендә Аксак ишан Гобәйдулла Корбангалиев, Сафа Баязитов, Чишмәдә Гайнелислам Мөхәммәдҗанов, Иркутскида мулла Байморадов.

кешеләр булсалар да, шөбһәсез түгел иделәр. Тәэвилне кабул эш күрделәр, гәрчә тәэвилләре урынлы булмаса да, алардан җинаятьләре садир булса да, Мәхкәмәнең сайланып яңа башланган заманда андый җәзалар үч төсен алачак иде.

Мулла Хәмзә – мулла Ишмөхәммәдкә караганда, акылы сәламәтрәк, мантыйгы дөресрәк, хәйлә һәм мәкере азрак зат. Әсәрләре дә, аның әсәрләренә караганда, аңлаешлы һәм якынрак. Хәтта ул вакытта Оренбург Шурасы «Дин вә мәгыйшәт» журналын туктатырга чара итеп, Мәхкәмәи-шәргыягә: «Дин күзлегеннән журналны файдалы табасызмы, зарарлы табасызмы?», – дип мөрәҗәгать иткән иде, Мәхкәмә җавап бирмәде. Халык арасында артык шау-шу чыгаруга риза булмыйча, җавапсыз калдырды.

Диния нәзарәте әгъзаларының барысы да прогресс яклы кешеләрдән төзелсә дә, һәр эштә уртача хәрәкәтне, фанатизмсыз сәясәтне үзенә юл [итеп] тотты. Һаман да шул юлда хәрәкәт итүдә.

Ни рәвешле булса да, яхшы һәм файдалы укыту, дин укыту белән беррәттән кирәкле кадәр дөньяви мәнфәгатьләр һәм аң арттыру өчен төрле фәннәрдән мөселман балаларын хәбәрдар итү. Көч җиткәнчә динне саклау, әхлак һәм ислам әдәбен шулай ук саклау – Диния нәзарәтенең даими мәсләге һәм сайлаган юлы. Әй Аллаһ! Безгә хаклыкны хаклык итеп күрсәт һәм аңа ияргергә насыйп ит, ә ялганны ялган итеп күрсәт һәм аннан читләшергә насыйп ит, әмин. Мулла Хәмзә әфәнденең бу әсәрләре – яхшы китаплар, хаталанучыларның читкә тайпылуларын яхшы күрсәткән. Изге Коръән һәм пакь Сөннәт юлы белән сөннәт һәм җәмәгатьнең таләпләрен күрсәткән, дин һәм изгелек ияләрен яклаган, Аллаһның рәхмәте булсын!

* * *

Быел гыйнвар урталарында казый Кәшшаф Тәрҗеманине Диния Нәзарәте кайбер дини йомышлар өчен Мәскәүгә җибәрәсе иде. Ләкин хөкүмәт идарәләре рөхсәт бирми торалар. Рәсми булмаган кешеләр өчен йөрергә хөкүмәт рөхсәт бирә алмый, сезнең йомышыгыз монда да үтәлер, дигән кебек файдасыз булган аңлатулар белән юатып, канунга каршы золымлык кылып, юлга чыгарга мөмкинлек бирмиләр. Инде җирле идарәнең ике олы кешесе Исполком идарәсенә гариза биреп карыйбыз. Бу 24 гыйнварда әлеге гариза бирелсә дә, һаман илтифат алулары беленми. 27 дә хәбәр алдык, һаман карамаганнар.

## Имамнарга мәҗбүри хезмәт

24 гыйнварда Уфа имам һәм мөәзиннәрен хөкүмәт канцелярия хезмәтенә чакырып, хәбәр иттеләр. Муллалалар аптырап, Диния нәзарәтенә килеп, Нәзарәт тарафыннан хөкүмәттән гафу итү теләп, бер проект тәкъдимен сорадылар. Мәхәлләдә һәр вакытта хезмәт булып тора, өйлә намазы һәм башка намазларда мәчеттә булу кирәк. Дин ирегe бирелгәч, халыкның дини эшләрен үтәүгә кысанлык тудыру яраклы эш түгел, дип, 26 гыйнварда бер проект җибәререлде. 25 гыйнварда кайбер имамнар хезмәттә дәвам итә башладылар. Гомуми җан хисабын башлаячаклар икән. Шул хезмәттә имам һәм мөәзиннәр май башына хәтле язу эшендә булачаклар икән. Ахыры хәерле булсын.

## Вакытлы курсларны туктату

26 гыйнварда җирле хөкүмәтнең төрле милләтләр идарәсенең рәисе Габделхәй Дукаев мөселманнар эше идарәсе рәисе Хаҗиәхмәт Бугаев имзалары белән кәгазь килде: «Вакытлы курсларны бу кәгазьне алу белән туктатасыз», – дигәннәр. Гүя ки, дәресханә өч төрле сәбәп белән гаепләнә: 1) фән укытыла икән (бу көннәрдә генә мирас бүлүнең дөресләү бүлегенә җиткәнлектән, зарурлык булгач, өч дәрес математика укыганнар иде); 2) гаскәр чиратында торган яшьләр курсларга кабул ителгән; 3) мәхәллә халкы һәм курслар рәисләре тарафыннан шәкертләргә авырлык күрсәтелә икән. Мәхәллә халкы тарафыннан фатир бәясе авыррак булган шәкертләргә Нәзарәтнең бер зур өе бирелсә дә, ашау-эчү әсбабы әзер булмаганлыктан, кабул итмичә, төрле фатирларга 4–5 мең айлык бәя белән таралдылар. Рәисләрдән нинди авырлык бардыр, билгеле булмады.

27 гыйнварда казыйлар (Кәшшаф һәм Сабир) барып сөйләштеләр. Артык сәбәп торгызмасалар да, курсларның дәвам итүен теләмәүләре, авырлык белән сәбәп табарга тырышулары аңлашылган. Математика дәресе тик өч дәрес укытылган иде. Өч булса да, дини курсларда булмаска тиеш, диделәр. Рәисләр һәм мәхәллә халкы тарафыннан авырлык дигәннәре шул: авылларыннан күбесе имамлык яки мөәзинлек приговоры белән килгәннәрен ишетеп: «Шәкертләрне мобилизовать итү юлы белән җибәргәннәр», – дип

уйлап, мәхәллә халкы тарафыннан авырлыкка төшерелгәннәр, дип язганнар икән. Аллаһ ахырын хәерле итсен.

* * *

27 гыйнварда зур печән алдым, ун поттан аз гына артык булыр, кырык мең сум түләдем. Мал һәм җан асрау кыен булып тора. Бер сыер өчен һәркөн ике мең сум кадәр чыгым кирәк. Җан өчен шулай ук, бәлки, артыграктыр. Ләкин Аллаһның Ризыкландыручы, Куәт иясе, Көчле икәненә ышанабыз.

Җирле хөкүмәткә 29 гыйнварда вакытлы курсларның тукталганлыгы, туктату өчен күрсәткән сәбәпләрнең ким булганлыктан, мәркәзгә (Мәскәүгә) үзебезне шикаять кылырга лаеклы икәнебезне белдереп, язу җибәрелде.

Сөенеч: 31 гыйнварда (22 җөмәдиәл-әүвәлдә) Эстәрлетамак ягындагы Ялгыз Каен авылы имам-мөхтәсибе мулла Гарифулла бине Заһидулла Ярмәкидән бер хат алдым, бу урында тулысынча күчерәм:

«Кереш өлештән соң: бу 1920 ел рабигыль-әүвәленең беренче көнендә сәхәр вакытында бер төшемдә үземне Диния нәзарәтенең өске кат залында күрдем. Бу вакытта мөфти хәзрәт өстенә ак җөббә, башына ак чалмасын киеп, билен буып, зур өстәленә Коръән кәрим, «Мишкәт» шәриф, «Мөватта», «Тәфсире Хазин» һәм шәригатебездә могътәбәр китапларны һәркайсын ачып салып куйган да, чин касәсе белән гаять тә саф су алып, бик ак мамык белән бу суга манып, өстәлдәге китапларның кер-тузаннарын сөртә. Бу вакытта Ризаэтдин, Кәшшафетдин, Сабир хәзрәтләр, Мөхлиса абыстай – һәркайсылары бар. Ярдәмләшү сыйфаты белән билләрен буып, хезмәткә әзер торалар иде. Остаз мөхтәрәм мөфти сөрткән китаплар шулкадәр нурлана иде, һич тә тел белән сыйфатлау мөмкин түгел. Бу вакытта бәндәгез (Гарифулла) дә казыйлар артындарак карап, күп вакытлар бу хезмәтләрне күреп тордым да әдәпле генә килеп: «Хәзрәт, бу эшне сез эшлисез, әгәр мәрхәмәт итеп миңа бирсәгез, мин дә ярдәм итәр идем», – дип әйтүемә: «Хуш булыр», – дип, миңа мамык белән суны биреп, мин дә бераз бу хезмәтне үтәдем. Минем сөрткән китаплар да нурлана иде. Ләкин (остаз мөхтәрәм) мөфти хәзрәт сөрткәнчә булып бетмәсә дә, шулай да, кер-тузаннары һич тә калмый иде. Күп вакыт бу хезмәтне үтәп торганда, Хак Сөбханәһү вә Тәгаләгә гыйшык һәм мәхәббәт төшеп: «Аллаһү әкбәр, Аллаһү әкәбәр, лә иләһә илләллаһү вәллаһү әкбәр, Аллаһү әкбәр, вә лилләһил-хәмде», – дип уянып киттем. Шуңа нигезләнеп, хәзрәт, сездән

күп өметләр өмет итәм. Җәнабе Хак [Аллаһ] гомер газизләрегезне биреп, барча мөселманнарга канәгатьләнерлек файдаларны насыйп итсә иде, әмин».

Февраль башында Уфаның беренче мәхәллә имамы Җиһангир Абызгилдин, Уфада бер атна кадәр тотылганнан соң, юлдашлары Әхмәд бине Газыйм Баймакай һәм аның хатыны Гайшә бинте Галәветдин Хурамшин Сарытави (Мирай исеме белән билгеле), элекке Касыйм һәм Петроград имамы Фатих бине Хәсән һәм башкалар Эстәрлетамак шәһәренә озатылыдылар. Мулла Җиһангирнең гөнаһы, шаять, юктыр. Әлеге Фатих баҗасы булу мөнәсәбәте белән, бераз аралашулары шөбһә тудыргандыр. Мәкәйләр – байтак сәүдә һәм икътисад кешеләре. Мәркәз хөкүмәт тарафыннан зур хөрриятькә вәкаләтләре булып, байтак эшләргә катышкан булулары ихтимал. Аллаһ ахырын хәерле итсен. Дәһшәтле заман. Аллаһ, безне заман дәһшәтләреннән сакла!

## Фетнә хакында хәдис. Фетнәнең файдалары

Бу 3 февраль көнне бер мөнәсәбәт белән фетнәләр турында бер хәдис искә төште. Шәех Әхмәд Зыятдин Көмешханәви хәзрәтләре «Гараиб әл-әхәдис» исемле китабыннан күчергән, «Ләтаиф әл-хикәм» исемле шәрехендә аңлаткан. Шуны бу урында язуны яраклы күрдем. Хәдиснең асылы Мәнәвинең «Көнүзел-хакаик фи хәдиси хайрил-хәлаек» китабында искә алынган: «Фетнәне начар дип күрмәгез, ул монафыйкларны юк итә», ягъни һәлак итә. Әд-Дәйләми «Фирдәвәс» китабында риваять кыла.

«Ләтаифел-минән»нән: «Фетнәне начар дип күрмәгез – фетнә ул, дини файдасы булмаган килеш, кешеләрне төрле хәлләргә кертү, михнәткә дучар итү, патшага каршы чыгарга өндәү кебек, кешеләрне ватаннан китәргә өндәү. Әгәр дини файдасы күренсә, рөхсәт ителә, шуңа да «ахырзаманда аның сәбәпле монафыйклар һәлак булыр», – диелгән.

[...].

Бу хәдис тикшерүчеләр тарафыннан каралган, хәзер хәтеремдә юк. Ләкин мәгънә ягыннан дөрес булуы бик мөмкин. Фетнәләрдә бәндәләрне сынау бар. Иманлы һәм имансыз, Аллаһка тапшырылучы һәм тапшырылмаучы кешеләр фетнә вакытында ачыклана, мәйданга чыга, аерыла. Аллаһның аларга каршы дәлиле була. Аллаһның бәндәләрендә серләре төрле!

## Мәхкәмә шәргыянең бер еллык хисабы

2 февральда Мәхкәмә шәргыянең 1920 елның беренче гыйнварыннан 1921 елның беренче гыйнварына кадәр бер еллык хисабы күренде.

Кыскача: бер ел эчендә керем: 8268849 сум 42 тиен. Тотылган 5263307 сум 92 тиен. Казнада калды: 1921 елга карап, 3005541 сум 50 тиен.

Бу сумма эчендә Мәхкәмәнең кулдагы ит һәм он – 794035 сумлык, әгъзаларда бурыч һәм әмәнәтләр – 848074 сум, башкаларда бурыч – 240000 сум, мөхтәсибләрдә һәм съезд әгъзаларында бурыч – 240000, барысы – 12093099 сум. Саф сумма – 912442 сум. 1921 елның гыйнвар эчендә керемнәр – 1234387, чыгымнар – 1292913, аерма – 58526 сум.

## Вакытлы курслар шәкертләре

Вакытлы курсларны җирле хөкүмәтнең деспотизмы белән туктатылып, шәкертләрнең кайберләрен имамлыкка, кайберләрен мөәзинлек өчен имтихан кылдык. Кайберләре фәкать гыйлем алу өчен генә килгәнлектән, өметсез булып таралдылар. Биш-алты кеше миннән хосусый дәресләр укып торалар.

Төрле милләтләр идарәсе рәисе, дәресханәне туктатучы Габделхәй Дәүкәйнең сүзенә күрә, рәсми булмаган укытуда зыян юк. Тәфсир дәресен дәвам иттерәм. 5 февральдән сишәмбе көннән бирле ахшам намазыннан соң ястү азанына кадәр бер сәгать ярым кадәр укытыла. Һәркөн бер бит кадәр укыйлар. Бер дәрәҗәдә аять шәрифәләрнең мәгънәләре бәян ителә. Күп тәфсирләр күреп, күп сүзләр риваять итеп укытылмый, ә үземдә булган кадәр, элек тә күп тәфсир күреп хасил булган гыйлем белән яхшысын сайлап алып һәм нәтиҗә ясап, аңлатыла. Дөрес булса – Аллаһның ярдәме, хаталансам, Барудизадәнең кимчелеге һәм гаебе. Аллаһ аны гафу итсен!

## Самарада дин укыту

12 февральда Мәхкәмәи шәргыя өчен Самарадан 304496 сум иганә ирешге. Вәкилләре мәхәлләнең мәчет эшләрен башкаручы Габдешшәкүр әфәнде Муллин сүзенә караганда, мәчетнең түбән катында ике йөз кадәр ир һәм кыз балалалар дин дәресләре белән

мәшгуль икән. Моннан хәбәр табып, коммунистлар туктатырга булып, әлеге мәктәпне Совет мәктәбе итү максатында булсалар да, мәхәллә халкының бердәмлеге көчле, нык булганлыктан, нәтиҗәгә ирешә алмаганнар. Җомга вакытында килгән ике коммунист катырак сөйләп, «пулемет» сүзләрен телләренә ала башлагач, халыкның даулавыннан куркып, мәчеттән чыгып киткәннәр. Вак коммунист татарлар яһүдләргә һәм русларга хуш килер өчен, һич зарурлык булмыйча, шундый халыкны дулкындырырдай хәрәкәтләр ясыйлар. Аллаһ дөреслекне белүче, болар яки монафыйк коммунистлар яки акыл һәм тәрбиядән мәхрүм кешеләр кебек тоела.

18 февральдә Кәшшаф казый Мәхкәмәбезнең йомышы белән Мәскәүгә сәфәр кылды. Бик озак көттергәннән соң гына рөхсәт язуы бирделәр. Шул ук вакытта Петропавелга сәфәр итүчеләргә вокзалда билет сатмаганнар. Поезд Чиләбегә кадәр генә йөри икән. Аргы якта тынычсызлык, юллар өзек икән. Бер атнадан бирле халык арасында имеш-мимеш хәбәрләр йөреп тора иде, бәлки, дөреслеккә чыгар, һәрнәрсәнең ахыры Аллаһтан.

## Очрашу әдәпләре мәсьәләсеннән бер кечкенә, ләкин әһле аз бер сүз

Безнең Казан һәм Болгар халкыбызда ике кеше юлыксалар, олысы да, кечесе дә, аермасыз: «Исәнме, сәламәтме?», – диешү гадәт. Кайсы сорашырга өлгерсә, сораша башлый, бер кагыйдә белән түгел. Күп вакытларда ике тарафтан да шул «исәнме», «сәламәтме» сүзләре белән үткәреп, Аллаһны мактау, шөкер итү я саулык һәм башка хәлләре бәян ителмичә дә үтә торгандыр. Кем сораша башларга тиешлеген уйлаучы да бармы, юкмы – мәгълүм түгел. Безнең халыкның ясалма мәдәният һәм тәрбия исемнәрен күтәреп йөреп тә, шундый тупас кына очрашу белән үткәрүләре күп үк була. Бу эштә бер табигый һәм тумыштан булган бер тәртип безнең мәдәнияттән төшеп киткән. Тәрбиячеләр, тәрбия ысулларын язучылар тарафыннан да тәрбия кагыйдәләренә кертелмәгән.

Башта шул: хәл сорау халыкның теләвенә күрә, яхшы булса – Аллаһка шөкер һәм мактау, киресе булса – бертөрле ярдәм күрсәтү нәтиҗәсе өчен булырга тиеш. Шунлыктан бу хәл сорау кодрәтлерәк саналган, олы кешедән башланырга тиеш. Яшь һәм кечкенә кешеләрнең олыдан хәл соравы артык бер эш хисап ителергә мөмкин. Бәлки әдәптән тыш бер мөгамәлә булуы ихтимал. Олы кешенең

хәлен сорап, кечкенә кеше нинди эш күрә ала, аның начар хәленә нинди ярдәм һәм нинди яхшы тәэсир бирә ала? Борынгылар арасында бер кеше икенчесеннән: «Ничек тордың?», – дигәненә «Ә син минем өчен нәрсә эшли аласың соң?» дигән җавап ишеткәч, сүзнең үткәнен, үзенең гаҗизлеген аңлап, һичкемнән хәл сорамаска сүз бирүе турында кайбер тәрҗемәи хәлләрдә күренде.

Бу өлкәдә булган табигый әдәп, бозык мәдәнияттән сәламәт калып торган, мөгамәлә кылу һәм очрашу әдәбендә безнең мәдәниләрдән күп урыннарда алда торган төрекмән һәм казакъ бәдәвиләребездә ишетелә һәм күренә. Аларда үзләреннән олы һәм карт кешедән башлап хәл сорашу юк. Хәтта төрекмәннәрдә бу өлкәдә игътибар янә артыграк икән ки, ике кеше очрашканда, сүз башлауны һәм хәл сорашуны икенчесенә биреп, икенче тарафны зурлап һәм ихтирам итеп: «Сора, сора», – дип, икенчесе дә моңа: «Сора, сора», – дип, араларында кабатлап торуда, соңрак кына берсе сорый башлый икән. Казакъларда бу кадәр булмаса да, олыларын ихтирам итү һәм алардан алдан сүз башламау, аларга һәрвакыт һәр эштә юл куюлары – гадәт. Сартиядә исә гади халык арасында олылары сүз башлап хәл сорый, кешеләр «әлхәмде лилләһ» [«Аллаһка мактау»] кебек сүз белән җавап бирәләр. Кечеләрнең олылардан саулык һәм башка хәл сораулары бик сирәк була. Зур галимнәр һәм остазлар арасында исә олылар илтифат һәм түбәнчелек итеп: «Ни хәлдә», – дигән кебек сүзләр белән сораганда, яшьләр һәм шәкертләр сикереп, урыннарыннан калкып, кулларын кушырып: «Коллык, тәкъсир», – диләр. «Коллык» сүзе аларда зур илтифат һәм шатландыруга каршы: «Илтифат итүегезгә һәм игътибарыгыз белән бәхетле итүегезгә шатландым һәм куандым», – дип әйтү, түбәнчелек күрсәтү урынында кулланыла. «Әш-шәкаик» авторы шәех Мөхәммәд Бәдәхшинең тәрҗемәи хәлендә бәян иткән бер вакыйга – бер дәрес, гыйбрәт. Шулай бервакыт солтан Сәлим Әүвәл[39], Димәшкъ, Шамны яулап алгач, бу шәехнең өенә барган, ләкин араларында һич сөйләшү булмаган. Икенче мәртәбә янә барган. Бу тапкырда шәех хәзрәтләре әйткән икән: «Һәр икебез – Аллаһның бәндәсе, ләкин шул аерма бар ки, синең аркаңда халыкның күп авыр йөкләре бар. Минем аркам җиңелрәк. Димәк, халыкның хокукын югалтмаска тырыш». Солтаннан бу очрашуларында сүзсез торуны сайлавының сәбәбен сорагач,

[39] Шәех Бәдәхши Шамда [һиҗри] 922 елда вафат булды, Аллаһ рәхмәтенә ирешсен. Солтан Сәлим [һиҗри] 926 вафат.

әйткән ди: «Сүз ачу олы кеше тарафыннан булырга тиеш. Минем аңа нисбәт белән олуглыгым юк, шәех тә әдәп күрсәтте, түбәнчелек күрсәтеп сүз ачмады». Янә әйткән: «Солтан Хөсәен Бәйкра нәселеннән булган Бәдигыззаман, Рум иленә килгәндә, миңа килде. Мин һич сөйләмәдем, ул да әдәп йөзеннән сөйләмәде». Солтан Сәлимнең, аңа Аллаһның рәхмәте булсын, шәехләр белән әдәпле, түбәнчелекле тотуы һәм шул хәлен янында булганнарга туры аңлатуы дин һәм инсафлык әсәреннән, иман куәте һәм дөрес ышану нәтиҗәсе. Аллаһ аңа хәерле әҗер бирсен!

Бу мәсьәләгә мөнәсәбәтле бер мәсьәлә – баласына әдәп өйрәтәм, дип хыялланган кешеләрнең кайберләре килгән-очраган кеше белән баласына күрешүне (кул бирешүне) искәртә, хәзерге заманча кешесенә күрә, шәригатькә һәм Сөннәткә туры килгән булса, русларга охшап, үзеннән олы кешегә бала бер кулын суза, олы кешенең кулын тота, гүя ки үзенә буйсынырга ант бирүче падишаһ яки шаһзадә. Бу рәвешнең тиешсезлеген җитешсез атасы да аңламый, шулай күрешсә, балам әдәп өйрәнә, олылар белән очрашу ысулын белә, дип куана. Наданлык һәм ахмаклык!

Күрешүнең асылы – дустын, кардәшен яклау, аны саклау һәм бәладән коткару өчен кулыннан алудан алынган күркәм мөгамәлә булса кирәк. Шунлыктан олы кеше бер кулын сузса җитә. Көчле кеше ихтирам тиешле урында ихтирамы тиешле кешегә ике кулын сузып, кулын үбәргә тиеш. Моның күрешүе кул бирү, олының кулын, ихтирам белән алып, үбүдән гыйбарәт булырга тиеш.

Кыскасы: күрешүдә олы кеше кул бирсә генә, кулын сузса гына, кечкенә кеше кул сузарга тиеш. Олы кешенең кул бирүе башкасын яклавына алу мәгънәсендә булып, кечкенәләрне зурлау һәм ихтирам юлы белән булырга тиеш. Шунлыктан, ихтирам урынында булганга, кечкенәләр олылар белән ике кул биреп күрешергә тиеш. Бер кул гына сузу – хөрмәтсезлек күрсәтү.

Рәсүлуллаһтан (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) бер кул белән, ике кул белән күрешүләр күчерелеп, урынына күрә, куллану өчен һәркайсы рәвешне күрсәтү булган булса кирәк. Бу әдәп – табигый буларак та аңланырга тиешле мәсьәлә. Европаның тәрбиялерәк фиркасына катышкан кешеләрдән ишетүемә күрә, күрешү вакытында бер кешене зурлаганда ике кул бирәләр икән.

Кешеләргә нәрсә сузу, кулына нәрсә бирү мәсьәләсендә дә бу мәгънәне игътибарга алырга кирәк. Ихтирам белән сузганда, ике кул белән тотып, кайтышрак булганда уң кул белән тотып, сул

кулын бер аз ияртеп, кечкенәләр белән мөгамәләдә тик бер кул белән бирү җитә. Бохара һәм башка Төркестан шәһәрләрендә чәйне бирүче, берәм-берәм тәкъдим иткәндә, баш кешегә уң кулы белән биреп, бераз ихтирам белән бирәсе булганда, уң кулына беләгенә яки беләзегенә кадәр кулын ияртеп тәкъдим итә. Зур кешеләргә тәкъдим иткәндә, ике кулы белән тотып тәкъдим итә. Башка нәрсә тәкъдимендә дә шулай. Бу – бер нәзек әдәп. Безнең халыкта бу әдәпне кылу бөтенләй юк. Бер тарафта әйткәндә, аңлаучы да аз булыр. Иминлекне Аллаһ сәламәт хис белән тудыра.

## Янә ГубЧКга чакыру

21 февральдә көндез сәгать бер тулганда, озын кылычлы, мылтыклы, батыр бер солдат кинәт, хәбәрсез кабинетка килеп керде дә, бер кәгазь сузды. Бер сәгатьтән соң ашыгыч [рәвештә] ГубЧКга чакырган. «Нигезле сәбәптән башка кичексәң, күзәтү астына алынырсың», – дип язылган иде. Хәзерге хөкүмәтнең, аеруча ГубЧКның эше ихтыярсыз булганга, байтак курку булды. Күңелгә дулкынлану керде, аны-моны карап, төрле ихтималларны күздә тотып, сәгатенә бардым. Хатыным дулкынлануыннан, ни булса да бергә булу максаты белән, минем өчен тәрҗемәче дә була алганга, бәргә барды. Бүлмәсенә кереп биш-ун минут кадәр көткәннән соң, җавап алучы килде. Бу сорауларны бирде:

– Тирә-якта булган оешмаларга акча бирәсеңме? Бәләбәйдә съезд ясарга фәрман җибәрдеңме? Тирә-яктан чыгымнарыгыз өчен килә торган иганәләр нинди рәвеш белән килә? Почта беләнме яки казначейство (банк) ашамы?

Мин сорауларга бу рәвешле җавап бирдем:

1. Оешмаларга, читкә акча җибәрмибез, бәлки тирә-яктан зарурлык кадәр генә үзебезгә акча килә.

2. Бәләбәйдә съезд ясарга боерганым юк, бәлки тирә-якта һич җирдә съезд ясатканым юк, съезд ясау, рөхсәт бирү – минем вазыйфамнан тыш эш.

«Фәкать районнарда мөхтәсиб сайлау өчен боерык җибәрәбез», –дигәнемә ул: «Районный гына җыен, аның әһәмияте юк», – диде. Бу мәсьәләдә: «Мөхтәсиблек никадәр көчкә ия һәм никадәр мулла аның кул астында, сайлау рәвеше ничек?», – дип сорашты. Җавабымда шулай аңлаттым: «Кырык-илле чамалы авыллар җыелып, үз ихтиярлары белән сайлап, мөхтәсиб күрсәтелә, сайлануы күпчелек

белән булса, башка яклардан да низамга муафыйк булса, шул кешене мөхтәсиб итеп раслыйбыз һәм билгелибез».

«Кайбер кешеләрне үзегез күрсәтмисезме яки тыймыйсызмы?», – дип сорады.

«Һич кешене күрсәтмибез яки сайланудан тыймыйбыз, сайлауда булган устав буенча хәрәкәт итәбез», – дидем.

«Бәләбәйдә мөхтәсиб бармы, ул мөхтәсибне сайланмаска кушмадыгызмы?», – диюенә: «Мөхтәсиб бар, шәһәрнең мулласы яхшы кеше дип белгәнгә, аның сайлануыннан курыкмыйбыз», – дидем.

3. «Акчалар күбрәк почта аркылы, кайчак банк аркылы килә», – дидем. Моңа каршы үзенең теләген күрсәтте: «Моннан соң акчагыз почта аркылы йөрмәсен, ә казначейство аркылы гына килсен һәм җибәрәчәк акча фәкать казначейство аркылы җибәрелсен», – дип миннән имза алыр өчен әзерләнгән кәгазен укытты. Эчтәлеге: һәр җиргә: «Аакчаны почтага салмагыз, ә казначейтсво аркылы җибәрегез», – дип минем игълан итүем өчен боларга сүз бирү.

Әйттем: «Безнең һәр эшебез әгъзаларыбызның киңәше белән (коллегиально гына) була. Тик минем фикерем генә йөрми. Шунлыктан бу кәгазьне бирегез, башка әгъзалар белән киңәшләшүдән соң, иртәгә имза куеп җибәрермен», – дидем. Башта бераз туктап торса да, соңра риза булып, кәгазьне миңа биреп җибәрде. «Тирәякка белдерүегезнең бер нөсхәсен җибәрерсез», – диде. Мөгамәләсе, Аллаһ рәхмәте белән, йомшак булды. Бу кәгазьне мәҗбүриләмичә иртәгәгә калдыруы, киңәшләшергә дип, имза билгеле булса да, биреп җибәрүе дә – байтак йомшау әсәре. Без дә сәламәт көенчә ГубЧК бинасыннан чыгып, Бөек һәм Олуг Аллаһка шөкер итеп. өйгә кайттык. Аллаһка мактау булсын.

Соңра чарасыз, аларның мәҗбүриләүләрен кабул итеп, 24 февральдә кәгазьләре, имза куелып, кайтарылды. Аларның кушулары буенча тирә-якка: «Акча җибәрсәгез, казначейство аркылы җибәрегез», – дигән кәгазьләр җибәрелде. Аллаһ ахырын хәерле кылсын.

**Бу хәлдән сизелгән әсәр һәм өйрәнелгән сәбәп.** Сентябрьдә булып үткән съезд гомум мөселманнарның Диния нәзарәтенә карашларын яхшыртты. Кайбеләреннән башка рухларын күтәрде, дини хисләрен арттырды. Шунлыктан аерылганнарга илтифат итмичә, элекке Нәзарәт әгъзалары үзләре теләмәсәләр дә, кайбеләре ике арада булсалар да, яңадан бөек ышаныч һәм канәгатьлелек күрсәтteләр. Чыгымнары өчен 35 милионлык еллык бюджет расладылар һәм дә һәр җирдә халык, гомумән, бу съездан хуш булуын белдер-

деләр. Бу хәлләр коммунистларның һәм тарафдарларының планнарына һәм теләкләренә бик каты начар тәэсир бирде.

Шуңа һәр җирдә каршы хәрәкәт максатында була башладылар. Мәсәлән, февраль башында Эстәрлетамак шәһәрендә мөхтәсиб сайлау мәҗлесендә Хәлил Юлдашев исемле бер коммунист, хөкүмәт тарафыннан Нәзарат өчен генә килгән булса да, вазыйфасыннан тыш чыгып, югарыдагы съезд мәсьәләсенә күчеп, «Диния нәзарәте мөселманнар бердәмлеген һәм панисламизмны тергезмәкче була, хөкүмәтнең китешенә балта чаба, дин рухын куәтли, шунлыктан башкортлар өчен аерым шундый Диния нәзарәте зарур, хөкүмәткә файда итсен, хөкүмәт планы белән йөрсен» дигән эчтәлектә каты рәвештә сөйләп, хәтта Диния нәзарәте өстеннән шикаять кылганын да белдереп куйды. Соңра өч маддә тәкъдим итте: 1) мөхтәсиб сайланмасын; 2) Диния нәзарәтенә дип тупланган акчалар анда җибәрелмәсен; 3) 10 мартта гомум Башкортостан съезды тупланып, аерым Диния нәзарәте төзү мәсьәләсендә киңәшләшү булсын».

Халык 1, 3 нче маддәләрен кабул итеп, вакытлы элекке мөхтәсиб мулла Гариф Ярмәковны урынында калдырып торырга һәм 10 мартта гомум Башкортостан дини съездын төзергә карар бирделәр. Бу хезмәт өчен 6 кешедән гыйбарәт [булган] бер комиссия төзегәннәр.

Менә шушы Эстәрле хәрәкәтләре Хәлил Юлдашевның начар максаты һәм Мәркәзгә язган тәкъдиме җирле идарәләрнең саклык күрсәтүенә һәм мине чакырып, җавап алып, акчаларның микдарыннан һәм чыгымнарынан хәбәрдар булып тору фикере кузгалган булса кирәк. Аллаһ башка артык начарлыкларыннан һәм зыяннарыннан сакласа иде.

## Башкортларның махсус Нәзарәт төзүләре

1917 ел урталарыда Уфада булган съездларында Зәки Вәлиди ике дусты белән: «Җирле сәяси хокук-рөхсәт алсак та, Диния нәзарәтеннән аерылачак түгелбез, хәлебезгә күрә, Нәзарәткә ярдәм дә итәчәкбез», – дип рәсми игълан итсә дә, бу мәсьәлә шул ел ахырында икенче съездларында Оренбургта янәдән бер дәрәҗәдә киңәшмәләренә алынып, бер шәйхелислам һәм ике казый сайламакчы булып, казый Ризаэддин бине Фәхреддинне шәйхелислам, Сабир мулла Хәсәни һәм Зыя Камалины казый итмәкче булып, карар чыгарсалар да, бу эшләр (башкортларның төп хокук-рөхсәтләре һәм

Diния нәзарәтенә икътисади һәм идарә көчләре) бик нигезле эш булмаганга булса кирәк, әлеге кешеләр кабул итмәгәннәр иде. Соңра алай-болай кешеләр кулына дини эшләрне тапшырып, мөфтилек һәм казыйлык төземәкче булып, хәрәкәтләре булды. 1918 елда янә безнең Нәзарәткә мөрәҗагать итеп, башкортка тиешле әсбап һәм акчаларын аерып бирүне сорап, ахырдан, бу Нәзарәттән бер урын алып, бер бүлек кебек эш күрергә дә йөрделәр. Ул вакытта Милли идарә бар иде әле. Аларның да бер дә уңай мөгамәләдә буласылары килмәде, шунлыктан уңай җавап бирелмәде. Соңра Зәки Вәлиди бу фикерен алга сөрсә дә, хөкүмәтнең дини мәсьәләләрне үзеннән аеру фикерен саклауга авышса да, соңра 1919 елда Кызыл мәчеттә бер мөфти (Орск ягы Күсе авылыннан Фазыл бине Җәлал), ике казый (берсе Оренбург ягы Саргаяз авылыннан Соруреддин бине Мифтахеддин, икенчесе Эстәрле ягы Ялгыз Каен авылыннан Гыйнәятулла) сайлап куйганнар иде. башкортлардан аз гына төркем аларга мөрәҗәгать белән чикләнсәләр дә, күбрәге һаман Уфадагы Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать белән эш күрәләр иде.

Инде Хәлил Юлдашев элекке Ильминский һәм Черeванский (гомумән, миссионерлар) юлын тотып, исламны бүлгәләргә керешкән. Черeванский 1905 еллардагы фикри хәрәкәт вакытларында төзегән проектында бу Оренбург мөфтилеге дип аталган мөфтилекне бишкә бүлүне хөкүмәткә тәкъдим иткән иде. Аларның миссионерлык рухы исламны бүлгәләр, араларына аерылу салып, дини, сәяси көчләреннән төшерү, бара-бара бөтенләй йоту, югалту иде. Инде төрки-татар исемен күтәргән, ялганлап ислам дәгъвасында йөргән ялганчы коммунистлар бу фикерне алга сөрә башладылар. Боларның ниятләре билгеле. Гади башкортлар, эш урыны һәм дәрәҗәгә кызыккан начар максатлы муллалар да халыкны ваемсыз итеп, бу фикерне алга сөргәләп йөриләр икән. 10 мартта Эстәрле ягында Аллакуәт авылында рәсми съезд ясамакчы булалар. Бу эшләрен тормышка ашыру өчен Эстәрле җирле хөкүмәтнең дә астыртын хәрәкәте кушылып, җитди хәрәкәт бар икән. Нәзарәткә дә ике вәкил чакыру язулары иреште. Ахыры хәерле булсын. Боларның Нәзарәттән аерылып үзләренә дини идарә төзүләре дөрес эшме? Үзләре өчен һәм гомум мөселманнар өчен мәслихәтме? Бу ике сорау турында фикерләү кирәк.

1. Башкортлар өчен якынлык, эшнең тиз үтәлүе кебек бик вак файдалар булыр. Ләкин чыгым ягыннан гомум Башкортстан авырлык күрер. Башкортстаннан бу көнгәчә дә үзләренә бәйле чыгымнар

өлешен дә үтәрлек [дәрәҗәдә] Мәкхәкәмәгә керем булмаган. Бу елларда бигрәк тә таландылар, фәкыйрьләнделәр. Араларында кәсеп ияләре бик аз, икътисадтан ерак халык. Шунлыктан яңадан Мәхкәмә төзеп алып барырлык хәлләре булмас.

2. Галимнәре бик аз. Яхшы мәдрәсә, яхшы тәрбия күргәннәре күренерлек дәрәҗәдә түгел (тик араларына кереп калган башкортланган Казан халкы булса гына). Шунлыктан мондый әһәмиятле дини Мәхкәмәгә лаеклы кеше сайлау кулларыннан килмәс. Үз эчләреннән табылу бигрәк ерак, тик эшләрне гади рәвешчә йөртерлек булса булыр.

1918 елда Оренбургта булган съездларында да бу фикер кузгатылганда, типтәр Зәки Вәлиди тыгылуы белән, типтәр сыйныфыннан Риза, Сабир, Зыя әфәнделәрне билгеләмәкче булганнар иде.

**Гомуми тәэсире.** Ислам нигезләре һәм дини фәлсәфә күзлегеннән, аерылу һәм карышу бүлегенә караган бер бозык хәрәкәт була. Зур бозыклыкның башы булуы бик ихтимал. Русиядә булган ислам галәменең гомумияте белән коммунизмга бирелмичә, рәсми булса да, диннәрендә ныклык белән торуларына риза булмаган Шура коммунист хөкүмәте өчен таләп ителгән нәрсә, исламны зәгыйфьләндерү, рухын сүндерү, арага каршылык һәм аерылу салу өлкәсендә бөек хезмәт була. Бу максат һәм план Романовлар вакытында ук бер дәрәҗәдә фикерләнгән, Черeванский тарафынан каләмгә алынып, Уфа мөфтилеген бишкә бүлү кирәклеген мәйанга куеп, хөкүмәт колагына төшергән иде. Ләкин форсат булмадымы яки мөселманнарның күп заманнан бирле килгән диннәре нокта карашыннан зур әһәмиятле булган Мәхкәмә шәргыяләренә кагылуны сәясәтчә яхшы күрмәделәрме – шул хәленчә, булдырмыйча калдырдылар. Бу Шура хөкүмәте – дәгъвада хөр булган хөкүмәтнең таләп ителмәгән бу Диния нәзарәтенең сәясәтчә әһәмияте зур булса да, аеруча боларның Шәрык тарафына хәрәкәтләре өчен бөтен хәленчә, хөрмәтле рәвешчә дәвам итүе зарур һәм файдалы булса да, хөкүмәт өчен дә кайбер яктан зыян хыялы белән аны бетерергә, христиан дини Мәхкәмәсе кебек бөтенләй кайсын ябарга теләгәннәрен ишетелеп торуда. Ишетелгәнгә күрә, башкорт хөкүмәте Башкортстанга аерым мөфтилек торгызуны тиешле [итеп] күрә һәм рәсми булмаган сурәттә ярдәм итмәкче була икән. Бу эшнең Диния нәзарәтенә һөҗүм булуын уйлап булса, ихтимал. Аллаһ мәкерлекләрен үзләренең муеннарына таксын.

## Башкорт съездына вәкилләр һәм мөрәҗәгать җибәрү

Башкортларның хөкүмәтләре әгъзасыннан югарыда исеме язылган бер коммунистның әйтүе белән (астыртын шул ук хөкүмәтнең теләге белән) бу фикер хәрәкәткә, югарыда язылган кебек киңәшләшүгә куюю өчен бу 10 мартта бер съездлары булачак иде.

Бу съезд кору комиссиясе тарафыннан съездга Нәзарәттән вәкилләр җибәрү тәкъдим ителгән иде. Нәзарәт үз тарафыннан ул тарафта укыту хезмәтендә булган элекке казый Габдулла бине Хәлил Сөләйман, Эстәрле ягы мөхтәсибе башкорт Гарифулла Ярмәк, Эстәрлебаш кантонлыгында мөхстәсиб Шакир бине Харис Тукай, Эстәрле ягында мөхтәсиб Мансур бине Хатыйп Габделхаликъ әфәнделәргә вәкаләт бирде. Аларның шул съездда хаклыкны һәм мөселманнар җәмәгате өчен лаеклыракны яклап, каршылык һәм бүлгәләнүгә каршы хәрәкәт итүләре мәсьәләсендә киңәш тә булды. Съездда, булып җитсә, уку өчен, бөтен кешеләргә укырга бер мөрәҗәгать тә күндерелде. Мөрәҗәгатьнең сурәте мондый: «Эстәрле өязе Аллакуәт авылында җыенлган галимнәр һәм мәчет эшләрен башкаручыларның дини мәҗлесенә тәкъдим. Милләтнең хөрмәтле вәкилләре, ислам диненең кадерле яклаучылары булган мәҗлес әгъзаларына ихлас сәламем, җыеннарының хәерле һәм бәрәкәтле булуы хакында хәер-догамны тәкъдим итәм. Бу җыеныгыз, милләтнең дини мәрасимнәрен сакларга, Коръән һәм пәйгамбәр Сөннәтенә туры килгәнчә, ислам хөкемнәрен үтәргә ярдәм өчен булганга, һәркайсыгызның ихлас йөрәк һәм туры ният белән хәрәкәт итүегез өмет ителә. Иншалла, саф дини эшләрдә Аллаһ йөзе өчен киңәш итәрсез, дип көтәбез. Хөкүмәтнең дә динне һәм аңа караган эшләрне үз сәясәтеннән бөтенләй аерганга, без, мөселманнар, динебез өчен файдалы дип кылган эшләребездә һәм чараларыбызда, шаять, керүе һәм тәэсире булмаса кирәк. Бары бездән сәясәткә каршы бармауны һәм тиешле чараларына каршылык кылмауны гына көтсә һәм күзәтсә кирәк. 1905 елларда электән үк миссионер юлы булган Диния нәзарәтен бүлгәләү фикерен Черeванский үзенең хөкүмәткә һәм бөтен христиан галәменә тәкъдим иткән проектында Оренбург мөфтилеген бүлүне, хәтта биш өлешкә таратуны ачык искә алган иде һәм барча мөселманнарның йөрәкләренә зур дини җәрәхәт салган иде. Әлеге Череванскийның фикердәш миссионерлары хөкүмәтләре белән мәйданнан югалып, ислам һәм башка диннәргә хөррият бирәм, дигән хөкүмәт урнашып, мөселманнарга бай-

так дини төсле булган иде. Шунлыктан Шура хөкүмәтенең хөррият декретларындагы Шәрык һәм ислам галәмен үзенә ышанычлы гражданнар дип тануыннан файдаланып, без, мөселманнар, бигрәк тә галимнәр, мәчет эшләрен башкаручылар һәм вәкилләр Аллаһның Коръәнендә әйткән һәм катгый рәвештә барча мөэминнәргә боерган «Барыгыз да Аллаһ җебенә тотыныгыз һәм таркалмагыз» аятенә тотынырга һәм теш-тырнак белән ябышырга тиеш һәм бурычлыбыз. Бу булачак Башкортстан җыенын торгызу өчен сайланган комиссиянең безгә белдерүенә күрә, Башкортстанның (мөселманнарның) Диния нәзарәтеннән аерым бер идарә төзү мәсьәләсе фикер алышуга куелачагы аңалашылганга, бу мәсьәлә турында югарыда әйтелгән маддәләрне игътибарга алып, мондый зур, мөһим мәсьәләдә ашыгып һәм сукырларча ияреп, эш кылмавыгызны хәтерләрегезгә төшерәмен. Бу мәсьәләдә җиңел карап, таркалу тарафына авышучы булса, Аллаһ һәм кешеләр алдында җаваплылык аның тарафында калачак. Кайбер ерак җирләр өчен юллар авырлыгы сәбәпле, кайбер районнарга имтихан комиссиясе төзү Диния нәзарәте тарафыннан дөрес күренә. Ничек ки, Казанда, Әстерханда, Троицкида, Петропавелда һәм Тара шәһәрләрендә төзелде дә. Аллаһтан барчагызның хәерле фикергә һәм файдалы эшләргә күнүегезне теләүче мөфти, милади 1921 елның 24 феврале.

## Истанбул, Анкара хөкүмәтенең үзләре<br>һәм Совет-инглиз мөнәсәбәтләре

Бу араларда кайбер газеталарда Төркия хөкүмәтенең азрак тормышын яза башладылар. Истанбул хөкүмәте белән Анкара хөкүмәте (Мостафа Кәмал хөкүмәте) мөнәсәбәткә керешкәннәр иде. Бу мөгамәләләре көздән бирле ишетелеп килә иде. Бу көннәрдә ишетелде: Истанбул хөкүмәте (солтан) Мостафа Кәмалны таныган һәм раслаган, Анкарада тупланган зур делегатлар мәҗлесен кануни мәҗлес дип тануын белдергән икән. Анкара хөкүмәте дә солтанны таныган, берләшүгә риза булган икән. Бу 20 февральдә Лондонда конференция тәшкил ителеп, Төркия белән башка илләрнең солых маддәләре каралачак икән. Англиядән солтанга: «Конференциягә җибәреләчәк вәкилләрегез арасында Мостафа Кәмалның вәкиле дә булсын», – дип хәбәр биргәннәр. Солтан бу хәбәрне Мостафа пашага хәбәр итсә дә, паша: «Чакыру үземә туры килсә – вәкил җибәрәм, юк икән – юк», – дигәч, Англия үзенә туры чакыру кәгазе җибәреп,

солтан белән паша вәкилләреннән биш кеше кабул ителәчәк булган. Бу эшнең ахыры хәерле булуы өмет ителә. Аллаһ Тәгаләнең әмере белән Төркия үзара берләшеп, Европа белән дә яхшы рәвештә солых маддәләрен үзгәртүләре өметле. Англиянең болай элекке фикерен алмаштыруы, Мостафа Кәмал пашага каршы тоткан сәясәтен йомшартуы, әлеге пашаның ныклыгы һәм идарәсендә күренгән осталыгының бәрәкәте һәм яхшы нәтиҗәсе булса кирәк. Төркиянең бөтен рухы һәм тормыш матдәсе булган бөтен Анатолияне үзенә каратты. Анатолиядән башка Истанбул өчен яшәү читен. Англия һәм Франция аңа каршы Грецияне куеп, сугыштырсалар да, Греция Измир ярыннан эчкә атлый алмады, төрек каһарманнары эчкәре атлатмадылар. Бары диңгез куәте аркасында ярны гына Мостафа Кәмал алуыннан саклап тора алды. Аның белән эш чыкмаячагы беленде. Паша Русия белән дә дустанә сәясәт тотты. Яхшы гына исем җыйды. Тирә-ягында булган кечкенә хөкүмәтләрне дә куркытты. Ислам галәменең мәхәббәтен үзенә җәлеп итте, шунлыктан солтан да инсафлыкка килеп, аның белән яхшы мөгамәләгә керешүгә мәҗбүр булып, мөнәсәбәт башлады. Әлбәттә, бу хәл кирәк солтан өчен, кирәк Истанбул өчен, кирәк гомум Төркия өчен, иншалла, файдалы сәясәт һәм яхшы чара булып чыгачак. Аллаһ ярдәмчеләре булса иде.

Ләкин аларның Европа белән яхшы мөгамәләгә керешүләре Шура хөкүмәте өчен файдалы булып чыкмавы ихтимал. Кавказ һәм башка көньяк өлкәләр турында байтак хәтәр булуы ихтимал. Аллаһ мөселманнар өчен хәерле хәлләр насыйп итсә иде. «Йә, Аллаһ, дингә ярдәм бирүчегә ярдәм ит, динне ярдәмсез калдыручыны ташла, мөселманнарның хәлен төзекләндер һәм мөэмин бәндәләреңә мәрхәмәтле бул», – дигән дога һәр мөэминнең көн саен укыла торган догасы булырга тиеш.

23 февральдә ГубЧКга миңа йөкләгән һәм тәкъдим иткән мәсьәлә турында сәркятибебезне җибәреп аңлатма соралды. Мәхкәмәгә киләчәк һәм аннан җибәреләчәк һәркайсы акчаларның казначейство аркылы йөртелүенең халыкка һәм Мәхкәмәгә уңайсызлыгы ирештерелде.

Җавап биргәннәр: «Бу мәсьәлә үзәктән килгән гомуми бер низам, сезгә генә хас түгел, христиан һәм башкаларга да шулай ирештереләчәк. Без бер рәвеш белән дә алмаштыра һәм үзгәртә алмыйбыз», – дигәнннәр. Бу мәсьәләдә җирле идарә белән бертөрле дә эш күреп булмый. Мәркәздә ни әйтерләр, бу ысул элекке хөкүмәтнең

тоткан юлы иде. Диния нәзарәтенә кайдан азмы, күпме акча килсә дә, барысы да казначейството тапшырылган һәм аның кулына кертелгән, җибәреләчәк акчаларның да барысы да аның аркылы җибәрелгән. Дини идарәләрнең барчасына хөкүмәт караучы һәм күзәтүче булып торган. Бу Шура хөкүмәте дә: «Динне хөкүмәттән аердык», – дисәләр дә, бу маддәдә шул иске планны тотмакчы булалар. Безнең иганә җибәрүчеләребез һәм бездән эш хакы алучы мөхтәсибләребез өчен байтак кына уңайсызлык булса да, түзми хәл юк. Аллаһ ахырын хәерле кылсын. «Аллаһ, Сиңа зарарыннан сыенам һәм аны хәерле кылуыңны сорыйм», – дип 24 февральдә имза куйдым.

## 66 яшь тулу мөнәсәбәте белән үткән гомерләргә гомуми бер караш

1921 елның 25 февралендә җомга көн ислам ай елы белән туумымнан нәкъ 66 ел кичте. Атамнан ишетүемә күрә, җомга көн икенде намазы вакытында дөньяга килгәнмен. Быел датасы хосусый көне белән дә туры килде. 66 ел кадәр дөньяда яшәдем. Бу вакытта Аллаһ Тәгаләнең чиксез, сансыз рәхмәтләрен һәм изгелекләрен күрдем ки, Бөек һәм Олуг Аллаһ иманлы ата һәм анадан тудырып, тумышымда булган исламны сакларга һәм шул ислам рухы эчендә, камил үк булмаса да, үсү белән бергә тәрбияләнергә насыйп итте. Төрки, гарәп, фарсы телләренә һәм шул өч телдә булган китапларны уку һәм аңлау кадәр аң һәм акыл бирде. Илебез гадәте буенча, гарәп теле һәм дини белемнәрдән өлеш бирде. Бохарада җиде кыш укуукыту белән гыйлем алу юлында торырга һәм остазлар, шәехләр яннарында булырга һәм замандашларым арасында абруй, фән, аң, белем фазыйләтләреннән дәрәҗәле булу белән хөрмәтле итте. Янә Истанбул, Мисыр, Шам, Кодс, Тараблүс һәм Бәйрут кебек ислам, гыйлем илләренә баруны һәм галимнәре белән очрашуны бүләк итте. Ике тапкыр [Аллаһ] йортына хаҗ кылырга һәм илчесе Мөхәммәдне (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) зиярәт кылырга дәрәҗә бирде. Соңгы баруымда Мәккәдә 100 көн кадәр, Мәдинә Мөнәввәрәдә алты ай кадәр булу хөрмәтенә ирештерде. Бу сәфәрләремдә кырык-илле кадәр хәдис остазлары һәм шәехләренә юлыгып, хәдис чылбырлары һәм риваять кылуга иҗазәтләр хасил булды. Казанда 35 ел кадәр имамлык һәм укыту вакытында гыйлем алучыларга һәм башкаларга дәрес һәм вәгазьләр аша файда китерү

максаты белән, вакыт уздырылды. Мәдрәсәләр арасында ташланган хәдис гыйлеме, тәфсир, бәлягать [риторика] гыйлеме һәм сира [пәйгамбәр тормыш юлы] кебек хөрмәтле гыйлемнәрне мәйданга куярга әһәмият бирелде. Нәкышбәндия, халидия тарикатьләренә күп тырышлыгым, көч түгүем, файдам булмаса да, ихласлыгым һәм мәхәббәтем белән яшәдем. Изгелек ияләренә, Аллаһ әүлияләре хәзрәтләренә әдәпсезлектән һәм кире кагу чүбеннән, әлхәмдү лилләһ, ерак тордым. Дөнья тормышында да киңлек һәм рәхәтлектә үткәрдем. Илле яштьтән артык атам янында булып, яхшы эшәрен һәм хәер-догаларын алу рәвешендә булдым. Итагатьле хатыннарга ике тапкыр өйләндем. Изгелек һәм белем ияләре булу сәбәпле, җәфаларын күрмәдем. Соңгы заманнарда теләк һәм ризалыгыма карамастан, бөтен Казан һәм Болгар халкының вәкилләре [тарафыннан] мәмләкәтебездә гыйльми һәм дини дәрәҗәләрнең иң югары булган мөфтилек (Истанбулда шәйхелислам) вазыйфасына сайландым. Кыскасы, бер мөселманга һәм бер галимгә мөмкин булган кадер һәм хөрмәт халыкның яхшы фикере минем хакта хасил булды.

Бу искә алынган эшләрнең барысы да – мин гөнаһлы фәкыйрьнең хаклылыгыннан һәм лаеклыгыннан башка, фәкать Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләнең рәхмәте, юмартлыгы, ярдәме. Туган көнемнән бу көнгәчә Аллаһ рәхмәтенең төрлесенә, Аллаһ нигъмәтләренең һәртөрле өлешенә канәгать һәм һәр тарафтан аның белән әйләндереп алынган хәлдә, меңнән берсенә дә шөкер итә алганым юк, шөкерен үтәүдән гаҗизмен. Бары беләмен ки, бу кадәр изгелекләрнең барысы да Аллаһның рәхмәте һәм юмартлыгы, шөкер итүеннән мин фәкыйрь оятлымын.

Аллаһ янына барыр вакытым ирешкән, дөньяны куеп, асыл ватанга кайту вакытым җиткән. Хисап дәфтәремә карасам, ахирәт азыгы булырдай һич эшемне күрмим, таяныч булырлык бер гамәл таба алмыйм. Тик тәүхид [бераллалык] иясемен, Коръән иясемен, Коръәнгә мәхәббәтем бар. Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) юлына керүне һәм аның сөннәте белән эш күрүне тиешле күрәм. Коръәнне һәм хәдисне аңларга, аңлаганча гамәл кылырга, кешегә дә шулай аңлатырга максат һәм бер дәрәҗәдә тырышлык сарыф итәм. Бу юлны үземә мәсләк [итеп] тотам. Моннан арысын Бөеклек һәм Хөрмәт иясе Аллаһның юмартлыгы һәм ярдәменә тапшырам. Аллаһның рәхмәтеннән өмет итә идем, бүген «әл-Гыймран» сүрәсенең уртасына ирешкән төрки телендәге тәрҗемәдән һәм шәрехтән гыйбарәт [булган] тәфсиремне Үзенең

ризалыгына туры килгән рәвештә тәмамлауны насыйп итсә иде һәм шул китабым мөселманнар файдалануына сәдака җариям [савабы гел килеп тора торган сәдака] булса иде. Яхшы үлем белән яткан урыным Мәккә яки Мәдинәнең берсендә булса иде. Аллаһ кодрәтле, ихтиярлы, Раббы, рәхимле, гаҗиз бәндәсен теләве һәм мәрхәмәте белән идарә итәр. Йә, Аллаһ, гомеремнең иң хәерле өлеше итеп ахырын кыл, эшләремнең иң хәерле өлеше итеп соңгыларын кыл, иң хәерле көнем – Сине очраткан көнем булса иде. Аллаһ илчеләренә сәлам, галәмнәрнең Раббысына мактау булсын.

## Кыйммәтчелек

Бу көннәрдә әйберләрнең кыйммәте тагын артты. Бәяләрнең артык күтәрелүеннән, ачлык дәрәҗәсенә ирешүдән курку бар. Элек артык кыйммәтчелек Мәскәү, Петроград, Казан тарафында гына ишетелә иде. Инде һәммәдән очсыз булган Уфада да кыйммәтчелек бик артты.

Арыш оның поты – совет акчасы белән егерме мең сум. Көрпәсез бодай – кырык мең сум. Сыер итенең поты – кырык мең сум. Сарык ите – илле меңнән артык. Гади тозның поты – 50–60 мең сум. Борчак һәм ярмалар арыш оныннан артыграк. Утынның бер колачы утыз меңнән артты, кырыккача сатыла. Бер шешә сөт – 2500 сум, ак май – 6000, сары май 7000, елкы мае 3500. Сату тыела, авылларда ашлык тартып алынып беткән хөкемендә, халыкның кулында азык беткән, сакланган орлыкларын да тартып алганнар. Һәр җирдән ачлык хәбәрләре ишетелә. Шул сәбәпле, ачлыклар, хәтта ачлыктан вафат булучылар бар, диләр. Алдыбыздагы язда сабан чәчү аз булыр, диләр. Язында, кышында ни хәлләр булыр. Хөкүмәт бу өлкәдә кайгыртмый, Мәркәзгә белдертмиләр икән, җирле идарәләр, ни сәбәпледер, ачлык белән хисаплашу фикерендә күренмиләр, катылык һәм деспотизм юлы белән мөгамәләләрен дәвам иттерәләр.

## 18 дән түбәннәргә дин укыту мәсьәләсе

Уфа, Бирски тарафларында дин укытуларны тыя башладылар. Мәктәпләрдә һәм өйләрдә укудан тыеп, дини китапларны волостька тапшырырга боерганнар. Уфа вилаяте Мәгариф идарәсеннән Диния нәзарәтенә: «Муллаларның дини мәктәпләр ачулары турында нинди

мөгамәлә итәсез», – дигән сорау җибәрделәр. 10 мартта җавап бирелде: «Муллаларның укытулары халыкның теләве буенча. Халык вәкиле һәм хезмәтчесенең, халык кушкач, укытмый хәле юк. Без исә декреттан ерак тормыйчарак укытуны тәкъдим итәбез».

Җирле хөкүмәтләрнең сәнәдләре: «Декретта балигълыктан (18 яшеннән) элек балага дин укытылмасын, балигъ булганнан соң, үз теләге белән бер динне сайлар», – дигән икән. Ләкин үзләре бик яшь балаларга коммунизмны аңлаталар, коммунизм рухы белән тәмам диннән биздереп үстерергә бар көчләрен сарыф итәләр. Боларның бу эшләре яхшы сәясәттән һәм идарәдән дә түгел.

Эчке һәм тышкы сугыш тәмам булмаган, хөкүмәт ышанычлы рәвештә урнашып җитмәгән, һәр тарафта ризасызлык исе аңкып тора, шул хәлдә ашыгыч, зарури булмаган, халыкның дини хисләренә каты орыла торган хәрәкәтләр ясыйлар. Диннең мәртәбәләре фарыз, сөннәт, мөстәхәбкә бүленгән кебек, сәясәтнең дә төрле дәрәҗәләре бар. Ләкин вак җирләрдән надан, куштан егетләрне, гыйлем һәм әдәп тәрбиясе күрмәгән балаларны эш башына куйганнар. Алар, үзләренең дәрәҗәләрен һәм урыннарын тәэмин итү максатыннан чыгып – эш тапмагач – шундый нәрсәләр белән хөкүмәтне мактыйлар, баһадирлык күрсәтәләр. Халыкка катылык һәм кырыслык күрсәтәләр. Шулай итеп, төп сәясәткә зыян китерәләр. Һәр эшнең идарәсе хакыйкый коммунистлар, вөҗданлы, халыкка шәфкатьле, фәкыйрьләрне яклаучы кешеләр кулында булса, бу рәвешле булмас иде, дип уйлана. Аллаһ дөреслекне белүчерәк.

Февраль башларыннан бирле Сибириядә вак-вак баш күтәрүләр барлыгы ишетелә, халык, казачилар һәм аларга кушылган хөкүмәт гаскәре фетнә чыгарганнар, байтак киңәйгәннәр. Ишем, Курган шәһәрләре һәм башка кайбер шәһәрләр баш күтәрүчеләр кулына кергән икән, дигән хәбәрләр телдән телгә сөйләнә, ашыгыч рәвештә гаскәр озаталар. Ике атнадан бирле Петропавелга, берәр атнадан бирле Чиләбегә билет сатмыйлар. Соңгы дүрт-биш көндә Златоустка да билет бирмәгәннәр, дип ишетелә. Поездларның барысы да гаскәр озату белән мәшгуль булса кирәк. Утын азлыктан да, поездларның һәр тарафка да йөрешләре азайды. Аллаһ эшләрнең ахырын хәерле итсен.

## Фәкыһия

Мәшһүр шагыйрь Әбү Нәвас Хәсән бине Һани [һижри] 198 елда вафат. Бу кеше габбаси хәлифәләрзаманындагы иң мәшһүр шагыйрь җөмләсеннән. Аеруча Мөхәммәд әл-Әмин бине Һарун әр-Рашидкә туганлык белән билгеле. Маэмун хәлифәдән күчерелә ки: «Дөнья үз-үзен бәян итсә, Әбү Нәвас кадәр бәян итә алмас иде»:

[...].

Казый Ибне Халләкян Әбү Нәвасның Аллаһ Тәгаләгә яхшы уй белән әйткән мондый шигырьләрен китерә:

[...].

## Мәхмүд Әсгадьнең «Ислам дине тарихы» китабы

Бу көннәрдә рәсми шөгыльләрдән бушанган ял вакытларында госманлы галимнәреннән һәм төрек әдипләреннән хөрмәтле, мәшһүр шәех Мәхмүд Әсгадь әфәнде хәзрәтләренең ислам тарихы [турында] язылган әсәреннән 3 нче томының «Мәкки» исемле бүлеген укыдым. Бу бүлектә Рәсүлуллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) тууыннан [алып] Мәдинәгә һиҗрәтенә, анда барып Кобага урнашуына кадәр булган мәшһүр вакыйгаларны билгеле хәдис һәм биография китапларыннан күчереп, каймагын алып язган. Бу китап – 343 битлек кыйммәтле бер әсәр.

Мәктәп галәмендә Җәүдәт пашаның (Аллаһ аны кичерсен) «Пәйгамбәрләр кыйссасы» – 6 томы белән кабул ителгән, яхшы бәян итүе, җиңел гыйбарәсе һәм күп мәгълүматы белән бик зур әсәр. Урта мәктәпләрдә безнең халык өчен дә укытырлык, тәмамлаган кешеләр өчен укырга лаеклы китап булса да, Мәхмүд Әсгадь әфәнде әсәре байтак мәсьәләләрдә чылбырлары искә алыну, мәсьәләләргә хикмәт белән карау, мөнәсәбәтле аятьләрнең тәрҗемәләрен искә алу, гыйбарәләре дә гыйльми булу кебек фазыйләтләрдә артыграк күренә. Бигрәк тә пәйгамбәрлекнең хак булуы, илаһият, вәхи иңү, Коръәнне исбатлау темаларын аерым искә алган 30 бит кадәр аңлатуы олуг, бөек һәм кыйммәтле булган. Аллаһ аңа хәерле әҗер бирсен.

Бу нөсхә авторының ярдәме белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе өчен Казанда да бастырган идек[40].

Автор мәрхүм дин гыйлемнәреннән һәм математика фәннәреннән бик күп ядкярләр калдырды. Фикыһ нигезләре буенча «Әл-Мәнар» китабының тәрҗемәсе, хәдис нигезләре буенча бер гүзәл әсәре, берничә том шушы ислам тарихыннан, математикадан берничә әсәр язган. Истанбулның урта һәм югары мәктәпләрендә зур мөгаллим, идарә эшендә вәзирлек дәрәҗәсенә ирешкән, тәдбирле бер акыллы киңәшче иде.

1907 елда Истанбулда финанслар буенча киңәшче вазыйфасын алган вакытында янә сөйләшеп утырдым. 1908 елда Вологдадан Хиҗазга үткәндә, 1910 елгы кайтышымда юлыгыштык, 1912 елдагы Русия сәяхәтендә кыска вакыт Казанда булуында, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, янә өебездә булып, дөньядагы соңгы очрашуыбызда өебездән чыгып, тәравих [намазы] алдыннан хушлашып, Казан пристанена юнәлдердек. Вафаты якынча 1918 елда. Аллаһның рәхмәтенә ирешсен.

## Том обсерваториясеннән алынган җәдвәл

12 мартта Том университетының обсерваториясеннән шушы 1921 ел өчен 12 айның башлары бәян ителгән рәсми, гыйльми язу алынды. Еллык җәдвәл төзү өчен, Казан, Мәскәү, Том университетларына мөрәҗәгать ителгән иде. Кайберләреннән кичегеп булса да, һәркайсыннан җавап килде. Һәркайсы тәфсилле язылган. Быел булачак айларның очрашу вакытларын, чирекләрен, ярымнарын, икенче чирекләрен сәгать, минут, секундлары белән язганнар. Бу обсерватория хисаплары алдагы көннәр өчен фәкать хисап белән чыгарылган. Аппарат ярдәме белән күрүдән чыккан бер эш түгел. Шунлыктан айның йөрешеннән хәбәрдар кеше обсерватория тышында да бу кадәрле генә белем өчен күп зәхмәт чигүгә мохтаҗ булмаса кирәк.

---

[40] Казанда басылганы – «Ислам тарихы» исемле, ике бүлектән гыйбарәт әсәр булып, монда язылганы – ислам тарихыннан Мәхмүд Әсгадьнең «Ислам дине тарихы» исемле әсәре. Икесе ике китап. *Ш. Шәрәф.*

## Җыелган иганәләрне Нәзарәткә тапшырмау хакында башкорт хөкүмәтенең чарасы

Мартта Златоуст мөхтәсибе мулла Габделхәким Сәлим тарафыннан гариза килде. Диния нәзарәте өчен тупланган иганәләрне Нәзарәткә тапшырмаска [дип] җирле хөкүмәт идарәсеннән хәбәр булган. Кантонлыктан белешкәч: «Үзәк башкорт хөкүмәтенең фәрманы шул рәвешле булды, үзгәртә алмыйбыз», – дип җавап биргәннәр. Боларның бу фикерләре башкортларның үзләре өчен аерым мөфтилек төзүләре, хөкүмәтләре өчен дә таләп ителгән нәрсә булуын сиздерә. Шул максатлары өчен керешү булса кирәк. Ләкин Нәзарәт бу эшләре турында Үзәк башкорт хөкүмәтенә каршы язса кирәк. Ихтиярый дини иганәләрне халык теләсә кайда бирергә Декрет буенча да ихтиярлы. Башкортстан хөкүмәтенең тыярга хакы юк.

Соңра мондый каршы сүз язылды, җавабында дулкынланган булганнар, сүзләре: «Бер-ике кешедән ишеттек: иганә ихтыярсыз көчләп алынган. Шуңа күрә тыйдык», – диделәр. Бу җаваплары дөрес түгел һәм мантыйксыз җавап. Ихтыярсыз җыю хәбәре бөтенләй нигезсез. Имеш, хәбәр белән генә тыю тиешле түгел, әгәр шундый маддә булса, туплаган кешене мәхкәмәгә чакыру тиешле.

Диния нәзарәтенә икенче мәртәбә Башкортстан мәркәзенә язу тиеш ки, кантоннарга иганәне тыю өчен тараткан язуларын боздырсыннар иде, мөхтәсибләр бу мәсьәләдә бик борчылалар.

## Ибраһим Акчурин хаты

Килгән хатлар эчендә иске заманнан бирле милли һәм дини эшләрдә юлдашым, барча Русия мөселманнары арасында мәшһүр Ибраһим Хурамша улы Акчуриннан алынган хатны күреп, икенче мәртәбә укыдым. Бик тәэсирләнерлек хат җибәргән. Бу кеше элек мөстәкыйль, зур сукно фабриканты, зур мәгълүматлы, күркәм тәрбияле, көнчыгыш телләрен, Казан төркие өстенә, чыгтай һәм госманлы телләрен, гарәпчә, фарсыча яхшы белүе өстенә, көнбатыш телләреннән русча, французча, алманча оста белүче кеше. Шулкадәр фазыйләте өстенә милләтче, динче кеше булып, һәркайда дини һәм милли хезмәтләргә кушыла, көче җиткән кадәр эшли иде. Шул кеше ватаны булган Сембердән Уфага, Уфадан Сибириягә барып, сәяси инкыйлаб сәбәпле, Новониколаевск шәһәрендә урнашып

тора икән. Шуннан миңа язган хатында дога, сәлам һәм саулык бәян итүеннән соң әйтә: «Безнең тормыштан Мәхмүд аркылы хәбәрдар икәнсез, аннан соң тормыш тагын да авыррак булды, Аллаһ ахырын хәерле кылсын. Тормышның матди ягыннан бигрәк, мәгънәви ягы авыр, бигрәк тә минем өчен. Иске ямаулы тишек киемнән йөрергә, туяр туймас ашау-эчүгә һич тарсынмыйм, Аллаһның язмышы шундыйдыр, сабыр итәм. Борынгы заманда, Аллаһ җан тынычлыгы бирсен. дип дога кылалар иде. Ул бар нәрсәдән артык икән. Шундый дога кылуны сездән үтенәм. Элгәре сез белгән Ибраһим Акчурин юк инде. Инде бүген аның урынына бер карт, эшкә яраксыз шәхес калды. Ни акыл, ни зиһен, ни мәгълүмат – һәммәсе тар-мар булды. Тере булсам да, үлгән хәбәрем сезгә ирешсә дә, догадан ташламагыз. Имза: Ибраһим». Гыйбрәт!

* * *

Мартның уннарыннан бирле Сибириягә машина юлы ачылды. Омскидан бирле тимер юл буенда шәһәрләрне алып, Курганга якынлашкан хөкүмәткә каршы чыккан төркемнәр чигендерелгәч һәм качырылгач, юллар төзәтелеп, тәртипкә салынган, ләкин тимер юл буеннан чиксәләр дә, тирә-якта җыелулары бетмәгән. Петропавелда көнбатыш-көньякта Күкчәтау тарафында 20–25 чакрым җирдә барлар икән дигән хәбәрләр сөйләнә. Бу 10 мартта рәсми телеграмма хәбәренә күрә, Гранштадта генерал Козлов исемле хөкүмәт игълан ителгән икән. Ахыры хәерле булсын. Петроград хәле ничектер (бәлки, Аллаһ моннан соң берәр хәл булдырыр)?

## Чулман буендагы хавариҗ җәмәгатенең ябылуы

17 мартта Чулман буе дини комитет исемен тагып йөргән, шәригатьчә булмаган җәмәгать рәисе Минзәлә имамы Ибнеябин Шәммасзадәдән хат алынды. Эчтәлеге: комитетлары хөкүмәт тарафыннан ябылган, шуңа күрә, кылган гөнаһларына тәүбә итеп, Диния нәзарәтенең җәза бирмәвен (үз гыйбарәсе белән, үч алмавын) сөйләп яза. Көче җиткәннән тыш кылган начарлыкларының, галимнәр хакында, хәтта Диния нәзарәте хакында кылган әдәпсезлекләренең барчасын комитетның ябылуын теләп, сәбәп булсын өчен эшләдем, дип ялган кереш сүзләр язган. 7 мартта рәсми кәгазь җибәрүен дә өстәп әйткән. Аллаһ ахырын хәерле кылсын. Мөхтәсиб Әбелмәхҗән әфәнде язуына күрә, Диния Нәзарәтенең түбәндәге

маддәләре белән сорашуы сәбәп булган икән. Минзәлә хакиме шул сорауларны урынлы табып, боларның хәрәкәтләрен низамсыз күреп, 12 мартта комитетларын туктаткан. Моның бу хәбәренә элек бер-ике кисәтү язылса да, тәэсире беленмәде. Кичәге көндә янә мөхтәсиб аркылы өч-дүрт маддәдә җавап алу өчен рәсми кәгазь язылды:

1) муллаларның элекке указларын үзләреннән алып, яңа указларын бирүләре;

2) һәр җирдән иганә акчалары җыюлары, кайбер җирләрдә куркытып, имам һәм мөхтәсибләрне язып, акча җыярга кушулары;

3) сентябрьдә Уфада булып үткән Диния нәзарәтенең Үзәктән рөхсәтле җыенына баручылардан икътисади хисап сораулары, арткан акчалары булса, үзләренә сораулары;

4) асыл комитетлары кем тарафыннан расланган, кем барлыкка китергән – барчасының чылбырларын сорап, җавап алып җибәрергә мөхтәсиб Әбелмәхҗән аркылы кәгазь җибәрелде;

5) 5 нче маддә итеп, муллалардан тупланган һәркайсы указларны Диния нәзарәтенә җибәрергә боерылды.

Ишетелгәненә күрә, Шаммаз хатының ишарәсенә күрә (кайберләре алданып, кайберләре куркып, кайберләре Диния нәзарәтенә начар уйда булып), әлеге комитетка ике йөздән артыграк имам һәм мөәзин язылган һәм указ яңартып алган икән.

19 мартта Шаммаздан рәсми кәгазь алынды. Кәгазендә идарәнең, төрле сәбәпләргә нигезләнеп, хөкүмәт тарафыннан ябылуын бәян иткән.

## Мөфти Мансур Халиков хаты
## һәм Башкортстан Диния нәзарәте

24 мартта Башкортстан җыенына җибәргән вәкилебез Мансур мөхтәсибтән язу алынды. 19 мартта язылган язуында Эстәрле ягы Аллакуәт авылында башкорт вәкилләреннән 79 вәкил, 8 кадәр тыңлаучы булып, 11 мартта мәҗлесләре ачылган. Диния нәзарәтеннән аерылулары турында күп бәхәсләр ике көнлек сөйләшүләрдән соң, аерылырга дигән карар биргәннәр. Бу мөхтәсибне үзләренә мөфти итеп билгеләгәннәр. Әлеге кеше, яраклы булмаган кешеләрнең мөфтилек теләгендә булганлыктан, өстенрәк кешеләрнең үтенечләре сәбәпле, кабул иткәнен язган. Тышта, үзара галимнәр аерылмауны куәтләп сөйләсәләр дә, мәҗлестә гаҗизлектәнме, кур-

куданмы яки эчке теләкләреннәнме, аерылуга каршы яхшы тора алмаганнар. Хөкүмәт тарафыннан бу мәсьәләне баш кузгатучы, دиния нәзарәтенә төрле яла һәм ялган итүче Х. Юлдаш исемле төрек качагы белән Хәбибулла исемле ике түбән [кеше] мәҗлескә килгәннәр һәм даими булганнар. Кулларыннан килгәнчә, аерылуны куәтләп, каршыларны мәҗлестә һәм тышта куркытудан кире тормаганнар. Җиңел рухлы, кыска уйлы, аз белемле башкорт галимнәре һәм мәчет эшен башкаручылары бу эшне эшләргә булдылар, карар чыгардылар. Эш дөрес юлына куеп, дәвам иттерүдә:

1. Бу җыенда Пермь, Шадрин, Самара кебек ерак җирләрдән вәкилләр булмаган, аларның фикерләре ничек булыр? Ике елдан бирле дәвам итү исемен күтәреп кызыл муллалар мөфтилеге кебек бер тарафта гына булып калуы ихтимал.

Башкортстан сәүдәсез халык булганга бу соңгы елларда бик фәкыйрьләнгән, кешеләре аз, айлык, еллык чыгымнарын күтәрә алулары шөбһәле.

3. Шул ук вилаятьләрдә эчләреннән бу карарга йөрәкләре карар итмичә, Диния нәзарәтенә мөрәҗәгатен һәм иярүен кисмәүчеләр булуы мөмкин.

27 мартта яңа башкорт мөфтилеге тарафыннан 5 санлы мөрәҗәгать иреште. 23 мартта язылган көйгә, болар Диния нәзарәте белән мөгамәләгә һәм хисаплашуга керешкәннәр. Ләкин җыен карарыннан рәсми кәгазь Диния нәзарәтенә ирешкәне юк. Рәсми протокол килгәч, кәгазьләре рәсми мәҗлесебездә каралыр, иншалла. Имазалары: мөфти Мансур Халиков, казый Сәгыйдҗан Акбирдин, Зәкиҗан Тимербулатов.

23 мартта Мәскәүдән Тәрҗеманов имзасы белән телеграмма алынды. Гомум халыкка иген чәчүдә җиңел карамаулары турында мөрәҗәгатьнамә таратуны сораган.

Ике көннән соң янә бер телеграмма алынды. Ачык аңланмавы сәбәпле, җирле телеграмма идарәсенә мөрәҗәгать ителсә дә, аңламауларыннан, чыганагыннан аңлатма алып, 28 мартта янә безгә тапшырдылар. Эчтәлеге: милләтләр идарәсендә безнең теләкләр кабул ителгән. Җентекләп аңлату белән мөрәҗәгать булыр. Әгъзалары: әлеге бүлекнең мөдире Гыйсмәти, Тәрҗеман.

Бу икенче телеграмма хәбәре Нәзарәт өчен куанычлы хәбәр. Тәрҗеман аркылы аерым тәкъдим белән байтак нәрсәләр соралган иде. Иншалла, ахыры хәерле булыр.

## Нәзарәтнең эш хисабы

Диния нәзарәтенә 1921 ел башыннан 22 мартка кадәр кереп чыккан эшләр хисабы:

беренче бүлеккә кергән – 433, чыккан – 756, беренчегә дәфтәргә теркәмичә кергән – 26; икенче бүлеккә кергән – 120, чыккан – 144; өченче бүлеккә кергән – 74, чыккан – 98; дүртенче бүлеккә кергән – 192, чыккан – 224; мөфтигә махсус – 5, сәркятипкә кергән – 4, чыккан – 23, кассага кергән – 3, чыккан – 4; барлыгы кергән – 857, чыккан – 1249.

Искәрмә: мөфтигә килгән һәм киткән кәгазьләрнең күпчелеге кереш-чыгыш дәфтәрләренә теркәлмәгәнлектән, дәфтәрдә аз күренә.

## Никах таркату турында фәтва

Троицк мөхтәсибе мулла Габдрахман бине шәех Зәйнулла Рәсүлидән 26 мартта сорау килде. Нөсхәсе: «“Лә зарар вә лә зирар” хәдис шәрифенә һәм имам Мөхәммәднең (Аллаһ аны рәхим кылсын) “Мөватта”да китергән хәбәренә күрә һәм гомуми яхшылыкны игътибарга алып, әгәр бер хатынның ирендә бергә тору мөмкин булмаган авыру, хатынны кыйнау, исерткеч куллану, хатынына шәригать буенча дөрес булган сәбәпсез азык-кием бирмәү, ире югалган яки читтә булу сәбәпле, хатынның тәрбиясез калып, тормыш итү ягыннан зарарлану кебек зарарлар һәм башка һәртөрле тору мөмкин булмаган зарарларның берсе яки бердән күбрәге шаһитларның шәһадәте белән исбатланса, хатын иреннән аерыламы яки башка бер юл белән аерырга мөмкинме? Ачык фәтва бирүегезне түбәнчелек белән үтенәм».

Бу кәгазенә яздым: «Әлеге сәбәпләр өчен аеру мөмкин. Аллаһ дөреслекне белүчерәк. Мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди.

## Нәзарәтнең теләкләре Үзәктә кабул ителгән

Мәскәүдән казый Кәшшаф Тәрҗеман 8 рәҗәптә (17 мартта) яза һәм аңлата:

«Мәхкәмәи шәргыянең теләкләре байтак хәрәкәтләрдән соң төрле милләтләр идарәсендә бу кадәрләре уңай хәл ителгән:

1) Наркомнацның хәбәрдарлыгыннан башка һичбер мәктәп һәм мәдрәсә ябылмас;

2) Диния нәзарәтенең гомуми нигездә типографияләрне куллану тыелмас;

3) кирәкле штамп һәм мөһерләр куллану тыелмас;

4) хезмәткә кагылышлы телеграмма йөртү тыелмас;

5) Диния нәзарәтендә хезмәт итүчеләрнең Мәхкәмә хезмәте белән йөрүләренә киртә булмас.

Бу кагыйдәләрне гомуми сурәттә Уфа исполкомына мөрәҗәгать язып, әлеге казыйның кулына бирелгән. «Башка вилаятьләргә дә моннан нөсхә язып җибәрергә мөмкин», – дигәннәр. Дини китапларны шәһәрдән шәһәргә йөртер өчен мөмкинлек соралган иде. «Моны һичкем тыймас, аерым рөхсәт кәгазенә хәҗәт юк», – дигәннәр. Мәхкәмә өчен хосусый бер типография алу турындагы язуыбызга: «Хәзер типография эше мөшкел, чит ил белән сәүдә башлангач, кузгату мөмкин», – дигәннәр. Моның кадәр рөхсәтләр дә яхшы, хуш хәл күренде, монсына әлхәмдү лилләһ.

Тәрҗеман әфәнденең хатында бер үкенечле хәбәр дә бар иде. Германиядә бер бәдбәхет әрмән тарафыннан тырышлыгы һәм ныклыгы белән галәмдә мәшһүр булган Төркиянең министры Тәлгать Паша шәһит ителгән.

## Совет хөкүмәтенең уңлашуы

Бу март эчендә атна кадәр дәвам иткән III съездда (партия съезды) хөкүмәт байтак уңлашып, халык белән дә хисаплашып, үзен тәэмин итү максатына керүе әлеге съездның хәрәкәтләреннән аңланган. Авыл халкына байтак иркенлек, милли эшләргә дә игътибар, сәүдә иреге турында да яхшы сөйләшүләр булган. Уфада бу көннәрдә авыл халкының быелдагыча, ашарларына да калдырмыйча, алып бетерү ысулын бетереп, налог юлы белән алуны игълан иттеләр. Шәһәргә печән, салам, иген кертүне рөхсәт итәргә торалар. Ахыры ни булыр, хәерле булсын.

Апрель башында шәһәргә азык кертүне иркен куйдылар. Һәр җирдән азык керсә, мөмкин булды. Ләкин юл йомшады, чана юлы өзелергә якын булды. Азык килә торган Бирск өязеннән килүче өчен хәтәрле хәл. Шулай да 40 мең сумга ирешкән арыш оны утыз мең сумга төште. 60 меңгә ирешкән бодай оны 40 ка кадәр бирелә башлады.

2 апрельдә Эстәрлебаш ягы мөхтәсибе мулла Шакир мәхдүм бине Харис Тукаев килеп, Аллакуәт авылында булып үткән Башкортстан җыенының хәлләреннән, мөфти һәм казый сайлауларның рәвешләреннән Диния нәзарәтенә ачыклык бирде. Вакыйганың кыскача хәлләрен яздырып китерде. Моның өстенә, вакыйганы теле белән дә яхшы аңлатты.

Вакыйганың кыскачасы: башкорт хөкүмәте тарафыннан вәкил ителеп җыенга җибәрелгән Х. Юлдашев исемле коммунистның тәэсире һәм гади кешеләрне куркытуы, хәтта янавы аркасында, күпчелек галимнәрнең ризалыкларыннан башка Диния Нәзарәтеннән аерылырга, аерым мөфтилек сайлауга ярдәм итүләре аңлашылды.

Җыелышта 12 кантоннан бары алты кантон кадәр вәкилләр килгәннәр. Аларның да кайберләреннән берәр генә вәкил килгән. Алты кантонлыктан һич кеше килмәгән. 69 кадәр кешедән гыйбарәт [булган] мәҗлес белән гомум башкортлар өчен аерым мөфтилек сайлаганнар. Аның идарәсе һәм башка кирәкле вазыйфалары өчен хәҗәт мәсьәләләрдә бер дәрәҗәдә карарлар чыгарганнар.

Бу мәсьәләдә әһәмиятле нәрсә шул: Шура хөкүмәте динне үзеннән тәмам аерган, дини эшләрне тәмам иясенә тапшырган хәлдә, башкорт хөкүмәте һәм хокук-рөхсәте дә шушы нигезгә корылган хәлдә, Эстәрле хөкүмәтенең мондый тик дини булган мәсьәләләргә катышуы, хәтта куркыту һәм кисәтү юлы белән катнашуы дәүләт кагыйдәсенә, Шура нигезенә бөтенләй каршы. Бу рәвешле халыкның (күпчелекнең) ризалыгыннан һәм ихтыярыннан башка мөселманнар арасында, дини идарәләренең игътибары белән, таркаулык салулары, Русиядә иң зур һәм мөһим идарә булган Диния нәзарәтен (искечә Духовное Собрание) бүлгәләү, әлбәттә, халыкка яман тәэсир бирәчәк. Үзәкнең тоткан мәсләгенә, ахырдан, зыянлы булып чыгуы ихтимал.

## Госман Коръәне хакында

Мәхкәмәи шәргыя бинасында Госман Коръәне исеме белән танылган мөбарәк әсәр [сакланган] бүлмәнең ишегенә язып ябыштырган кәгазьнең нөсхәсе:

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әл-китаб әл-мөкаддәс әл-Коръән әл-газыйм. Бу бүлмәдә булган Коръән шәриф тирегә күфи язуы белән ноктасыз һәм хәрәкәсез язылган: «Әмирел-мөэминин

Госман бине Гаффан (Аллаһ аннан риза булсын) яздырып, нәшер иткән берничә нөсхәләрнең берсе булуы билгеле. Бу – [һиҗри] 1338 елдан бер мең ел элек Гыйрак һәм Хорасан илләренә сәяхәт иткән, һәр җирдә бөек галим һәм остаз икәнен күрсәткән, Шаш (Ташкент) галимнәреннән имам Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Гали әл-Каффәл әш-Шаши хәзрәтләре бер сылтау белән үз шәһәре булган Ташкентка китергән мөбарәк Коръән шәриф китабы. Озак вакыт әлеге кешенең бала һәм нәселе кулларында сакланган. Тугызынчы гасырда бу имамның балалары һәм нәселләреннән шәех Гобәйдулла Әхрар Нәкышбәнди хәзрәтләре Ташкенттан Сәмәрканд шәһәренә күчкәндә, Коръән китабын үзе белән Сәмәркандка китереп, үзенә караган мәдрәсәнең мәчетенә урнаштырган. [Һиҗри] 1285 елда Русия дәүләте Сәмәркандны алганнан соң, бу Коръән китабын тарихи һәм кыйммәт бәяле әсәр икәнен белеп, Петроградның солтан китепханәсенә алганнар иде. 1335 (1917) елда инкыйлабтан соң әлеге шәһәрнең мөселман шурасы кайбер ислам гаскәрләренең ярдәме һәм Шура хөкүмәтенең булышлыгы белән әлеге китапханәдән алып, 1336 елның 30 рабигыль-әүвәлендә (1918 елның 12 гыйнварында) зур саклык белән һәм зур тантана белән Уфага китереп, бөтен Русия мөселманнарының дини мәркәзләре булган Мәхкәмәи-шәргыягә тапшырдылар. Шул заман мөфтие, бу хәрефләрне җыючы мулла Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди йортыннан иң зур бүлмәне билгеләп, әлеге мөфтинең һәм мөхтәрәм казыйларның җаваплылыгына тапшырдылар. Хәзер бу Коръән китабы бу бүлмәдә саклана. Һәркайсы мөселман кереп, зиярәт итә һәм җомга көннәрендә җәмәгать белән зиярәт кылып һәм укып, Аллаһыга гыйбадәт кылына. Моны мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди язды, [һиҗри] 1338 елның гашура көне».

Монда күчердем [һиҗри] 1339 елның 26 рәҗәбендә.

## Яңа имамнарга указларын тапшырганда сөйләнә торган вәгазем

Имамлык – зур бер мөхтәрәм урын. Бу хезмәтне йөкләвең белән бөек вазыйфа йөклисең. Ул вазыйфаны тиешенчә үтәү дини һәм вөждан бурычың.

1. Биш вакыт намазны мәчетеңдә, вакытларын сөннәткә туры китереп, җәмәгать белән үтәрсең, мөмкин кадәр намазны игътибар һәм ихтирам белән укырсың.

2. Үзеңне күркәм әхлак һәм дин ягыннан, бөтен мөселманнарга үрнәк булырлык дәрәҗә яхшы тотарсың. Яраклы булмаган, дин һәм кешелеклелеккә каршы булган эшләргә якын булмассың. Дини хөкемнәр һәм гыйбадәт, хәләл-хәрам, күркәм әхлак мәсьәләләрендә һәрвакыт мәчет халкын вәгазь кылырсың. Бер яраклы китапны тәртип белән укып барсаң, бигрәк хуп. Ничек тә мондый бозык заман вакытларында кат-кат тиешле булган вәгазьләрдә кулдан килгән кадәр кимчелек китермәссең.

3. Халык белән күркәм мөгамәләдә булу тиешле. Биргәннәрен алып, бирмәгәннәренә нәфес комсызлыгы белән сорану кебек түбәнчелектән ерак торырсың. Аз-маз игенчелек итәрсең, умарта кәсеп кылырсың, бөтенләй комсызлык белән кичтерергә тырышма.

4. Балаларны укытырсың, ир һәм кыз балаларның дин танулары хезмәте имам өстендә. Өлгермәслек булсаң, яраклы булганда, мөәзинне укытышырга боерырсың яки мөгаллим алырсың.

5. Бу кадәрле генә гыйлемгә канәгать булмыйча, һәрвакыт гыйлем арттыру теләгендә бул. Аңлый алган кадәр китап кара, очраган галимнәрдән файда алырга тырыш, гыйлем арттыру заманы мәдрәсә заманы түгел, бәлки, мәдрәсәдән чыгып, дөньяда тормыш башлангач. Мәдрәсә – фәкать юл күрсәтүче.

Мөәзиннәргә дә шушыңа охшаш вәгазь сөйләп, мөхтәсибләренә игълан итеп, хезмәткә керешүне васыять итеп, «Фатиха» [сүрәсе] укып, указлары тапшырыла.

* * *

6 апрельдә Мәскәүдән бер пакет алынды. 17 мартта Милләтләр идарәсе бүлегеннән комиссар Каменский имзасы белән Уфа хөкүмәтенә язылган нөсхәдән копиянең эчтәлеге:

1) Мәркәздәге наркомнация хәбәреннән башка мәктәпләр һәм мәдрәсәләр ябылмас;

2) Диния Нәзарәтенең кешеләре Мәхкәмә эшләре сәбәпле йөрүләренә тыю булмас;

3) Мәхкәмә шәргыянең телеграмалары йөртелер;

4) Мәхкәмәи шәргыянең мөһерләре, штамплары белән файдалануга тыю булмас;

5) Мәхкәмә эшләрендә типографияләрдән гомуми кагыйдә буенча файдаланырлар;

6) элек казый Кәшшаф Тәрҗемән әфәнденең хәбәр итүе белән беленгән карарлар, казыйның үз кулына бирелеп, безгә әлеге бүлек

мөдире Габдулла Гыйсмәти имзасы белән җибәрелделәр. Шул ук карарның нөсхәсе югарыда искә алынган Каменский имзасы белән. Моның өчен Аллаһка шөкер. Ишетелгәнгә күрә, җирле хөкүмәтнең үзенә дә туры бу фәрман ирешкән икән.

## Архив хакында Мәркәзгә мөрәҗәгать

11 апрельдә Мәркәзгә архив турында биреләчәк телеграммабызны, телеграмханәдә күрсәтү белән, казна хисабына кабул иттеләр. Бу да әлеге заманда, кечкенә генә булса да, бер җиңү, моның өчен Аллаһка шөкер. Мәркәзгә җибәрелгән телеграмма хәбәребезнең эчтәлеге:

«Мәскәү наркомнациягә (төрле милләтләр бүлегенә), архив турында сезгә җибәрелгән кәгазьләребезгә ачык җавап килгәнче, гомуми архив хокук идарәсе белән киңәшләшеп, монда эшне туктатып торырга фәрман җибәрсәгез иде».

Җирле регистрация идарәсе электән белдергәнчә, бу көннәрдә архивка килеп, архивның таратылачагын, һәр вилаятькә бәйле кәгазьләрне әлеге виләятьләргә җибәрәчәген белдергән иде.

Бу хәл хөкүмәт өчен файдасыз. Һәр вилаятьтә, районнарда, авылларда берәр нөсхә метрика дәфтәре бар. Безнең архивта икенче нөсхәсе яхшы сакланып тора иде. Инде вилаятьләргә таратып, ни кылмакчы булалардыр? Без аңлаган максатлары юк. Тик Диния нәзарәтенең көчен, халык өчен мөрәҗәгәть урыны булуын киметү һәм бетерү максаты булса гаҗәп түгел. Бу вәкил сүз арасында: «Собрание бетереләчәк, аның кулында эш калачак түгел», – дип кат-кат сөйли. Ләкин эшләр белән идарә итүче хикмәтле Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә динсез колына никадәр ихтияр бирер икән? Өмет ки, мөселманнарга мәрхәмәт карашын салса иде.

## Иманлы исерек

Иптәшебез казый Ризаэддин әфәнденең, шәһәр урамында бер тарафка баруында, янында алпан-тилпән хәлдә баручы бер карт мөселман байтак ара барган. Шулай һичкемгә карамыйча шәһадәт кәлимәсен, тәкбир, салават укып, сынык, ялварган хәлдә юлын дәвам иткән. Сүз һәм Аллаһны мактау арасында «Йә, Аллаһ, гөнаһлы бәндәмен, Ходайга бәндәнең гыйбадәтеннән файда юк, гөнаһыннан зыян юк, шулай да, бәндә булгач, аны тыңларга, гөнаһ

кылмаска тиешле» дигән сүзләрен әйтә икән. Риза әфәнде дә бу затның әлеге төрле хәрәкәтләреннән һәм сүзләреннән ләззәтләнеп, тыңлап, хәтта күңеле нечкәреп, юлында озак бергә баруны дәвам иткән.

Бу вакыйганы ишетүемнән соң, элекке казый Габдеррәшид Гомәр Ибраһимовның Гомәр аганың тәрҗемәи хәлендә сөйләгән кайбер сүзләре хәтеремә килде. Әлеге кеше, бик кәефле булып кайтса, өйдәгеләрне борчыган. Тик, аның шул хәлдә кайтуын сизеп, кайтуына «Йосыф» сүрәсен укый башлыйлар икән. Ага кайтып керүенә, Коръән тавышы ишетү белән идәнгә тезләнеп, тавышсыз-тынсыз гына тыңлый, шул хәлдә йокыга китә икән. Соңра бу мөнәҗәт касыйдәсен көйләп, күзләреннән яшь чыгара икән: «Йә, Ходa, Гафу итүче син, Рәхимле син бәндәләргә, аеруча минем кебек явызларга». Бу хәлләр ислам хикәятләре китапларында искә алына: «Бәлки, гөнаһ түбәнчелеккә, күңел сыныклыгына китерер һәм масаюга, тәкәбберлеккә китергән изге эштән хәерлерәк булып чыгар».

Фәкыйрьнең: «Һәр эштә гыйбрәт алучыга дәрес бар, акыл һәм фикер иясенә шатлык булсын!»

## Чимкенттан (Черняевтан) хат. Бала тәрбиясендә мөһим искәртүләр

10 апрельда Төркестан вилаяте Чимкент шәһәреннән Юныс бине Хөснеддин исемле казанлыдан хат алдым. Хатында минем язган хатымны алуын һәм куануын, атасы Хөснеддин хаҗиның вафат булуын яза. Бу Хөснеддин хаҗи [һиҗри] 1338 ел рамазанының 2 нче көнендә ай хисабы белән 111 яшендә дөньядан кайткан. Чыгышы Казан ягы Мамадыш өязе Шәмәрдән авылыннан булып, Петропавел шәһәрендә бераз торган. Троицкида мәшһүр Яушев гаиләсеннән Әхмәдҗан (Кара Әхмәд) бине Гайсәнең сәүдә вәкиле булып, Русия хакимлегенә күчүдән элек үк Ташкент сәфәренә чыккан.

Габделвәли бине Әхмәдҗан Яушев моны сөйләгән иде: «Яшь көнемдә атам мине әлеге Хөснеддин әкә кулына хезмәтче итеп тапшырды. «Яхшы күзәт, Ташкентка барсын, эш өйрәнсен», – дип кушты. Әлеге кеше мине бай баласы [итеп] хисапламыйча, атамның кушуы буенча, үзенең бер өйрәнчек хезмәтчесе кебек тәрбияләде һәм сәүдә белән мөгамәлә эшенә өйрәтте. Хәтта барышыбызда кәрванда кайвакыт намазга һәм тәһарәткә ялкаулансам, каты шелтәләрен күрдем, ишеттем».

**Искәртү**. Мәрхүм Габделвәли бай әлеге Хөснеддин аганың урыны белән каты тәрбиясеннән файда күрүен, шул сәфәрләренең бәрәкәтле булуын сөйләр иде. Бу сәфәрләре 1855–1860 елларда булган. Бу вакыйгада икътисади һәм тәрбияви ике мөһим мәсьәлә бар, Әхмәд бине Гайсә Яушев аңа игътибар иткән һәм кулланган.

**Икътисади.** Сәүдә өчен ерак сәфәрләрне сайлау, ислам галәмендә күп заманнан бирле, хәтта Бәни Үмәйя һәм Габбаси хәлифәләреннән үк гарәпләрдә булган. Һинд, Кытай, Ява мәмләкәтләренә кадәр сәяхәт һәм сәфәр кылып, сәүдә итүләре, шул сәүдәләре, аралашулары аркасында ислам таралуына хезмәт итүләре тарих китапларында язылган. Хәтта безнең Болгар халкының, Багдадтан, Габбаси хәлифәләреннән Мокътәдир заманында ислам өйрәтү өчен, Ибне Фазлан кулы астында килгән делегациядән элек үк, Төркестаннан килеп китүче сәүдәгәрләр аркылы исламга килүләре, соңра ничә еллардан соң ислам падишаһлары вакытында, аеруча Габбаси хәлифәләреннән дини хәлифә булып танылган Мокътәдир билләһ вакытында рәсми мөселманлыкларын белдерер һәм кирәкле тәгълиматны алыр өчен, хәлифлеккә мөрәҗәгать иткәннәр булса кирәк. Дөресен Аллаһ белүчерәк.

Кыскасы, сәфәр һәм сәяхәт – кирәк сәүдәчә, кирәк әдәпәхлакча [булсын] – бик әһәмиятле, күп файдаларны китерә. Казан һәм Болгар халкы да бу сәүдә сәфәрләренә теләкле, керешүчән төркем. Диннәрендә нык төркем булганга, һәр барган җирләрендә җирле халыкның карашларын үзләренә җәлеп итеп, тугрылык, әманәт белән мөгамәлә күрсәтеп, үзләре турында яхшы фикер тудыралар.

Барган җирләрендә дини мәрасимнәрне үтәп, мөмкин булган кадәр мәктәп һәм мәчет торгызырга керешүләре – тәҗрибә белән күренгән яхшы гадәтләре. Башкортстан, Казакъстан җирләрендә дә сәүдә белән таралып, һәр җирдә дин рухы, дин тәгълиматы таралуга болар сәбәп булдылар. Башкортстаннан күп җирләрдә бу сәүдәгәрләр урнашып, мәчет һәм мәдрәсәләр торгызуга, дини дәресханәләр ачылуга, шул юл белән башта вәхши булган башкортларның мәдәният төсенә керүләренә, араларында дини гыйлем таралуына сәбәп булдылар. Бу хәлләр башкорт эчендәге типтәр төркемнәренең тарихларыннан бик ачык күренә. Шулай ук Казакъстанда боларның яхшы тәэсирләре гадәттән тыш артык булды. Матди файдаларны казанлылар казакълардан алсалар, мәгънәви, зур файдаларны казакъларга бирделәр. Карагыз: казакъ эчендә Оренбург, Тро-

ицки, Петропавел, Семипулат кебек шәһәрләрне казанлылар торгызып, казакъ эчендә зур тәэсир иттеләр. Һәр шәһәрдә мәчетләр һәм мәдрәсәләр торгызып, казакъларны һәм башкаларны укыттылар. Бәдәвилек галәмендә надан калган исламның рөкеннәрен, кагыйдәләрен аз белгән казакъларның нык һәм дин өлкәсендә байтак мәгърифәтле булуларына сәбәп булдылар. Үзләреннән байтак галимнәр, мөгаллимнәр, мөдәррисләр җитештерделәр, әхәмдү лилләһ моның өчен.

Казан халкы Кытай җиренә кадәр сәүдә ачып, Төркестан тәмам өйрәнелгән җирләре булып, зур сәүдә иттеләр. Төркестаннан байтак әдәп файдасын алулары булган. Казан ягындагы Курса, Мәчкәрә, Кышкар, Мәңгәр кебек авыллардан бохарчы сәүдәгәрләр булу мөнәсәбәте белән, икътисади файда алулары өстенә, байтак әдәп һәм дин әсәре китергәннәр.

**Икенче мәсьәлә – бала тәрбиясе мәсьәләсе.** Бай балаларын укудан туктаткач, яхшы идарәле чит кеше кулына хезмәткә биреп, эш өйрәтү тиешле. Ата-ана кулында бала эшкә өйрәнә алмый, киресенчә, күбрәк вакытта бозыла гына. Ата кулындагы сәүдәханәдә белер-белмәс хуҗалык кылып, сәүдә вәкилләренә өстенлек кылган булып, эш өйрәнми калуына кайбер вакытта алар тарафыннан шәхси мәнфәгать өчен тиешсез юлга керүләренә сәбәп була.

Бу хәл – безнең хәзерге Казан һәм Болгар байларында таралган зарарлы гадәт. Шунлыктан атадан калган дәүләт варислар кулында яшәми, гомерсез була. Мал табуның юлын белмәгән, асатлык белән кулына мал керткән бай баласында малның кадере һәм кыйммәте күп булмый. Максатчан исраф итмәсә дә, бәрәкәтен очырырлык кадәрле идарәсезлек белән болар күп вакытта фәкыйрьлек хәленә дучар булалар. Әгәр дә моның киресенчә, 15–16 яшендә чит кеше кулында хезмәт итсә, хезмәтенә яраклы эш хакы алып, тормышын үткәрсә, һәртөрле кеше күрсә, һәртөрле мал таныса, акчаның мәшәкать белән килүен яхшы белсә, чын яхшы мөгамәлә һәм идарәгә өйрәнсә, әлбәттә, соңрак атасы хезмәтенә дә катышып, ярдәм итә белер, атасының малын саклый алыр иде.

Безнең Әхмәдҗан Яушев улын ят кеше сәүдәсенә хезмәтче итмәсә дә, каты куллы вәкиленә иярчен, хәтта хезмәтче итеп тапшырып, сөекле улы Габделвәлине Ташкент сәфәренә дөя кәрваны белән озатты. Шул сәфәрләреннән һәм шуннан соңгы сәфәрләреннән бәрәкәтләре артып, Габделвәли мәрхүмнең үз вакытында ук төп һәм күп бәрәкәтләре Ташкент тарафыннан булу сый-

фаты белән, миллионнарга хуҗа булганнар иде. Әлеге Габделвәли әфәнде дә вакытында Троицкида зур көч казанып, дәүләтенә яраклы ук булмаса да, дин һәм милләт юлында мәктәпләрне яхшырту эшендә байтак аңлы һәм тугры хәрәкәтле һәм иганәле булып, динле гомерен үткәрде. Ташкент һәм Мәскәү халкы арасында да игътибары зур иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын!

Югарыда искә алынган зат, безнең Хөснеддин ага Яушевларда хезмәт итеп, үзе дә бер дәрәҗә файдаланган, ләкин хуҗаларына күп файда ирештергән тугры вәкил булган. Үзе Чимкент шәһәренә урнашып, Черняевның Төркестанга һөҗүме вакытында Чимкентны алуында, шул шәһәрдә булган Черняевка очрап, җир һәм су турында аерым язу алса да, җиңел караганмы – кәгазен югалтып, файдалана алмады. Хөснеддин ага үзе игътибарлы, эшендә төгәл, тугры, нервылары сәламәт, гәүдәсе нык, җәмәгать намазына даими йөри, пөхтә, басуына барып эшләп йөри, диндар кеше иде. Үзе хаҗ кылган, Чимкент шәһәренә дә Вәли Яушевның ярдәме белән казанлылар өчен мәчет торгызган һәм бер мәхәллә ачтырган иде. Аллаһның рәхмәтендә булса иде. Улларыннан олысы Ягъкуб 65 яшендә үзеннән бер ел элек вафат булды. 1916 елда йортларында айлап кунак булган идек. 1917 елда янә дүрт-биш көн булып үттек, хөрмәтләрен күрдек.

* * *

9 апрельдә Уфада чана юлы бетеп, арба юлы төшү сәбәпле, юллар киселеп, артык кыйммәтчелек булып китте. Азыгы булмаган кешеләр өчен бик авыр хәл, бер шешә сөт совет акчасына – бик мең сум, бер кадак кара ипи – бер мең биш йөз сум. Бер кадак сарык ите – өч мең сум. Бер резин калушымда аз гына ертык бар иде, аз гына заманга түзәрлек итеп төзәттердем – биш мең сум түләдем. Бер савыт шырпы – өч йөз сум, бер кадак тоз –ике мең сум, диләр.

Бәндәләрнең дин һәм әхлак мәсьәләсендәге ваемсызлыклары һәм игътибарсызлыклары сәбәпле, Аллаһ тарафыннан вакытлы бирелгән гыйбрәт һәм кисәтү булса кирәк. Аллаһ сакласын, җәза булмасын иде, әгәр дә җәза бирү теләге булса, Аллаһ сакласын, чиксез дәрәҗә кыйммәтчелек, ачлык артуына лаеклыбыз. Йә, Аллаһ, бәндәләреңә рәхимле бул.

## Ай хәбәрләре һәм кояш тотылу

Богырслан өлкәсендә фәлән авылда мөдәррис Шакирдан Диния нәзарәтенә язу бирелде. Авылларында Кәлимулла исемле ышанычлы кеше хатыны белән пәнҗешәмбе көн 29 рәҗәбтә (7 апрельдә) шәгъбан аен күргәннәр. Шәһадәтләрен әлеге имам кабул итеп, шәгъбан башын җомга көн итеп, якшәмбе көн 3 шәгъбан дип язган. Мәскәү, Казан, Томски обсерваторияләреннән алынган мәгълүматка күрә, рәҗәб ае туган 9 мартта чәршәмбе көнне кичке 9 сәгать 53 минутта, 8 апрельдә пәнҗешәмбе көндә ай йөрешенә 29 тәүлек тулып җитми. Икенчедән, җомга көн 8 апрельдә 12 сәгатьтә 35 минутта кояш тотылу ачык булып, 3 сәгать чамаларында гына кояш ачылды. Шунлыктан айның үзәге кояшның үзәгеннән аерылуы көндез 12 сәгатьтән соң гына мөмкин була. Әлеге өч обсеваториядән алынган мәгълүматка күрә дә, җомга көн 8 апрельдә көндез 12 сәгатьтә 59 минутта шәгъбан ае туачак (ай үзәгенең кояш үзәгеннән узачак). Обсерватория, хисап, кояш тотылуы – барысы да ачык катгый рәвештә аның хәлләрен белдерә торган сәбәпләр. Бу фәннәрнең таралуыннан элек игътибарга лаеклы булырлык ачык сәбәпләрдән булмасалар да, бу заманнарда мәйданда булган гыйлем әсбапларыннан. Бары пәйгамбәр тарафыннан махсус юл белән исбатланган текст булган маддәдә генә болар (юкка чыгару юлы белән түгел) игътибарсыз калдырыла. Анда да шәригать текстларын аңлауда тиешле урыннарда гамәлгә керткәндә әсбап хисабына, әлбәттә, игътибар ителер. Шунлыктан әлеге авылдагы күрү һәм имам Шакир әфәнде янындагы шәһадәт тә, ни булса да, бер буталу булуы уйланыла. Моның кебекләрдә булган шикелле күрүнең үзендә буталу яки көндә хата булу ерак түгел. Гомумән, шәгъбан аен исбат итәр өчен бер ир һәм хатын шәһадәтләре җитәрлек түгел. Алар белән генә исбатланмас. Аллаһ дөресрәген белүчерәк.

Җомга көнне кояш тотылу һәм өч обсерваториянең Диния нәзарәтенә рәсми белдерүләре буенча шәгъбан ае, җомга көн төш авышу белән туып, кичәсендә күренү мөмкинлегенә ирешкәнгә, шимбә көн 9 апрельдә шәригатьчә исбатланган булыр. Шунлыктан рамазан ае күренмәсә, шәгъбанны тутырып, якшәмбе көн тәравих [намазы] укылып, дүшәмбе көн беренче рамазан булып, ураза булса кирәк. Аллаһ Тәгалә тиешле рәвешчә үтәргә һәм гыйбадәт кылырга тәкъдир иткән булса иде.

24 апрельдә Троицки мөхтәсибе Рәсүлидән хәбәр иреште: алтынчы мәхәлләдә имам Саләхеддин янында дүрт кеше җомга көн шимбәгә каршы шәгъбан аен күреп, шәһадәт биргәннәр. Шунлыктан аларда күрү белән шәгбан башы шимбә булуы исбатланган.

## Архивка угрылар керү

8 нче апрельгә каршы төндә, урам ягындагы бер тәрәзәнең зәгыйфьлегенннә файдалып, кәгазь угрылары кереп, архивыбыз бинасыннан метрика дәфтәрләрен алып чыкканнар. ЗАГС, үз кулына алып, идарә итәм, дисә дә, ләкин эш белмәс, төзәтү максатында булмас халыкларның идарәләре, караулары, әлбәттә, кимчелекле, идарә астына кергән нәрсәләрнең күбрәк тә югалуы бик ихтимал. Башкорт архивларыннан да күп кәгазьләр урлануы ишетелә иде. Безнең мөселманнарның тарихи дәфтәрләре югалуы, тәмәкегә сарыф ителүе – безнең өчен дини һәм милли зур үкенеч. Һаман дәфәтәрләрне таркату фикередә булулары аңлашыла, бу рәвештә бер зур югалту булачак.

## Игенчелек мәсьәләсендә мөрәҗәгатьнамә

23 мартта Мәскәүдән Тәрҗеман имзасы белән, гомум халыкка игенчелек мәсьәләсендә кызыктыру мөрәҗәгатьнамәсен нәшер итү соралып, телеграмма килгәне язылган иде. Шул вакытта кыскача игенчелекнең дини яктан әһәмиятле икәнен бәян итеп, бер мөрәҗәгатьнамә язып, җирле идарәләрнең төрле урыннарына мөрәҗәгать ителде. Хезмәт бигрәк хөкүмәт файдасы өчен булганга, хөкүмәт кәгазьләренә бастыру соралса да, кәгазьдән өметне кискәнгә, үз кәгазебездә бастырачак булып, мөрәҗәгать иттек. Бу 17 апрельгә хәтле җавап алганыбыз юк, ахыры ни булыр?!

19 апрельдә җавап алынды: «Бирерлек кәгазебез юк, май башы (бәйрәм алды) булганга, типографияләр хөкүмәт хезмәтләре белән мәшгуль, май ае кермичә, сезнең эшне үтәү мөмкин түгел», – диделәр. Димәк, халык иген чәчеп туктагач, бастырырга булганнар. Бу кешеләрнең мондый хәрәкәтләре ике нәрсәнең берсе сәбәпле булса кирәк. Я эш белмиләр, мәмләкәтне яхшырту ысулларыннан ваемсыз яки Диния нәзарәтенең халыкка яхшы тәэсир итүеннән куркалар. Ни булса да, бер сылтау белән эшләребезне калдыралар. Бер рәвеш белән туктатырга тырышалар. Инде соң булса да, яздырып, кайбер

мөхтәсибләргә таратырга уйладык. Кайбер җирләр өчен, кайбер яшелчәләр өчен һаман форсат бар.

### Чиләбе тарафларындагы дини мәдрәсә

21 апрельдә Чиләбе имамы элекке казый мулла Салихҗан бине мулла Фатих Урман тарафыннан бер гариза тәкъдим ителде. Гаризаның эчтәлеге мондый иде:

Һәр җирдәге кебек Чиләбе вилаяте, имамнар һәм дини мөгаллимнәр өлгертү өчен, бер дини мәдрәсәгә мохтаҗ. Бу кирәк нәрсәне вилаять халкы үзе кайгыртырга тиеш. Шунлыктан Чиләбе шәһәрендә бер комиссия төзеп, тирә-як һәм Нәзарәт белән хәбәрләшергә карар биргәннәр. Нәзарәтнең бу турыда фикерен һәм мөмкин кадәр мәгънәви ярдәмен сорыйлар. Чиләбе вилаятенә кертелгән Троицки, Верхнеурал, Курган, Мияс өязләре һәм боларга якын Шадрин, Екатеринбург, Кустанай шәһәрләре 400 дән артык мәхәлләне үз эченә алган.

Бу гаризага Диния нәзарәте ризалык белән карап, кулыннан килгән кадәрле ярдәмдә булуны, Салихҗан әфәндегә рәсми җавап бирүне карар итте. Болар бу язда, әлеге шәһәрләрдән вәкилләр чакырып, бер җыен корып, киңәшләчәкләр. Мәдрәсәнең урынын, чыгымнарын, идарә рәвешен уйлашачаклар. Хәерле эш булса иде. Аллаһ һәр нәрсәгә Кодрәтле.

**Бу хакта фикерем**. Мәсьәлә бик мөһим, кайгырту зарур. Һәр вилаять үзе өчен бер дини мәдрәсә әзерләп, динле имамнар җитештерергә тырышырга тиеш. Бу көннән үк мәмләкәт эчендә иң азы биш мәдрәсә кирәк: Казанда, Хаҗитарханда, Сибириядә берәр, Уфа вилаятендә ике мәдрәсә торгызу зарур күренә. Мөмкин булганда артык булса, бигрәк яхшы. Ләкин бу эш җиңел түгел, теләк белән генә теләүдә файда юк. Кешеләре тарафыннан җитди рәвештә хәрәкәт шарт.

1. Беренче шарты исә – яхшы ният һәм тугрылык. Исем-шөһрәт күтәрү кебек бәрәкәтсезлек сәбәбе катышмаска тиеш.

2. Мәдрәсәнең урыны халыкның күзе төшкән, авышкан, күңел баглаган җир булырга тиеш.

3. Мөдәррис, мөгаллимнәр диндар, ышану һәм гамәлләре белән дин өйрәтерлек, халыкны читтән караганда да ышандырырлык кешеләрдән гыйбарәт булырга тиеш.

Диния нәзарәте бу дини мәдрәсә торгызу турында Чиләбе вилаяте мөхтәсибләренә белдерде. Чиләбе дә уянган фикергә кушылуны һәм куәтләүне тәкъдим итте. Гомум мөхтәсибләргә дә бер мөрәҗәгатьнамә таратачак булды.

## Тарихи көн, нәк кырык ел

24 апрель (16 шәгъбан) минем өчен тарихи бер көн дип игътибар итәргә тиешле. Бохарадан [һиҗри] 1299 елның 3 рәҗәбендә чыгып, Казанга 16 шәгъбанга караган сәхәр вакытында кайтып кергән идем. Хәзер бу көнгә тәмам кырык ай елы тулды. Кырык ел үтеп китте. Кырык көн үттеме, кырык сәгать үттеме – үтте-китте, вәссәлам. Хисапланса, хисап алынса, ни әйтә алам, ни эшләдем? Аллаһның биргән шул кадәр вакытында ничек хезмәт иттем, ничек итагать кылдым – әйтерлек бер нәрсә дә юк. Маташтым, юандым, мәчет, дидем, мәдрәсә, дидем, шәкерт, дидем, китап, дидем, фәлән, дидем. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә янында яраклы, дөрес нияткә якын, сәламәт йөрәк һәм дөрес хәрәкәттән килгән берәр эш булдымы – Бөек һәм Олуг Аллаһ Үзе белүче. Минем кимчелегемне танудан башка бер нәрсә итәр хәлем, өмет иткән җирем юк. Бары Аллаһның диненә хыянәтне максат итмәдем, кеше алдауны ниятләмәдем. Тышкы булса да, дини мәрасимнәрне үтәргә, мөселманнарга аз-маз аң һәм аңлату бирергә, зәгыйфьлек һәм кимчелек белән булса да, дин һәм дин гыйлемнәрен белдерергә тырыштым. Җитешсезлегем күп, камиллегем юк, Аллаһның киң рәхмәтеннән өметем бар. Иман, тәүхидемә таянам, рәсүл Мөхәммәдкә (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) мәхәббәтем бар, аның хәдисләрен тарату, халыкны аның гыйлеменә һәм аның Сөннәтенә якынайтуны теләдем.

Казанга кайткан елда Казанның байтак дәрәҗәле карт галимнәре бар вакыт иде: 1) дамелла Шиһабеддин Мәрҗани, 2) дамелла Хөсәен Әмирхан, 3) дамелла Габделвәли бине Габделгаффар, 4) дамелла Мөхәммәд бине Салих; икенче дәрәҗәдән: 5) дамелла Габделгалләм бине Салих, 6) дамелла Йосыф бине Сәгыйдь, 7) дамелла Нургали Баруди, 8) дамелла Закир бине Хаммад, 9) дамелла Сабир бине Хаммад, 10) дамелла Габделкаюм бине Габденнасыйр, 11) дамелла Хәбибулла Кышкари; өченче дәрәҗәдән: 12) мулла Хуҗаәхмәд Мозаффар, 13) мулла Хисамеддин бине Габделвәли,

14) Бишбалтадан мулла Билал, 15) мулла Шакир бине Хөснеддин, 16) мулла Зариф Әмирхан, 17) мулла Шакир Күләй.

Бәрәкәт, яхшы мәҗлесләре, тыштан күркәм мәдрәсәләре, бер дәрәҗәдә житеш «Мәрҗания», «Кәримия», «Әҗем», «Халидия» [дигән] өч-дүрт мәдрәсәләре бер дәрәҗәдә яхшы укытып баралар иде.

Тирә-якта да карт имамнар һәм остазлар байтак сәламәт иделәр: 1) Норлаттан дамелла Фәхреддин бине Мостафа, 2) дамелла Исмәгыйль бине Муса Кышкари, 3) дамелла Габденнасыйр бине Әмин Буави, 4) дамелла Габделвәли Сембери, 5) дамелла Мөхлисулла Мәчкәрәви 6) кари дамелла Габделхәким бине Габделкәрим Питракси һәм башкалар.

Бүгенге [һиҗри] 1339 елның 16 шәгъбаны тарихына, хәлләре чагыштырылса, гаять аерма, чиксез алмашыну булган. Саналган галимнәрдән бары мулла Хисам Габделвәли, мулла Зариф Әмирхан, мулла Шакир Күләй исән. Башкалары башкарды. Кайберләрендә «күркәм алмаш», кайберләрендә «начар алмаш» укылырлык хәл булды. Барудиядә, Бишбалтада, Яңа Бистә янында иске каберстан өстендә берәр мәчет арттырылды. Бүген Казан һәм бистәләрендә тәмамланган рәсми 17 җамигъ мәчет, 21 имам бар. Аллаһ бәрәкәтләрен насыйп итсен.

## Троицки вакыйгасы

Сүезднның «Хатын-кызларга вәгазь сөйләнсен» дигән маддәсенә таянып, бу шәһәрдә өченче мәхәллә имамы Зыятдин бине Мөхәммәдҗан Рахманколый хатыннарны җомга намазына чакырган. Җыела башлаганнар. Югары катта (сәндерәдә) ирләрдән аерым урында укый башлаганнар. Мәхәллә халкы бу эшне начар күреп, мулла тарафыннан бераз деспотларча каршылык күрелеп, халыкта байтак хәрәкәт туып, мөхтәсибнең фәтвасенә мөрәҗәгать иткәннәр. Ул да ни эшләргә белмичә, мәсьәләне хәдис китапларында булганча бәян итсә дә, янә Диния нәзарәтенә тәкъдим иткән иде. Нәзарәтнең карашы да аның карашына туры килеп, имза белән кайтарылган иде. Бу мәсьәләдәге хәдисләрнең нәтиҗәсе: күз төшмәслек, ирләргә катышмаслык рәвештә җәмәгать намазына килүдән хатыннар тыелмаслар, ләкин өйдә укулары яхшырак.

Троицкига җибәрелгән язуымның сурәте:

Хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре турында Троицки мөхтәсибе мулла Габдрахман Рәсүли җәнапләренең фәтванамәсен

Русия, Себер һәм Казакъстан мөфтилеге дөрес таба. Моның кадәрне өстидер:

Шартларын үтәп, мәчеткә йөргән хатын тыелмаса да, җәмәгать намазына чыгу мәсьәләсендә кызыктырылмас. Рәсүлүллаһтан (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) эчке бүлмәләрендә укуларының яхшырак булуы турында дөрес хәдисләр бар. Бары намаз вакытларыннан башка аулак вакытта хатыннарга махсус вәгазь мәҗлесе төзү шәригатьчә тиешле һәм яхшы. Быелгы 16–26 сентябрьдә булган съездда гомумрусия галимнәре һәм мәчет тарафыннан да бу рәвешкә карар бирелде һәм Диния нәзарәте тарафыннан халыкка игълан ителгән иде. Шушы һәм дөресен Аллаһ белүчерәк. Моны мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди язды. [Һиҗри] 1339 елның 17 рәҗәбе.

Озак та үтмәде, мәхәлләдән 30 мартта 248 имза белән әлеге мулланы теләмәгәннәрен теләп, эштән алуын теләп, төзелгән приговорлары да Диния нәзарәтенә килеп җитте. Мулланың элекке кимчелекләрен искәртеп, бу маддәне аеруча сылтау итеп, халыкка яхшы мөгамәлә итмичә, деспотларча хәрәкәтләрен дә шикаять итеп, катгый сурәттә эштән алуын таләп иткәннәр. Моңа каршы мәсьәләне тикшерер өчен Троицки имамнарыннан карт дамелла Мөхәммәт Бикмит, мулла мөхтәсиб Габдрахман Рәсули, мулла Габделәхәд бине Хуҗаҗан әфәнделәргә тапшырылды.

24 апрельдә әлеге шәһәрдә халык зарланган Зыятдин мулладан үзен пакьләп язган гаризасы, кайбер хәдис риваятьләре белән һәм мәхәллә халкыннан азчылык җәмәгатьтән шулай ук аны аклау кәгазе иреште. Мәхәллә халкыннан Габдрахман Әхмәровтан хосусый хат алынды ки, ул да бу эштә гаҗәпләнеп, мөхтәсиб фәтвасын минем дөрес күрүемә дә үкенеч белдереп язган.

Бу турыда Габдрахман Әхмәровка язган җавабым: «Хатыгыз ирешеп, аңлашылды. Ләкин, кызганыч, озын язган хатыгызның минем имза куйган фәтвага бер дә кагылышы юк. Хатыннарны тәрбия һәм укыту мәсьәләсе – җәмәгать намазы мәсьәләсеннән бөтенләй аерым мәсьәлә. Беренчесе исә – Мөхәммәд (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) тарафыннан гамәли сурәттә күрсәтелгән, тиешлегенә карар бирелгән. Икенче мәсьәлә исә – капма-каршысына өндәү, шартлары үтәлгәнне тыймау, гадәт юк икән – кертелми. Кыяматкәчә дин мондый, вәхи иңгән кеше кадәр бер акыллы кеше дә белә алмый. Тиешле рәвештә мин үзем дә Петропавелда үтәдем. Һәр җирдә

үтәлүе тиешле, съездның да теләге. Аллаһ барчабызны хәерлесенә күндерсен».

## Нәзарәтнең бер бинасы алынуы

1920 елның яз башында казый Габдулла Сөләйман фатирына казый Ризаэтдинне күчерәбез, дип торганда, безнең ихтыярыбыздан башка, Уфада Мәгариф мөдирлегенең татар бүлегендә хезмәт итүче Шәрип Сүнчәләй исемле бер зат көчләп кереп, моның өстенә, күршедәге сабыйлар мәктәбе шәкертләре исеменә [дип], бакчабызны тәмам үз идарәсенә алган иде.

Бу кешенең кирәк фатир, кирәк бакча өчен идарәсендә ордер барлыгы ишетелсә дә, милек мөдире казый Кәшшафеддин Тәрҗемани үз кулына алып җиткермәде һәм каршы тиешле хәрәкәт тә итә алмады. Башта бакчада җимешләргә кагылмыйча, тик яшелчә чәчеп, файдаланачакларын сөйләсәләр дә, җимеш вакыты ирешкәч, алма, чия, кура җиләге, карлыганнарның ләззәте һәм базарда акчасы яхшы булганга, аз гына да үзләреннән безгә өлеш чыкмады. Хәтта ишетелгәнчә, мәктәп балалары җир казышсалар да, бәрәңге һәм башка яшелчәләргә байтак хезмәт кертсәләр дә, рәсми файда һәм нәтиҗә аларга булырга тиеш булса да, өлеш аз алганнар. Деспот чиновникларның үзләренә сыйган икән. Җаваплылык моны сөйләүче өстендә. Инде бу 1921 елда җирле идарәләргә бакчаның тәмам үзебезгә тапшырылуын тиешле күреп, язсак та, колак салмыйча, март ахырларында рәсми язу белән: «Бакча бөтенләй мәгариф идарәсенә бирелде», – дип язганнар иде.

Янә канәгатьләнмичә, бу тиешсез карарга каршы чыгып, августта Мәркәздә Диния нәзарәтенең бинасы бөтенләй мөфтигә һәм мөселманнарга тапшырылуын язып биргән кәгазьгә таянып, үзебезгә кайтарылырга тиеш, Нәзарәтнең үз әгъзалары һәм хезмәткәрләре файдаланырга тиеш, дип язган идек. Бүген 26 апрельдә исполкомның мондый эшләрне карау бүлегеннән 1075 номерлы 25 апрель датасы торган рәсми кәгазь алдык. «Бөтен бакча мөфти карамагына калдырылды», – дип язылган. Әлхәмдү лилләһ моның өчен, бу да – кечкенә генә булса да, бер җиңү.

Деспот залимнәр үткән елгы ярым миллионлык җиләк-җимешне ашап сеңдерсеннәр, янә шулкадәр бәрәңге дә алган булырлар. Моннан соң Аллаһ Тәгалә үзебезгә тынычлык белән файдаланырга насыйп итсә иде.

* * *

Бу кышта ике кадәр дәвам иткән вакытлы курсларда Мәхкәмә вакытларыннан арткан вакытларымда Коръәнне дөрес уку фәне, тәфсир, фикыһ дәресләре белән шөгыльләндем. Соңра март ахырларында Бәләбәй ягындагы Мәскәү авылы имамы Сиражеддин әфәнде кайбер иптәшләре белән яратып Коръән һәм «Мохтасарел-викая» дәресләрен дәвам итеп, биш парә кадәр Коръән, «Ураза» бүлегенә кадәр «Мохтасар» укып, 23 апрельдә чәчү өчен кайтып китте.

Шул арада апрель ахырларында әлеге яктан яшь укытучыларыннан Сөереш имамы мулла Габделхәмид Рәҗәп тәртип белән «Кафия»не укып чыкты. Әлеге кеше аңлы, дөрес укучы булганга, аз арада булса да, «Шәрхе Җами»не тәртипле рәвештә әзерләп килеп, нәкъ сигез дәрестә тәмам «Кафия»не укып чыкты. Бу уку безнең җирдә, хәтта Төркестанда ят рәвеш [булып] күренә. Ләкин тарихи хәлләр, галимнәр биографияләре, укыту ысулы бу рәвешкә ярдәм итә. Укыган, фәннән һәм тәрҗемә рәвешеннән хәбәрдар шәкерт өчен һәр сүзне тәрҗемә итеп уку – буш эш, аның өчен рәттән уку, кайбер аңлашылмаган җирләрне аңлату белән канәгатьләнү җитә. Күп китапларны һәм фәннәрне, шушы рәвешчә генә өйрәнеп, кулга кертергә мөмкин. Тоташу чылбыры белемен алу, бәрәкәткә ия булу рәвеше дә шушы. Аллаһ теләгән бәндәсен күндерер.

## Тәфсир авторы Шәех Мәхмүд әл-Әлүси әл-Багдади

Ул – Әбүс-Сәнә Шиһабеддин Мәхмүд бине сәед Габдулла әл-Хөсәйни әл-Багдади әл-Әлүси. Бу зат Багдадның мәшһүр, хәтта бөек галимнәреннән. [Һиҗри] 1217 елның шәгъбан аенда дөньяга килеп, [һиҗри] 1270 елда вафат булды. Аллаһ рәхмәтендә булсын. Бу кеше «Тәфсире рух әл-мәгани» исемле зур тәфсире белән дөньяга танылды. Бик яшьли гыйльми көч хасил итеп, хәнәфи һәм шәфигый мәзһәбләрендә белем алып, һәр ике мәзһәбтә мөфтилек вазыйфасы моңа тапшырылып, бөек дәрәҗәгә иреште. Күп остазлардан файдаланып, төрле як галимнәреннән иҗазәт алды. Күбрәк укыган шәехе – Галәведдин Гали әл-Мусыйли, Гали әс-Суәйди, атасы сәед Габдулла, суфи шәех Зыяддин мәүляна Халид әл-Багдади ән-Нәкышбәнди һәм башкалар. Аллаһ рәхмәтендә булсыннар.

Гарәп һәм фарсы әдәбиятыннан да киң мәгълүмат иясе. Дини гыйлемнәр, әдәбият буенча байтак әсәрләр язган. Акыл фәннәрендә

дә киң мәгълүматлы. Мәуляна Халид ән-Нәкышбәнди хәзрәтләре заманында пәйда булган һәм кайбер галимнәр һәм хәйдәрия сәедләре тарафларыннан кайбер каршылыклар булганда, бу кеше аны яратучы, һәм, гомумән, тарикать әһелләренә ихласлы булганлыктан, яхшы халидиянең казанышлары турында язды.

Заманының шәйхелисламы, хөрмәт иясе Гариф Хикмәт әфәнде хәзрәтләренә нисбәтле булып, аның хакында да «Шуһән-нигам фи тәрҗемәти шәех әл-ислам вә вәли ән-нигам» исемле тәфсилле биография язган. Бу китапны әлеге шәйхелисламның Мәдинәи Мөнәввәрәдә ачкан, нәфис һәм сирәк китапларны туплаган китапханәсендә язма нөсхәсен күргән идем. Мәдинәдә иң бөек һәм әсбаплары җитеш, китабы күп китапханә – шушы шәйхелислам китапханәсе.

Әлеге Әлүси хәзрәтләре дә, башка галимнәр кебек, дошман көнчелегеннән һәм көнчеләр дошманлыгыннан тыныч була алмаган. Фәтва бирү, дәрес укыту урыннарыннан читләштерелгән, кайбер тарлыклар күргән һәм Истанбулдан мәрхәмәтле чакыру сәбәпле, [һиҗри] 1266 елда Истанбулга сәфәр кылган. Багдадтан сәфәре 1267 елның җөмәдиәл-ахирендә булып, Багдадка кайтып керүе 1269 елның 5 рабигыль-әүвәлендә була. Бу сәфәрдә күргән һәм ишеткән нәрсәләрне дә аз гына мөнәсәбәт белән дә өстәп язган, гыйльми мәсьәләләрне үз эченә алган «Гараиб әл-игътираб вә нүзһәт әл-әлбәб» исемле бер гүзәл сәяхәтнамә язган. Байтак файдалар керткән. Бу сәяхәтнамәсе Багдадта [һиҗри] 1327 елда 451 битле булып басылган. Бу шәгъбанда иптәшебез мулла Ризаэтдин Фәхретдин әфәнденең китапханәсеннән алып торып, бу китапны тикшердем, укыдым. Күп файдалы нөсхә дип таптым. Аллаһ аңа хәерле әҗерен һәм мәрхәмәтен насыйп итсен. Тәфсире 15–20 елдан бирле китапханәбезне бизәп тора. Кайбер вакытларда аны уку белән хөрмәтләнә идек.

Бу кешенең улы шәех Ногман Әлүси шәйхелислам Әхмәд бине Хәҗәр Мәкки Һәйтәминең һөҗүмен кире кагып, «Куррат әл-гайнәйн фи мүхәкәмәт әл-әхмәдәйн» исемле бик гүзәл әсәр язган. Соңра бу кеше Бәһүпал (мәшһүр галим сәед Садыйк Хәсән Бәһадирхан яклавы астында) хөкүмәтендә кайбер гыйльми хезмәтләр белән мәшгуль булды. Соңгы заманнарда шәех Йосыф Нәбәһанинең «Шәвәһид әл-хакк» исемле әлеге шәйхелислам каршысында

Әбел-Мәгали әл-Хөсәйни псевдонимы астында «Гаятел-әмәни фирradди галә Нәбәһани»[41] исемле зур әсәр нәшер итте.

Әлүси хәзрәтләренең Истанбулда күп галимнәр һәм тарикать шәехләрен, сәясәтчеләрне күреп, алган гыйбрәте күп булса да, искә алырга лаеклы булган кадәрлесе – шәйхелислам Әхмәд Гариф Хикмәт әфәнденең дин һәм әдәп гыйлемнәре, юмартлык һәм кешелеклелеген яхшы күреп, искә ала. Аннан иҗазәт алганын, аңа биргәнен искә ала. Чыннан да, халык авызында йөргән хәбәрләргә күрә дә, бу шәйхелислам кадере һәм әхлагы ягыннан да урынына лаеклы булган. Һәр җирдә үзенең кадерен исбат иткән. Мисыр һәм Шам шәехләреннән иҗазәтләр алган галим икән.

Әлүси шәех Гомәр бине Габделкәрим бине Габдеррасүл әл-Гаттар әл-Мәккидән шәехе Салих әл-Фәләни җыентыгына иҗазәт алган. [Һиҗри] 1229 елда шәех Хәсән Тунисидан, 1238 елда шәех Хәсән бине Мөхәммәд әл-Гаттардан, шәех Габидтән һәм башкалардан, 1235 елда шәех Мөхәммәд әл-Әмир әл-Кәбир, шәех Габдулла бине Габдрахман, шәех Әхмәд әт-Тахтавиның «Дөррел-мохтар» хашияләрен язучы шәех Зәйнелгабидин хәзрәтеннән иҗазәтләр алган.

Шәйхелисламнан башка байтак галимнәр күрсә дә, канәгатьләнгән кешесе аз булган. Шәех Мөгаммәр Хөсәен әд-Дагыстанидан иҗазәт алганын, шәех Мөхәммәд әт-Тәмими әл-Мәгриби әл-Мисри әл-Кустантанидан иҗазәт алганын яза. Бу кешедән, хәдис белгечләре гадәте белән, «беренчелек чылбыры» хәдисен ишеткән. Үзе дә аңа ишеттергән. Әлеге Тәмими шәех Мөхәммәд әл-Әмир әл-Мисридан риваять итә. Мисырда Мөхәммәдгали паша вакытында улы Ибраһим паша балаларының укытучысы булып, Габбас паша I вакытында сөрелеп, Истанбулга килгән.

**Искәртү.** Димәшкъның озын гомерле шәехләре белән [һиҗри] 1227 елда очрашып, «беренчелек чылбыры» хәдисен ишеткәндә, бөтен шәехләре арасыннан Мөхәммәд әл-Әмир әл-Кәбир риваятеннән, шәех Тәмимидән риваять иткән иде. Хәтеремдә, Истанбулдан китүендә хәдисне сөйләде, дигәне башта калган. Тик әлеге шәехне шәех Габбас паша дип иҗазәтнамәсендә яздырган. Бу нисбәт хатамы яки икенче Тәмимиме – соңгысы ераграк.

[41] «Нәбәһәнине кире кагуда хыялларның чиге». Бу китап авторы Шиһабеддин Әлүсинең оныгы – Шакир Әлүси, Ногман Әлүси түгел.

Шәех Мәхмүд Әлүси: «Истанбулның бөтен галимнәрен яхшылык-ризалык күрсәтми, чит кешеләргә һәм гарәп галимнәренә яхшы мәхәббәт күзе белән карамыйлар, хөсетлек белән мөгамәлә итәләр», – ди. Үзләренең гамәлләре дә ким дәрәҗәдә икәнен, аз кешеләрнең чын өстенлек һәм мәгърифәт иясе булганын белдерә, вәгазьчеләрендә дә чамадан чыгу һәм кимчелек китерү барлыгын аңлата. Бу мәсьәләләрне шәйхелислам янында да искә алып үткән. Сәяхәтнамә авторының бу карашы дөрес булырга мөмкин.

Истанбулның укыту һәм тәрбия ысулларында (араларында өстенлек ияләре күп булган хәлдә) зур кимчелек бар. Дәресләрендә фикергә хәрәкәт бирерлек китаплар укылмый, өстен мәгълүмат белән үткәрәләр, үзләрендә булган микъдарга канәгать булалар. Бохара галимнәренә караганда, мәгълүматлары, төрле фән белүләре артык булса да, тикшерү һәм эзләнү сәләтләре артык түгел, хәтта ким булуы бик ихтимал. Истанбулның бөеклек һәм олуглыгына, җир йөзендә булган мөселманнарның мәхәббәт урыннары булуына караганда, һәр җирнең гыйлем алу рәвешләрен күргән, һәр мәмләкәтнең укыту ысулларыннан хәбәрдар булган, Гарәбстан, Иран, Һиндстан сәяхәтләрен кичергән галимнәр эш башында булып, һәр өлкәдә чыганак һәм киңәшче булып торырга тиеш иде. Истанбул алынган вакытларда бу рәвеш булган. Күрани, Кушчи кебек Мисыр, Иран, Төркестан галимнәрен һәм фикерләрен китереп, байтак күп хөрмәт ирештергәннәр, ватан ияләре зур файдаларга ирешкәннәр.

Сәяхәтнамә авторы тарикать ияләре турында мәхәббәтле, яхшы фикердә булганга, бик файдалы сүзләре бар. Истанбулның шәехләреннән кайберләрен күреп, файда бирерлек һәм алырлык мәҗлесләре булган. Истанбул халкының тарикать шәехләренә мәхәббәтләре артык булуын һәм кайбер шәехләрнең кимчелек һәм җитешсезлекләрен дә искә ала. Истанбулга барышында Мосулдан соң Җәзирә Әби Гомәр шәһәрендә кайбер галимнәрнең тарикатькә бәйле кайбер мөрәҗәгатьләренә күрә, 15–20 маддә белән яхшы файдалар язган, инсафлы җаваплар һәм аңлатмалар бәян иткән. Шулардан, шәехләрнең «Аллаһ» сүзен кабатлап, даими зикер әйтергә боеруларына каршы кайбер галимнәрдән, хәтта Нәвави, Ибн Тәймия кебек зур галимнәрдән каршылык юлында сүз күчерелгән һәм шул сүзгә ябышып, кайбер суфичылыкны инкяр итүчеләр ифратчылык күрсәткәннәр. Бу шөбһәгә каршы Әлүси җавапта, чыганаксызрак булса да, әйтә: «Тик тору һәм сүз әйтмәү каршысында зикер – тел

эше, гафләт һәм йөрәкнең тик тору каршысында йөрәкнең зикер эше – дөрес эш. Сүз белән дә хасил булыр. Нәвави зур галимнәрдән булса да, һәр сүзенә иярү мәҗбүри түгел. Шәехләрнең «Аллаһ» сүзенә йөрәкләре белән дәвамчылык итүләре һәм йөрәк куәте шарты белән, ягъни мисалсыз изге затка юнәлүче йөрәген юнәлгән һәм килгән хәлдә тотып, «Аллаһ» сүзен кабатлый. Бу хәл – шөбһәсез, дөрес һәм мактаулы эш». Сүзе тәмам.

Бу сүзләр белән мәсьәлә хәл ителә. Шулай ки, аерым «Аллаһ» сүзе йөрәкне, әлеге шарт белән гадәт иттерелсә, мөэмин йөрәгендә илаһның бөеклеге чагылып, йөрәкнең хозурлыгы урнашып, ваемсызлык күтәрелеп, һәртөрле тел зикеренә әзерлек барлыкка килә, иң зур максат булган зикер иясеннән булып әверелә, Коръәндә чакырылган хакыйкый зикергә ирешә.

## Зәмәхшәри

[Һижри] 467 елның рәҗәбендә туган, [һижри] 538 елның гарәфә кичәсендә вафат.

Бу кеше Әбел-Касыйм Мөхәммәд бине Гомәр бине Мөхәммәд бине Гомәр әл-Хәрәзми әз-Зәмәхшәри исеме белән дөньяда шөһрәт тоткан. Һәртөрле гыйлем белән өстенлек казанды, хаклы рәвештә Хәрәзем галиме, бәлки, дөнья галиме исемен алды. Бөек галим, диндар, тәкъва, аскет остаз. Өстенлекле остазы – шәех Мансур Әбү Мудар. Гыйлем алу яшенә ирешкәч, Бохарага барганда, аттан егылып, бер аягы сынып, дәвалаганда аны кисеп, агач аяк куярга мәҗбур булган иде. Кайберәүләр Хәрәзмедәге каты салкын һәм күп кар булган вакытта суык тиеп, соңыннан аягын кисәргә кирәк булган, диделәр. Акыл һәм аңның кул-аяклары сәламәт булгач, бу мөбарәк затның бер аягы агачка алмаштырылуы түбәнчелек бирмәгән, галимнәр һәм әмирләр араларында алга чыгуына, югары булуына зыян ирештермәгән.

Туган илендә, Хәрәземдә (моның мәркәзе күргән көнбатыштагы Җөрҗан шәһәре, бу заманда аның янында Үргәнеч) һәм Бохарада гыйлем алганнан соң, озак заманнар Мәккә Мөкәррәмәдә торды, хәтта Аллаһ йортының күршесе булу теләге белән Җарулла кушаматын алды. Соңгы гомерендә Җөрҗанга кайтып, вафат булды. Мәккә халкы арасында, Мәккәдә күмелгәнлеге сөйләнелсә дә, тарихчылар аңлатуларына күрә, иленә кайтып, вафат булган. Зәмәхшәри гарәп теле һәм дин белемнәреннән күп әсәрләр язган.

Бөтен тәфсир галәме эчендә «Кәшшаф» исемле тәфсире лаеклы шөһрәт кәсеп итте. Үзенең шушы шигыренә лаек:

Дөньяда бихисап тәфсирләр саны,
Ләкин һич тә «Кәшшаф»ым кебеге юк.
Әгәр туры юлны теләсәң, укы син аны.
Наданлык – авыру, ә «Кәшшаф» – шифа.

Ләкин заманындагы Хәрәзмиләр кебек, юлында могтәзиләләр фикерендә булганга, әлеге тәфсирендә байтак кадәрендә үз юлына төзүе, «әһле сөннә» юлына каты һөҗүмнәре бар. Тәфсиренә аңлатма язучылардан Тәфтәзани, Җөрҗани күбрәк тел белеменә игътибар бирсәләр дә, Насыйреддин Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Мөнир әл-Искәндәри (Аллаһ аны рәхим кылсын) «Интисаф» исемле аңлатма язып, әлеге маддәләрдә тиешенчә гаделлек кылды, хакны күрсәтте.

Илебездә Дагыстан тарафыннан кергән «Әнмүзәҗ», «Әл-мүфәссаль» китабы мәшһүр. Ирдибили шәрехе белән укуы элек (бер дәрәҗәдә гарәп теле гыйлемнәре белән шөгыльләнгән заманда) гарәп теле белемнәрен өйрәнгәндә, төп дәрес китабы буларак тотыла иде. Чыннан да, бу «Әнмүзәҗ» китабы – үзенә яраклы шәрех һәм аңлатма булганда, иң файдалы китап. Һич вакытта калдырырга һәм ташланырга ярамаган нөсхәләр җөмләсеннән.

Бу китапны тик үзен астөшермәдәге кайбер аңлатма һәм мисаллар белән бастыруны ничә мәртәбә теләсәм дә, насыйп була алмавыма бик үкенәм. Типография эшләре юлына төшкәнчә гомер калган булса, бу гыйльми хезмәтне җиренә җиткерсәм иде. Гыйлем өйрәнүчеләрнең төрле китаплар, файдалы-файдасыз әсәрләр белән чуарлануларыннан артык булыр иде. [Һиҗри] 1268 нче елда булса кирәк, остазым дамелла Нургали бине Габдеррәкыйб бине Габделмөэмин Баруди хәзрәтләре шушы «Әнмүзәҗ» китабын укый башлаганда, китабым артына «Тәзкират әл-хикәм фи табәкат әл-үмәм» исемле кыска, ләкин байтак мәгълүматлы тарих китабыннан авторның кыскача тәрҗемәи хәлен язып биргән иде. Биографияләр язучы галимнәр белән ләззәтләнү ишеген 11 яшьлек кечкенә шәкертенә ачкан иде. Аллаһ аңа хәерле әҗерен бирсен.

## Кызык хәл

«Гакаид» һәм «Сүлләмхан» өйрәнгән вакытларыбызда, иптәшләребез белән тарих кабатлаганда, берсе Зәмәхшәринең йөрәге туктап күмелгәнен, соңрак исән икәнлеге сизелеп, кабердән чыга-

рылган, дигән ялган кыйссаны сөйләгәч, иптәшләребездән мулла Әхмәджан Турави мәрхүм: «Шунлыктан аны “зи мәхшәри” (“кубарылу иясе”) дигәннәр», – дигәч, «Әнмүзәҗ» башлаганда хасил иткән кечкенә белемем белән: «Бу сүз мөнәсәбәтсез, “Зи мәхшәри” түгел, ә “зә” һәм каты “х” авазлары белән әйтелә торган Зәмәхшәр авылыннан булганга, Зәмәхшәри», – дип аңлаттым.

Зәмәхшәринең «Мүфәссал» китабы – гарәп синтаксисының иң тулы һәм могтәбәр китапларыннан. Сибәвәйһинең «Әл-китаб» исемле белән билгеле булган бердәнбер тулы гарәп синтаксисы китапларыннан соң, китапларның остазы, гарәп синтаксисының остазы булган китап – шушы «Мүфассаль». Мисырда һәм Искәндәриядә яхшы төзәтелеп басылды. Минем кулда бу нөсхәләр өстенә, аңлатучысы Ширази Котбеддин Мәхмүд бине Мәсгудь нөсхәсеннән чагышытырылган борынгы нөсхә дә газиз һәм замананың ганимәт китапларыннан.

## Икенче кызык хәл

Остазым дамелла Сәлахеддин Сәгыйдь Зәмәхшәрине искә алу мөнәсәбәте белән: «Элек шәкертләр “Әнмүзәҗ” укыганда: “Автор әйтте (аңа Аллаһның рәхмәте булсын) әгәр могътәзиләләрдән булмаса”, – дип укыйлар һәм артыгын эшлиләр иде», – диде. Мин язучы әйтәм: «Әгәр “булмаса“ сүзе урынына, “булса да” дигән булсалар, аның кайбер хакларын үтәгән булырлар иде».

Зәмәхшәридә шигырь сәләте дә яхшы булган. Табигыймы яки күп мәшгуль булу сәбәплеме – шагыйрьләрнең, яхшы күреп, күчергән шигырьләре бар. Ләкин күбрәге гыйльми һәм хикмәтле. Ибне Хәлләкян кайбер шигырьләрен күчергән, кайберләрен башка биографлар язганнар:

[...].

**Файда**. Кайбер галимнәр, кайбер урыннарда [Зәмәхшәри] яшерен рәвештә могтәзилә булганлыктан, «Кәшшаф» укуны тыйганнар, мәзһәбенең нечкәлекләреннән хәбәрдар булмаган кешенең сизмәстән хатага төшүе ихтимал, диделәр. Ләкин күпчелек тикшерүче галимнәргә күрә, аны укуда гомуми файда бар, кайбер хаталары мәзһәбләрнең теркәве белән этәрелер. Аның Коръән аятьләренең бәлагәтенә һәм мәгънәләр чыгаруына караган эзләнүләрен һәм тикшерүләрен карау тиешле.

## Уразага керү һәм ай башлары

Уфада 8 майда якшәмбе көн тәравих [намазы] башланып, дүшәмбе көн рамазан нияте белән уразада булдык. Троицкида 6 нчы мәхәлләдә җомга көн 8 апрельдә өч-дүрт кеше шәгъбан аен күреп, имамнары мулла Сәлахеддингә шәһадәт биргәннәр. Имам кабул итеп, мөхтәсибкә ирештергән. Диния нәзарәтенә мөхтәсибтән рәсми хәбәр иреште. Җомга көн көндез булган кояш тотылудан һәм шул вакытта шәгъбан аеның башы булуы аңлашылган иде. Аллаһ Тәгалә ихласлы гыйбадәтләр насыйп итсә иде.

Уфа һәм Эстәрле тарафларында сишәмбе көн тәравих [намазы] укып, якшәмбе уразада булган җирләр дә байтак ишетелде. Богырслан ягында ай күрү белән шәгъбанны җомга көннән [дип] игътибар итүләре язылган иде. Әмма Буа тарафының дәлилләре мәгълүм булмады. Бәлки, кайберләрендә Нәзарәт тарафыннан таратылган бәйрәм җәдвәлендә, якшәмбе [намазы] – рамазан башы, дип күрсәтү булгандыр. Әлеге җәдвәлдә шәгъбан 29 көннән исәпләнгән. 30 дан исәпләнсә, обсерватория карашына да якынрак булыр иде. Обсерваторияләрчә, җомга көндә шәгъбан ае туып, якшәмбе көн иртән ярты төннән соң рамазан ае туа. Ләкин якшәмбе айны күрү мөмкин булмаганлыктан, шәригать буенча, якшәмбе ай башы булып исәпләнә алмый.

Уфаның өченче районы мөхтәсибеннән 9 майда язган хат алынды. Яза: «7 майда ахшамнан соң 9 сәгать 15 минутта кисәкле болытлар арасында өч ир бер хатын рамазан аен күреп, имам Миңлегалигә шәһадәт биргәннәр. Боларның шәһадәтеннән соң, әлеге мулла үзе һәм башка халыклар күргәннәр. Бу күрүгә нигезләнеп, шимбә көн кич тәравих [намазы] укып, якшәмбе уразада булганнар. Өченче район мөхтәсибе Миңлеислам Гариф улы Госманов».

Рамазан башы керүгә, мәмләкәттә, аеруча Уфа вилаятендә кыйммәтчелек бик арткан иде. Мәсәлән, арыш онының бер поты – 140 сум, ит кадагы – биш-алты мең сум, бәрәнге поты – 35 мең сум, чәй кадагы – 60 мең сум, бер шешә сөт – 6 мең сум. Хезмәт ялы шулай ук артык югары, һәммә әсбабын биреп, беркөнне кәлүш тектердем, 12 мең сум түләдем. Игеннәр аз чәчелде, халык орлыкка мохтаҗ, хөкүмәт халыкның чәчәр өчен саклаган бодай, солы, ярма – барысын да алып бетерделәр. Чәчү вакытында бирербез, дисәләр дә, дисәтинә саен бер пот бирделәр. Казанда да артык золым һәм чиктән чыгу белән халыкның барлык азыкларын алып бетергәннәр.

Тәтеш, Спас якларында бигрәк кырганнар, халык бик ачыккан. Ишетелгәнгә күрә Тәтеш ягыннан күп гаилә Казанга килеп, сорашып, көн үткәрәләр икән. Хөкүмәтнең, балалар хөкүмәте булып, чарасызлык, халыкны куркытып кына итагать иттерү, файдаларына гомуми яхшылыкка караган эш күрә алмау белән, мәмләкәтне алып бара алмау ачык. Йә, Аллаһ, дингә ярдәм итүчегә җиңү бир, динне ярдәмсез калдыручыны ярдәмсез калдыр, әмин!

8 рамазанда (16 майда) Мәхкәмә әгъзалары һәм хезмәтчеләре өчен эш хаклары арттырылды. Мәхкәмәнең 13 меңгә алынган арыш онынннан, шул бәя белән оннар бирергә карар ителде. Мөфти вазыйфасы – 75 мең, казыйларның – 60 меңнән, башка хезмәткәрләрнең дә илле процент арттырылды. Алынган бәясеннән шул рәвештә он бирергә карар бирелде. Биш әгъзага берәр пот, сәркятип һәм өстәл башларына – 25 кадактан, ярдмәче һәм язучыларга – 20 кадактан, җыештыручыларга – 15 кадактан.

## Ястүнең вакыты хакында фәтва

18 рамазанда Самара вилаяте Мәләкәс ягындагы Филип авылы имамы Гомәр бине Шәрәфеддин Паравидан кыска кичләрдә, кояш баеганнан бер сәгать чирек кадәр вакыт кына үткәреп, ястү укуның дөрес яки түгеллеген сораган кәгазь иреште. Моңа түбәндәгечә җавап язылды:

«Һәркайсы намаз, вакыты кергәч кенә, дөрес була. Вакытыннан элек бер намаз да дөрес түгел. Тик бик кыска төннәрдә ястү вакыты кермәс булса, кызыллык батканчы, таң атса, уртача мәмләкәтләргә охшатып, чама белән укылыр. Калдыру дөрес түгел. Уртача мәмләкәтләрдә бер сәгать һәм өч чирек сәгать [1 сәгать һәм 45 минут] үткәндә генә кызыллык батып бетә. Шунлыктан кызыллык бер дә батмый торган вакытларда бер сәгать өч чиректән элек укырга юл юк. Батарлык вакытларда, әлбәттә, батуын көтәргә тиешле. Монда азрак шөбһә булганга, саклык өчен, баюдан ике сәгать үткәреп укуны диндарлык һәм гыйлем ияләре тиешле күргәннәр. Шунлыктан без дә ике сәгать үткәреп укуны тиешрәк һәм дөресрәк күрәбез. Ахырдан, бер сәгать һәм өч чирек үтмәстән укуны һич дөрес күрмибез. Дин карендәшләре! Намазның дәрәҗәсе олуг. Аның шартларын һәм рөкеннәрен саклау тиешле. Бу мәсьәләдә җиңел карау – зур гаеп. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә һәр мөэмингә иман һәм дииненең рөкеннәрен сакларга тәүфыйк бирсә иде. Мөфти

Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди, 1339 елның 18 рамазаны (1921 елның 16 мае)».

## Хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре хакында

22 нче майда Троицки шәһәренең өченче мәхәлләсендә хатыннарның җәмәгать намазына йөрү мәсьәләсендә туган фетнә турында, тыючылар тарафыннан имамнары Зыятдин бине Мөхәммәдҗан Рахманколый, хатыннар тарафыннан ике хатын җибәреп, аларга Уфадан бер хатын һәм икенче мәхәллә имамы Зыя (Пәрваз) Камали мөһере куелып, вәкаләт белән Диния нәзарәтенә 141 имзалы шикаятьнамә тапшырдылар.

Мәхәллә халкының вәкилләре Нигъмәтҗан исемле кеше сөйләгәндә, хатыннарның җәмәгать намазына керешмичә, тик мулланың кайбер әхлаксызлыклар, мәхәлләгә артык һөҗүм иткәнен кушып, халыкның күпчелеге белән эштән алынуын теләүләрен, элекке эштән алынуы өчен 141 имзалы приговор тупланып, Нәзарәткә күндерелгән таләпләренә өстәмә итте.

Хатыннарның өстәмәләре Пәрваз мулла үзеннән, мөхтәсиб Габдрахман Рәсүлигә һәм минем элек язган мөхтәсиб фәтвасына өстәгән, имзалаган кәгазьне кайтарып алуны таләп итеп, үзе язган каралама Мәхкәмәдә укылды. Бу кадәрлесе Троицки хатыннары гаризаларында һәм телләрендә булмады. Хатыннарның гаризаларында төрле әдәп һәм тәрбия булган артык сүзләр бар.

16–26 сентябрь сүездында булган тәкъдимнәрнең 30 нчы маддәсендә, хатыннар өчен мәчет ишекләре ачылсын, дигән маддәне җәмәгать намазына дип, теркәп, арттырып яздганнар. Бу маддәне Нәзарәт вәгазь белән башлап, намаз мәсьәләсен әкренләп гамәлгә куюны тиешрәк күрү фикере белән, мөхтәсибләр аркылы вәгазь мәсьәләсен игълан итеп, намаз мәсьәләсен калдырып торган иде.

Бу турыда хатыннарның гаризасында тупас рәвешчә мондый гыйбарә язылган: «Диния нәзарәте бу мәсьәләгә карата бүгенге көндә кулында бер норма булган 30 нчы маддәгә таянып, безнең хакыбызны якласын иде, галимнәр җыены тарафыннан норма итеп кулына тапшырылган бу маддәне яшереп яткыру безгә каршы эшләнгән бик зур җинаять икәнен исенә төшереп, бу маддәне гамәлгә кую өчен бөтен Троицки имамнарына рәсми рәвештә язу күндерелсен иде».

Бу мәсьәләнең кыскасы, мөхтәсибнең һәм минем (мөфтинең) имзалар үтте. Анда искә алынган хәдис риваятьләре һәм Нәвавинең аңлатмалары хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре дөрес, ләкин зиннәтсез, хушбуйсыз рәвештә булулары, өйләрендә укулары хәерле, Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) тарафыннан ачык әйтелгән, Әбү Дауд риваятендә бар икәне аңлатылган иде.

Троицкиның гади халкы бу фәтваләрне күргәч һәм ишеткәч, асыл мәсьәләдән хәбәрдар булып, йомшадылар, шунлыктан муллалары Зыя Рахманколый турында бар начар хәрәкәте һәм деспотларча эшләре сылтавы белән, хатыннар мәсьәләсен катыштырмыйча, эштән алынуына карар бирделәр. Хатыннарның надан дуслары, фанатик яклаучылары ул мәкаләдәге «ләкин мәчеткә йөрергә кызыктырылмас» гыйбарәсен авырсынып, пәйгамбәр өйрәтмәсенең рухы булган шушы чикләүне начар күреп, фетнәгә сәбәп тоттылар.

Зыя мулланың электән булып үткән ысулсыз хәрәкәтләре дә бертуганы Таҗеддиннең хәрәкәтләндерүе һәм кызыктыруы, һәр язуларда кереше белән башланган һәм куерган. Каршылык һәм бозыклыкны шул тиешле гыйбадәткә нисбәт итеп, миннән ризасыз булдылар һәм Габдрахман Әхмәр тарафыннан үземә дә язылды.

Бу кадәр хәрәкәтләрне сылтау һәм яхшы сәбәп итеп, минем хакта байтак нәфрәт һәм дошманлык саклап, форсат килгәндә, аны ачык күрсәтүендә кимчелек китерми торган Зыя Камали язуында «Мөфти биргән фәтвасен кайтарып алсын» дигән гыйбарәсенә кадәр язган иде.

Зыя Камали минем хакта Аллаһ һәм илчесенең шәригатен бозу, тарайту, фәкыйһләргә сукырларча иярү, хатыннар хокукын бозу һ.б. кебек сүзләр керткән. Троицки хатыннары язуларында мондый тупас яла ягулар булмаса да, вәкаләтне ганимәт дип белеп, йөрәгенә бераз рәхәтлек суын сипкән.

Бу мәсьәлә турында Чиләбе имамы Салихҗан Урманов, төбәк мәдрәсәсен торгызу сылтавы белән, Троицкига барып, хатыннарны туплап, вәгазь һәм кайбер кисәтүләр сөйләүдә булган иде. Үзе югарыда искә алынган Урманов электән үк Рахманколый гаиләсе белән дуслыкта, үзе Чиләбедә байтактан ук бу мәсьәләне гамәлгә куйган булганлыктан, бу мәсьәләнең бишенчесе иде. Рахманколыйлар тарафыннан Мөхлиса ханымга язылган хатларында әлеге затны тикшерү өчен таләп иткән булса да, Троицки кебек зур мөселман

шәһәренә читтән һәм мәсьәләдә ачык бер тарафны тоткан адәмне күндерү яраклы күрелмәгән иде.

Ниһаять, Нәзарәт 23 майда Зыя [Рахманколый] мулланың эштән алыну мәсьәләсен тикшереп, тикшерүчеләрдән килгән язуларны күреп, халыкның аны эштән алынуын үҗәт теләүләре күренсә дә, Зыя мулла бу тикшерүчеләргә риза булмыйча, җавап бирмәгәнгә, Мәхкәмә мәҗлесендә соңгы карар чыгарылмыйча, үзеннән җавап алырга, тикшерү комиссиясе рәисе мулла Мөхәммәд Бикмәти аркылы язу җибәрелүгә карар бирелде. Шулай да үзара сөйләшүдә: «Әлеге имамга мәхәллә халкы тарафыннан ягылган гаепләр бер дә гаеп түгел», – дип казый Ризаэддин игълан итте. Һәркайсы гаепләрне берәм-берәм, авырлык белән булса да, аңлатырга тырышты. Гаепләр:

1. Мәхәллә халкына әйтмичә, хатыннарны мәчеткә китергән.

2. «Намаздан соң, хатыннар чыкмый торып, ирләр чыкмасын (монысы дөрес)», – диюеннән соң, чуалыш булып, халык тарафыннан муллага ризасызлык күрсәттеләр. «Троицки галимнәр съезды карарына каршы эшләдең», – дигәннәр. Мулла әйткән: «Ул – минем эшем, ничек телим – шулай эшлим», – дигән, шул арада күкрәгенә сугып: «Бу минем эшем, үз теләгемчә эшләдем, сезнең мәчет миңа кирәк түгел, сезне мөселман дип белмим, мәчетне калдырам», – дигән сүзеннән соң мәчеткә килмәгән.

3. Мәхәлләдә фәкыйрьләрне кайгыртмады, күмү хезмәтләрен үтәмәде.

4. Төрле әхлаксызлыгы сәбәпле, рухани булып торырга лаек түгел.

5. Берничә ел элек бер сабый кызның намусына тиеп, балигълыкка ирешкәнче тәрбияләп, ирешкәннән соң, үзенә никахланачак булып, фетнәне басып калдырды.

6. Хәзер спекуляция белән мәшгуль, җәмәгать намазларына айларча килми, кыш көннәрендә дә ястү намазына [килүен] дәвам итми.

Бу вакыйгада Диния нәзарәтенең карашы:

Нәзарәт Троицки Зыя мулланың хосусый бу мәсьәлә игътибары белән эштән алуны тиешле бер эш [дип] тапмый, халыкның артык хәрәкәтләрен һәм бөтенләй эштән алуын теләп, үҗәтләнүен чиктән ашу [дип] күрә. Тикшерүчеләрнең бик вак кимчелекләрен сылтау итеп, әлеге Зыя мулла аларга җавап бирмәгән, башка тикшерүчегә җавап бирәчәген белдергән. Җавап биргән булса, үзе өчен яхшырак

иде. Үзеннән туры җавап сорап, Мөхәммәд мулла Бикмитов аркылы язу күндерелде. Аның бу мөгамәләсе Мәхкәмә хакында яхшы мөгамәлә булмаса да, Мәхкәмә һаман күркәм мөгамәлә белән хәрәкәт итә. Казый Ризаэддин әфәнде: «Зыя мулланың бу эштә бөтенләй гөнаһы юк, югарыда әйтелгән маддәләрне гаеп түгел, һәммәсе юллауны кабул итә», – ди. Сабир казый: «Эшнең тышкы ягыннан күренгәнчә, әхлаксызлык, мәхәллә кешеләре белән имамнар өчен кирәкле булган дәрәҗәдә мөгамәлә һәм сәясәте юк, зарурлыксыз деспотларча мөгамәлә күрсәткән», – дип бераз җәза бирү ягында иде. Кәшшаф казый исә урта бер хәлдә, Мөхлиса да аннан ерак түгел.

Ничек тә эшне тәмам хәл итмичә, үзеннән җавап алуга кадәр калдырылды. Мәчетләрендә Зыя мулланың йөз чөерүеннән, мәхәллә кешеләренең дә аны кабул итмәүләреннән, ничә атналар җомга укылмаган. Мөәзиннәре, указлы булса да, ни өчендер батырчылык итмәгән. Мәхәллә һәм мәчетне җомгасыз асрау фетнәне басу булмый, ә кабарту булганга, халыкның вәкиле Нигъмәтҗан Әхмәдһади улының соравын сылтау итеп, мөәзиннәре Вәлиуллага җомга укыту өчен язу бирелде. Ризаэддин казый бу мәсьәләдә дә каты рәвештә каршылык күрсәтте: «Гаебе исбатланмаган, фәкать яла ягылган имамны эшеннән тыю төсен биреп, золым була», – дип аерым фикер игълан итте. Ләкин бу эшендә бер төр тыйнаксызлык, артык җөрьәт бар иде. Яла ягылган имамны, мәсьәләсе хәл ителгәнче, вакытлы сурәттә эшеннән туктату мөмкин һәм рөхсәт ителгән эш, бигрәк тә аның эш үтәвендә фетнә арту ихтималы булса. Чынлыкта, эшеннән без туктатмадык, халык белән ике арасы бозылган, «Сез мөселман түгел вә фәлән» дигән әдәпсез сүзләр кулланган, «Мәчетегез кирәкми», – дигән. Шундый мөгамәлә сәбәпле, бөтен кеше аны мәчеттән тыйган. Мулла мәчеткә килмәгәндә мөәзиннәрнең җомга укытулары – ысул һәм гадәт, хаклары бар. Бу кыюсыз мөәзингә хакын белдерү өчен генә язу җибәрелде.

Бу арада балаларына һәм якыннарына шәфкать күзе белән генә караучы ахун Әхмәдхаҗи Рәхмәнколый, бертуганының энесе Зыятдин мулланы яклау һәм кияве мөхтәсиб Габдрахман Рәсүлине гаепләү рәвешенчә, миңа язган хаты иреште. Искә алынган зат та, мөхтәсибнең асыл мәсьәләдә (хатыннарның мәчет җәмәгатенә килүләре турында) хәдис шәрифләрне күчереп һәм Нәвавинең кайбер сүзләрен өстәп, Троицки съездында үз карарларынча, мәчеткә аерым капкалар, урыннар торгызганчы сабыр ителсә, яхшырак» ди-

гән кебек сүзләр белдергәнлектән, байтак шелтәләгән. Йорт хуҗасы йорт эчен яхшырак белә, дигән сүз буенча мөхтәсибнең бу фәтвасе һәм аны минем раславым мулла Зыя тарафыннан начар хәрәкәте һәм мөгамәләсе белән бозылган, гади халык өчен бераз дәлил булса булгандыр. Ләкин төп мәсьәләне аңлауларында байтак файда иткән булса кирәк ки, хәзер Диния нәзарәтенә килгән вәкилләре телендә хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре мәсьәләсе бер дә булмады, анда шөбһәләре беткәнгә охшады. Бары башка төрле сәбәпләр белән мулланың эштән алынуын сорауда үҗәтлек күрсәтте. Шуның аркасында муллага файда булачагын әйтеп куйды. Хатыннарның сорауларына күрә, чиктән чыгу һәм салкын карауларны алып ташлаганнан соң, бер дәрәҗәдә җавапны яраклы күреп, кулларына мөхтәсибкә Диния нәзарәте тарафыннан бер фәтва сурәте язып бирелде. Моннан гыйбарәт:

«1921 елның 25 маенда булган хөкем: Троицки шәһәрендәге мөселман хатын-кызларыннан гыйбарәт [булган] җәмәгатьнең вәкилләре тарафыннан: «Пәйгамбәр яшәгән бәхетле заманда пәйгамбәребез янында мөселман хатын-кызларының Аллаһ йортына килергә хаклары булган, бу замандагы мөселман хатын-кызларының да Аллаһ йортына килергә хаклары бар икәнлеге хакында фәтва бирсәгез иде», – дип фәтва сорала. Мәгълүмат, 8 нче канун, 10 нчы маддәләр.

Карар. Югарыда зикер ителгән фәтва соравына мондый рәвештә фәтва бирелде: «Имам Әхмәд бине Хәнбәл тарафыннан риваять ителгән: «Аллаһ хатын-кызлардан булган Аллаһ колларын мәчетләргә барудан тыймагыз, ләкин бизәнеп чыкмасыннар», имам Мөслим тарафыннан риваять ителгән: «Хатыннарыгызны, әгәр рөхсәт сорасалар, мәчетләрдән тыймагыз», һәм Әбү Дауд тарафыннан риваять ителгән «Хатыннарыгызны мәчетләрдән тыймагыз, ләкин алар өчен өйләре хәерлерәк» хәдис шәрифләренең сүзе буенча, дини вәгазь ишетү һәм гыйбадәт кылу өчен мәчетләргә йөрергә хаклары бар. Гыйбадәт өчен йөрүче мөселман хатын-кызлары мәчетләрдән тыелмас. Бу фәтва Троицки мөселманнарына белдерелер. Хәдис шәрифләрнең мәгънәләренә күрә, мәчетләргә йөргәндә зиннәтләнми, ислемай сөртмичә йөрүләре тиешле булыр һәм мәчетләрдә җәмәгать намазларына килүләренә шәригать тарафыннан тыю булмаса да, өйләрендә уку хәерле икәнлеге дә аңлатылыр. Мөфти: Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди. Казыйлар: Ризаэд-

дин бине Фәхреддин, Кәшшаф Тәрҗемани, Мөхәммәдсабир Хәсәни, Мөхлиса Бубый».

Мондый сурәттәге фәтва мөхтәсибкә җибәрелеп, 3 нче мәхәллә халкына белдерергә, сораган имамнарга да нөсхә җибәрергә язылды. Троицкида туган бу мәсьәләне хәл итү өчен мөхтәсиб Габдрахман бине шәех Зәйнулла җәнапләренә мөрәҗәгатьләре, аның фәтвасе дә минем тарафтан дөрес күрелеп, имзасы хатын-кыз галәменә, аларның мактау сүзе көйләренә, фәтвадә һәм хәдистә бераз чикләү һәм кысалар булганлыктан, муафыйк күрелмәде. Шул сәбәпле, югарыда язылган төрле сүзләр арттырып, дәрәҗәләреннән үтеп, гаризалар, тәкъдимнәр тәкъдим иттеләр. Бу озын язу – мөхтәсибнең фәтвасе һәм минем имзам сурәте:

«Уфада Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының Диния нәзарәтенә:

Бу тарафта хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре хакында күп сүзләр булып, халык арасында каршылык булып, бик зур эшләр булып тора. Бу турыда безгә рәсми рәвештә вәкилләр аркылы фәтва сорап мөрәҗәгатьләр булды. Мин зарарның кечерәген игътибарга алып һәм урта юлны тотып, түбәндә искә алынган рәвештә фәтва бирдем. Бу фәтванең чынбарлыкка туры килү-килмәве хакында рәсми рәвештә белдерүне Диния нәзарәтеннән үтенәм. Бу тарафтагы каршылыкны басу өчен «Сүнән Әби Дауд»та искә алынган хәдис шәрифләрнең текст һәм ишарәтләренә һәм дә имам Нәвави хәзрәтләренең «Сахих Мөслим шәрехе»ндәге сүзләренә нигезләнеп, хатыннарның җәмәгать намазына, зиннәтләнмичә, ислемай сөртмичә, тавыш чыгара торган бизәкләрсез, ирләргә катышмый һәм башка фетнәгә сәбәп була торган рәвешләрдән сәламәт булып, килсәләр, аларның җәмәгать намазларына килүләренә тыю юк. Ләкин хәзерге заманда хатыннарга бу шартларны йөкләтергә бездә мәгънәви һәм матди куәт юклыгыннан (гасры сәгадәттә кебек), хатыннарның, кайберләре шартларны үтәсәләр дә, күбесе үтәмәячәк, мәчетләрдә хатыннар өчен аерым ишекле бүлмә булганда гына бу шартлар табылып, ул вакытта хатыннарны җәмәгать намазына килүдән тыярга юл булмаячак. Болардан чыгып, хатыннар өчен мәчетләрдә аерым ишекле бүлмә әзерләгәндә, хатыннарны җәмәгать намазына барудан тыю юк. Аерым ишекле бүлмә әзерләнмгәндә, хәзерге заманда шартлары табылмаганга, хәзерге заманда тыюга юл бар.

Аерым ишекле бүлмә булу тиеш булу хакында «Сүнән Әби Дауд»та Ибне Гомәр хәзрәтләреннән күчерелә, пәйгамбәребезнең

«Бу ишекне хатыннар өчен калдырсак иде» дигән сүзен ишеткәннән соң, «Ибне Гомәр, үлгәнче, ул капкадан кермәде» дигән хәдистә ишарә бар. Чиләбе вилаятенең 3 нче районы мөхтәсибе Габдрахман бине шәех Зәйнулла Рәсүли».

[...].

Хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре турында Троицки мөхтәсибе мулла Габдрахман Рәсүли җәнапләренең фәтвасен Русия, Себер, Казакъстан мөфтилеге дөрест таба. Бу кадәрне өстәп әйтә:

«Шартлар үтәп мәчеткә йөргән хатынны тыелмаса да, җәмәгать намазына чыгу мәсьәләсендә шәригать буенча кызыктырылмас һәм өндәлмәс. Рәсүлүллаһтан (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) эчке бүлмәләрендә укуларының яхшырак булуы турында дөрес хәдисләр бар. Бары намаз вакытларыннан тыш, аулак вакытта хатыннарга махсус вәгазь мәҗлесе төзү шәригать буенча дөрес һәм яхшы.

Быелгы 16–26 сентябрьдә булган съездда гомумрусия галимнәре һәм мәчет эшләрен башкаручылары тарафыннан да бу эшкә карар бирелде, Диния нәзарәте тарафыннан халыкка игълан ителгән иде. Мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди, [һиҗри] 1339 елның 17 рәҗәбе».

Хатыннар мәсьәләсе хакында һәр ике тарафтан килгән вәкилләр һәм шикаятнамәләр Диния нәзарәтендә каралды. Хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре турындагы сораулар хакында Ризаэддин әфәнде электән үк «Җәвамигыль-кәлим шәрехе» китабында язганча, киңәйтү ягында булып, җавапта тик дөреслеген әйтү кирәк, искәрмә һәм шарт урынында хәдисләрдә килгән «Бизәнмичә чыксыннар, йортлары алар өчен хәерлерәк» дигән чикләүләрне искә алмауны тәкъдим итте һәм байтак үҗәтлек күрсәтте. Ләкин мәҗлес әгъзаларының күбесе әлеге чикләүләрне фәтвадән калдырмыйча язуны тиешле күрделәр. Кәшшаф казый асыл мәсьәләне ашыгыч башланган, элек, намаз вакытларыннан тыш, башка вакытта хатыннарга вәгазь мәҗлесе ачып, халыкның күзен ияләштергәнче башланса да, яраган булыр иде, Зыя мулла ашыккан, дисә дә, һәр тарафка да карау ысулынчарак фәтва тестында дөреслекне абсолют сурәттә язып, әлеге ике чикләүне тиешле кисәтү сурәтенә кертеп язуны тәкъдим итеп, Ризаэддин әфәнде дә соңыннан моңа риза булачак булгач, мин, Сабир казый, Мөхлиса казый да, шуңа риза булып, яздык. Югарыда күчерелгән фәтва нөсхәсен мөхтәсибкә һәм хатыннарның вәкилләре кулларына биреп җибәрелде. Вәкилләрнең

берсе Кәшшаф казыйга икетуган булганга, торган урыны да анда иде.

Гәрчә бу фәтва минем язганым һәм мөхтәсибнең язганы фәтва сурәтенә тәмам туры булмаса да, мәгънә ягыннан күп аерма булмаганга, мин үз гыйбарәмдә артык үҗәтләнмәдем. «Рөхсәт булса да, кызыктырылмас» [дигән] гыйбарәмне Троицки хатыннары тарафдарлары һәм казый Риза әфәнде кирәгеннән тыш күргәнгә, хәтта кайберләре шәригатькә каршы дип уйлаганга, эчтәлеккә туры килү белән чикләнеп, артык сүзгә сүз туры килсен дип артык омтылмадым. Бу мәсьәлә әһәмият кәсеп иткәнгә, бу урында булган хәдис шәрифләрне җыю яраклы күренде:

[...].

Рәсүлүллаһның (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) хәдисләрендә күренгәнгә күрә: 1) хатыннарны Аллаһның мәчетләреннән тыймыйлар; 2) хатыннар мәчетләргә чыксалар да, өйдәге хезмәт киемнәре белән, хушбуйлар белән исләнмичә генә, чыгарга боерылган; 3) хатыннарның өйләрендә, өйләренең эчке бүлмәләрендә укулары мәчетләрдә, хәтта «Хәрам» мәчетендә дә [укуларына карагандa] яхшырак булган һәм анда [«Хәрам» мәчетендә] бер намаз башка мәчетләрдәге мең намаздан хәерле булган рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) мәчетендә укудан яхшырак икәне үзенең сүзендә ачык белдергән; 4) мөэминнәр әмире Гомәрдән (Аллаһ аннан риза булсын), мөэминнәр анасы Гайшәдән (Аллаһ аннан риза булсын) башлап бу көнгәчә килгән күпчелек галимнәрнең хатыннарның (бигрәк тә яшьләрнең хәлләренә, күбрәгендә күренгән үзгәрешләргә күрә) җәмәгать намазына йөрүләрен тиешле эш санаулары, кайберләренең хөкемендә «мәкруһ» сүзе күренүе хәдис шәрифләрнең эчтәлекләренә һәм рухларына бик туры килә; 5) хатыннарның дөрес вәгазьләргә, дини, әхлакый һәм иҗтимагый мәсьәләләрдә дөрес укыту һәм кисәтүгә ихтыяҗлары бар һәм ачык. Бу хәҗәтләрен остазбикәләр үти алмаулары ачык. Үзләре дөрес тәрбия, чын иясеннән дөрес укыту алмаган бу кешеләр хатыннарны кичек укытсыннар, нинди рух бирә алсыннар? Әлбәттә, бу җитешле түгел. Рәсүлүллаһның гамәленнән бу мәсьәлә ачык. Рәсүлүллаһның (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) гомуми укыту һәм тәрбиясе була торып, хатыннарга аерым вәгазь сөйләгән, үзенең хатыннарыннан (мөэминнәрнең аналары) вәгазь ишетсәгез, җиткән, димәгән, Шунлыктан имамнарга, сирәк-сирәк булса да, хатыннарга

вәгазь сөйләргә кирәк. Гади халык бу эшкә каршы тормаска һәм бу эшне инкяр итмәскә тиеш.

| **Троицки 3 нче мәхәлләсе халкының кайбер каршы чыгулары** | **Җавап** |
|---|---|
| Мөфтинең фәтвасе кайтарып алырга тиешле | Шәригатькә муафыйк булганга, кайтарып алынмый |
| Мәхкәмә шәргыя мөфти фәтвасенең эчтәлегенә туры килгән фәтва биргән | Шәригать таләпләренә туры килгәнгә күрә, туры килгән |
| Мөхтәсиб кәгазьләренә тиз җавап бирелгән хәлдә, алар сорауларына тиз җавап бирелмәде | Каршылык һәм фетнәнең басылуын теләп, тиз җавап бирелгән. Халык сорауларына да элекке җавап җавап булганга, аерым җавап һәм фәтва тиешле күрелмәгән |
| Тикшерү комиссиясенә мөхтәсиб кертелгән | Төбәк мөхтәсибенең читтә калуы яраклы күрелмәгән. Ләкин фәтвасе булганга, эштә рәис итеп билгеләнмәгән |
| Фәтвадә ярый яки ярамый дип кыска җавап бирелмичә, озын һәм койрыклы фәтва бирелгән. | Яхшы аңлату тиешле булганга, шәригать иясенең фәтвасенә яраклы фәтва бирелгән |
| Съездның бу мәсьәләдәге карарлары игътибар ителми | Игътибар ителә. Съезд шартларны игътибар иткән, Мәхкәмә дә шул шартлар белән мәйданга чыгуын тели |
| Әлеге карар тиз генә бөтен җиргә игълан ителмәгән | Элек вәгазь мәҗлесләре аркылы халыкны әзерләп, фетнәгә юл куймауны күздә тотып, акрынлап эш күрү тиешле күрелгән |
| Бу маддәдә съезд карарына каршы фәтва чыгарыла | Фәтва съезд карарына каршы түгел, мәгънәсенә һәм максатына туры килә |
| Хәдис шәрехләүчеләр һәм мөҗтәһид-галимнәр сүзләре хәдис урынына кулланыла, аларның фикерләре белән шәригать алмаштырыла | Хатадан саклану өчен бер якка авышу белән гаепләнмәгән галимнәрнең аңлауларын һәм аңлатмаларын дөрес күреп, якланыла. Шартлар белән чикләү Мәхкәмә яки элекке галимнәр тарафыннан уйлап чыгарылган нәрсә түгел, Рәсуллүлаһның (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) үзеннән чыккан. Аның |

| | |
|---|---|
| | эшенә тәнкыйть ирештерү – зур әдәпсезлек һәм җинаять. Бу мәсьәләдә һичкайсы мөҗтәһиднең үзлегеннән бер чикләү һәм шарт өстәлмәгән |
| Хатыннарның җәмәгать намазларына йөрүләрендәге тарлык сәбәпле, милләтнең төзеклеге һәм үсеше тоткарлана | Аларның төзеклек һәм үсешләрен тиешле күреп, элек вәгазьләр белән башлауны, ирләрен дә, үзләрен дә акрынлап мәсьәлә белән таныштыру тиешле күрде. Вакыты килгәндә, җәмәгать намазы турында да белдерәчәк иде. Хатыннарның әхлакый үсүләре өчен яхшы вәгазьләр файда итсә итәчәк |

**«Мөкаддимәи җәзәрия» китабы**

22 рамазанда (29 майда) Коръәнне дөрес уку гыйлеме буенча мәшһүр «Мөкаддимәи җәзәрия» шигъри әсәрен укытып тәмамладым. Ике данә аңлы һәм мәхәббәтле адәм башлаган иде. Тар-тар араларда укып тәмамладылар. Бер дәрес Коръән башыннан да укып, ярты җөз [Коръән өлеше] укып, гает мөнәсәбәте белән, өйләренә кайтырга рөхсәт алдылар. Кайбер вакытта кушылган башка шәкертләр дә булгалады. Вакытым, сихәтем һәм бәдәнем куәте бик ярдәм итеп тормаса да, мәхәббәт белән укыганга, башка җирдә бушлай укытучы табылмаганлыктан, өстемә йөкләгән идем. Аллаһ ихласлы кылсын.

Коръәнне дөрес уку гыйлеме бу соңгы елларда кечкенә балаларга мәктәптә икенче сыйныфта укыла торган булып киткәнгә, аларның дәрәҗәләренә туры килгән «Карабаш тәҗвиде» һәм башка җиңел Коръәнне дөрес уку нөсхәләре укылганлыктан, зур шәкертләр шулкадәр укыту белән канәгатьләнә торган булып киттеләр. Һәр фәнне дәрәҗә-дәрәҗә уку, бара-бара шулай камил дәрәҗәгәчә хасил итү тиешле иде. Урта, соңгы сыйныфларында яки соңрак бу «Мөкаддимәи җәзәрия» укылуы да файдалы һәм кирәкле. Ничә төрле таләп ителгән фәнне үз эченә алган. «Аваз чыгу урыннары», «аваз сыйфатлары», гамәли Коръәнне дөрес уку сурәте, «туктау», «сузу» бүлекләре, Коръән язуы, «ялгау һәм туктау һәмзәсе». Менә бу мәсьәләләрнең һәркайсы – гыйлем алучы өчен әһәмиятле мәсьәләләр. Бу олы кагыйдәләрне 107 бит белән бәян иткән. Һәркем өчен

ятлавы җиңел. Гыйлем алучылар исеменнән аңа Аллаһның хәерле әҗере булсын!

Минем бу нөсхәдә һәм искә алынган Җәзәринең «Әл-хисън әл-хәсыйн мин кәләми сәййидил-мүрсәлин», «Ән-нәшр фи әл-кыйраәт әл-гашр», «Әснә әл-мүталлиб фи мәнәкыйб Гали бине Әби Талиб» яки «Фи мүснәд Гали бине Әби Талиб» һәм башка файдалы китапларында тоташу чылбырым: ... *(бу урында бер бит кадәр ачык калдырылган)*.

## Бәләбәй өязенә сәфәрем

Уфа ягында булган авылларны күрү, имамнарның һәм мәхәлләләрнең хәлләреннән хәбәр алу күптән зарур иде. Быел Бәләбәй өязе алтынчы районы мөхтәсиблегендә мулла Габдулла бине Сәгъдеддин идарәсендә вакытлы курслар ачылып, шул сылтау белән кайбер дәресләрен күрү өчен чакырылган идем, бер дәрәҗәдә вәгъдә биргән идем. Бу көннәрдә бәйрәм ялы әлеге сәфәргә ярдәм булып, бераз ялга да ихтияҗым булганга, 27 рамазанда (4 июньдә) иртәнге сәгать алтыда өемнән чыгып, Иделнең аргы тарафында булган Ибраһим авылыннан киләсе атлар янына бару өчен, су буена төшеп, ялгызым (хәер, бер кәҗә белән сакчысы [булган] бер кечкенә кыз бар иде) бер көймәдә кичеп, хуҗасына 250 сум биреп, атлар килеп җитмәгәнгә, рәхәтләнеп тәһарәт алдым. Озак үтмәде, атлар да килеп җиттеләр. Яр буенда хөкүмәтнең арбаларны кичерү паромы халыкны буш чыгарып торса да, чират тиз җитмәгәнгә, хосусый адәмнәрнең арба сыйдырырлык көймәләренә дә ике-өч мең түләп чыгучы арбалар да күп була икән. Икешәр йөздән алып җәяүлеләрне үткәрүче кечкенә каеклар да байтак килеп торалар. Бу кечкенә каекчылар көнлек биш-ун мең, хосусый зур көймәчеләр һәр кешедән кырык-илле меңгә кадәр хасил итәләр икән. Көнлек чыгымнарына җитәрлек һәм бераз запаска җитәрлек та була торгандыр.

Искә алынган атлар Уфадан кыйбла тарафында 45 чакрым кадәр ераклыкта булган Ибраһим исемле мишәр авылының имамнары тарафыннан җибәрелгән ике ат гади, көймәсез генә тарантас иде. Җиде туларга чирек сәгать калганда, Аллаһка тәвәккәлләп, утырып юлга чыктым. Атны йөртүче шул авылда имам Гыйzzеддин бине Садреддин, бер атның хуҗасы иде. Гади генә бер сәгатьтә җиде чакрым йөреш белән, Романовларның сәясәте буенча, һәр

шәһәр тарафындагы кебек, Уфаның да якын түгәрәгенә урнаштырылган урыс авылларын үтә-үтә 25 чакрым кадәр йөргәч, бер күлгә очрап, атларны тугарып, аннан соң кечкенә бер урманда ярым сәгать кадәр атларга ял бирдек. Агач арасында булган яхшы гына чирәмне ашадылар. Һава бик кызу, зонтик куллану гадәтем түгел, уртача булу шарты белән, кояштан файдалануны сихәт өчен файдалы күргәнгә, бер дә ялыгусыз, бүрегемне дә салгалап, гади, юка, ак кәләпүшем белән дә килдем, әлхәмдү лилләһ, зарар күрмәдем. 17 чакрым кала бер матур агым суда тәһарәт алдым, аякларымны юып, рәхәтләндем. Бер ярым сәгать булган иде, өйлә намазының ике рәкәгатен укыдым, намаз өчен ашыгыч булмаса да, сахрадагы азан һәм камәт турындага хәдис шәрифләрдә өндәү-кызыктырулар, фәрештәләрнең килүләре турында сүзләр булуын хәтергә алып, яшел чирәм өстендә укуны ганимәт дип белдем. Сәфәрдә, иртә намазының сөннәтеннән [кала] башка сөннәтне укымау әсәрләргә күрә артыграк күренгәнгә, бу соңгы елларда Габдулла бине Гомәрнең (Аллаһ аннан риза булсын) риваятен дәлил итеп, юлда сөннәтне калдыра торган булган идем. Сәгать нәкъ ике тулганда Ибраһим авылына җитеп, Садреддин агайның йортына – балчык белән сылаштырган кечкенә генә өйнең бер тарафындагы ак келәтенә – кердек.

22 рамазанда якшәмбе көн төштән соң гына бу авылда Гыйззеддин мулланың күршесеннән генә ут чыгып, мулланың йорты, каралтысы һәм башкалардан җитмеш ике кадәр капка йорт янган. Зур хәсрәт булган. Бер-ике еллык саклап тоткан азыклары һәм әсбаплары да янып, байтак авыр хәлгә калган адәмнәр булган. Бичара безнең Гыйззеддин мулла дәрвиш табигатьле, шәех Зәйнулла хәзрәтнең тышкы һәм эчке тәрбияләрендә булган, сабыр, канәгать, бер юмартлык иясе булганга, бер дә борчылмый, шулкадәр авыр хәлгә төшкән булса да, ихласлык һәм мәхәббәт белән мине каршы алуына һәм хезмәтенә килгән иде. Атасының келәтенә урнашып, шөкер итеп яшәүдә икән. Йорт әсбаплары, китаплары, кием-салымнары юкка чыккан, савыт-сабалары, азыклары, арба-чаналарының барысы да һәлак булган. Аллаһ югалган әйберсен хәерлерәге белән алыштырсын.

Берәр сәгать шул келәттә ял иттем. Соңра очрашу, күрешү өчен килгән имам-мөәзин һәм башка мәчет әһелләрен кабул итеп, икенде намазына хәтле сөйләшеп утырдык. Икенде намазына чыгып укыганнан соң, авылның ике мәхәлләсеннән дә имамнары һәм халкы

тупланганга, мәчетнең кайбер җирләрен буяп, һавасын авырайткан-га, мәчетнең алдына чыгып, ахшам азанына кадәр бераз вәгазь-нәсыйхәттә булдым. Ихласлык белән тыңладылар. Дин саклау, күркәм әхлак, фәкыйрьләргә, ятимнәргә шәфкать, авырлыкларга, бәлаләргә сабыр итү турында сөйләнде. Нечкә күңел, күз яшьләре белән каршы алдылар. Ахшам намазын укып, мулла Гыйзздеддин өендә ашап, андагы әманәт бер умартамны күреп, соңра бергә эшләүче имамы-хатыйбы мулла Гобәйдулла өенә барып, берәр пыяла чәй эчеп, кояш батудан ике сәгать үтүгә, шул беренче мәчет-кә кайтып, тәравих [намазы] укыттым. Мәчетнең сөннәт бүлмәсендә хатын-кызлардан байтак кеше күренде. Укыр өчен килгәннәрме яки фәкать күрү һәм тыңлау өчен килгәнннәрме? Тәслим аятьләре («Сәләәмүн галәә...») белән укып, тәмам иткәннән соң, икенче мәхәллә имамы Гандәлиб өендә кыскача кунак кабул иттек. Бу адәм гади генә, динле һәм әхлаклы адәм [булып] күренде. Намуслылыгы һәм мәхәлләсенә файдасы бар икән. Троицки Зәйнулла хәзрәткә та-рикатьчә нисбәте булган. «Дәләил әл-хайрат» укырга теләге булып, берәр остаздан рөхсәт алмаганга, туктап тора икән. Дөрес укырдай булганда, рөхсәт шарт түгеллекне, тик гыйбарәләрен дөресләү, мәгънәләрен уйлау һәм ният төзәтү кирәклеген аңлатканнан соң, мулла Гыйзздеддин белән икесенә рөхсәт бирелде.

Бу сәхәрдә ике кешегә кыскача кереп чыгып, таң каршы алын-ды, намаз укып, ял иттем. Иртәсендә очрашу өчен кайбер авыллар-дан килгән муллаларны кабул итеп, әзерләнеп сәгать 9 да янә юлга чыктык. 40 чакрым кадәр ераклыкта булган Чуенчы авылына дип юнәлдек. Бу авылга да элегрәк таныш Гобәйдулла мулла үз атлары белән илтәчәк булса да, соңыннан арбасының тәртәсе сынганын хәбәр итеп, мулла Гыйзздеддингә аударды. Искә алынган зат исә шат һәм риза булып, күчерлек хезмәтен дәвам итте. Ибраһим авылын-нан 15 чакрым ераклыкта булган Мөрәс авылына ирештек. Иске Мөрәс, Яңа Мөрәс исемле авыллары – ярым чакрым кадәр ике авыл. Иске Мөрәс башкортлары җирләрен сатмакчы булгач, бер өлеше бүленеп, җирләрен үзләренә калдырып, яңа авыл тәшкил иткәннәр, мәчет торгызганнар, имам һәм мөәзин куеп, яхшы гына тормыш итү юлына кергәннәр. Иске авыл аз калып, фәкыйрьлек һәм авырлык хәленә төште. Бу Яңа Мөрәстә Мәгъсүм мулла исемле кеше, кирәк вакытта туктау өчен билгеләнгәнгә, белмәгән кешебез дип уйласак та, сугылгач, үзебезнең белеш һәм дус дамелла Габдерәхим Утыз-Имәни оныгы, ак сакаллы мулла Мәгъсүм бине мулла Әхмәдҗан

бине мулла Габдерәхим бине Госманның капка ачып каршы алуын күрдем.

Куаныч белән очрашкач, өенә кердек. Соңра ишегалдына чыгып, тормышын һәм әсбабын күздән кичердем. Бу адәм Уфада бер-ике мәртәбә юлыккан иде. Бу сәфәремдә, Идел буенда судан кичәр өчен көймә көткәндә, очраткан идем. Табигатендә шагыйрьлек һәм матурлык, җиңеллек белән ягымлылык бар. Гарәп һәм фарсы телләреннән өстән генә аңларлык дәрәҗәдә танышлыгы бар. Бабасының китапларына мәхәббәте һәм фанатизмы, эчтәлекләре белән гомуми танышлыгы бар. Байтак иркен ишегалды чиста, җирәнгеч чүп-чардан пакь, олы чәчүлек иясе булганга, тиешле яңа әсбаплары тиешле урыннарына урнаштырылган, һәрнәрсәсе матур җыештырылган, пөхтә, эшлекле карт икән. Уңышлы ике улы Уфада бер елга якын төрмәдә булганга, алар янына барып, азык биреп кайтканын сөйләде. «Нинди гөнаһ белән ябылдылар», – диюемә: «Белемле булуларыннан башка, гөнаһлары юк», – диде. Сүз арасында, бабасының кечкенә китапларын караганда, кыска кичләрдә ястүнең фарыз булмавын ихтыяр итеп, хәтта фарыз булуына барган замандашларын (Курсави, Симәки кебекләр булса кирәк) бетереп атып язылган китабын күрсәтеп: «Ястүнең өстән төшүе 28 китаптан күчерелгән», – дип горурлануы турында әйтте. Китап электән дә күренгән, вафат [булган] хәзрәтнең гафу ителүе һәм кичерелүе турында Аллаһка дога кылынды. Кыска гына әйттем: «Күп китапның әйткәне дәлил түгел, могътәбәр дәлил – бишвакыт намазның фарызлыгы катгый, вакытларны билгеләү фаразга нигезләнгән, шартлыгы, фараз ителгән шартның булмавы белән катгый фарыз калдырылмый».

29 рамазанда якшәмбе өйләдән соң сәгать дүрт чамасында тирә-ягында атаклы булган Чуенчы исемле мишәр авылына килеп, элек бер кунак булып үткән беренче мәхәллә имамы Харис хаҗи исемле имамның улы мулла Гатага килдем. Бу авыл – хәзер өч мәхәлләле, 650 чамалы капкага ия [булган] олы авыл. Беренче мәхәлләсендә имам Гата бине Харис бине Камаледдин бине Габделлатыйф бине Әбелхәсән бине Ярмөхәммәд хафиз хаҗи. Икенчесендә Миңлеәхмәд бине хаҗи Мөхәммәд (Кышкарда укыган). Өченчедә Сафиулла бине Габдулла бине Габденнәфыйк бине Гобәйдулла бине Бәхтияр бине Әбүшәхмә бине Сөләйман бине Кадермәт бине Үзәй Кучкаров. Бу адәмнең төп гыйлем алуы Оренбургның «Хөсәения»сендә Уфа имамы Җиһангир Абызгилдин

белән булып, соңра Эстәрле ягындагы Әрмәт авылында шәех мулла Зәйләгый бине Хәсән мәрхүм мәдрәсәсендә уку-укытуда булып, 1902 елда бу Чуенчыга имам булган. Бу кичәне Чуенчыда үткәрдем. Өч мәхәлләдән тупланган халык белән икенде, ахшам намазларын үтәп, ике намаз арасында бераз вәгазь сөйләнеп, соңгы тәравих [намазы] булган тәравихны да имамлык итеп үткәрелде. Тәравихтан соң Габденнасыйр бине Габделкәрим өендә кунак булдык. 30 рамазанда дүшәмбе көн көндез сәгать икедә Бәләбәй өлкәсе Зифа авылына ирешеп, имамы Садыйк бине Хафиз бине Мөхәммәдрәхим бине Габделвахид йортына килдек. Бу кеше Троицкида дамелла Хуҗаҗан бине дамелла Җарулла әс-Сатыги янында белем алган, уртача зиһенле генә, милади 1913 елда имам булган кеше. Килү белән гает хәбәрен сөйләделәр. Шулай икән, Эстәрлебашта дүшәмбегә каршы якшәмбе көн алты кеше, шәүвәл аен күреп, шәһадәт биргәннәр. Шуның белән тирә-якка хәбәр йөртелеп, кайберләре иртән үк, кайберләре өйләдән соң элек гает [намазы] укыганнар. Зифа авылында да сәгать 10 нарда гает [намазы] укыганнар. Рамазаннан туйган кешеләр, хәбәрне тиз кабул итеп, гает [намазын] укыганнар. Ләкин Мәскәү, Казан, Том – өч обсерваториядән безгә рәсми хәбәр шәүвәл аеның фәкать дүшәмбе көн иртәнге 9 сәгатьтә 58 минутта туачагы ирешкән иде. Шунлыктан бу ихтимал бөтенләй хәтергә килми иде. Рамазан аенда да обсерваторияләрнең өчесе дә якшәмбе көн ярты төннән соң, Казан, Мәскәүдә 12 сәгать 45 минутта, Том хәбәрендә 1 сәгать 5 минутта туачагын бәян иткәннәр иде. Ләкин Оренбург, Златоуст ягындагы Бәләбәйнең Атнагол мөхтәсибе хәбәрендә, тирә-ягында булганнан хәбәр итеп, шимбә көн ахшамнан халыкка ай күрүләрен рәсми хәбәр иткәннәр иде. Шулай ук Уфа янындагы Гомәр авылында мөхтәсиб Миңлеислам мулла да үз авылларында шимбә көн рамазан аен күреп, 4 кешенең шәһадәт биргәнннәрен, болардан соң үзенең дә күрүен язган иде. Шуңа нигезләнеп, Мәхкәмә шәргыядә гаетнең сишәмбе булуына карар бирелгән иде. Фәнне ялганга чыгару да мөшкел, шәригать буенча дөрес булган шәһадәтне дә ялганга чыгару мөшкел. Тик күрү ничек булгандыр, кайбер җирләрдә кояш баер алдыннан иске айны кояшның сагымында күрүләре була, кояштан узып бетмәгән айны күрәләр. Шәгъбан ае турында Богырслан ягында шәгъбан аен пәнҗешәмбе көн бер ир һәм хатын күргәннәрен, ай күрүче җомга намазында муллага әйтүен, тикшерүләреннән соң шәһадәт алып, җомга көн – шәгъбан башы, дип карар бирүләрен мөхтәсиб Габ-

делбари бине Габделмәҗид язган иде. Чынлыкта, шул җомгада көндез сәгать 12 ярымда кояш тотылу башланып, сәгать 4 ләргәчә сузылды. Һәркемгә күрергә мөмкин булды. Димәк, ай үзәгенең кояш үзәгеннән узуы җомга көн җомга намазыннан соң булды. Ай үзәгенең кояш үзәгеннән узуы берничә дәрәҗә көнчыгыш тарафына, кояштан сул тарафка чыккач кына яңа ай күренергә мөмкин. Иске астрономия китаплары бәян итүенчә, 12 дәрәҗә кадәр үтү тиешле. Шулкадәр үтмәгәндә, аерып күреп булмый, дигәннәр. Хәер, соңгы заманнарда кирәк, үтсә дә, күрү мөмкин булырга ихтимал биргәннәр.

Кыскасы, шәгъбан аеның пәнҗешәмбе көн күренүе, рамазан аеның шимбә көн күренүе, шәүвәл аеның якшәмбе көн ахшамнан соң күренүе –заманның гаҗәп хәлләреннән. Яки фән әһелләре бердәм хисапларында хаталанганнар, яки бу күрүчеләрдә бер шөбһә булган булса кирәк. Юкса катгый эшләрдә мондый хаталык булмаска тиеш.

## Карамалыда гает һәм вәгазь

Дүшәмбе көн икенде алдыннан сәгать биштә Бәләбәй өлкәсе алтынчы мөхтәсиблек Өршәкбаш-Карамалы авылына ирешеп, каршы алу өчен Мәләш авылына барган, сәфәребезнең сәбәбе үзе булган мөхтәсиб мулла Габдулла бине мулла Сәгъдеддин бине Гыйззеддин бине Биккенә бине Әбелхәер бине Нәдеркәй йортына килдек. Халык гает [намазын] үткәргән. Беренче, өченче мәхәллә имамнары Эстәрлебаш хәбәре буенча, гает укып, имамнары өйдә булмаганлыктан, икенче мәхәлләдә гает укымасалар да, башка мәхәллә имамнары тәкъвалык күрсәтеп: «Гает көнендә ураза хәрам», – дип, бу мәхәллә халкына уразаларын бозарга, авыз ачарга игълан иткәннәр. Гает укыган имамнары Зәки бине Әхмәднур, икенче имам Габдерәхим бине Хәбибрахман, Кәшшафеддин бине Мифтахеддин каршы алдылар. Гает уку мәсьәләсендә оялган хәлдәрәк, Эстәрлебаш мөхтәсибе Шакир бине Харис Тукайның хатын казыйдан казыйга язган китап кебек уйлап укуларын сөйләделәр. Хат китерүче анда язылганнан хәбәрдәр булса да, ул бер генә кеше. Галимнәрнең карашларынча, башлангыч шәһадәт кадәр адәм икенче казыйга ирештерергә тиеш. Хатның үзе ирешкән, имамга да укымаска юл ачык. Фән һәм тәҗрибә буенча, бу шәһадәтнең вакытыннан элек икәне ачык. Яңа Мирзакол авылы мулласы Ахунҗанга

да хат барган. Хатта «Сәгать бердән соң күрделәр» дигән җөмләдән шөбһә күреп, кабул итмәгән. Сөйләмәүне теләсә дә, үзләрендә дә шул дүшәмбе кич өч ир, өч хатын күргәннәре беленеп, бер ир, ике хатыннан шәһадәт алып, шуны да кушып укыганнар.

Бу күрү анык булганда, күргән урыннар өчен җитәрлек булса да, башкалар өстенә йөкләргә сәбәп юк, ашыгып-ашыгып тирә-якка хәбәрләр җибәрү дә һич зарур түгел. Гает көнендә ураза хәрам, дигән бер мәсьәләне бик олы дәлил [итеп] тотып, һәр җирдә авыз ачтырырга тырышканнар. Гает көнендә ураза мәсьәләсе – күп вакытта галимнәр һәм халык арасында булыр-булмас дәлил, хәтта шөбһә белән уразаны бозуга сәбәп була.

Ике гает көнендә, тәшрикъ көннәрендә ураза тоту – мәкруһ, ләкин бу хөкем гает көне икәне ачык билгеле булганда, ихтимал белән генә мәкруһ булмый. Гаетне исбат итүдә шәригать буенча дөрес булып җитмәгән дәлил янына кушымта итеп, гает булуы ихтимал, ураза тоту хәрам, димәк, гает укырга кирәк, дип әйтү – мантыйксыз һәм юлсыз бер сүз. Исбатланган рамазан уразасын – фарыз гыйбадәтне – ташлап чыгу, бигрәк тә тулмас борын гает [намазы] уку – зур хәтәрле эш. Хәтта бер кешенең, ике кешенең шәһадәтләре белән уразага керелсә, утыз көн ураза тотылса, чыкканда, аяз була торып, ай күренмәсә, 31 көн дә ураза тотар, дигән сүз бар. Исбатланган гыйбадәтне туктату, аннан аерылу өчен, куәтле шөбһәсез дәлил зарур. Юкса гыйбадәтнең һәм фарызның хөкемен җиңел санау була. Бу ай күрүдә беничә төрле шөбһә бар:

1. Ахшамнан соң бер сәгать үткәч күрдек, диюләре бер шөбһә.

2. Астрономнарның бердәм шәүвәл ае шимбә көн көндез 9 сәгатьтә 58 минутта туачак, диюләре, хисап аңлаган белем ияләренә күрә, икенче зур шөбһә.

3. Чуенчыда имамнар: «Якшәмбе көн иртә белән иске ай бар иде», – дигәннәр иде. Бу хәл янә шул көндә кич яңа айның күренүен ераклаштыра. Ибне Габидин: «Бу мөмкин, шәригатьтә дөрес булган шәһадәт исбатланып җитсә, бу кадәрле белән кире кагылмас», – ди. Яхшы тикшерүдән соң шәһадәтләре шәригатьтә дөрес булса, бу киртә булмас, ләкин башка шөбһәләр янында шөбһәне арттырачак бер эш.

4. Эстәрлебашның үзендә гает укырга яраса да, башка авылларга ат чаптырып, хәбәрләр йөртү бер яктан да зарури түгел иде. Уразага керү мәсьәләсендә тырышу, нык булган хәбәрләрне төрле якка ирештерү, итагатькә ашыгу төреннән булганга, яхшы һәм тиешле

күрелсә дә, гыйбадәт калдыру өчен мондый хәрәкәтләр зарури түгел. Аеруча соңрак кергән, уразасы ким калачак халык өчен бигрәк зыян. Бер көн казасы [соңга калып булса да, үтәү] мәҗбүри булып, каза кылу [соңга калып үтәү] бик аз тәҗрибә ителәдер. Шунлыктан көчләнеп кенә, кабул ителерлек хәбәрне кабул итмичә, айны тутырып чыгу – әлбәттә, өстен һәм артыграк эш. Гомумән, ураза гаете аенда ашыгып халыкка дәлил булу яхшы түгел. Үз тирәңдә ай күренгән икән, шөбһәсез булып җитсә, тир-ягың белән гает итсәң, башкаларга хәбәрләр йөртеп, артыгын кылану өстә тиешле булган эш түгел. Бер җирдә ай күрсәләр, казый тиз арада тирәякка атлар чаптырсын, телеграфлар йөрттерсен, дигән сүз китапларда күренми. Бу эш булса, фәкать уразага карата гына булырга мөмкин. Туры юлда булучыларга сәлам булсын.

Зифа һәм Карамалы авылларында гает укысалар да, үзләренең вөҗданнары тыныч түгел иде. Сөйләшүдән соң үзләре дә бик тәэсирләнделәр. Эстәрле шәкертләре төрле юллар белән сөйләргә тырышсалар да, башкаларның йөрәкләрендә байтак күңелсезлек хис ителә иде. Ләкин дөресме, юкмы – гади халык бер яктан ишетсә, ашыгучан, кешеләргә йөкләүчән булалар да, имамнары ирекле-ирексез гаетне укырга була.

Соңра Илчегол волосте Яңа Мирзакол авылының имамы Ахунҗан Әхмәдҗан улы үз авылларында шул дүшәмбегә каршы күрүләрен һәм кайберләренең вакытында ук шәһадәт алуларын сөйләде. Карамалы авылында да бер ир һәм бер хатынның күрүләрен беренче мәхәллә имамы Зәки әфәнде сөйләде.

## Карамалыда безнең гает

Дүшәмбе көн икендедән элек Карамалы авылына ирешүебезне язган идем. Тукталуыбыз икенче мәхәллә имамы мөхтәсиб Габдулла бине мулла Сәгъдеддин өендә булды. Бу мәхәллә халкы үз мәчетләрендә гает укымасалар да, кайберләре күрше мәчетләргә барып укыганнар. Муллаларның ураза тотудан куркытулары аркасында барысы да авыз ачканнар икән. Шулай да, һәммә халык безнең белән гает укырга әзерләнде. Гает укыган имамнар да безнең белән гает укырга рөхсәт сорадылар. «Кабат гает уку сөннәткә каршы булса кирәк, килеп, вәгазь тыңласагыз, догада катнашсагыз, тыю юк», – дидем. «Без нәфел [өстәмә намаз уку] нияте белән оербыз вә фәлән», – дип сөйләүдә булдылар. Гает урынында (мәчет-

нең ишегалдында) бөтен авыл халкы, хәтта якын күрше аыллардан җәмәгатьләр килгән, зур җыен барлыкка килгән иде. Халыкның ихтирам итә торган, вагәзьчеләрдән аз-маз нәсыйхәт ишетә килгән һәм, тәҗрибәләргә күрә, бераз тәэсирләнә торган җыелышлары булганга, бу дин шигарен, ислам гаетен, суфыйлык күрсәтмичә, элек укыган кешеләргә каршылык күрсәтмәдем. Зур җәмәгать белән гает [намазы] укыттым. Байтак озын вәгазь сөйләдем. Вәгазь «Гасыр» сүрәсе тәфсиренә бәйле булса да, халыкның башына төшкән һәм төшәчәк мәсьәләләрдән байтак сөйләнде. Иман, изге гамәл, берберенә хаклыкны, сабырлыкны васыять итү турында тәфсилләп, аңлатып сөйләнде. Иман саклау, Коръән хөкемнәрен ихтирам итү, гаилә мәсьәләләре, балалар тәрбиясе эшләре турында сөйләдем. Халык байтак тәэсирләнде, күзләренә [яшь килгән], елаган кешеләр дә булды. Халык бик куанышып таралдылар. Аллаһ миннән һәм алардан кабул итсен.

Бәйрәм арасында халыкта үзара кунаклашу бар икән. Минем сәбәпле дә, бу кунаклык күбәйде. Ашлык кыйммәт, арыш бу авылда юк, ашларында бодай ипие, поты ике йөз мең сум булса да, юнәткәннәр, кайберләренең кулларында талканнан аз-маз калган, кайберләре сатып алганнар, ни булса да, бәйрәм мөнәсәбәте белән кунак ашлары күп булды. Рухлары бөтенләй төшенке түгел, дәрәҗәләренчә сабырлыклары бар.

Карамалы авылы, Өршәкбаш иseме белән билгеле, тау астында, матур гына, өч мәхәлләле, 570 кадәр капкалы авыл. Халкы мишәр затыннан, электән үк яхшы галим имамнары булып килгән. Эстәрлебаш ишаннары белән дә катышканнар. Халкына дин рухы, ислам мәхәббәте яхшы урнашкан, мәчетләрендә җәмәгатьләре яхшы була, җомгаларда (шактый иркен 24, 35 аршинлы мәчетләре) тулы була икән. Яшьләре дә әдәпле, хатын-кызлары да оялчан, пәрдәле, уза китмәгән төркемнәр. Елның авырлыгы каты тәэсир иткән хәлдә, бәйрәмнәре яхшы, бер-берсенә кунак булып, фәкыйрьләр хакында да ихтирамлы булдылар. Һәркөн дүртәр-бишәр җирдә кунак ашы булды. Кунак ашларында шулпа, соңрак күбрәк тавык ите катыш сарык ите, соңра тозлы каз, ахырдан чәй, кайберләрендә тарыдан бәлеш була, сирәк булса да, кайберләрендә кымыз була.

Йортларына кереп урнашкач, һәммә кешеләргә, муллаларга һәм башкаларга сәдака өләшәләр, һичкемне калдырмыйлар. Соңра Коръән укуны үтенәләр. Бу, гомумән, һәркемгә садака бирүләре

яхшы гадәт [булып] күренде. Һәркемнең күңеленә яхшы хәлдер. Имамнарының вөжданнарына да җиңелрәк була.

Бу якта. гомумән, өйләр гади балчыктан, нечкәрәк агачтан булса да, күбесе тыштан балчык белән сыланган. Барысы да салам түбәле. Агач түбә дә, тимер түбә дә юк.

## Әнәс, Кыргыз-Миякә, Сатый авылларында

8 шәүвәлдә дүшәмбе көн иртәнге сәгать 9 да Карамалының кыйбла тарафында 10 чакрым җирдә булган Әнәс авылына бардык. Өченче мәхәллә имамы Шәрәфеддин бине Камаледдин, мәхәллә халкы каршы алырга әзерләнгән, капкасы алдында көтеп торалар иде. Әлеге Шәрәфеддин Троицкида мулла Мөхәммәд бине Зариф Бикмәт мәдрәсәсендә укып Зәйнулла хәзрәт тарикатенә нисбәтле, укыган, диндар, инсафлы кеше. Башта өе каршысындагы мәчетенә кереп, ике рәкәгать намаз укып, соңра өенә кердек. Мәчетләре кыйбладан күп кыек түгел, бик аз гына микъдарда көнбатышка авыш. Өйлә намазыннан чыкканда мулла Шәрәфеддингә: «Мәчеткә нигез корганда мәчетегез кыйбладан аз гына көнбатыш тарафына авышкан», – дигәч, Шаһвәли бине Габделвәли бабай да: «Һай, балалар, аз гына көнчыгыш тарафына борасыгыз калды, кояш баешына күбрәк бордыгыз», – дигән иде, бер инженерның да шулай диюен берсе күчерде. Ничек тә боларның мәчетләре, Карамалы мәчетләренә караганда, дөреслеккә якынрак. Бу Шаһвәли аз гына укыган, белгәне белән гамәл кылучы, балаларының тәрбиясенә карамыйча, кул көче белән көн күрә торган аңлы карт булды. Динне кайгыртучан кешеләрдә дөрес караш булгалый, Аллаһ Тәгаләнең хикмәте белән.

Мулла Шәрәфеддин өендә каенатасы – карт мулла Шиһабеддин бине Шәмседдин саңгырау хаҗи – белән очраштык. Бу кеше Эстәрлебашта укып, байтак елар указсыз дәрес биреп, соңра бу Әнәс авылына икенче мәхәлләгә указ белән имам булып урнашкан. Җиренә күрә, байтак гарәп телен һәм әхлак укытып торган. Диндар, әхлак һәм хәдистән хәбәре булган зат.

Саңгыраулыгы бик куәтле булганга, сөйләшүе бик мөшкел, үзе 74 яшендә булса да, җәмәгать [намазына] даими [рәвештә йөри], зикердә. Хәдистә, зикерләрдә, догаларда тоташу чылбыры булмаганга, «Мишкәт», «Дәләил әл-хайрат», Хизб әгъзам» өчен иҗазәт язып бирдем, куанды, рәхмәт әйтте.

Үтенүе белән, өендә дә кунак булып, ихтирамын күрдек. Яхшы, бәхетле тормыш итә икән. Ничек тә зиһене ачылган, уянган: [җәмәгать намазларында] имам артында «Фатиха» сүрәсе укый икән. Остазларында мондый зиһен ачылу булмаса да, бу кеше һәр эштә остазлар һәм үлгәннәргә иярүдә катылык күрсәтмәве аңлашылды. Саңгыраулыгы куәтле булу сәбәпле, бу мәсьәләдә үзеннән бер фикер алып булмады. Кияве мулла Шәрәфтән «Имам укуын ишетмәгәнемә күрә, буш тормыйм, я уку, я тыңлау булсын», – дип укыйм, дигәнен аңлаган идем, бу да бер фикер.

Бу мулла Шиһабеддиннең мәчеттәге иптәш имамы – Сабахеддин исемле кеше. Беренче мәхәлләдә Әхсән бине Хәсәни һәм Садреддин бине Галәведдин. Садреддин гыйлем, зирәклек иясе булса да, зәгыйф йөрәк һәм бөергә сыналып, бәвел таму аркасында имамлык хезмәтләреннән калып, авыр тормыш хәлендә калган. Атасы Галәведдин дә яхшы гыйлем иясе булып үткәргән, Казанда Мөхәммәдкәрим хәзрәт шәкертләреннән икән.

Өйләдән соң бер мәчет картында кунак булып, Кыргыз-Миякә авылыннан килгән атларга утырып, сәгать 2 дә Әнәстән Кыргыз-Миякә авылына юнәлдек. Атлары җитез, атларның иясе [булган] кучер өченче мәхәллә мөәзине Хәбибрахман бине Габдрахман да тиз баруны максат иткәнгә, 12–13 чакрым җирдә булган Кыргыз-Миякә авылына илле минутта барып җиттек. Бу авыл районның үзәге, өч волостьнең җирле идарәсе, атаклы өч мәхәлләле, дүртйөздән артыграк өйле авыл икән. Элек чакырган икенче мәхәллә имамы Кирамеддин бине Галләмеддин өенә килдек. Бу кеше гади генә, тормышы һәм байлыгы яхшы [булган] кеше икән. Ике көн элек бер кызы туып, безнең килүебезне ганимәт [итеп] белеп, исем бирүне үтенде. Утырган җиремдә якыныма баланың башын куеп, исем бирдем. Исем сайлауны миңа куйды. Мәймүнә исеме белән атадым. Бу рәвешле баланың нәкъ колагына азан-камәт укып, исем бирү рәвешен мулла Шәрәфеддин бик яхшы рәвеш [итеп] күреп, яхшы санаганын белдерде.

Соңра безне атлары белән алып килгән мөәзиннең өенә бардык. Моның өе һәм мәхәлләсе бер чакрымнан артыграк ерак иде. Бу авыл таркаурак утырган. Арада хөкүмәтнең хастаханәләре, идарәләре вә фәләннәре булу белән дә, авылның йорт саннарына күрә, киңрәк утырган. Тиз генә кунак итүен үткәреп, каршысындагы атасы Габдрахман агага да кереп, умартадан яңа алган балы белән берәр чынаяк чәй кабул итеп, яңа корылган бу мәхәлләнең муласы Зариф

бине Сабир өендә булып, сәгать 6 да 13 чакрым чамалы булган Сатый авылына юнәлдек. Сатый авылы имамы, ике атын җигеп, алырга килгән. Атларны үзе тотып, безне юлга алып чыкты. Җиде чакрым кадәр баргач, икенде [намазы] мөнәсәбәте белән, «Тимер су буе» дигән су буена төшеп, икенде [намазы] укыдык. Арбада иптәшем, минем баш кунак итүчем мулла Габдулла Биккенә иде. Әнәс имамы Шәрәфеддин әфәнде дә Сатыйга хәтле бара иде. Намаздан соң яныбызда булган кымыздан бераз эчеп, кояш баюга ярты сәгать калганда, Сатый авылына юнәлеп, халык ахшам [намазыннан] чыккан вакытта искә алынган имам мулла Шакирҗан бине Әсфәндияр йортына килдек.

Бу кеше Истанбулда байтак укып, җамигъ мәчет дәресләрендә булып, «Мәгани бәян» фәннәре һәм бераз «Сахих Бохари» укып, Хөсәен Гауни бине Хәсән Гарәбкирле исемле кешедән «Бохари» укып, тоташу чылбырын алган һәм яхшы тәфсилләп язылган иҗазәтнамәгә ия булган. Укыган, кешелекле, идарәле кеше. Карамалыда минем килүемә тупланган галимнәр эчендә бу кеше дә килеп, тугрылык һәм мәхәббәт белән авылына чакырган иде. Байтак яхшы китапларга ия булган. Бу үткән кышта өч пот бодай, бер пот ярым бодай оны, бер пот бәрәнге биреп, «Гомдәт әл-Кари», Гайнинең «Бохари шәрехе»нә ия булган. Якынча ул вакытта 300 мең сум була. «Бохари шәрехе»нә бу кадәр мал биреп алу – байтак зур тырышлык, сирәк [булган] гыйлемгә мәхәббәт. Бу заманда бу кадәр тырышлык, гыйлем китабына бу кадәр мал бирү – байтак эш. Бу тарафларда имамнарның, хәдис китабы дип, «Тарикате Мөхәммәдия», «Гайнел-гыйлем» нөсхәләре – гыйлемнең иң югары дәрәҗәсе, хәдиснең тәмам иясе булу, дип танып йөргән кешеләр арасында байтак бәяләрлек тырышлык. Аллаһ Тәгалә китабы белән файдалануын насыйп итсен.

Планыбыз буенча сишәмбе көн иртә белән Сатый авылыннан 25 чакрым җирдә булган Дим буе Мәнәвез авылына бармакчы булсак та, иртәдән бирле юл йөрү, кешеләр белән аралашу, вәгазь һәм нәсыйхәт мәҗлесләре байтак ардырган, йокысызлык бигрәк тәэсир иткән иде. Шунлыктан сишәмбе көн Мәнәвез базарында халыкка чәршәмбе көн барачагымны бер базарчы аша белдереп, бүген Сатый авылында ял итәргә карар бирдем.

Сатый мукшы теленнән «яхшы» дигән мәгънәдә булып, Сатый исемле бер мукшы авыл башы булып утырган. Соңра чабаталы башкорт исемен алган бу мөселманнар утырганнар. Бүген өч

мәхәллә булып, беренче мәхәлләсендә Габделхәсиб исемле карт имам, аз гына гыйлем белән имамлыкка урнашкан, озак яшәү белән колагына аз-маз гыйлем кергән. Икенче мәхәлләдә – безне өендә кунак итүчебез Шакирҗан бине Әсфәндияр. Бу Әсфәндияр да яхшы гына укыган, элек кием тегүче булып, соңра сәүдә һәм игенчелек юлына кергән, бер дәрәҗәдә гыйлеме дә бар. Төрки теле яхшы, гарәп теленнән дә өлеше юк түгел. Өченче мәхәлләдә яңарак Зариф бине Габделкадыйр исемле егет имам булган, бөтенләй лаексыз, ваемсыз зат түгел. Бу авылда Шакирҗан әфәнденең атасы Әсфәндияр һәм каенатасы Мөхәммәдкәрим, янә Бәхтияр исемле бер байның булуы авылга башкалардан артык зур салым салырга, ягъни рәсми талауга сылтау ителеп, каты талауга дучар булганнар. Күренгән ашлыкларын алганнар. Халыкның һәм бала-чаганың төсләрендә ачлык галәмәтләре ачык булып тора. Боларда да, башка авыллардагы кебек, этлек үләне тамырын ашау, алабута ашау таралган икән. Шулай да, бу тарафның барчасында да халыкта эш өйрәнү арткан, киндер сугу, үзләренә кияр өчен әзерлек күрү башланган. Һәр җирдә күн эшләү була башлаган. Киндер, җитен чәчү дә башланган. Шакирҗан әфәнде, дәүләтле кеше булган хәлдә, хатынының өчйөз аршин кадәр киндер сугуын сөйләде. Өметле яхшы эш.

Сишәмбе көн өч мәхәлләдән халык икенде намазына без тукталган икенче мәхәллә мәчетенә килеп, намаздан соң ахшам азанына кадәр вәгазь һәм нәсыйхәт әйттем. Темалары – сабырлык һәм бәла аятьләре (5 аятьне[42]) укып, шунда искә алынган мәсьәләләр, бер дәрәҗәдә аңлатып, бәян ителде. Соңра гаилә мәсьәләсе, өйләнү әдәбе, яхшы мөгамәлә, килен-каенана мөнәсәбәте, балалар тәрбиясе маддәләрен өстәп, өч чирек сәгать кадәр сөйләдем. Ишетүчеләр файда күргән кебек булдылар.

## Канбәк, көчләп чукындырылган кешеләр, Эстәрлебаш тәэсире

Чәршәмбе көн 10 шәүвәлдә иртәнге сәгать сигездә Канбәк (Ханбәк) авылына юнәлдек. Атбашчыбыз һаман Шакирҗан әфәнде үзе иде. 12 чакрым кадәр юл йөргәч, бер матур агачлык урынына килеп, җиңеләеп, яныбызга алынган кымыздан бер-ике пыяла эчеп,

---

[42] «Йә әййүһәл-ләзинә әмәнүстәгыйнү бис-сабри... үләикә һүмүл-мүһтәдүн». – «Бәкара» сүрәсе.

30–40 минут торып, юнәлдек. 7–8 чакрым кадәр йөреп, Канбәк авылына ирештек. Бу авылда элек көчләп чукындырылган кешеләр булып, күп еллар рәсми исламга чыга алмыйча, Япон сугышыннан соң, 1905 елларда гына рәсми мөселман булганнар, иске һәм хакыйкый мөселманнар. Бабаларыннан 4 кеше, 1777 елда Казан Тәтеш ягы Чирмешән авылыннан күчеп, Канбәк исемле карт утырган бу авылга урнашканнар. Бу көннәрдә бу дүрт карттан таралган бөтен авыл җәмгыятен тәшкил иткән җитмештән артык гаилә булган. Канбәкнең үзеннән нәсел калмаган, фәкать ядкяре булып исеме калган. Имамнары үз җәмәгатьләреннән Габделгаффар бине Габделхәбир бераз укып, 1920 елда Уфа сьездында вәкил булып, әзерлеген һәм сөйләү куәтен күрсәткән һәм шул вакытларда гына указ алган иде. Гыйлеменә күрә, халык арасында абруе артык, сүзгә оста, батыр, идарәле егет. Троицки Зәйнулла Рәсүли хәзрәтләре мәдрәсәсендә бераз укыган, чын дәрт белән шәкерт укытып, мөхтәсибнең әйтүенә күрә, бик яхшы укыткан, күбрәк мәдрәсәсендә шәкертләре белән бергә кунып, укытып яткан, авылларында язу танымаган яшьләре калмаган. Халкы да авырлык белән һәм чын ныклык белән исламнарын саклап килгән халык булганга, диннәрен саклау мәсьәләсендә ата-бабаларыннан бирле күп җәфа күреп килгәнгә, бу хөрриятләренә куанышып, балаларын әһәмият белән укытып, үзләре дә ихласлык белән гыйбадәт кылып киләләр икән. Мәчетләре яхшы, мәдрәсәләре дә олы, яхшы бинада. Мөәзиннәре Габдрахман бине Габделхаликъ яхшы, аңлы, сөйләү көче бар, игътибарлы, кешелекле карт. Араларында Казан, Мамадыш якларындагы, Курсадан егерме чакрым кадәр төньякта, Мәчкәрә юлы өстендәге Керәшен Утары дигән авылдан (исламга чыга алмагач, гаҗиз булып, авылын ташлап, бу авылга сыйныфташлары янына килеп урнашкан) Биктимер агай бине Ибраһим [исемле] күркәм карт күренде. Атасы дүрт-биш ел Казан төрмәләрендә дин өчен тоткынлыкта калып, ахырда шул Казан төрмәсендә вафат булган. Утар якларын сөйләшеп, Мәчкәрә якларын искә төшереп, бераз сөйләшеп утырдык. Кырык елдан бирле бу авылда торып, урта белемле өч-дүрт ул атасы булып, яхшы дәүләт һәм тормышка ирешкән. Бу авылга Эстәрлебашларның шактый яхшы тәэсирләре булган. Гобәйдулла бине Харис килеп-китеп йөреп, дини тәрбияләренә кагылышы булган. Мәчет салышуда да Зариф бине Ибраһим бине Муса бине Габдулла Үтәмишевне чакырып, ярдәме булган.

Мөәзин Габдрахман ага һәм бу Биктимер аганың һәр икесе миңа берәр умарта бүләк иттеләр. Кабул итүдән бераз тартынсам да, «Умарталарыбыз бар, Эстәрлебаш мәхдүм хәзрәтләргә дә бирә торган идек, һәммә мәшәкатьләрен үзебез йөклибез, кабул итә күр», – дип кабат сораганлыкларыннан, соңыннан гына оялып кабул иттем. Мөәзиннең умартасы читтәге кортлыгында булып, имамнары Габделгаффар алыр өчен вәкил булды. Биктимер аганың умарталары йортында булып, биш-алты данәдән сайлап алуны тәкъдим итсә дә, «Бер кечерәген үзең сайласаң, ярар», – диюемә, мулла Габделгаффар берсен сайлап, уртача бер умартаны билгеләп куйды. Аларга Аллаһ минем исемнән хәерле бүләк бирсен, сәдакаларын кабул итсен, гыйбадәтләрендә бәрәкәт бирсен, изгелекләрен арттырсын! Данәсе ике-өч йөз мең сум булган заманнарда дин галиме дип мәхәббәт һәм теләк белән бер кешегә бер умарта бирү – байтак динилек, чын мәхәббәт, бөек тырышлык ахыры. Бу кадәр эш – борынгы буржуй байларда булмаган эш.

Умартасын күреп алыр өчен бакчасына чыкканда, аңсыздан бер корт мине каршы алып, колагыма бер сер сүзен әйтер кебек, кинәт килеп, угын урнаштырды. Азрак тир исен сиздеме яки хушбуй исен тойдымы – бер мәртәбә тәрбия биреп алды. Җитез үк угын тартып алдылар. Артык авыртуы булмады. Бу кортларның чәнчүләре һәм чагулары, тышкы яктан куркыныч булса да, соңгы заман табибларының тәҗрибәләренә күрә, бик файдалы икән. Бик сирәк генә әҗәлгә сәбәп булганнары, хәтта атны үтергәннәре була, дип хикәят кылалар. Ләкин күпчелеге зарасыз була. Канга хәрәкәт бирә, чагылган урын янына җылылык бирә икән. Салкынлык сәбәпле, кан оешу әсәре булган кайбер хасталыкларга шифа булуы өметле икән. Элек Бәйрутта нәшер ителгән «Сәмәрат әл-фөнүн» газетында Европа табибларының паралич суккан кешеләргә шул бал кортын чактырып, дәва итүләрен, файда күрүләрен укыган идем. Аллаһның идарәсендә, хайваннарны файдалы яки зарар күренгән төрле төрләрен яратуда бәндәләргә һаман ачылып бетмәгән, күп тәҗрибәләр һәм фикерләр белән аз-аз беленә барган чиксез серләр, хикмәтләр, яхшылыклар бар. Аның бар итүендә һәм идарәсендә буш һәм юк эш бөтенләй юк. Бары бәндә күп кимчелекле, күп ваемсыз, аңлаудан гаҗиз, шөбһә һәм вәсвәсәгә авыш, белер-белмәс карышу һәм тәнкыйть мәсьәләсендә ашыгучан, әдәбсезлектә батыр. Аллаһ туры юл бирсен, хәлләрен үзгәртсен һәм иманнарын арттыручы, ышануларын яхшыртучы юлга күндерсен.

## Мәнәвез ир-хатыннарына вәгазь, милиция рәисе

Ханбәк авылыннан җиде чакрым Дим буенда Мәнәвез авылына чакыруларына һәм көтеп торуларына күрә, төштән соң дүрт ярым сәгатьтә юнәлдек. Димне чыккач, яр буенда туктап Димдә тәһарәт алдым. Бераз юанып, яныбыздагы кымызны һәм Чирәштамак авылыннан бер егет китергән кымызны бераз эчеп, ул авылдан дүрт-биш мөселман белән сөйләшеп утырып, кузгалдык.

Дим суы – башкортларда атаклы бер су. Оренбург вилаятеннән чыгып, борма-борма булып агып, Уфаның көньяк-көнбатышында Агыйделгә коя. Тирә-яклары агачлык һәм печән, матур җирләре күп. Башкорт, типтәр һәм Казан халкы исемле халыклар авыл-авыл булып утырганнар. Күбрәге башкортлар. Бу су ярларының табигый матурлыгы, бар ителгән күркәмлеге белән моңлы башкортларны хәрәкәткә китергән, төрле вакыйгалар астында капланган моңнарын кузгата килгән шөһрәтле елга. Ләкин бу заманда агачлары азайган, бәрәкәте кимегән, табигый матурлыгына да байтак кимчелек ирешкән.

Сәгать алты чамаларында Димнән 3 чакрым кадәр җирдә Мәнәвез суы буенда өч мәхәлләле Мәнәвез Тамагы авылына килеп, икенче мәхәллә мәчет эшләрен башкаручылардан Гариф әфәнде йортына төштек. Капка төбендә имамнары, мөәзиннәре һәм картларыннан байтак кешеләр көтеп торалар иде. Танышып, чәй кабул итеп, икенде намазына әзерләнеп, тулы мәчет җыелган халык белән икенде намазын укыдым. Намаздан соң бераз азан һәм зикерләрне төзәтүгә әһәмият бирүләрен, көчләре җиткәнчә, дин өйрәнүдә тырышлыкларын тиешле күреп, вәгазь сөйләдем.

Пәнҗешәмбе көн икенде [намазыннан] элек бер иркен йортка, яшел ишегалдында хатын-кыз төркемен җыеп, бераз нәсыйхәт иттем. Ислам баганалары, дингә шөкер итү, аны саклауга тырышлык кую, ир-хатын хокуклары, гаилә төзеклеге, балалар тәрбиясе, шайтанның Адәм нәселенә дошманлыгы һәм хөсетлеге турында бер сәгатьтән артыграк сөйләдем. Тормыш һәм яшәү мәсьәләләрендә дә кайбер нәрсәләр, бигрәк тә бакчаларда яшелчәләр игүләргә кызыктырдым. Бик куаныштылар, елаштылар, хәер-дога күрсәттеләр. Өйлә [намазыннан] соң беренче мәчеттә ирләргә дә бераз вәгазь сөйләп, хатыннарны яхшы тәрбияләрен һәм кайгыртуларын киңәш иткән идем. Аллаһ барчасын хәерлегә күндерсен, күркәм тормыш,

камил иман, ахыр сулышта яхшы үлем белән барчасын хөрмәтләсен. Әмин.

Пәнҗешәмбе көн Мәнәвез милиция рәисе йолкып, рәсми кәгаземне сорады. Җибәрдем. Диния нәзарәте тарафыннан: «Уфа, Бәләбәй, Эстәрле өлкәләрендә мөхтәсибләрнең эшләрен тикшерү өчен Нәзарәт тарафынан рәисе Фәлән бине фәлән күндерелде», – дип язылган нөсхәне таныймыйча: «Вилаять мәхкәмәсеннән язу булмаганда, йөрергә рөхсәт ителми, бәлки туктатыла», – дип сөйләп маташты. Сишәмбе көн Мәнәвез базарында тупланып, безне көткән муллаларны да кайбер сүзләр белән куркытып, куркаклары кайтып киткән, калганнарына да кайбер уйлар килгән. Бер кагыйдәгә нигезләнмичә, деспотизмга нигезләнгән кечкенә идарәләрнең тиешсез хәрәкәтләр кылулары да тәҗрибәдә күренә.

Җомга кичәсендә бераз курку астында булсак та, җомга көн иртән бер кешедә кунакта булган вакытыбызда милиция рәисе үзе рәсми киемнәре һәм кораллары белән яныбызга кереп, фикерен аңлатты. «Вилаятьтән командировка белән чыгарылу хакында кәгазегез булырга тиеш иде, вилаятьтән рөхсәтсез чыккан кешене йөртмәскә, ә туктатырга хосусый кисәтү бар», – дип сөйләде. Мин әйттем: «Безнең дини оешма хөкүмәт идарәләреннән аерым һәм цстен санала. Һәр җиргә шундый язу белән йөрибез, Казан һәм Мәскәүдә каршылык күрсәтмиләр. Вилаять идарәләреннән имза һәм раслауны тиешле тапмыйлар, шуның өчен без вилаятьтән раслауны һич уйламаган идек, кирәксенмәгәнбез». Соңра йомшап, куркуыбызны бетереп, кулында кич уздырган рәсми кәгаземне кайтарып, җибәрде.

## Никифор авыл мәчете һәм имамнары, җомга вәгазе

Имамнар һәм сөеклеләр белән хушлашып, сәгать 10 да 17–18 чакрымда булган Никифор авылына киттек. Юлда бер яшел җирдә чирек сәгать микдары туктап, ике өч пыяла кымыз эчеп, Уса ягындагы Кинә җиреннән күчеп килеп утырган Кинә исемле мөселман авылының бер почмагыннан үтеп, 11 сәгать 40 минутта Никифор авылына килеп кердек. Никифор авылы бу тарафтагы авыллардан яхшы планлы, биналары төзек, тимер һәм такта түбәле, каралтылары җитеш, Казан тарафындагы бай авылның төсен алган, өч мәхәлләле типтәр авылы. Авылның әһәмиятле төсен күрсәткән кешеләр – Казан сәүдәгәрләре. Күбрәге Арча тарафынан, Кырлай

авылыннан килгәннәр. Беразы Мөндеш, Иске Йорт авылыннан килгән сәүдәгәрләр. Егерме биш, утыз, кырык, кырык биш еллардан бирле шушы авылга урнашып, сәүдә белән шөгыльләнгәннәр. Күбрәге бер дәрәҗәдә байлыкка ирешкән. Ләкин бу соңгы чуалыш байтагын туктаткан, кайберләрен бетергән дә.

Никифор авылында өч мәчет бар:

Беренчесендә имам Габделгафур бине Хафиз. Бу зат җитмештән үткән, картайган, Эстәрлебаш шәкертләреннән. Исмәгыйль Исламбулов исемле яшьрәк имам бу кешенең мәчеттәге иптәш имамы. Уфа Хайрулла ахунда укып, анда бераз мөгаллимлек тә итеп, имам булган, хәзер дә Шура хөкүмәтендәге метрика дәфтәрләре хезмәтендә эшли.

Икенче мәчетне Кырлайдан килгән Йосыф бине Ибраһим 1890 елларда башлап, мәхәллә аерып, төзегән. Бу зат 1915 елда юлбасарлар тарафыннан сәфәрдә үтерелгән. Бу мәчеттә элек мулла Габдеррәхим бине Габдессаттар имам булып, хасталык ирешкәч, хәзерге имам башкорт мулла Солтангали бине Шаһиәхмәд бине Сәедбаттал бине Муса бине Яхъя исемле хөрмәтле затны үзе теләп имам иткән. Бу зат, элек Эстәрлебашта укып, соңра Уфага мулла Хайрулла ахун янына барып, өч-дүрт ел торып, 1900 елда бу авылга имам булган. Аңлавы туры, белеме яхшы, инсафлыгы бар, фанатизмсыз, гыйлемгә теләкле һәм мәхәббәтле зат. Байтак еллар гыйлем һәм мәдрәсә хезмәте белән мәшгуль булып, байтак имам һәм мөәзиннәр җитештергән. Төшкән урыныбыз бу имам йортында булды. Бу авылда булганда, 42 сәгать эчендә, гыйльми файда алудан туктамады. «Алты китап», «Мөватта», «Мөснәд Әби Хәнифә», «Мөснәд Шафигый», «Мөснәд Әхмәд», «Мөснәд Дәрими» башларын, «Әрбәгыйн Нәвави»дән кайбер хәдисләр укып, күп укытучылар арасында кайбер бозу һәм хаталарны төзәтү, игътибарсызлыктан килгән хаталарны кисәтү хасил итте. Гыйльми әңгәмәләребез янә озаграк булганда, күп файда алачак, инсафлы бер зат. Элекке көндә икенде белән ахшам [намазлары] арасында халкы янында: «Төзәтергә ихтыяҗ туган урыннарымны күрсәтерсез», – дип, «Фатиха», «Ихлас» сүрәләрен, «әт-тәхият», «көнут» догаларын укып күрсәтте. Укуы яхшы булса да, саклануы һәм динилеге таләп иткәнчә, бу сүзләрен әйтте. Кайбер җирләрен төзәтүенә шат калды. Күп кешеләр бу кадәр инсафлыктан мәхрүм.

Өченче мәхәлләдә Казан Кырлаеннан хаҗи Габделгафур бине Гайззәтулла һәм бертуганы Нигъмәт бай ярдәме белән Корматау

ташыннан олы, яхшы мәчет торгызган. Имамнары Тимербәк бине Әхмәдҗан икенче мәхәлләдәге Солтангали янында укып, бу мәчеткә имам-хатыйб булган. Белеме, укуы да бозык түгел, инсафлы егет. Ләкин дөньяга тырышлыгы бар [булып] күренде. Икенче имам Ибраһим бине Зариф элек мулла Солтангалидә, соңра Уфада Хәйрулла ахунда, аның вафатыннан соң, Пәрваз мулла тәрбиясендә булган. Бозык фикерләрен ишетмәдем, вәкарьле генә адәм [булып] күренде. Атасы гади халыктан булып, баласын мәхәббәт белән укыткан, диндар, дәүләтле кеше булып, байтак байлык калдырып, 1920 елда вафат булган. Байтак ятим һәм сабыйлары шушы улы яклавында калган. Бу Никифор авылына җомга [намазыннан] ярым сәгать элек җитештек. Имамнарына: «Өч мәхәллә халкы да урта олы таш мәчеткә җыелсын», – дип хәбәр иттек. Халык җыелып җиткәч, җомга [намазына] чыгып, мәчет алдында җыелган халык белән күрешеп, мәчеткә кердем. Азан укылып, намазга, соңра хөтбәгә керешелде. Хөтбәне кыскача Аллаһны мактау сүзләрен һәм вәгазен гарәпчә укып, намазны тәмамлаганнан соң, аерым төркичә бер хөтбә белән озын вәгазь сөйләдем. Вәгазь хөтбә эчендә тиеш булса да, озын хөтбә сөйләнсә, сөннәт микъдарыннан тыш булачак, кыска ителсә, кисәтү һәм белдертү өчен күп мәсьәләләр сөйләнми калачак булганга, җомга хөтбәсен сөннәткә туры китереп, кыскарак үткәрдем. Соңгы вәгазьнең әһәмияте кимемәсен, дип гарәпчә генә укып тәмамладым. Намаздан соң [булган] бу вәгазь бер җомгада ике вакытта ике хөтбә булып, бер яктан, сөннәттән тыш кебек тоелса да, хосусый зарурлык сәбәпле, халыкка яхшылык булуына карап, белем бирү вәгазе булып, дөрес һәм яхшы булыр дип уйладым. Бер сәгать микдары биш-алты йөз кадәр халыкка байтак нәрсә сөйләдем. «Йә әййүһәл-ләзинә әмәнүстәгыйнү бис-сабри вәс-саләһ» һәм ахырындагы аять белән укып, аңлаттым һәм аңлатмасын бирдем. Бәла-казаларны каршы алу турында, мөэминнәрнең сакчыл булулары, шулай булсалар, үзләре хакында яхшы булачагы, моның капма-каршысы булса, иман һәм ышануга зарар булачагы, ачлык һәм кыйммәтчелекнең күбрәк күп гөнаһлар сәбәпле булулары хакында сөйләдем. Гаилә томышларына күчеп, алар белән күркәм мөгамәләдә булуны, гаиләне һәм, гомумән, бала-чаганы шәфкатьлек белән идарә итүне, аларның хокукларын саклау, ата-ананың балалары алдында яхшы үрнәк булуы, алар алдында ата-анадан яхшы булмаган хәрәкәтләр булмаска тиешлеге турында киңәшләр бирдем. «Хатыннарга яхшы булгыз» хәдисен укып, хатыннар хокукы ту-

рында бераз аңлатма бирдем. Халкыбызда хатыннар мәсьәләсендә деспотларча хуҗалык итәргә тырышу күбрәк булганга, бу мәсьәлә аңлатырга тиешле күрелде. Шуның белән бергә, хатыннарның фетнәләрен дә гомуми бәян итеп, тыелган эшләрдән аларны тыю тиешлеге һәм бу мәсьәләдә дә, башка урынардагы кебек, шәригатьне саклауга кызыктырылды. Халык та байтак тәэсирләнде, үзем дә тәэсирләндем. Бер сәгать микдары сөйләгәнемнән соң, «Фатиха» [сүрәсе] укып, мәчеттән чыгып, кайбер кунак чакыруы кабул ителде. Казанлы мөһаҗирләр дә, Мөндешнең Камал хаҗи да, Иске Йортның Минһаҗеддин дә, Кырлайның Дәүләтша бине Ибраһим да, бертуганының улы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте Габдешшәкүр бине Йосыф та, Нигъмәт бай бине Гыйззәтулла да, имамнарның барчасында кунакта булдым, юмарт булдылар. Дөнья байтак кысылган булса да, юмартлык кылып, бертөрле күркәм мөгамәләдә булдылар.

Тирә-як имамнарының ишеткәннәре, форсат табып, күрешкәләп киттеләр. Миякә Тамагы имамы Насыйбулла бине Хәммад, Кинә имамы Сибгатулла, Балгачы имамы мулла Әхмәдҗан һәм башкалар күрештеләр. Никифор авылының беренче мәхәллә имамы Габделгафурның агасы – сиксән яшеннән үткән Хайрулла ахун бине Хафиз – авылдан килеп, бер кичкә калып, әңгәмәдә булдык. Тирәягында өстенлек иясе санала икән. Гыйлеме юк түгел, китап күрә икән. «Гайни шәрехе», «Бохари», «Фөтухат Мәккия» кебек газиз китаплар да кулында бар икән. Ата-бабадан бер йөз ел имамлык итеп, дәрес укытып килгән гаиләдән икән. Ләкин бәян итүе зәгыйфь, бераз күп сөйләүче булганга, сүзенә халык аз әһәмият бирә икән. Бу кеше Эстәрлебашка мөнәсәбәтле, фаниатик ихласлыларыннан, мәдрәсәсендә бераз хәлфәлек итеп, игътибар казанучылардан.

## Яңгыр, бер русның рәхмәт әйтүе, гыйбрәт

[...Бер рус мин килгәч, яңгыр явуны] яхшыга юраудa булып, рәхмәт белдерүне үзенә тиешле тапкан. Мондый инсафлы христианнар бер дәрәҗәдә хаклык һәм дөреслеккә башкалардан якынрак булганлыктан, безгә карашлары да заман таләбенчә күпкә яхшыруын күрсәтә. Бу рәхмәтләре күп гадилекләреннән, христианнарның, Коръән әйткәнчә, яһүдиләргә караганда исламга дуслыклары якынрак булуыннан.

Әмма безнең мөселманнар христиан галименә һәм рәисенә мондый яхшы фикердә булырлык бер эш булганда, андый мөгамәләдә булмас, үзләренә ул эшне дөрес күрмәс иде. Чынлыкта, христиан һәм башка кәфернең дөньяви догасы кабул булу мөмкин, шәригать тарафыннан бу мәсьәләдә тыючы дәлил беленми. Ахирәт теләкләре һәм догалары гына буш икәне мәгълүм. Дөньяви файдаларның Аллаһ каршында кадер һәм кыйммәте бик аз булганга, Аллаһ Тәгалә дөньядагы рәхмәтен алардан кызганмый. Сораганга, юлына кергәнгә, азгын булса да, кәфер булса да, бирә.

Шунлыктан догалары кабул булырга да мөмкин. Бу кадәрле эш диннең хак иясенең туры юлда булуына галәмәт түгел. Шулай да, яңгыр сорау намазында кәферләр ияртелми, гади халыкның иманына зарар килү ихтималы бар.

### Эстәрле тәэсире, Шафигыйның остазына каршы язуы, кисәтүләр

Бу тарафлар, гомумән, Эстәрлегә мөнәсәбәтле кешеләр Эстәрленең хатасын да, дөреслеген дә, артыклыгын һәм кимчелеген дә урталык һәм дөрес дип уйлыйлар.

Бу тарафларда Шафигыйның үзенең остазы Мәлик хакында «Радде Мәлик» исемле китап язганын хәтеремә төшердем. Шулай ки, имам Шафигый Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Идрис хәзрәтләре яшь вакытында 13 яшендә үк Мәккәдән Мәдинәгә барып, имам Әбү Габдулла Мәлик бине Әнәс янында, аның тәрбиясендә һәм йортында булып, «Мөватта» укып, фәтваләрендә шунда булып, зур файда алган. Соңра берничә вакытлардан соң Мисырга урнашып, халыкның Имам Мәлик мәзһәбенә артык авышуларын, аңа артык чиктән тыш мәхәббәтләрен күреп, «Радде Мәлик» китабын язган. Мисырда имам Мәликнең шәкерт иярченнәреннән байтак күп кеше булганга, бу китапны язуыннан гаҗәпләнеп, сәбәбен сораганнар. «Остазы хакында әдәпсезлек итте», – дип уйлаучылар да, табигый, булгандыр. Җавабында:

«Ике нәрсә сәбәп булды: берсе – халык. “Мәлик әйтте” дигән сүз “Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) әйтте” дигән сүз дәрәҗәсендә [тота] яки артык күрә башлаганнар. (Соңгы заманнардагы “Әбү Хәнифә әйтте”, “Казыйхан әйтте”, Куһистани әйтте», «Ибне Габидин әйтте» сүзләре «Рәсүлүллаһ (Аллаһ аны

олыласын һәм сәламләсен) әйтте» дигән сүздән артык күрә башлаганнарын күрсә яки ишетсә, нинди хәл булыр иде?!).

Икенчесе – артык мәхәббәт белән Мәгъриб халкының (Тунис, Җәзаир, Маракеш, Фәс халыкларының) Имам Мәликнең бер бүреген кулларына төшереп, шифалану өчен чайкап эчүләрен ишеттем. Шунлыктан Мәликнең дә хаталана торган кеше икәнен күрсәтергә дин ягыннан мәҗбүри булды. Халыкның мәхәббәттә артык китүләреннән кайтару ваҗиб булды да хаталарын күрсәттем», – дигән.

Кайбер вакытларда галимнәр һәм шәехләрнең кимчелекләрен күрсәтү, шундый максатлар һәм дин максатлары белән булганга, әҗер һәм савапка сәбәп булуы өмет ителә. Бу сәфәремдә мин дә шул төрле хәрәкәтләрдә булдым. Кайбер ишаннарның ихласлыларына, мөридләренә кисәтү ясауны хәҗәт күрдем. Аеруча бу тарафларда, гомумән, Уфа вилаятьләрендә икенде намазы бик кичектерелә, ахшам азанына манарага менмичә, түбәннән «ахшамлык» дип аталаган бер сәндерәдән генә азан әйтелә. Иртәнге һәм икенде намазларыннан соң түгәрәк булып, бераз вакытлар утырулары, мохтаҗ булган дини тәгълиматка сарыф итмичә, бушка яки ялгыш-йолгыш зикер һәм тәсбих белән үткәрүләре кебек урыннарын кисәттем. Имамнарның михраб эченә кереп торулары, бу эшләре белән үзләренә файдасыз өстенлек бирүләре, имамнарның үзләреннән белемлерәк кеше булуына игътибар итмичә, халкы алдында үзеннән артык кешенең күренүенә ризасызлыгыннан (шәех һәм изге галимнәр сөннәтләренчә) аны имамлыкка тәкъдим итмичә, үзләренең имам булулары – динне кирәгенчә игътибар һәм ихтирам итмәүче имамнарның гадәте булуы хакында да кисәтүләр бирелде.

Ләкин Эстәрле мохлислары (тарафдарлары) ачык инкяр итү күрсәтә алмасалар да, кайберләренең наданлык фанатизмнары сизелгәләде. Бер мәчеттә мөәзин ахшам [намазы] азанын укып, мәчеткә кергәнче, башка берсе камәт әйтергә аякка басканда, тыеп, туктатып: «Азан кем әйтсә, камәт шуның хакы, ашыгычлык юк, үзе әйтер», – дидем. Ул кеше мәхәлләнең бер сорыкорты булган икән. «Эстәрлебаш хәзрәтләре тыймыйлар иде», – дип үзенең риза булмаганын халыкка белдергән. Эстәрлебашлар дусларым булганга, аларның кайбер хаталарына халыкның иярүләрен туктатырга, аларның җаваплылыкларын киметергә тырыштым. Бу авылда һәм башкаларда икенде-ахшам [намазлары] араларында мәчеттә түгәрәк булып утыру таралган, тарикать әһелләре булмасалар да, бу гадәтне үз өсләренә алганнар. Шул сәбәпле, икенде [намазын] бик кичектереп

укыйлар. Бу мәсьәләдә имам һәм халыкка, дини һәм әхлакый кирәклекләрен, укырга-укытырга, өйрәнергә-өйрәтергә кирәклеген кисәттем. «Намаз кирәкләре, аның зикерләре, догалары төзәтелеп бетмәгән, күбегез дәрескә мохтаҗ, нәфелләр [мәҗбүри булмаган өстәмә гыйбадәтләр] белән шөгыльләнгәнче, бу форсатыгызда дини вазыйфаларыгызны өйрәнегез, имамнарыгыздан сорагыз, җиңел карамагыз», – дип, ике тарафның исләренә төшердем. Аллаһ – Туры юлга кертүче, безгә Җитүче һәм Иң яхшы вәкил.

Дүшәмбе көн иртәнге сәгать сигездә Никифор авылыннан егерме биш чакрымда булган Чебенле авылына киттек. Күрешә килгән Алдар авылының имамы мулла Мөхәммәднең (элек исеме Мөхәммәдия) чакыруына күрә, алты чакрым җирдә булган әлеге авылга ирештек. Мулла Солтан һәм мулла Тимер, чакырулы булганга, бергә бардылар. Мулланың өендә Балгачы авылының имамы мулла Әхмәд тә килгән иде. Соңра иптәш имамы Тимернең атасы мулла Әхмәдҗан да килде. Болар һәркайсы үзләренең кунаклыкларын кылып, берәр чиләк, бәлки артыграк кымыз китергәннәр иде. Мулла Мөхәммәд тә өч-дүрт бия савып, кымыз ясап, артыгын сатып, кәсепләнер икән. Үткән көздә генә йортлары янып, бөек казага очраган, хәзер яңа йорт, келәт һәм каралтылар оештырган. Киң күңелле, сәламәт күкрәкле зат. Бер сарык бугазлап, ашарга әзерләп, озак сөйләшеп утырдык. Карендәше мулла Әхмәд тә гыйлем иясе булганга, кайбер гыйльми сөйләшүләр белән мәҗлес кызык һәм яхшы булды.

## Башкортларда кунак итү ысулы

Бер-ике сәгать кымыз эчкәннән соң, гадәтләренчә, кымызны бастыру, гайрәтен сындыру өчен чәй эчәләр. Без дә шулай иттек. Кымыз бирүләре яхшы, әдәпле рәвешчә, Төркестан ысулына туры китереп тәкъдим итәләр. Шулай ки, бер кул белән генә касәне бирүне әдәпсезлек яки кимсетү күреп, ике кул белән бирәләр. Бу әдәпне һәрбер гади кеше һәм надан да белә. Кайтарып биргәндә дә бер кул белән генә кайтарып бирүне җиңел карау, дип саныйлар икән.

Кунак янына кунак булып килгәндә кымыз алып киләләр, мәхәббәт белән сөйләшеп утырып, эчеп бетереп китәләр. Кымыз мәҗлесеннән бераз вакыт үткәч, кымызның авырлыгы басылгач, янә кымыз белән аш (ит һәм шулпа) ашау була. Элек ит китерәләр. Кой-

рык мае, кисәкле-кисәкле ит һәркемнең алдына куела, үзе турап ашый. Монда игътибар итү урыны шул: һәркайсы, башкаларга да бирү һәм каптыру ысулынча, бергә ашыйлар. Һәркем, үз өлешенән бер калҗа май катыштырып, бөтен табындагы кешеләргә өләшеп чыга. Өстенлекле, олы кешеләр авызларына каптырса да, күбрәк кулларына гына бирәләр. Һәркем шулай бөтен табын халкына тәкъдим итү һәм бөтен халыктан кабул итү рәвешенчә ашауны тәмамлыйлар. Бу эш – үзләренчә, бик могътәбәр гадәт. Чебенле каршысындагы Нарастау авылында саф башкортлар арасында да бу гадәтне күрдем.

Мондый рәвеш белән ит биргәннән соң, итнең куе, файдалы, саф (камыр, ярма салмаган) шулпасын эчеп, икенче камырлы токмачлы шулпасын китерәләр. Бу шулпада токмачны бигрәк таләп ителгән нәрсә кебек тоталар. Шул рәвешле ризык ашауны тәмамлагач, янә бераз кымыз эчеп, эчләр тулгач, безгә күчәргә дә вакыт җитте.

## Күл авылы, Илчегол, язма китаплар

Якын авылдагы Балгачы имамнары мулла Әхмәдҗанны, мулла Мөхәммәдне, иптәшем мөхтәсиб Габдулланы утыртып, сигез чакрым чамалы булган Күл авылына илттеләр. Дим буе белән барган булуыбызда ике тау арасында тезелгән кечкенә-кечкенә авыллар матур булып күренеп калалар. Кайберләре Димнең үзенә, кайберләре Димгә коючы кечкенә елга буена утырганнар. Җирләре иркен, печәннәре күп, ләкин быел, яңгыр аз булу сәбәпле, игеннәр, печәннәр зәгыйфь күренәләр.

Күл авылында Кырлайдан килеп урнашкан Мөхәммәдша аганың уллары Гариф, Шакир, Закирләрнең йортларына килдек. Аш һәм ат әзерләп, көтеп торганнар икән. Бу авылда соңгы елларда гына мәчет торгызып, Габдешшәкүр исемле бер намуслы хәлфәне имам иткәннәр. Бик озакламый боларның ат арбаларында, Шакир әфәнде үзе кучер булып, Чебенлегә юнәлдек. Юлда Яңа Илчегол (Илчекол) авылына ирештек. Бу авыл бик кечкенә бер башкорт авылы булса да, тарихи бер әһәмияте булуын ишеткән идем. Бу авылда Иске Илчеголдан халыкны күчереп алып, төрле мәдрәсәләрдә гыйлем алып, алтмыш еллап язу белән шөгыльләгән мулла Госман бине Хәсән бине Юлдаш бине Назаркол бине Илчегол бине Таймасны ятсынып һәм гаҗәпләнеп һәркем сөйләде. Бу зат «Мир-

кать», «Шәрхе тарикать хадиме», «Җамигыр-ромуз», «Хәләби кәбир» кебек зур китаплар [күчереп] язган. Һәркайсында кайбер төзәтмәләр, юл астында аңлатмаларын язган. Ләкин үзе бөтенләй гарәп морфология-синтаксисын укымаган иде, дип ишеткән идем. Әсәрләрен, каләмен күрү тиешле иде. Юл өсте булганга, кызының оныгы Габделмәҗид бине Ногманга кердек. Бабасы Госман хәзрәттән калган өйдә тора [торган], кызының балаларына (ир баласы юк икән) бүләк ителеп, саклана торган китапларын саклый икән. Бар китапларын алдыма куйды. Барысын да актардым. Иң бөек зур китабы «Миркать шәрхе Мишкәт»не яхшы гына каләм белән язган. Бу кешенең китап ахырларына язганына күрә, Әлшәй (Раевка) авылында Мөхәммәдрәхим бине Монасыйб мәдрәсәсендә «Саглүк», 1854 елда Кыргыз Миякә авылында Лотфырахман бине Габделгалим хәзрәт мәдрәсәсендә «Җамигыр-ромуз» язган. Халык телендә Куганакбаштан Тимербәк ахун Мәксүдь хәзрәт мәдрәсәсендә укыганы сөйләнелә. Күбрәк китапларын, имам булгач, өендә язган. «Ихья голумед-дин» язган, 1879 елда тәмам. Ибне Мәликнең «Шәрхе мәҗмәгыль-бәхрәйн»ен 1873 елда язган. Хадиминең беренче томын 1869 елда, икенче томын 1875 елда язган. «Шәрхе Хәләби кәбир»не 1864 елда язган. Бу китаплардан кечерәк янә биш-ун китаплары бар, тарихларын хәтергә алмадым.

Бу кеше гыйлемнән бигрәк китапка, укудан бигрәк язуга мәхәббәтле булмадымы икән? Әлбәттә, укымыйча язмагандыр. Ләкин гарәп телен белүе бик [үк] дөрескә охшамый. Кайбер урыннардан язган китап ахырлары, китаплар турындагы бүләк итү язулары гарәпчә язылса да, бик үк дөрес язылмаган. Шулай да, гыйлемгә зур хезмәт иткән. Балалары өйрәнсәләр, шактый олы сәдака җария [үлгәннән соң да савабы иясенә килеп тора торган сәдака] калдырган. 1917 елда сиксән биш яшендә вафат булган. Аллаһ аны кичерсен һәм рәхим кылсын.

Тимербәк ахун мәдрәсәсендә бергә урындаш булып торган Карамалы мөәзине Ахунҗан аганың әйтүенә күрә, дәрестә тырыш, намуслы һәм аңлы кеше булган. Атасы Хәсән бабай бер гади кеше булган хәлдә, мәхәббәт белән улын тәрбияләгән. Бу кешенең гарәп морфология-синтаксисын укымый калуы ни сәбәптән булгандыр? Ачыгы шул: элекке хәлфәләре кечерәк әхлак китаплары гына укытучы мөдәррисләр булып, соңра Тимербәк ахунга күчкәндә яше олыгайган, балалар белән озын сүзтезмәләр һәм фәләннәр өйрәнүне үзенә уңайсыз тапкан. Әлеге грамматик зәгыйфьлекләр һәм озын

сүзтезмәләрдән башкача гарәп морфологиясе укуны берсә дә уйламаган булса кирәк, шунлыктан ул заманда күп гарәп морфология-синтаксисын укуны читенсенеп кире какканнар. Юкса бер укыту ысулы белгән хәлфә мондый затларга бер кышта кирәк кадәр гарәп морфология-синтаксисын белдерер һәм шәкертләрне рәхәтләндерер иде. Гөнаһы шул озын грамматик зәгыйфьлекләр, озын сүзтезмәләрне чыгаручыларга һәм мәйданга куючыларга булыр.

**Чебенле, Нарыстау кыйблалары**

Иске Илчегол авылыннан үтеп, биш чакрым җирдәге Чебенле өлеше Нарыстау исемле башкорт авылына килдек. Бу авыл 1917–1919 елларда гына Димнең каршы тарафына тау буена күчеп утырганнар. Чебенле башкортларының гомуми халык җирләрен сату фикеренә төшеп, сатуга риза булмаганнары аерылып күчкәннәр. Башкорт арасында шундый хәлләр күп булган. Сатканнары вакытында кием-салым, әсбаплар ясап, кәеф-сафа корып, җир акчаларын бетергәннәр. Сатмый аерылганнары җирле, сулы, елкылы, кымызлы, игенле булып яхшы көн күрүдә.

Җитмеш-сиксән капкалы бу авыл күркәм генә авыл булган. Авылның урталык бер җиренә тау кабыргасына мәчет салынган. Мәчетнең алдында, артында, көнчыгышында корылмалар юк. Ләкин михраблары аз гына көнчыгышка таба булган. Компаска (кыйбланамәгә) карап салган булсалар кирәк. Мәчет кыйблаларын кыйблага туры китерүне, арабызда фәне булмаганга, һаман халык төзәлә-төзәтә алмыйлар. Фән белмәгәндә, инженер чакырып, Мәккә юнәлешен чыгарып-белдереп, мәчетне турылау бик мөмкин. Мәккә дип сорауда дини мәсьәлә дә булмый, фәнни һәм дөньяви мәсьәлә булып, кәфернең сүзе кабул булганга, шәригатьтә дөрес булган һич тыю һәм шөбһә булмыйча, кыйбла билгеләнә. Кыйбланың үз исеме белән чыгарып, мөселманнар үзләренең белем һәм эзләнүләрен кушып, тынычлык табып, билгеләсәләр дә мөмкин. Бары эшкә әһәмият бирергә, хакны эзләүдә игътибар итәргә кирәк. Кайберләрнең телләрендә борынгы михраблар сүзе йөри. Бу сүзне «элекке бабайлар салдырган мәчет» мәгънәсендә аңлап, аеруча ялгыш көнбатышка юнәлдерелгән шул мәчетләр дә, бер-ике игътибарлырак карт мулла үткән булса, аның мәчетен үрнәк тотуларын аңлата. Шулай итеп, «борынгы михраблар» Мәккә яулары заманнарында сәхабәләр тарафыннан билгеләнгән михраблар булганга күрә, бездә Болгар

йортында борынгы михраблар юк. Болгар шәһәренең михрабы, Мәрҗани тикшерүенә күрә, хата түгел. Аңа караган булсалар да, яхшы булган булыр иде.

Бу Нарыстау авылында имам Әбелхәсән бине Әбелгази бине Сәедгази бер дәрәҗәдә укыган, китап күргәләүче, тирә-ягында өстенлекле, игътибарлы карт мулла. [Һижри] 1328 елда Хиҗазга барып, Мәдинә Мөнәүвәрәдә күрешкән идек. Минем мөфтилек заманында мәчетләре беткән, шул арада Уфада очрашкан [идек], бу сәфәрдә Карамалыга килеп зиярәт итте, ихласлык күрсәтеп авылына чакырган иде. Үзе бик ачык сөйләмәве өстенә, саф башкортча сөйләгәнлектән, сүзләрен аңлау кыенрак, кабатлавын сорарга мохтаҗ булып сөйләштек. Бу кичәдә аның өендә кунып, икенче көндә мөәзине Габделваһһаб бине Галимкол өендә, башкорт ысулынча, бер табынлык кунаклыкта үткәрдек. Бу мәҗлестә Әсән авылының имамы мулла Чәһрияр хаҗи килде. Моның бик зыянлы, авыр хәлдә янганын ишетеп, тәэсирләнгәнебезне сөйләп юаттым. Кыскача әйттем: «Күп нәрсәң янган, ул нәрсәләрнең барысы да Аллаһның милке, синең кулыңда вакытлыча иде («Дөрес шулай», – диде). Инде Аллаһ теләгән – кире алган. Син сабыр һәм савап өмет ит, янә, иншалла, бирер».

Мәчетләре дә янганга, җомга һәм җәмәгать намазын укымый торалар икән. «Читәннән ихата ясап, мәчет итегез, вакытлы рәвештә намаз укырлык урын булыр. Түбәсе булмаса да, пакь, борынгы изгеләр гадәтләренчә, бер гыйбадәтханә булып торыр. Ике-өч көндә оештырырсыз», – дидем. Колак салган кебек булды.

Төш вакытында мулла Әбелхәсән хаҗига тирә-яктан имамнар һәм башкалар җыелып, олы җәмгыять булды. Кымыз да күп иде, эчүче дә күп иде. Ике-өч касәдән кымыз эчеп, бер сәгать тулгач, соңра каршыдагы мәчеткә барып, өйлә намазын укып кайттык, соңра аш тәкъдим ителде. Янә башкортча, Алдар авылындагы кебек, ашалды. Кайбер вак гамәли сөйләшүләр булып алды. Тоташкан «рәхмәт» хәдисен һәм «Аллаһүммә әгыйнни галә зикрикә вә шүкрикә вә хүсни гыйбадәтик» хәдисен тоташ итеп укыдым. Намазларны мөстәхәб вакытларында уку, икенде-ахшам [намазлары] арасын буш үткәрмичә, дини вәгазь һәм гыльми өйрәнүләр белән үткәрергә кирәк, дип кисәтттем.

Берәр пыяла чәй эчеп, кымыз да канәгатьләнерлек кадәр эчкәннән соң, юлга чыктык. 3–4 чиләк кадәр кымызлар мәйданда калды.

«Син киткәч, бу кымызны бетерәбез», – дип сөйләнеп калдылар. Чыннан да, безне күп авыллардан эзләп йөргән, артыбыздан әлеге авылга барган Кичү авылы имамы Сәйфеләбрар мулла бездән аз гына соңрак анда барып, калган кунаклар белән кымызны бетереп, артыбыздан Зифа авылына килеп җитте. Хатынымнан җибәрелгән хатны тапшырды. Кирәк хатның ирешүеннән, кирәк бу имамның кешелеклелеге һәм тырышлыгыннан шат булдым. Күрешеп һәм танышып та кайтырмын, дип 3–4 авылдан әйләнеп-әйләнеп йөреп, безгә ирештерде. Аллаһ аңа хәерле әҗер бирсен.

Шул көн ахшам [намазыннан] бер сәгать үткәч, бу Зифадан юнәлдек. Ике сәгать эчендә биш-алты җирдә хөрмәт күреп, кешелекле егетләрне мәхәббәт һәм тырышлыкларын тәҗрибә итеп, Карамалыга кайтып чыктык. Өч чирек сәгатьтә ястү [намазы] вакытында элекке туктаган урыныбыз булган Карамалыга кайтып кердек. Уфадан хатынымнан килгән һәм дуслардан, төрле яктан килгән хатларны алып укып, ял иттек. Аллаһка барысы өчен дә мактау булсын.

Чәршәмбе көн 22 июньдә Карамалыда ачылган вакытлы курслар шәкертләреннән имтихан алдык. Боларның күбесе имамлык һәм мөәзинлек өчен приговор алган кешеләр булып, Уфага барулары мәшәкатьле булганга, указ өчен җитәрлек дәрәҗәдә шәһадәтнамә бирүне теләгәнлектән, шуңа туры китереп имтихан үткәрелде. Әгъзалар: мин (мөфти), янында мөхтәсиб мулла Габдулла бине Сәгъд Карамалый, шул ук авылда беренче мәхәлләдә имам Габдеррәхим бине Хәбибрахман, Әнәс авылы имамы мулла Шәрәфетдин бине Кәмалетдин әфәнделәрдән гыйбарәт иде. 14 кеше имтихан биреп, берсе урта дини мөгаллим дәрәҗәсенә лаек күренде, калганнары имам, башлангыч дини мөгаллим, мөәзин булырга лаеклы табылдылар. Күбесе элек бер дәрәҗәдә укып, гарәп морфологиясесинтаксисыннан хәбәрдар булган егетләр, дәрес вакытлары бер ай кадәрле генә булып, кытлык сәбәпле, артык дәвам иттерә алмаулары беленгәч, курсларны да туктатырга карар бирделәр. Имтиханны тәмамлап, ашау-эчү һәм башка мөһим эшләрне тәмамлаганнан соң, сәгать биштә Карамалы авылы белән хушлашып, 10 чакрым җирдә булган, Өршәк суына корылган Карамалыдан Габдулла аганың тегерменәнә килдек. Ике сәгать микдары анда утырып, якында булган Гаид авылы имамы мохтар исемле кеше һәм башкалар белән бергә икенде намазын үтәп, кымыз эчеп, ашап, Эстәрлебашка киттек. Юлда Җомгакол, Мортаза исемле башкорт авылларын үтеп, егерме

биш чакрым кадәр юл йөреп, сәгать 11дә Эстәрлебаштан Шакир бине Харис бине Нигъмәтулла бине Биктимер йортына килдек, әлхәмдү лилләһ.

## Эстәрлебаш, тарихы, җомга һәм вәгазьләр

Эстәрлебаш! Нәрсә ул Эстәрлебаш? Бөек авыл, хәтта ки, зур шәһәр, үз ишеләрен нигъмәтләре белән узган. Монда зур мәдрәсәләр салынган, гүя ки ул мөстәкыйль авыл сыман, Харис һәм Харрас юлы белән гыйлем басулары чәчелгән, галимнәр җитешкән, изге бәндәләр монда җыелган, аның даны тирә-якка таралган, әсәрләре читкә узган, башкорт, казакъ кебек төрле мөселманнар файда күргән.

Эстәрлебаш 73 дәрәҗәдә озынлыкта, 53 дәрәҗәдә киңлектә урнашкан. Халкы – Казан ягыннан килгән татарлар. Беренче яраклы имамы – Мөхәммәдҗан мөфти атасы Хөсәен бине Габдрахман, бу авылда имам булган. Янә мөдәррис Гаделша бине Габдулла мәшһүр Дәүләтша ишан атасы 1812 елда 80 яшендә вафат. Балыклыдан Хөснетдин ахун моның мәдрәсәсендә 1799 елда булган. Нигъмәтулла 1772 елда туган, 1801 Бохарага киткән, 1813 елда имам һәм мөдәррис булган, 1844 елда вафат булган. Харис 1810 да, Харрас 1814 елда туган. Бүген Эстәрлебаш авылы өч мәхәлләгә бүленгән. Соңгы инкыйлаб булу белән, ике мәчетне берьюлы төзегәннәр. Икенче мәчеткә Таһир бине Әхмәдҗан бине Нуриман, өченчегә Габдрахман бине Гали Казакый имам булган. Таһир бераз хәлфәлек иткән, бер дәрәҗәдә укымышлыгы һәм гыйлеме бар, әхлаклы кеше. Бу 1921 елда Диния нәзарәтеннән указ алды.

Габдрахман элекке карт хәлфә улы булып, шул ук Эстәрлебашта туып үскән. Бохарага барып дүрт-биш ел торган. Башкортстан мөфтилеген торгызганда, форсат [итеп] белеп, анда имтихан биреп, указ алган кеше.

Пәнҗешәмбе көнне 23 июньдә Эстәрлебашның үзеннән һәм тирә-ягыннан күп халык тупланып, Шакир мәхдүм өендә очрашу һәм зур кунак ашы булды. Мәҗлестә Эстәрлебашның тарихи әһәмияте, дини һәм гыйльми хезмәтләре, хәзерге хәлдә зур хәсрәтләргә очравы, моннан соң өметне кисмичә, яше-карты, олысы-кечесе саклау һәм гайрәт күрсәтеп, янәдән әлеге авылны терелтергә тырышырга кирәклеге турында озын сүз сөйләдем. Байтак кызыктырдым. Халык тәэсирләнеп, тыңлап тордылар, хакыйкый

тыңлаулары ничек булыр? Эстәрлебашның элекке мәчете (олы мәчет) бөтен авыл халкын сыйдырырлык була торып, ике мәчет арттырулары язылган иде. Бу элекке мәчете Казанның беренче һәм икенче мәчетләре кебек кыйбладан биш-ун дәрәҗәдә уңга, көнбатышка төшкән, яңа мәчетләре 4–5 дәрәҗә кадәр сулга, көньякка борылган.

Җомга элекке мәчет ишегалдында өч мәхәллә халкы җыелып, җомга намазы укыттым. Намаздан соң зур халык булып тупланып, бер сәгать микъдары вәгазь сөйләдем. Башка авылларда сөйләнгән маддәләрнең күбесе сөйләнде. Бары, кызганыч ки, хатын-кызларга махсус вәгазь яраклы күрелмәде. Мин Эстәрлебашка килгәч, волостной исполкомда, аларны туплап сөйләвемне агитация дип юрап, идарәләре астында гына сөйләү мөмкин булуны белдереп, хәтта башкортлар эченә кереп, вәгазь сөйләп йөрүгә эчләре пошканын белдергәннәр. Бу хәбәрләрне ишетмәмешкә салышып, кеше җибәреп әйттердем: «Хатыннарга дини-иҗтимагый вәгазь сөйләячәкмен, хөкүмәт кешеләреннән тыңларга килүчеләр булса, киртә юк. Бераз сөйләшкәннән соң, мандаты булса, сөйләсен, дигәннәр. Элекке сүзләре һәм рәвешләре өстенә, бу шартлары да бераз уйларга сәбәп булып, кәеф тә бик яхшы булмаганга, бөтенләй сөйләмәүне сайладым. Бичара хатыннар әзерләнеп көтсәләр дә, өметсезләнеп кайтып киттеләр. Хәвефкә сәбәп булырлык бер нәрсә булмаса да, корал һәм инкыйлабка алданып, һәр эшне кылудан сакланмый һәм авырсынмый торган төркемнең деспотизмыннан саклануны артык күрдем. Башкорт мөфтилеге хөкүмәтнең рәсми булмаган бертөрле яклавында булып торганга, кайбер деспотларның, чын Декретка карамыйча, Уфа Диния нәзарәтенә һәм мөфтилегенә зарар һәм зыян ирештерү өчен мөфтилек эшенә тыкшына башлаганлыктан, минем башкортлар арасында булган бу вәгазьләремне бертөрле агитациягә кайтарып калдырулары ихтимал иде.

## Бу сәфәрдә иҗазәт бирелгән затлар

Бу сәфәремдә Кармалы авылындагы вакытлы курсларда укыган шәкертләр, башка галим һәм имамнар «Гакдел-җәүһәр әс-сәмин фи әрбәгыйнә хәдисән мин әхәдис сәйидил-мөрсәлин салләллаһу галәйһивәсәлләм» нөсхәсеннән, хәдис китапларының башларыннан күбрәге кырыклап хәдис укып, кайберләре икенчеләренә укытып, иҗазәт бирелгән кешеләр:

1. Мөхтәсиб мулла Габдулла бине мулла Сәгъдеддин Биккенә Карамалый.

2. Мөгаллим һәм мөдәррис Әхмәдгали бине Баймөхәммәд Казакый Эстәрли.

3. Карамалы имамы Габдеррәхим бине мулла Хәбибрахман.

4. Әнәс авылының имамы мулла Шәрәфетдин бине Камалетдин.

5. Сатый имамы мулла Шакирҗан бине Әсфәндияр.

6. Җилдар имамы карт мөдәррис Хәбиберриҗәл бине Әһлиулла.

7. Никифор имамы һәм мөдәррисе мулла Солтангали бине Шаһиәхмәд.

8. Никифор имамы Тимер бине Әхмәдҗан.

9. «Мишкәт әл-мәсабих», «Дәләил әл-хайрат», «Хизбе әгъзам» укыр өчен Әнәс имамы мулла Шиһабетдин бине Шәмсетдингә иҗазәт бирелде.

Шимбә көн иртәнге сәгать 11 дә Эстәрлебаштан 15 чакрым җирдә, вакытында дәрес һәм мәдрәсәсе белән танылган Куганак (Куанак елгасы башы) авылына килеп, янында булган каберстанда, тирә-ягының мәшһүр остазы Тимербәк ахунга, улы һәм үзеннән соң калган урынбасары Шәйхелислам җәнапләренә сәлам биреп, «Фатиха» [сүрәсе] укып үтеп, имамнары Мөхәммәдҗан Карамалы базарында булганлыктан, Гыйззәтулла исемле бер карт өендә кунак булып, салкын катык һәм әйрән өстенә, бер-ике касә чәй эчеп, максатыбыз булган Гаид авылына юнәлдек. Гаид авылы – Куганактан 13 чакрым җирдәге башкорт авылы. Дәүләтле кешеләре бар, бик гади тормышлы, балчыктан сылап ясаган өенә кыек һәм түбә кормаган, фәкать түшәм белән канәгатьләнгәннәре дә бар икән. Үзләре җирле, сулы, елкылы, кымызлы, тук кына халык икән. Безне өенә чакырыр өчен күп авыллар йөреп, эзләп тапкан галимнәр хезмәтчесе, шәехләр яратучы Хөсәеннең тегерменәнә ирештек. Бу зат Тамбов мишәрләреннән булып, Оренбург тарафына күчкән, соңра Эстәрлебашта торып, бу көндә Гаид авылына тегермән корган. Монда тирә-ягыннан байтак имамнар, мәчет эшләрен башкаручылар, картлар килгәннәр. Авыл башкортлары кымыз алып килгәннәр иде.

Байтак кымыз эчеп, һавада йөреп, ашаганнан соң, Баһаветдин исемле башкорт, соңра Мохтарулла исемле имамнарында кунак булып, мәчетләрендә икенде намазы укып, үзебезне алырга килгән Габдулла исемле кешенең ат һәм арбасына утырып, Утар авылына

юнәлдек. Авыл янындагы Өршәк суында артык кымызларыбызны җиңеләйтеп, тәһарәт алып үттек. Утар басуына җиткәч, ахшам намазын үтәдек. Ахшам вакыты элегрәк кергән булса да, Өршәктән кичкәч тә, бер немец басуы иде, арбачыбыз үз басуыбызга җиткәч укысак, яхшырак булыр иде, дигәнгә, каршы килмәдек. Кәфер басуында укыганчы мөселман җирендә укуны артыграк күргән, юллы фикер. Ихласлы мөселманнар намазда күп хәер-бәрәкәт көтәләр һм күрәләр, бу кеше дә шулай уйлаган булыр.

Иптәшләребез мөхтәсиб Шакир бине Харис Тукай, Габдулла бине Сәгъд Биккенә, Шәрәф бине Камал Әнәси, арба иясе Габдулла белән биш кеше, җәмәгать белән ахшам [намазы] үтәп, тугыз ярым сәгатьләрдә Утар авылына килеп, имам Гыймран бине мулла Гайнетдин йортына килдек. «Утар» – гарәпчә «зайга», русча «хутор» диелә торган игенлек җир.

Ун чакрым чамалы җирдәге Усули авылыннан Хәмзә, Кырмыскалыдан Шаһиәхмәд исемле ике картның уллары, шушы урыннан 1875 елларда җир сатып алып, утырганнар. Бер-беренә кодалык кылып, нәсел-нәсәпләре карендәшләр. Бүген унсигез йорт хуҗасы булып, яхшы тормыш тәшкил иткәннәр. Бу Утарны Шаһиәхмәд исемен бозып, күбрәк Шахмай дип, кайбер вакытларда Хәмзин дип, кайвакыт Айсулы утары дип тә әйтәләр икән.

Утар халкының барысы да кәсепле, киң булган җирләрендә Европа әсбабы белән тиешенчә игенчелек белән шөгыльләнәләр. Шунлыктан тормышлары бик яхшы, һәркайсы бер кечкенә бояр булып яшиләр икән. Хәзерге хөкүмәткә бер мең пот бодай биргәннәре дә булган. Йортлары шәһәрчә, киң ишегалдылы, яхшы агач бакчалы, тимер түбәле, өч-дүрт бүлмәле агач өйле. Күркәм генә яхшы салынган мәчетләре бар.

## Башкорт мөфтие Мансур бине Хатыйб бине Габделхаликъның килүе

Якшәмбе көн 28 июньдә кичке сәгать 6 да аңсыздан: «Мөфти Мансур Габделхаликъ бар, рөхсәт сорый», – диделәр. Кабул итәчәгемне белдердем. Озакламый керде. Очрашудан соң, гореф-гадәтчә саулык сорашканнан соң, бераз сөйләшү өчен берәр сәгать вакыт сорады. «Дүшәмбе көн иртәнге сәгать тугызда мөмкин», – дип җавап бирдем.

Билгеләнгән вакыт җитәр-җитмәс килде. Аулакта сөйләштек. 1921 елның мартында Аллакуәт җирендә Башкортстан өчен аерым Мөфтилек ясалгач, Диния нәзарәте бу эшне шәригатькә каршы эш итеп күргән иде, рәсми каршылык күрсәтеп, башкортларның (галимнәр һәм мәчет эшләрен башкаручыларның) бу хәрәкәтләре, нигездә, исламга һәм дини максатка каршы икәнен күрсәтеп, тәфсилле проект күндергән иде. Бу язуыбыз бу Мөфтилеккә авыр тоелып, төрле рәвешчә фикерләр йөртсәләр дә, минем бу тарафка чыгуымны яхшы сылтау [итеп] санап, яңа мөфти Мансур бине Габделхаликъ хосусый очрашу өчен идарәләре тарафыннан вәкил булып килгән икән. Диния нәзарәте язуының кыскасы шушы иде: «Йөз илле елдан бирле бердәмлек һәм берләшү белән килгән Нәзарәтне бүлгәләү – Уфаның якынында гына булган Башкортстан өчен бигрәк мөнәсәбәтсез һәм тиешсез [эш], элекке миссионерларның максатларына хезмәт кылу. Европада никадәр төрле дәүләтләргә ияргән христиан (католик) җәмәгатьләре, Һиндстан, Кытай дәүләтләренә ияргән Будда вә Браһмалары, бөтен аерым дәүләтләргә ияргән хәлдә, махсус бер мәркәзгә, мәсәлән, католиклар Римдагы папага ияреп яшиләр. Шул рәвешле дини куәтләрен саклыйлар».

Диния нәзарәтенең бу сүзенә каршы яңа мөфти Мансур әфәнде җавап бирергә булып миңа юлыкты. Башта Мансур әфәндегә әйттем: «Мин сезне тик рәсми булмаган сурәттә кабул итәм, һәр сүзем һәм тыңлавым рәсми түгел, фәкать хәбәрләшү генә».

Мөфти Мансурның сүзе: «Аллакуәт съездында аерылырга теләмәсәм дә, риза булмасам да, халыкның теләве һәм үҗәтлеге белән мөфтилекне кабул иттем. Мин кабул итмәсәм, башка зарарлырак кешенең мөфти булуы ихтимал иде. Бервакытта да Диния нәзарәтенә әдәбсезлек кылу, аның дан-хөрмәтен киметү теләгебез түгел. Һәрвакытта аның юлынча йөрү, аннан файда күреп, хезмәттә дәвамлы булу максатыбыз булып тора. Диния нәзарәтенең протесты белән Диния нәзарәтенең аерылуыбызга һәм Башкортстан мөфтиятеннән риза түгел, дип, бөтен Мөфтиятне япсак, барчабыз да ташласак яки авыр икътисади хәлләргә сылтап, таркалсак, артык фанатик булган башкорт җәмәгатенең фанатизмнары алдында Диния нәзарәте зур җаваплылыкта калып, күп уңайсызлыкның тууы ихтимал. Икътисади хәлләргә сылтап, янә баягы фанатизмнары белән артык мөгамәләләгә дучар булулары ихтимал булудан тыш түгел. Шунлыктан без Нәзарәтнең протесты белән хәрәкәт итүне тиешле [дип] таба алмадык. Мәхкәмәбез тарафыннан катырак җавап язу

уйланса да, аны да туктаттым. Уфага үзем барып, әдәпле мөрәҗәгать итәргә тели идем, инде сезнең бу тарафка чыгуыгызны яхшы очрак [итеп] күреп, Мәхкәмәбез тарафыннан ихласлык күрсәтү өчен вәкил ителеп күндерелдем. Бала кебек кабул итүегезне үтенәм», – дип, түбәнчел һәм әдәпле рәвештә телдән генә үтенечләрен сөйләп бирде.

Минем сүзем: «Аллакуәт съездына Диния нәзарәтеннән аерылмауга, башкортлар өчен аерым мөфтиятнең зарарлы икәнен аңлатырга, Диния нәзарәтенең бөтенлеген саклар өчен тырышырга вәкил итеп җибәрелдең. Шулай була торып, ахырдан, үзең мөфтилекне кабул иттең. Бу хәрәкәтләрең Нәзарәтнең вәкаләтенә каршы, максатына каршы бару булып күренде. Зарурлык булды вә фәлән сүзләре мәйданда сөйләнсә дә, дөресме, түгелме – эшнең рәвешендә, рәсми күренешендә анык табылмады. Шунлыктан башкортларның аерылуы өстенә, синең мөфтилегең икенче мәртәбә Нәзарәт хөрмәтенә икенче мәртәбә тукынды. Аңсызлыктан туган, тиешенчә хөкүмәтнең җәберенә, вазыйфасыннан тыш начар тәэсиренә карап, мөселманнарның бердәм сүзенә каршы эшләнгән бу Мөфтиятнең зарарларын, акыл һәм чагыштыру юлы белән дә мөнәсәбәтсезлеген ачыграк белдереп, сезнең Мөфтиятнең үзенә һәм ризалык күрсәткән мөхтәсиблек районнарына үзенең фикерен һәм искәртүләрен ирештерүне, вакытлымы, соңмы, хакыйкатьне аңлатып калуны вазыйфасы дип таныганга, [Диния нәзарәте] шул вазыйфасын үтәде».

Мансур үзләренең һәрвакытта Диния Нәзарәтенә әдәпле мөгамәләдә булачагын әйтеп, үз идарәләренә шәфкатьле мөгамәләне, хаҗәт булганда кайбер кисәтүләр, өстәмәләр бирүне түбәнчелек белән тәкъдим итте.

Башкортлар арасында үзләреннән нәфрәтләндерү ысулынча хәрәкәттә булмауны сорады. Әйттем: «Диния нәзарәте сезнең белән тартышу максатында түгел, бары бу аерылу мәсьәләсендә үзенең вазыйфасын үтәде. Хаклыкны бәян итте. Тик һәркем, һәр мәхәллә теләгән мөфтияткә иярүдә ихтиярлы. Һичкайсы мәхәллә, бер идарә дә: «Ник анда карыйсың, ник монда карыйсың», – дияргә хаклы булмаса кирәк. Шунлыктан бу мәсьәләдә бер идарә дә тиешсез хәрәкәттә булып көчәнмәскә тиеш. Шуны белдерәм ки, кайбер кантон казые исемен күтәргән вәкилләрегез мөхтәсибләргә, Диния нәзарәте өчен тупланган иганәләрне үзләренә сорап, мөрәҗәгать иткәннәр. Мондый хаксыз мөгамәләләр тиешле түгел. Халык тарафыннан безнең өчен җыелган, вәкилләребез булган мөхтәсибләргә

тапшырылган. Шунлыктан ул акчаларга хәтта иганә итүчеләрнең дә ихтыяры юк, вәкилләргә тапшыру вәкил җибәрүченең үзенә тапшыру хөкемендә. Соңра ихтыярлы иганәне һәркем теләгән урынына бирергә ихтиярлы. Һичкем тарафыннан тыю булмаска тиеш», – дидем.

Бу мәсьәләне тиешсез хәрәкәттә булган вәкилләренә (кантон казыйларына, волость мөхтәсибләренә) хәбәр итәчәк булды. Гомумән, кабул итүемнән, яхшы мөгамәләмнән риза булып, бер кичкә Утар авылында калганнан соң, Эстәрлегә кайтып китте. Минем килүем мөнәсәбәте белән, Эстәрледән Габдулла казый Сөләйман да Утарга килгән иде. Бу кеше Башкортстанда укытучылык хезмәтендә булып, фикерләре, тел куәте, мәгълүматы белән ул тарафта бик игътибар казанган. Мөфтият белән дә яхшы мөгамәләдә булып, кайбер эшләрдә, бигрәк тә Диния нәзарәте белән булган мөнәсәбәтләрдә Мансур әфәндегә байтак юл күрсәтә икән. Диния нәзарәтенә хәерхаһлыгы даими булган кебек, Башкортстан мөфтияте өчен дә бик хәерхаһлы һәм Мансур белән байтак яхшы мөнәсәбәттә икәне беленде.

* * *

Утар авылы, Эстәрле өязе Башкортстан эчендә булып, минем килүем мөнәсәбәте белән, мулла Гыймранның үзе тарафыннан Башкортстан мөфтилегенең байтак имамнары һәм мәчет эшләрен башкаручылар чакырылган иде. Эстәрле имамы мулла Гариф ахун Рәмиев, Усыйле имамы Хаҗелислам бине Тимербәк ахун Куганакый кебек кунаклар булдылар. Үз мөфтилекләренә караулары, мөфтилекләренә күрсәткән мөгамәләләре мәхәббәтле һәм ихласлы түгел иде. Мөфти Мансур әфәндегә элекке мөхтәсиб вакытындагы мөгамәләдән артык мөгамәлә күренмәде. Мәҗлестә хөрмәтле итү кебек гади дәрәҗәдәге мөгамәләләре дә юк, «Мансур әфәнде» исеме белән генә мөрәҗәгать итәләр. Элек күрмәгән муллалар бигрәк түбән күз белән карадылар. Ләкин Мансур әфәнденең бәян итүенә күрә, мөфти сайлау мәҗлесендә булмаган кантонлыклардан да (Күди кантонлыгыннан кала башкаларыннан тәбрикләүләр ирешкән). Хәтта Башкортстанга кермәгән Дим буеның атаклы ахунларыннан, район мөхтәсиб җәмәгатеннән Мөфтияткә керү өчен гаризалар килүен, башкорт Мөфтияте матур итеп кире кагуын сөйләде.

Әйттем: «Сәбәбе ачык, бу ахун мөхтәсиблек хисабын Диния нәзарәтенә тапшырудан тукталып тора, тупланган иганәләрне тәмам

тапшырмады, мөрәҗәгать ителсә дә, һаман җибәрми. Шундый сәбәпләр аркасында төрле хәрәкәтләрдә булуы ихтимал».

Габдулла казыйның Мансур әфәндедән аңлаганына күрә, безнең Сабир казыйдан да телдән тәбрикләү ирешкән икән. Хәтта Нәзарәтнең протест кәгазендә аның имзасы булуга гаҗәпләнгәннәр икән. Мин гаҗәпләнмәдем. Уфаның икенче мәхәллә имамы Зыяддин Кәмалидән, Башкортстанда бер мөгаллимлек хезмәте сорап, гариза килгән икән. Ләкин, ни сәбәпледер, Мансур әфәнде кабул итеп, уңай җавап бирәчәк түгел икән.

Шимбә көн беренче июльдә үзләренең чакырулары белән, Утардан ун чакрым җирдә булган Бәгәнәш авылына юнәлдек. Әлеге авылда Башкортстан мөфтилегендә кантон казыйлыгы вазыйфасын алган аңлы, туры акыллы, башкорт арасында байтак өстенлек казанган имам Габделхәбир бине Мәхмүд йортына индек[43].

Тирә-яктан чакырылган кунаклары да бар икән.

## Хәбибенәҗар хәзрәтнең вафаты, тәрҗемәи хәле

Мосафирлардан ишетелгәнчә, Эстәрле ягы Үтәк авылында 33 ел кадәр дәрес биреп, дин гыйлемнәрен тараткан мулла Хәбибенәҗар ахун дөньядан кайткан. Дүшәмбе көн тирә-яктан Утарга килгән элекке мөхтәсиб Гарифулла Ярмәков Нәйрүс авылыннан мулла Хәлил әфәнделәр, элекке ашказаны авыруы өстенә, көндез булганын, бер табиб операция ясавын сөйләгәннәр иде. Инде әҗәл вакыты ирешкән була. Аллаһ аны кичерсен.

Искә алынган зат шәех Шиһабетдин Мәрҗанинең өметле һәм игътибарлы шәкертләреннән, «Мәрҗания» мәдрәсәсендә бер дәрәҗәдә дәрес укытып, остазыннан ризалык алып, гыйлем таратырга керешкән иде. Троицкида шәех Зәйнулла Рәсүли хәзрәтләренә тарикатьтә ияреп, ике канатлы галим булырга тырышкан. Эстәрле тирә-

[43] Бу Габделхәбир бине Тәкый бине Кәрим бине Гомәр бине Мәхмүд бине Мөхәммәд бине Калмәт хәзер дә үзе теләмичә генә башкорт Мөфтилегендә хезмәт кабул иткән булса да, ул Мөфтилекнең оешуына баштан ук каршы, хәзергә кадәр каршылыкта, йөрәге белән риза түгел, бу фикерендә нык. Бичара бу 1921 елның августында вабадан вафат булган. Тирә-ягында ганимәт, фикер иясе, диндар кеше иде. Аллаһ аны кичерсен. Үзе Эстәрлетамакта Ширнияз хәлфәдә укыган, русчадан азрак хәбәрдар, халыкның хөкүмәттә булган йомышларына катышыр җан, дөрес йөрәк белән хәрәкәт итүчән иде.

ягында байтак мөрәҗәгать ителә торган зат, үрнәк булган. Байтак имам һәм мөәзиннәр җитештергән, изге, акыл иясе иде. Бу кешенең дөньядан күчүе үз ягы өчен, бигрәк тә милләт өчен гомуми зур югалту. Аллаһ Тәгалә үзен рәхим кылып, өметле булган балаларына файдалы гыйлем биреп, хәерле нәсел булуны насыйп итсен. Яше якынча 65 тә булса кирәк. Бу Бигәнәш авылында якын-тирәдән байтак имамнар, авылдан мәчет эшләрен башкаручылар бар иде: Балыклы, Күл имамы Хафиз һәм бертуганы мөәзин Садыйк, Бөре Казыган имамы Габдрахман бине Харис, Талач авылыннан Лотфуллаһ бине Зиннәтулла, Айсулы авылының имамы Нурулла хәлфә һәм башкалар. Эстәрле мөфтиятенең өченче казые Исмак бу авылда имам икән. Мәҗлестә булды. Җәмгыять корылып беткәч кенә килеп, очрашты. Кул бирешкәнгә каршы икеләнебрәк: «Без ихтыярсыз алгаладылар, дип бер-ике кешедән ишеткән идек. Шуңа күрә кантоннарга язган идек», – дигән җавап килде. Шунлыктан һәркем үз ихтыяры белән теләгән җиренә ярдәм күрсәтүдә ирекле, һичкем тарафыннан тыюга очрамаса кирәк», – дидем. Бу сүзем байтак нәрсәне аңлатса кирәк, дип уйладым. Мәҗлестән соң озак юанмый, егерме чакрым ераклыкта булган Балыклы авылына юнәлеп, икенде [намазы вакыты] ахырында Балыклы авылына килеп, беренче мәхәллә мөәзиненә кердек.

Бу Балыклы авылы – моннан илле ел элек, илле ел кадәр дәрес әйтеп, шөһрәт тапкан Хөснеддин хәзрәт исемле галим белән дан һәм шөһрәт тапкан авыл. Бу авыл чыгышлары белән ике йөз ел элек Нижний Сергач вилаяте Мәдәнә Суксу авылларыннан килгән мишәрләр. Алатырь дигән исемнәре дә бар. Хәзер өч мәхәллә булган.

## Яңа Карамалы һәм мөхтәсибне тикшерү

Якшәмбе көн сәгать 11 дә вак кына сибеп торган яңгыр астында бу авылдан күчеп, сигез чакрымда булган Таубазы авылыннан үтеп, янә дүрт чакрым йөреп, Яңа Карамалы исемле ике мәхәлләле зур авылга килеп җиттек. Мондагы мөхтәсиб Кәшшаф Ждановка сугылсак та, ялан карарга киткән булганга, Насыйбулла бине Әхмәдулла исемле бер хаҗига кердек. Кыш вакытлы курсларыбызда укып, имтихан тоткан Габделәхәд икенче мәхәлләсенә имам итеп сайланган икән, килеп күреште. Бичара якын көннәрдә Башкортстан мөфтиятеннән указ алган. Кайбер яхшылыкларны сөйләшү өчен мулла Кәшшафны күрү тиеш булганга, бу авылда бераз сабыр ит-

тем. Бер-ике сәгать кадәр вак яңгыр дәвам итте, җирне туйдырырлык булмаса да, тузан басар кадәр яңгыр булды. Юмартлыгы өчен Аллаһка мактау булсын.

Кичке сәгать 5 чамаларында мөхтәсиб мулла Кәшшаф урманнан кайтып, Габделәхәд мулла өендә чәй эчкән вакытыбызда килеп күреште. Бичара бөтен гаиләсе белән урманга үлән тамыры кебек нәрсәләрдән азык җыймакчы өчен барган икән. Мине дә өенә чакырды. «Икмәк юк, чәй (үлән чәе) мөмкин», – дип тәкъдим итте. Бардым, ашау-эчүгә хаҗәт булмаганга, бары катык капкаладым. Өйдә бөтен нәрсәләрен сәфәр хәленә китергән. «Уттан куркабыз, киләткә куйсак, карактан куркабыз, күз алдыбызда шулай асрыйбыз», – диде. Башкорт мөфтие боларны көчләп, коммунистларның мылтыкларына сыенып, куркытып, үзләренә каратырга һәм иганәләр җыярга, Уфа Диния нәзарәтенә җыелган иганәләрне үзләренә тапшырырга боера икән. Куркыта торгач, куркып, Диния нәзарәтенә диелгән йөз меңнән артыграк акчаны җибәргән дә. Әйттем: «Безнең вәкилебез буларак, мөселманнардан ихтиярый иганәне кулыңа алгансың, бу мал безнең милкебезгә кергән, законлы хакыбыз булган. Башка урынга бирү шәригатьчә дөрес түгел, башка урынга, кайда тапшырган булсаң да, гарант булырсың, түләрсең», – дидем. Эстәрле мөфтиятеннән сорау итеп мондый эчтәлектә хат язарга әйттем: «Халык Уфа Диния нәзарәтенә тапшыру өчен фәлән микъдар иганә биргәннәр, әлеге Нәзарәттән вәкил булуым сыйфаты белән, минем кулыма тапшырылган иде. Бу акчаны минем сезгә тапшыруым шәригать буенча дөрес булдымы, Диния нәзарәте миннән таләп итсә, аларга түләвем тиеш буламы? Бу мәсьәләдә миңа шәригатьчә һәм фикыһ китаплары буенча фәтва бирсәгез иде».

Имамнарның һәм халыкның рухларына һәм бәян итүләренә күрә, иганәләрнең барысы да Диния нәзарәте өчен тупланган, үз ихтыярлары белән Эстәрле мөфтиятенә әйләндерергә халыктан ризалык булмаячак. Шулай булгач, алар бер мәртәбә вәкилебез кулына тапшырганнан соң, иганә һәм садакалары тәмам була, кайтарулары һәм башка чыгымга алыштырулары үзе дә дөрес түгел. Башта әйтелгән чыгымга гына тапшыру тиешле. Шулай итеп, һәркайсы мөхтәсибләр мондый рәвешле мөгамәлә итсәләр, җаваплы булалар, үз кесәләреннән түләүләре тиешле була.

Алты ярым сәгатьтә яшь мулла Габделәхәд үзенең ике атын җигеп, әйберләремне төяп, мулла Кәшшаф өенә килеп җитте. Икенде намазын укып, җиде туларга 15 минутта Карамалыдан 12 чакрым

җирдә булган Исмәгыйль авылына сәгать сигез булганда килеп җиттек. Габделәхәд мулла тырыш, яңа гына өй җитештергән, миче өчен үзе кирпеч сугып, үзе мич чыгарган. Көн күреше намуслы гына, аз гыйлемле булса да, арттырырлык, гамәл кылырлык, өметле бер мулла икән. Аллаһ аның диненә, гыйлеменә, ризыгына бәрәкәт бирсен.

**Исмәгыйль, Карлыман, Фәтхулла ахун җыентыгы**

Исмәгыйль авылында беренче мәхәлләнең имамы Имаметдин бине Габденнасыйрга килдек. Бик шат булып кабул итеп, каенатасы имам Таһир бине Сәгъдетдин белән дә очрашып, арган хәлдә ястү [намазын] укып, тизрәк ял иттем.

Исмәгыйль авылы мишәр Алатырь җәмәгатенннән тупланган халык икән, башка авыллар кебек быел ачлык хәлендә. Дүрт-биш көн элек ут чыгып 17 кадәр йорт янган. Имаметдин мулланың каршы тарафлары янганга, мулла һаман әйберләрен туплаган, баглаган хәлдә иде. Һәр җирдә корылык булганга, ут казалары булып тора икән. Зур Кырмыскалы авылында ике йөздән артык йорт янганы ишетелде. Ике көн элек Иске Атҗитәр авылында (Мөхәммәдҗан мөфти мәрхүмгә мөнәсәбәтле авыл) кырык кадәр йорт янган икән. Аллаһ барчасына хәерле каза итеп, хәерле ахыр бирсен.

Дүшәмбе көн 29 шәүвәлдә (3 июльдә) иртәнге намазга бардым. Мулланың өе ярым чакрым кадәр читтә икән. Алты-җиде кеше булып намаз үтәдек. Мәчетләре компас буенча көньяккарак салынган. Аз гына уң тарафка авышып укыдым. Бераз ялдан соң бу ике бит язуны язып, ике-өч җирдә гади генә кунак булып, сәгать тугызда Исмәгыйльдән Кырмыскалыга таба хәрәкәт иттем.

Мулла Имаметдин үзеннән бер ат, икенче мәчет имамы Лотфырахманнан бер ат – пар ат – белән ат башына утырып, яхшы йөртеп, 11 сәгать чирек минутта 17 чакрым арада булган Калман авылына ирештек. Имамы башкорт, башкортлыгында байтак фанатик мулла Галәветдин бине Габдеррәшид өенә килдек. Бу адәм элек бер мәртәбә Уфада кайбер сораулар белән килеп танышлык хасил иткән иде. Күргәч, таныдым. Эстәрлетамакта Камал хәзрәт мәдрәсәсендә Гомәр авылына имам булган Габдрахман хәлфәдән һәм Уфада булып үткән Хәйрулла хәлфәдән гыйлем алган, ярым-йорты уку хасил иткән кеше. Китаптан бөтенләй бизмәгән. «Нинди китапларың бар?», – дигәч, якын гына торган бер олы җыентык күр-

сәтте. «Якын көннәрдә генә бер кешедән 30 мең сумга алдым», – диде. Тикшереп карадым, Оры Фәтхулла ахун бине Хөсәен җыентыгы булып чыкты. Яхшы китап дип, төзүченең тәрҗемәи хәлләрен, фәтва бүлекләрендә тәҗрибәләрен бәян итеп, китапны укырга киңәш иттем. Йорт хуҗасы милади 1887 елларда имам булган, алтмыш яшьләр чамасындагы башкорт мулласы. Авылында кымыз ясаучылар булса да, күбрәк базар көннәре алдында сатар өчен ясыйлар икән. Безгә сатып алыр өчен дә табылмады. Чәй, йомырка, арыш ипие ашадык та, соңра өйлә намазын укып, мулла Галәветдин үз арбасына утырып, сәгать 3 тә Кырмыскалы тарафына киттек. Арбачым мулла Галәветдин үзе иде. Бер генә ат булса да, аты яхшы, өч чирек сәгатьтә Кырмыскалыга ирештек. Кырмыскалы халкы – төрле җирдән җыелган мишәр халкы.

Пугачевтан күп куркыныч, зыян күреп калган башкортлар күршеләренә һәм җирләренә мөселманнарның урнашуын ганимәт дип белеп, Кырмыскалы халкының 13 гаиләсе Карлыман башкортларыннан җир сорагач: «Һәр морҗа башына ел саен 7 тиен акча түләрсез», – дип җирләштергәннәр. Бара-бара мишәрләр күбәеп, авыллары артып, хәзерге заманда биш мәхәлләле бер кечкенә шәһәргә охшаган, зур байлыкка ирешкән кешеләрнең биналары белән күркәм авыл булып киткән. Тик бу җәй ике зур янгында 400 гә якын йортлары һәм бер мәчетләре янып, зур зарарга дучар булганнар.

Кырмыскалыда мулла Миргали ахун Солтангалиевтә кунак булып, йортлары янган Хәйдәр Солтангали һәм Шәйхетдин ахуннарны күреп, кайгыларын уртаклашып, сәгать 7 дә 10 чакрымда булган Биш Угыл авылына юнәлеп, сәгать сигездә ирешеп, Низаметдин бине Хәйретдин өенә килдек. Хәзер генә өлгергән мәчетләренә ахшам намазына барсак та, кеше юк иде. Иптәшем мулла Галәветдин азан укып, икебез генә намаз укып чыктык. «Эш һәм печән өсте, халык йөри алмый», – дип салкын акланучылар булды. Шимбә көн иртән Гайнетдин исемле бер тырыш агада кунак булып, сәгать 10 да Манчади авылына килдек. Имамы Солтангәрәй әфәндедә мосафир булып, сөт-май капкалаганнан соң, электән [үк] кайбер хезмәтләребездә булган Гыйззетдин бине Шәрәфетдин исемле кешегә күчтек. Гыйззетдин белән кайбер тормыш һәм яшәү киркәләрен сөйләшеп алдык. Бу зат печән белән эш иткәнгә, ике елдан бирле безгә дә печән җитештереп килә иде. Җитештермәсә дә, ярым-йортысын тапшырып, башка урыннарга сатып, үз файдасын

да күзәтеп, мөгамәлә итеп килә иде. Инсафлык-вөжданы заманача гына булса да, кайбер мөгамәлә итүенә мәҗбүр була идек. Быел да бераз печән әзерләгән. Дүрт-биш йөк печәне барлыгын әйтте. Бәясен бераз сөйләшкәч, 15 пот чамалы бер арбасын 100 мең сумга шәһәргә өебезгә илтәчәк булды. Вәгъдәсендә торса, бик шат булачакбыз. Һәр поты 6675 сум чамалы була. Уфада бер йөк йөз илле мең сумга кадәр сатыла икән. Бер сыерга һәркөн ун кадак печән бирелсә, 1666 сумлык печән кирәк, 1334 сумлык вак-төяк бәрәңге кабыгы һәм фәлән бирсәк, көнлек 2500 сум торышлы була.

Җиде айга (көз һәм кыш көннәренә) 575000 сум була. Аллаһ – Ризыкландыручы, Нык көч иясе.

Төштән соң Манчадидан китеп Сәвәләй авылының бер тарафыннан үтеп, Ибраһим авылына килеп. Әбү Язид бине Сәлим Өметбай әфәнденең өенә килдек. Бу җиргә кадәр ат-арба иясе иптәшебез мулла Галәветдин булды, Аллаһ аңа хәерле әҗер бирсен.

## Юлыккан нәрсәләр

Кара ясау тәртибе:

1. Ат шомырты кайнатылыр, шул яхшы кара була. Моны Чуенчыда имам Сафиулла әфәнде тәҗрибә иткәнен сөйләде.

2. Имән кайрысы кайнатып, бераз күгәргән тимер заты кушылыр. Моны Эстәрлебаштан Шакир Тукай сөйләде.

3. Имән яфрагында торган сөял һәм чикләвек бер данә барлыкка килә. Башкортча «таңкау» диләр. Шуны җыеп, баягыча тимер салып, кайнатылыр. Моны Чебенле имамы Әбелхәсән хаҗи тәҗрибә иткәнен сөйләде. Карлыман авылында имам Галәветдин Пугач вакытында язу карасы тәмам беткәч, соңыннан шул «таңкау»дан кара ясаганнар, дип сөйләде.

## Йомран, Кабак, Кыешкы, Уфа

Йомран (Җомран, Ибраһим) – мәшһүр Өметбаевлар авылы. Уфа тарафында элекке атаклы башкорт гаиләләренең олыларыннан, күп еллар кантон булып торган Ишмөхәммәд, кадетский корпуста укып, Диния нәзарәтендә сәркятип булып торган аның улы шагыйрь хаҗи Мөхәммәдсәлим Өметбаевлар бу авылдан. Хәзер Мөхәммәдсәлимнең улы хаҗи Баязид – сәламәт, картлык яшенә яңа ирешкән, шагыйрь, каллиграф, әдип, гарәп телен дә белә, хуш табигатьле, ки-

тап карау белән мәшгуль, нәкышбәндия тарикатенең ихласлы иярчене, яхшы кеше. Дөньясы бик киң булмаса да, канәгатьле, динле кеше. Бер кич анда калып, чәршәмбе 5 июльдә иртән үз аты белән Йомраннан китеп, Колыш авылы яныннан үтеп, Кабак авылына ирештек. Бу авыл өч мәхәлләле: бер мәхәллә татар, бер мәхәллә типтәр, бер мәхәллә башкорт икән. Башкорт мәхәлләсе типтәрләргә тоташ булса да, арадан читән белән бүлеп куйганнар. Җирләре аерым, тормышлары бераз башка, башкортлыкларын югалтмыйча торырга тырышалар икән. Шулай да имамнары мулла Кәшфулла типтәр җәмәгатеннән икән. Кабак авылында типтәр мәхәлләсендә булган Гариф бине Сәйфетдин Җуашига килдек. Бу адәм атабыз белән бертуган карендәш Гайшә бинте Бинеяминнең кызы Фатыймадан туган булып, якын карендәшем була. Казан җиреннән кәвеш остасы булып бу авылга урнашкан. Бер улы гаскәри хезмәттә, ике улы белән кәвеш-галуш тегеп, яхшы гына тормыш итәләр икән. Аш һәм чәй белән кунак итеп, аты белән Галимҗан исемле улын безне озатырга билгеләп, өйләдән соң сәгать өчтә Уфа тарафына юнәлеп, Кыешкы авылына юл тоттык. Кабак авылыннан Агыйделне кичеп, Кара һәм Ак Иделләрнең урталарыннан Уфага дүрт-биш чакрым кадәр туры юл булса да, Кыешкы вакытында яхшы гына гыйльми хезмәт иткән һәм шөһрәт кәсеп иткән авыл булганлыктан, Кыешкы юлын тоттым. Дүрт ярым сәгатьтә анда килеп, мулла Мотаһһир бине Хәйдәр бине Камалетдин бине Габделхәким бине Дәүләтша бине Тиләббирде бине мирза Мамай бине мирза Дунай бине мирза Сүнчәләй өендә кунак булып, сәгать алтыда аннан чыктым. Кыешкы авылы мишәр халкыннан тупланган, кыйшык, бормалы, озын күл буена утырган. Авылны «Кыешкы» диюләре дә шул мөнәсәбәт белән булган булса кирәк. Шактый олы булса да, бер мәхәллә генә булып торган бу авыл бәрәкәтсез авылга охшамый. Мулла Мотаһһир вакытында салынган яңа мәчетләре бик иркен һәм күркәм, кыйбласы да төзек кенә, корылмалы мәдрәсәләре бар, тыныч заманнарда яхшы дәресләре булган. Мулла Мотаһһирдән элек атасының бертуганы мулла Мирсаяф бине Камал вакытында һәм аннан соң мулла Мотаһһир вакытында укып, тирә-ягына байтак имам урнашкан. Аеруча Мирсаяф ахун байтак шөһрәт белән дәрес укытты. Аллаһ аны кичерсен. Бер дәрәҗәдә укыган шәкертләре дә бар, диләр.

Мулла Мотаһһир үзе Уфага хәтле китермәкче булса да, минем Кабак авылындагы якыным Гариф бине Сәйфетдин улы Галимҗан:

«Үзем Уфага хәтле илтәм», – дип әйтүе сәбәпле, Мотаһһир ахун каршылык күрсәтмәде, бәлки, күңеленнән шат та булгандыр. Бер генә ат булса да, сәгатенә сигез-тугыз чакрым йөреп, кояш баюына Иделдән көймә белән кичеп, халык ахшам намазыннан чыкканда мәчет урамына килеп тә җиттек. Йортыбызга ирешеп, хатыныбыз белән шатлыкта очраштык. Моның өчен Аллаһка күп, иң яхшы, бәрәкәтле мактаулар булсын.

27 рамазанда (4 июньдә) шимбә көн иртәнге сәгать алтыда Уфадан юнәлгән идем. 33 кадәр авылда булып, кайберләрендә кунып, кайберләрендә бер-ике сәгать, кайберләрендә күбрәк торып, 33 көн кадәр булып, 33 нче көннең ахырында 1 зөлкагдәдә (6 июльдә) Уфага кайтып кердем.

| № | Йөргән авыллар | Өязе | Ничә мәхәллә | Имамы | Торуым |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Әнәс | Бәләбәй | 3 | Шиһабетдин, Шәрәфетдин | Бер кундым |
| 2 | Исмәгыйль | Эстәрле | 2 | Таһир, Имаметдин, Лотфырахман | Бер кундым |
| 3 | Алдар | Бәләбәй | 1 | Мөхәммәд (Мөхәммәдия) | 6 сәгать |
| 4 | Утар (Усыйле) | Эстәрле | 1 | Гыймран бине Гайнетдин | 7 көн |
| 5 | Эстәрлебаш | Эстәрле | 3 | Габделгалим бине Хәбибулла, Таһир, Габдрахман | 3 көн |
| 6 | Ибраһим | Бәләбәй | 2 | Гыйззетдин, Гандәлиб, Гобәйдулла | Кундым |
| 7 | Ибраһим (Җомран), Өметба-евлар | Эстәрле | 2 | Гобәйдулла | Кундым |
| 8 | Илчекол | Бәләбәй | 1 | Габделмәҗид | 2 сәгать |
| 9 | Балыклы Күл | Эстәрле | 3 | Хафиз, Габделкави | Кундым |
| 10 | Бәгәнәш | Эстәрле | 2 | Габделхәбир, Исхак | 4 сәгать |
| 11 | Биш Угыл | Эстәрле | 2 | Хөсәен, Хөснетдин | Кундым |
| 12 | Яңа Чебенле | Бәләбәй | 1 | Әбелхәсән бине Әбелгази | Кундым |
| 13 | Ханбик | Бәләбәй | 1 | Габделгаффар | 5 сәгать |
| 14 | Чуенчы | Бәләбәй | 3 | Сафиулла, Гата, | Кундым |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Миңлеәхмәд | |
| 15 | Зифа | Бәләбәй | 1 | Мөхәммәдсадыйк | 6 сәгать |
| 16 | Сатый | Бәләбәй | 3 | Шакирҗан, Габделхәбиб, Зариф | 2 кичә |
| 17 | Гаид | Бәләбәй | 1 | Мохтар | 5 сәгать |
| 18 | Куанак | Эстәрле | 1 | Мөхәммәдҗан | 3 сәгать |
| 19 | Карамалы | Эстәрле | 3 | Габдулла, Зәки, Габдерәхим, Кәшшаф | 8 көн |
| 20 | Яңа Карамалы | Эстәрле | 2 | Кәшшаф Жданов, Габделәхәд | 8 сәгать |
| 21 | Кабак | Уфа | 3 | Хәлил, Кәшфулла, Хәлф | 5 сәгать |
| 22 | Кыешкы | Уфа | 1 | Мотаһһир, Садр | 1,5 сәгать |
| 23 | Кырмыс-калы | Эстәрле | 5 | Миргали, Шәех, Гыйззетдин, Нигъмәт | 3 сәгать |
| 24 | Кыргыз Мияк | Бәләбәй | 3 | Кирам, Бадырша, Зариф | 5 сәгать |
| 25 | Күл | Бәләбәй | 1 | Габдешшәкүр | 3 сәгать |
| 26 | Карлыман | Эстәрле | 1 | Галәветдин | 4 сәгать |
| 27 | Мәнәвез | Бәләбәй | 3 | – | 2 көн |
| 28 | Манчади | Эстәрле | 1 | Солтанбәк Гәрәй | 4 сәгать |
| 29 | Никифор | Бәләбәй | 3 | Солтангали, Тимер, Ибраһим, Габделгафур | 3 кичә |
| 30 | Мәләш | Бәләбәй | 2 | Гатаулла, Лотфулла | 1 сәгать |
| 31 | Мөрәс | Бәләбәй | 1 | | 3 сәгать |

## Сәфәрдә күргән хәлләр

Бу авылларда мин күргән халык өч фирка: башкорт, мишәр, казанлы (типтәр, татар).

1. Башкортлар – төп җирле, җирләр хуҗалары булган җәмәгать. Үзләре хуш табигатьле, рәхәткә авыш, кәеф-сафаны сөя, киләчәк өчен күп борчылмый, затларында зирәк, яхшы тәрбияче булганда һәрнәрсәгә сәләтле, эштә күп уйлап тормый алга атлаучы, авылларында йортлары ярлы гына, әйберләре ким, һәрнәрсәдә иң зарур булган нәрсә белән чикләнәләр. Ләкин бу хәлләре канәгатьлектән, ахирәткә бирелүдән түгел, бәлки эшкә өйрәнмәгән, гадәт итмәгән, элек җирләре һәм маллары күп булу сәбәпле, җиңеллек белән генә дөнья көткәннәр. Дөнья тарайгач та, кисәтү белән уянма-

ганнар. Башларын ватмый гына яшәргә яраталар. Бу халыкта сәүдә юк, гыйлем хезмәте дә бик аз, гыйбадәтләре дә аз, һәр фиркага күрә, боларның мәчетләре харап, намаз укучылары бик аз, имам һәм мөәзин дигәннәре дә хөрриятне сөя, гыйбадәт бавы белән бәйләнүне теләми, Аллаһ теләгәннәреннән башка. Бу көнгәчә боларны мәдәният һәм гыйбадәт юлларына алып барган, кайбер сәүдә һәм гыйлем юлларын күрсәткән [кешеләр] – Казан тирә-ягыннан килгән сәүдәгәр мөһаҗирләр. Бу сәүдәгәрләрнең Башкортстанда үзләре икътисади файда күрүләре бәрабәрендә, башкортларга гыйльми һәм дини файдалары күп булган.

2. Типтәрләр – болар Казан тарафыннан киң иркен җир эзләп, башкортларны сәяси [яктан] тоту һәм мәдәнияткә өйрәтү өчен хөкүмәтнең ярдәме белән рус мөһаҗирләре кебек күчерелгән җәмәгать. Болар тырыш, Эчке Русиядә тар дөньяда авырлык белән көн күреп, мәшәкатькә өйрәнгән, игенчелек өлкәсендә, ысулы белән булмаса да, аз җирдән күп алырга өйрәнә алган халык. Болар Пугачевның авыр вакыйгасыннан соң башкортлардан җиңеллек белән җирләр алып урнашканнар. Пугачевтан күп җафа күреп калган башкортлар боларны иптәш булырлар, үз мөселманнарыбызның файдалары тияр, дип җирләштергәннәр. Ләкин бу халык тырышлыклары, дөнья тормышына яхшы өйрәнүләре сәбәпле, башкортлар көнләшерлек дәрәҗәгә ирешкәннәр. Боларның игеннәре яхшы, сәүдәләре дә бар, авылларда йортлары төзек, әйберләре җитеш булып, иген кораллары күбесендә немец ысулынча, яңа машиналар белән җиңел асылга куелган. Үзләре намаз укучан, мәчетләре бар, мәктәп-мәдрәсәләре кирәк кадәр бар, дин һәм гыйлем өлкәсендә иганәгә өйрәнгән.

Бу Казан тарафларыннан килгән, типтәр исемен алган татарларга Казан яныннан килгән татарлар – казанлы исеме белән йөртелә торган халыклар – әхлак һәм тормыш ягыннан бик якын. Тик болар игенчелектән бигрәк сәүдәгә тартымрак, ул өлкәдә әһәмият бирүләре артыграк. Мәчет һәм мәдрәсә төзү өлкәсендә дә болар теләклерәк. Табигый, сәүдә ияләре дини һәм дөньяви эшләрдә тәҗрибәрле, акчаны җиңелрәк юнәтүчән, шунлыктан дини урыннарда болар акчаны җиңелрәк чыгаручан булалар. Күп җирләрдә гыйлем тарату мәсьәләсендә болар хезмәт итәләр.

3. Мишәрләр. Боларның Тамбов, Пенза тарафларыннан килгәннәре мишәр, Сембер тарафынан күченгәннәре Алатырь исеме белән йөрсәләр дә, һәммәсе дә мишәр җәмәгатеннән. Болар игенчелек

өлкәсендә тырыш, сәүдә өлкәсендә дә башкортлардан күп алда, динле, тугры, тырыш халык. Үзләре мәчет-мәктәпләргә мөнәсәбәтле, араларыннан имамнар һәм мөдәррисләр күп чыккан. Байтаклары өйләнү мәсьәләсендә үз җәмәгатьләре белән генә мөгамәлә иткәнлектән, телләрен һаман онытмаганнар, югалтмаганнар. Ләкин күбесендә типтәрләрдәге кебек Казан теленә якын бер тел таралган.

Әлеге халыкларның (башкорт, мишәр, типтәр) һәркайсында сабан, чәчү, уру, аеру өчен игенчелек кораллары, яңа машиналар күпчелек йортта бар. Башкортларда азрак булса да, әкренләп алга баралар. Бик күп йортларда каймак аеру машинасы бар. Вилаятьләре игенчелек вилаяте булганга, элек Земство да бу мәсьәләдә ярдәм иткән. Болар бу өлкәдә, Казан тарафына караганда, байтак иген эшен алга җибәргәннәр. Казанда җир бик кысан булганга күрә, иген игүгә артык әһәмият бирмичә, сәүдә һәм һөнәр өлкәләренә күбрәк әһәмият биргәннәр. Йорт саен булса бер сыер булганга, аеру машиналары да гомумилек кәсеп итмәгән. Уфа вилаятендә исә бер сыерлы авыл кешесе авылда бер я ике булып, Шура хөкүмәтенең дошманлыгы һәм талавыннан элек, күбесендә бер дистә ярым, дистә кадәр савым сыер булып килгән. Елкы малы да шул тирә. Тик быел (1921 елда) артык корылык булганга, бер сыердан һәм бер аттан артыкны тәрбияләп булмас, дип куркышып торалар. Авылларда да хәзердән үк – печән өстендә үк – печәннең поты совет акчасы белән сигез мең сум кадәргә ирешкән. Салам булу бөтенләй өметсез. Халыкта дини хис байтак яхшы, электән үк бу тарафларда яхшы исем белән танылган ишаннар һәм мөдәррисләр булгалаганга булса кирәк, дин өчен мөгамәлә бар. Дин әһеле, изгелек иясе дип уйлаган кешеләрне ихтирам итеп килгәннәр. Бу көннәрдә динсезләр тарафыннан дингә һәм дин әһелләренә булган һөҗүмнәр, төрле әдәпсезлекләр булгалавы дини хисләрне арттырган. Әгәр имамнар яхшы тырышлык һәм гайрәт белән халыкны көтсәләр, изгелек һәм алга китү өметле күренә. Хатын-кыз җәмәгатьләрендә нечкә күңелләренә туры килгән яхшы сүзне яхшырак тыңлау бар.

Кайбер яшьләрендә чиктән ашу, ваемсызлык ишетелсә дә, бу эш шайтаннар тәэсире белән вакытлы гына булып, өстенлек изгелек ияләре тарафында булачагы өмет ителә.

Һәр җирдә бакча җимешләре чәчү башланган. Башкортларда бәрәңге утырту яңарак башланса да, казанлы, типтәр һәм мишәр халыкларында инде кишер, суган, кәбестә, шалкан, кабак, кыяр, алма, чия, кура, карлыган утыртулар башланган. Бу мәсьәләдә һәр

авылда кызыктырып сүзләр сөйләдем. Басудан җир алып әлеге яшелчәләрне чәчкән кешеләр ишетелде. Әлбәттә, Аллаһ Тәгалә бирсә, бу кыйммәтчелектә һәм ачлыкта бу яшелчәләр эш булып, башкортларга күп гыйбрәт булачак. Араларында умартачылык та бар. Ләкин бу һөнәр һәм кәсеп башкортларда күбрәк. Аеруча тау эчендәге башкортларда, корт өчен урманнары бик уңайлы булганга, бик ысуллы булмаса да, бик яхшы икән.

## Искә алынган тарафларда гыйльми хәл

Элек гыйлем һәм дәрес эшләре бик яхшы булган. Кырык-илле ел элек Эстәрлебаш, Куганакбаш, Балыклы Күл, Кыешкы авыллары гыйльми хезмәт белән бик яхшы танылганнар. Эстәрлебашның тышкы һәм эчке дәресләре, халыкны әхлакый тәрбияләре, башкорт һәм казакъ җәмәгатьләренә яхшы тәэсирләре мактарлык, «җәзәһүмүллаһү хайран» [«Аллаһ аларга хәерле әҗер бирсен»] догасын кабат-кабат әйтерлек дәрәҗәдә булган. Шәех Нигъмәтулла бине Биктимер Салавычи белән башланып, уллары Харис һәм Харрас ишаннар вакытында, чаралары һәм күркәм идарә итүләре сәбәпле, күп алга китеп, шәкертләр алты-җиде йөз санга ирешеп, әлеге Эстәрлебаш авылы атаклы бер дәресханә төсен алган.

Искә алынган ике шәехнең вафатлары белән, биш-ун яхшы хәлфә калса да, мулла балаларыннан эш белән идарә итәрлек кодрәтле адәм булмыйча, озак кына өзеклектән соң, Хәбибулла бине шәех Харрас Бохарадан кайткач, янә үсү юлын тотып, җәмгыять яхшы булып киткән. Ләкин әлеге хәзрәтнең яхшы өлеше булса да, идарә һәм күркәм чара юлында булмаганга, гомере дә кыска булганга, нигезле рәвештә юлга куя алмыйча, аның вафатыннан соң тиздән юкка чыгу юлын тоткан. Хәзер кечерәк бер авыл я утар кадәр төзелгән мәдрәсәләр кайгылы хәлдә. «Йортларга карасаң, аларны да кешеләр кебек бәхетсез я бәхетле дип күрәсең» шигыре буенча бәхетсезлек хәлендә күренә.

Куганакбаш авылы да шулай, хәтта тышкы әсәрләре дә калмыйча, гади бер авыл булып калган. Тимербәк ахунның үзеннән соң улы Шәйхелислам бераз заман дәрес белән шөгыльләнсә дә, бары бетәргә йөз тоткан дәүләтне акрынлык белән генә бетерер кадәр тырышкан. Бераз якорь салып маташкан байбичә кебек кенә хәрәкәт итә алган. Балыклыда исә Хөснеддин ахуннан бер әсәр дә калмаган. Тау башындагы мәдрәсәләр, аларның янында шәкертләргә җиңел-

лек өчен казылган бер бассейн – һәммәсе юкка чыккан. Бары каршы тарафында соңгы имамнар өчен төзелгән бер яхшы мәктәп күренде. Хәзерге имамнары – дөрес кенә гыйлемле, мөнәсәбәтле һәм мәхәббәтле Габделкави әфәнде – сихәте яхшы заманда, динсезләр тарафыннан тыюга очрамаганда, башлангычтан югарырак дәрес белән дә шөгыльләнгәләгән икән. Кыешкыда исә бөтенләй сүнеп бетмәгән, бәлки, бу инкыйлаб бер карарга килсә, бераз хәрәкәт булса булыр, өметсез түгел.

Боларның араларында Эстәрлебаш – дәрес һәм тарикать өчен иң кулайлы һәм уңай урын. Әгәр бер тырыш, гайрәтле кеше кулына төшсә, Тукаев нәселенең «Үзебезнең мирас хакыбыз» дигән зарарлы дәгъвадан үтсәләр, яңадан яхшы эш торызырга лаек булган урын. Бөтен кешеләрнең мәхәббәте һәм күркәм карашы, юнәлеше һаман калган. Аз гына ысуллы укыту һәм тәрбия булганда, һәркем киләчәк, бик тиздән яхшы җәмгыять булачак. Күргән авылларда күбрәк имамнар Эстәрлебаш, Эстәрлетамак, Уфада укыганнар. Уфага якынрак авылларда, Кыешкыда укучылар да күп күренә. Троицки, Кышкар һәм башкаларда укыганнар да азрак бар. Бу имамнар арасында әзерлекле зирәк кешеләр дә юк түгел. Ләкин яхшы укыту һәм чын уку юлы күргәннәре бик аз. Эстәрлебаш шәкертләрендә тышкы суфилык һәм диндә нык тору рәвешендә булганнары байтак күренә. Ләкин соңгы шәкертләрендә гыйлем куәте ким, элекке шәкертләрендә бер дәрәҗәдә гыйлемгә мөнәсәбәтләре булуы сизелә. Эстәрлетамак та шул үлчәүдәрәк.

Уфадан Хәйрулла ахун Госман шәкертләре шактый уяу һәм беркадәр гыйлем юлына кергән, Казан, Мәчкәрә юлынча уку ысулыннан хәбәрдар. Гомум Уфа вилаятендә Хәйрулла ахун Госманның әсәрен һәм гыйльми нәтиҗәләрен башкаларга караганда аерым, югары санарга мөмкин. Кыешкы шәкертләре дә яхшы гына гыйлемгә мөнәсәбәт хасил итә язганнар. Куганак, Балыклы Күл, Ашказар Балыклысы нигезләре үтеп бетә язганнар, болардан әһәмият бирерлек кешегә очрамадым.

Ләкин бу тарафларда гомуми бер яхшы эш һәм күркәм холык бар. Гыйлемне ихтирам итүләре көчле, диндә нык торулары яхшы, тиешле рәвешчә яхшы гыйлем алган булмасалар да, бозык укыту һәм начар фикер катыш тәрбия белән бозылмаганнар. Бу заманда бу хәлләре – ганимәт ителерлек хәл. Әгәр арада бер гыйлем, чара иясе һәм диндар кеше чыгып тәрбия, укыту юлын ачса, зур өмет күренеп тора. Аллаһ теләгән бәндәсен күндерә.

## Кайбер дини мәрасимнәре

Бу тарафлар иң зур тәэсирне Эстәрлебаштан алганнар. Эстәрлебашта булган гадәтләрнең яхшысы да, яхшы булмаганы да гомум тирә-якка тәэсир иткән. Бу хәл – табигый диярлек бер хәл: һәр тараф халкы араларында өстенлекле, искәрмә булган кешенең тәэсиренә бирелә, теләсә, теләмәсә – аңа иярүчән була. Галимнең гыйлем дәрәҗәсе югары булган саен Аллаһтан куркуы, тәэсире арткан саен күбрәк саклануы тиешле булу да бу сәбәпле. Эстәрлеләрнең дөреслекләре хаталарыннан, яхшылыклары начарлыкларыннан күп күренә, тәрҗемәи хәлләреннән дә шулай ачыклана.

Аларның гадәтләреннән – иртәнге намаздан соң кояш чыкканчы, икенде [намазыннан] соң кояш батканчы мәчеттә утыру. Күбрәкләрендә түгәрәк рәвешле утыру бар. Күп авылларда бу хәл күренде. Яхшы гыйбадәт. Бер намаздан соң икенче намазны көтүнең өстенлеге хакында байтак хәдис шәриф бар. Ләкин бу мәсьәләгә дә шайтан катышмый калмаган. Намаз көтүне азайту, аяк авырлыгын җиңеләйтү өчен иртәнге һәм икенде намазларын чамадан тыш дәрәҗәдә артык кичектерәләр. Иртәнге намазны да сөннәт вакытыннан кичектерәләр, икенде [намазын] да мәкрүһ вакытка, хәтта хәрамга кичектерәләр. Хәер, бу гадәт зикер түгәрәге булмаган җирләрдә дә, Казан тарафларында да бар, һәр җирнең шайтаны бу өлкәдә хезмәт итә.

Югарыда язылганча, бу мәсьәләдә әйттем: «Кимендә бер чирек сәгать кадәр иртәнге һәм икенде намазларын алданрак, иртәрәк укыгыз. Бу утыруларыгызны ганимәт дип белегез дә дини кирәклекләрегезне өйрәнегез бу эш башка зикерләрдән сезнең өчен яхшырак булыр. Ваҗиб, сөннәт булган өйрәнүләрегез җитешмәгән, башка вакытта форсат таба алмыйсыз, шуңа бу вакытны дини дәресләрегез өчен сарыф итегез», – дип, имамнарга, халыкларына кисәтү ясадым.

Азаннарында тәкбирләренең [«Аллаһү әкбәр» сүзләренең] һәркайсын аерым, кушусыз әйтәләр. Күп җирләрдә дә тәкбирне икешәр-икешәр әйтү гадәт булган. Боларның бу рәвешләре «тәкбир аерым, азан аерым» [дигән] риваятьләренең тышкы мәгънәләренә туры килә, мөәзингә җавап биреп бару өчен кулайрак була. Ләкин арада кыска туктау гына җитмичә, тукталу дәрәҗәсендә аерсалар, яхшырак булыр иде.

Күбрәк мәчетнең михрабына каршы тарафта «ахшамлык» дигән бер кечкенә сәндерәләре була, ахшам азанын шунда гына

әйтәләр. Бу рәвешне кайсы уйлап чыгаргандыр? Бу эш ислам йортларында юк. Азанның югары урында укылуы, ирештерү һәм игълан итү өчен файдалырак булу хикмәтеннән сөннәт булган. Хаслау һәм искәрмә ясау китапларда күренми. Шуңа күп заманнардан бирле бу гадәтне кире кагып киләм, очраган җирләрдә кисәтәм, бу тарафлардагы төрле җирләрдә бәян итәм. Безнең ярдәм белән салынган бер яңа мәчеттә бу «ахшамлык»ны күргәч, имамы оялып: «Бу «ахшамлык»ны ясамас өчен кисәткән булсагыз да, халыкка каршы торып булмады, эшләттеләр», – дип акылсыз гозерен бәян итте. Бу гадәт Казан ягына йокмаган булса да, Эстәрле тирәсенә килеп йөргән надан суфиларда гына.

Очрашу вакытында күрешеп, йөз сыпыру – һәркайсында гадәт. Ашау вакытында булса да, кулны алып, бик каты кысып, ышкып, дога сурәтен кылалар. Бу ике мәсьәләнең асылы яхшы. Бездәге гадәт кебек күрешүне сәфәрдән килүгә хасламыйча, дин карендәше белән һәр очраганда кул алышу тиешле, бәлки сөннәт. Ләкин ашау арасында түгел, ә соңрак тиешле.

Дога исә гыйбадәт һәм аскетизм иясенең яхшы бер гадәте. Кирәгенчә кылынса, йөртелсә, бик хуп. Мөэмин мөэмингә мәхәббәт һәм шатлык белән юлыкса, Аллаһның рәхмәтенә, әҗер-савапка сәбәп булачак. Шунлыктан бу хәлдә (күрешкәндә) бер-берсе өчен чын дога кылып, хәер-дога итешсә, ганимәт булачак. Ләкин бу иярү таралып, фәкать сурәтендә (гадәткә) калып, күңел ашауга киткән, хәтта тел башка артык сүзләр белән мәшгуль, Аллаһны зикер итүдән бөтенләй гафил вакытта кул күтәреп йөз сыйпауда бер хасият тә юк. Хөрмәтле доганың сурәтен бер начар куллану, шат йөрәксез дога кылуга өйрәнү генә. Бу мәсьәлә турында кисәтүгә бераз гаҗәпләнсәләр дә, имамнары һәм акыллылары тиз аңладылар. Бу гадәт асылында дөрес, яхшы булса да, чыгырыннан чыккан, файдасыз дәрәҗәгә төшкән. Кайбер гыйбадәтләр шулай гадәт булып, рухсыз калып, гыйбадәтлегә бетеп, коры кабык булып калалар. Бу гадәт Төркестаннан [кала] башка ислам илләрендә – Төркия, Гарәбстанда – юк. Әгәр бу дога яхшы мәҗлесләрдә үтәлгән кебек тиешенчә кылынса, яхшы. Йөрәкне шатландырып дога кылыну, әлбәттә, шәригатьтә дөрес, хәерле эш.

Бу тарафта азаннан соң мөәзиннең, кайбер галимнәрнең «тәсвиб» [чакыру] дигән булып, салкын юллаулар белән, мәгънәсез аваз белән «сала» дигән тавыш чыгарулары юк. Бу да – бер яхшы гадәтләре. Казан тарафларында бу тавыш – гадәт. Кайбер җирләрдә

«тәсвиб» урынына «әс-саләһ» исеме белән эндәшү бар, Куһистани дә искә ала. Безнең надан мөәзиннәр игътибарсыз имамнар ярдәме белән шул дөрес сүзне бозык «сала» тавышына үзгәрткәннәр. Азанга башка ялгышлар да керткәннәр. Мәсәлән, «әкбәр»не «әкбар», «хәййә»не «хәййа», «галәс-саләһ»не «галәс-сала» дигән кебек.

«Тәсвиб» – төрле җирдәге гадәт буенча, азаннан соң намазның якынлашуын белдерү урынындагы игълан итү. Кайбер җирләрдә «камәт», кайбер шәһәрләрдә «әс-саләһ», кайбер урында «намазхан» дип белдерәләр, ләкин бу белдерү азаннан байтак соң булырга тиеш.

## Халыкның тормышлары

Халыктан, бигрәк тә мөселманнардан үткән кыш хөкүмәт, халыкның хәлләренә карамыйча, артыгы белән ашлыкны алган. Күпчелек җирләрендә яңа ашлыкка җитәрлек калдырмыйча, чәчү өчен орлык өлешен калдырмыйча, тапкан кадәрен себереп алганнар. Шунлыктан бичара мөселман халкы, кылыч һәм мылтыктан куркып, каршы сүз әйтергә, соңыннан шикаять итәргә кодрәтле булмаган. Бүген уннан тугыз өлеше диярлек ач, азыксыз. Орлык булмаганлыктан, чәчүдә дә өчтән бер өлшен генә чәчкәннәр. Урманда этлек үләне тамырын, ул беткәч балдырган, ат кузгалагы, имән кайрысы, юка агач кайрысы ашап, җан саклап торалар. Күбесендә сыер булганлыктан, сөт белән файдаланалар.

Күп авылларда күченү башланган. Бөтен гаиләләре белән Сибирия тарафына, Оренбург тарафына күченәләр. Күп халык бу күченү белән дә адашып йөрүдә булалар. Юлларда ачлык һәм тәрбиясезлек сәбәпле, төрле авыруларга очрап, һәлак булалар. Вабага очраучылары да күп икән. Июнь ахырларында Эстәрле, Бәләбәй, Уфа шәһәрләрендә һәм төбәкләрендә башланган һәлакәтле вабадан вафатлар бу ачлык, тормыш рәвешләрен алмаштырып, хәвефле сәфәрләрне сайлау сәбәпле туган, дип уйланыла. Рус халкында азык бар, төрле рәвешләр белән кулларында калдырганнар, шунлыктан бу авыр хәлләр аларда аз, хәтта сатар өчен арттырулары да күренә һәм ишетелә.

Кыскасы, эшнең барышына һәм керешенә каралса, мөселманнардагы бу авырлыклар – хөкүмәтнең махсус эшләнгән эше, диелмәсә дә, чарасындагы зур хатасыннан туган. Хөкүмәт хөкүмәт була белгәндә, халыкның тормышын кайгыртырга тиеш, шуңа туры

килерлек чаралар күрергә кирәк иде. Кече әгъзаларының сөйләүләренә күрә, Шура хөкүмәте тик коммунистлар файдасы өчен», дигән мәгънәнең, Аллаһ белер, ачык хәрәкәтләренә күрә, дөрес булуы да мөмкин. Шулай итеп, хәзерге рәвештә Уфа якларында мөселманнар, аеруча башкортлар кырыла, йогышлы авырулар, ачлык, ялангачлык белән һәлак булалар.

Әлеге тарафларда урман булмаганга яки бик аз булганга, тирес кирпеч белән җылыналар. Һәр йортта моны эшләп торалар. Бу эш элеккедән бер гадәт булган. Элек мал-туар күп булганга, бу нәрсә дә мул ясалган. Бу елларда мал азайган, тирес тә азайган. Шунлыктан бу кирпечләргә дә кысанлык килгән. Бу тирес кирпече, тирес ягу Төркестан халкында да бар. Бохара тирә-ягында юллардагы ат, сыер тизәген балалар капчык белән җыештыралар. Ат кумалакы, дөянеке кебекләре самовар кайнатырга яраклы, сыер тизәге кебекләре шул хәленчә киптереп (үзе юлда кипкән була) аш һәм башка нәрсә пешерүдә кулланыла. Бездә моңарчы күп иркенлек булып килгәнгә, мондый экономияләүгә халык өйрәнмәгән, күп өлкәдә исрафка өйрәнеп килгәннәр. Утын исрафы да чиксез булып килде. Инде утынның колачы 80 мең сумга җиткәч, һәр җирдә хатыннарда, хезмәтчеләрдә, башкаларда бераз экономияләү була башлады.

Июньдә артык эсселек булды. Авылда вакытта кояшта 47 дәрәҗәгә [градуска] ирешкәнен сөйләделәр. Мәмләкәтебездә ишетелмәгән эсселек. Төркестанда була торган дәрәҗә. Шул эсселек яңгырсызлыкка дучар булган ашлыкны көйдерде. Арышларны, хәтта язгы ашлыкларны киптерде, көйдерде. Аллаһ ахырында рәхмәтен салсын!

### Шәйхулла Алкин вафаты

9 июльдә Милли идарәдә финанс бүлегендә рәис булып хезмәт иткән Шәйхулла бине Сибгатулла бине Габди Алкинның үлгән хәбәре иреште. Бичара дөнья тормышыннан, төрле хәвефләр арасында яшәүдән туеп, яшь көнендә үлемне үзе ихтыяр иткән икән.

Яшь чакта, атасы белән бабасы дусларыбыздан булу мөнәсәбәте белән, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә тапшырылып, башлангычны 9 яшендә тәмамлап, сәүдә мәктәбендә дәвам итеп, Мәскәүдә абруй белән сәүдә мәктәбенең югары бүлеген тәмамларга якын булганда, безнең Милли мохтарият туып, яшьлек омтылышы белән Казанда аңа әгъза [булып] сайланып, соңра беренче Милләт мәҗле-

сендә Уфада (кеше юк җирдә) торгызылып, финанс бүлегенә рәис итеп сайланган иде. Бу җитәкчелектә яңа туган сәясәттә төрле рәвештә хезмәт итеп, яшьлек, балалык катыш булып, финанс бүлек белән идарә итте. Теоретик икътисад дәресләрен яхшы укыган булса да, гамәлияте һәм практикасы яңа гамәлгә кергән хәлдә булганлыктан, чын финанс министр булган кебек, зур хәрәкәтләрдә дә булгалап, 1918 елның апрелендә Шура хөкүмәте тарафыннан Милли идарә бетерелгәч, әлеге хөкүмәт тарафыннан финанс эшләр хисабында шөбһә астында калып, кулга алынып, үзем һәм Милли идарә рәисе Садри әфәнде Максуди һәм башкалар Мәскәүдә вакытыбызда хәбәр алып, Мулланур Вахидигә вәкил җибәреп сорагач, азат ителгән иде.

Шура хөкүмәте Уфадан чигенгән вакытта, Милли идарә янә хәрәкәткә килеп, минем Казакъстан эше белән Сибириядә [булган] вакытымда Мәгариф әгъзасы белән Финанс әгъзалары да Петропавелга урнашканнар иде. Анда халык тарафыннан яхшы каршы алу һәм күркәм кабул [итү] күрмәсәләр дә, кайбер хәрәкәттә булып, Дини нәзарәте әгъзаларыннан Салихҗан Урманов, Хөҗҗәт казый Мәхмүдовны үзләренә кушып, Милли идарә исеменнән – урынында аңлатылып язылганча – бераз эш күреп, кызылларның Уфадан чыгу мөнәсәбәте белән, кайту теләгенә кереп, аларның янә Уфага һөҗүмнәре башланса да, Сибириядә алган малларын Уфада сатарга тиеш булып, аз заманга гына кайтып, берәр атна эчендә эшләрен бетереп, гомуми качышта янә Сибириягә киткәннәр иде. Бичара шәех Томскида кызыллар кулына яңадан төшеп, байтак төрмәдә калып, бер мөнәсәбәт белән котылып, янә зур курку эчендә исем һәм кыяфәтен үзгәртеп, бер ел яшәгән. Ләкин авыр хәлдә яшәгән иде. Кулга төшсә, үлемгә хөкем ителәчәге уйлана иде. Бичара бәхетсез бала. Шулай, чыннан да, хөкем ителеп дөньядан киткән булса, хөрмәт белән югалачак икән. Соңра баш миенә зарар килгән булса кирәк. Каннарында да баш мие үзгәрүенә әзерлек бар иде. Атасы Сибгатулла хаҗи да хыял авыруына дучар булып, озын авыру белән дөньядан кайткан иде. Тәрҗемәи хәле сөйләнүченең дә, әлбәттә, мие зарарлангандыр. Егерме яшьләрендә Оренбурда асылынып, үзенә кул салган. Аяныч, әзерлекле, өметле егет иде. Милли идарәгә кергәнче, һәркем тарафыннан сөелеп килгән, гыйффәтле, әдәпле телле, оратор, холыклы, аңлы бала иде. Аллаһ аны кичерсен.

## Зариф хәзрәт Әмирхан

Сәфәрдән килүемә Казаннан килгән хатлар Казандагы Яңа бистәдәге имам Әбелфатих Зариф бине Хөсәен бине Әмирхан җәнапләренең вафат хәбәрен китерде. Аллаһ аны кичерсен, рәхмәтенә алсын. Мәрхүм 1852 елда дөньяга килеп, башлангыч белемен атасы мәктәбендә тәмамлап, соңра урта белемнең бер өлешен безнең белән бергә шәех Сәлахеддин остаз мәдрәсәсендә укып, соңра Курсадан шәех Хәсән бине Халид, Норлаттан шәех Фәхреддин бине Мостай Курра мәдрәсәләрендә булып, мактаулы Коръәнне ятлаган. Норлатта Коръән укыту рөхсәтен алган иде. Яшь вакытларында да мулла Сәлахеддин бине Сәгыйдьтән, имам булгач шәех Шиһабеддин Мәрҗани әңгәмәләреннән файдаланган иде. Рәсми дәресләрне бетермәсә дә, бер дәрәҗәдә гарәпчә аңлауны өйрәнеп, 1884 елда атасы янына имам булган иде. 47 ел имам булганнан соң, быел 1921 елның 24 июнендә (1339 елның 19 шәүвәлендә), эче китеп, ваба белән дөньядан кайтты.

Үзе зирәк, аңлы, акыллы, алдан күрүчән, сәламәт йөрәкле, үч итү һәм хөсетлектән пакь, мәхәллә халкы өчен хәерхаһлы, яшь һәм картларын тәрбия итү өлкәсендә тырыш, хуш авазлы, Коръәнне дөрес уку иясе булып, гади халыкны да бу өлкәдә байтак төзәткән иде. Уллары мәшһүр мөхәррир Фатихны һәм Ибраһимны яхшы укытты. Фатихны «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаганчыга кадәр [тәрбияләде], Ибраһимны югары белемнең күпчелек дәресләрен тәмамлаганчыга кадәр укытып, Ибраһимны Бәйрутта, Америка көллиятендә дә ике-өч ел тәрбияләде. Үз өендә низамлы башлангыч, урта белемле кызлар мәктәбен дәвам иттерде. Бу мәктәптә үзе дә хатыны Рабига бинте Зиннәтулла бине Габдуллага булышты.

Тәрҗемәи хәле сөйләнүче, зур гыйлем иясе булмаса да, туры юлда булучы галим иде. Гыйлем, изгелек ияләреннән файда алуда, милләтнең дини, гыйльми, икътисади файдаларында тырышлык һәм туры фикер белән хәрәкәт итә иде. Соңгы елларда гыйбадәтен арттырган, җәмәгать намазларын калдырмый, Коръән укуда дәвамлы, сынык күңелле, яшьле күзле, юмарт, хөрмәтле нәфесле, сагынырлык кеше иде. Бу затның дөньядан күчүе шәхси минем өчен дә үкенечле булды. Минем бер чын ышанычлы дустым, күп эшемдә таянычлы киңәшчем, илле биш еллык белешем, якынча кырык еллык хәерлек теләүчем иде, югалды. Гомумән, Казанның ирләр кытлыгы заманында күркәмнәрдән санала, беренче дәрәҗәдә

күзгә күренә торган бер имамы дөньядан китте. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә иманын юлдашы, изге гамәлләрен иптәше итсә иде. Җәннәттә барчабызны мәңге юлдаш итсә иде. Әмин.

* * *

Уфа, Эстәрле шәһәрләрендә һәм төбәкләрендә хасталык куәтләнеп тора. Ваба бизгәге каты. Эстәрледә йөзәр һәм артыграк кешенең вафат булуы сөйләнелә. Уфада да кырык-илле кадәр беленә. Күбрәге ачлыктан, күчү юлындагы кешеләр. Җирле йортлы кешеләрдән дә бар. Таланган, ач калган башкортлар һәм башкалар арасында вафат булучы күбрәк икән. Казанда да бу хасталык бара икән. Сибириягә таралудан куркалар. Йөрергә рөхсәт беткән. Спекулянтлар рәсми булмаган юллар белән йөреп торалар. Вабаның таралуы ихтимал. Саклану, дәвалану әсбабы юк. табиб җитешми, дәва юк. Кайбер халык арасында вабага прививка кадау белән вабага каршы тору бар, табиблар файдасын өмет итәләр.

**Юлы һәм тәэсире.** Ваба микробын үтереп, аркадан канга катыштыралар. Бәдәндә куәтсез генә ясалма ваба авыруы хасил була. Микроб үлгән булганга, үрчеми, артык зур тәэсир итә алмый. Ләкин бәдәндә әсәре калып, ваба микробына ияләшкәнгә, яңа сау ваба микробына җиңелмәслек бер рәвеш хасил була икән. Бер мәртәбә кызамык, чәчәк, тиф белән авырганнан соң, икенче мәртәбә булмавы да бу хикмәттән икән. Ләкин кайбер маддәләрдә, мондый прививка сәбәпле, куәтле вабага дучар булып, чыдый алмаган, дөньядан күчкән кешеләр була икән. Эстәрлетамакта төзелгән мөфтияттә казый Вәлиҗан әфәнде бу прививка белән хасил булган ясалма вабадан вафат булган икән. Әлбәттә, мондый дәвалар өчен йөрәкнең сәламәтлеге һәм куәте шарт. Караган-тикшергән табибның хаталануы мөмкин.

Уфада табибым Хөсәен бине Хәмзә Максуди миңа бу мәсьәләне (прививканы) тәкъдим итсә дә, кабул итмәдем. Мондый хасталыкларга шикле уй, котырту белән карамыймын, йөрәк куәте һәм иман белән карыйм. Ашауга һәм чисталыкка әһәмият бирәм. Аллаһтан саулык сорыйм. «Вә изә әрадтә би-гыйбәдикә фитнәтән фәкъбидни иләйкә гайра мәфтүн» [«Колларыңа дин һәм дөнья сынавын җибәрергә теләсәң, мине Үзеңә сынау ирешкәнче ал»] дигән сөннәттә килгән доганы да укыйм. Эче китеп, вафат булучының шәһит булуы «Сөнән Әби Дауд»та риваять ителгән. Иманлы мөэмин үлемне бетү, тәмам юкка чыгу дип белми, бәлки бары киңрәк тормышка, мәңгелек яшәүгә күчү дип белә. Хәвеф һәм курку

зур булса да, иманы булу сәбәпле, Иң мәрхәмәтле зат булган Раббысына таянганлыктан, зур өмет белән үлемне көтә. Шунлыктан мондый гомуми авырулар таралганда, артык куркуга, котыртуга һәм шикле уйга бирелү тиешле түгел.

Бары шәригатьтә дөрес булган кадәр белән саулык-сәламәтлек сәбәбен сакларга тиешле. Моның артыгын Аллаһка тапшырырга тиеш. [Аллаһ] Үз милке белән теләсә ничек идарә итә. 1339 елның 11 зөлкагъдәсе, шимбә.

**ГубЧКның финанс идарәсенә катышу**

Уфа финанс идарәсеннән безнең Дини идарәгә янә уңайсызлык:

Быел мартта Уфа ГубЧКның яшерен бүлеге: «Һәр җирдән килгән һәм киткән акчагыз финотдел аркылы йөрсен, анда акчалар туктатылмыйча, үз теләгегез буенча йөртелер», – дигән иде. Китешләреннән безнең бары керем-чыгымда сәяси уңайсыз хәрәкәт юклыгын аңларга теләүләре аңлашылган иде. Аларның теләкләре буенча мөхтәсибләргә игълан да иттек. Язуга карап гамәл кылучылар шулай банк аркылы җибәргәннәр. Инде банктан сорасак: «Безнең акчабызны бирми, үзәк ЧКдан бирмәү өчен махсус кәгазь килде», – диләр. «Байтак акчагыз бар, шулай да, үзәктән аерым икенче гамәлдән чыгаручы әмер килмичә, бирә алмыйбыз», – диләр. Кара боларның хәрәкәтләренә: халык хөкүмәте исемен күтәреп, нинди мөгамәлә кылалар. Әлбәттә, бу турыда Мәркәзгә мөрәҗәгать итәрбез. Мәхкәмәнең дәвам итүенә рөхсәт биргән хөкүмәт халыктан үз теләге белән җибәрелгән иганәне туктатмаска тиеш. Иншалла, соңра рөхсәт бирерләр. Бу мәсьәләдә үзләренә, ГУБисполкомга мөрәҗәгать ителсә дә, колак салмадылар, соңра Мәркәзгә язарга карар бирелде.

* * *

Уфада башка җирләрдәге кебек кыйммәтчелек, кытлык һәм кыйбатлык хөкем сөрә. Бер атнадан бирле башланган яңгырлар азмаз икмәк бәясен сындырса да, арыш оны һаман ике йөз мең сум тирәсендә. Печән поты ун мең, йөге йөз егерме мең, яхшырак йөк йөз илле мең сум тирәсендә. Бу арада бер буяусыз тимер чиләк алынды – тугыз мең сум. Бу арада халыкта акча азайганлыктан, алыш-биреш азайган, әйбер бәясе төшкән, диләр. Ләкин бәя шулай. Аллаһ ахырын хәерле итсен. Ваба авырулары дәвам итә.

## Янә Троицки вакыйгасы

17 июльдә Троицкидан Фәхреддин Балтагулов исемле бер аксакаллы 5 нче мәхәллә мәчете эшләрен башкаручы, шәһәрнең җиде мәхәлләсеннән 1596 кадәр ир, 1940 кадәр хатын-кызлардан имзаланган һәм тупланган приговор тәкъдим итте. Үткәндә язылганча, Троицкиның 3 нче мәхәлләсендә имам Зыятдин Рахманколый, хатыннарны җомга намазына җыйганлыктан, төрле сүзләр, тиешле-тиешсез хәрәкәтләр туган иде. Каршы һәм яраклы булу тарафыннан килгән вәкилләрнең Диния нәзарәтеннән алып киткән фәтваләрне, хатын-кыз вәкилләр бераз бетереп һәм кыскартып: «Нәзарәт хокукыбызны раслады. Җәмәгать намазына йөрергә ярдәм итте», – дип янә кузгалганлыктан, халкы тарафыннан артыграк хәрәкәт булып, соңра бөтен шәһәр халкыннан мәсьәләдә урталыкта булуны, өммәт фәкыйһләренең карарлары рәвешле ачыграк фәтва сорап, приговор туплаганнар. Ахун хаҗи Әхмәд Рахманколый һәм бертуганының улы – вакыйга иясе Зыя Рахманколыйдан [кала] башка имамнарның барысы да кушылганнар.

Вакыйганың башында ук мәхәллә мөхтәсибенә мөрәҗәгать иткәч, фәкыйһләр һәм хәдис белгечләре бәян иткәнчәә язган фәтвасенә, аның фәтвасен дөрес һәм шәригать, Сөннәткә яраклы күреп, минем раславым язылган иде. Диния нәзарәтенә мөрәҗәгать итүләрендә шул фәтва имза ителгән булса, каршылык бетеп, җәнҗал сүнеп, фетнә басылуы өметле иде. Ләкин иптәшләребездән Ризаэтдин Фәхри бу фәтвадән риза булмыйча, тулысынча мөмкинлек бирү ягын алып, хәдистәге «[Мәчеткә] бизәнмичә чыксыннар, йортлары алар өчен хәерлерәк» дигән чикләүләрен искә алмауны тиешле күреп, Нәзарәттә бер дәрәҗәдә дулкынлану булып, соңра югарыда язылган «Җәмәгать намазына чыгулары дөрес» дигән җөмләсенә югарыдагы чикләүләрне кушып язылган иде. Бу рәвешле язу, үзара каршылыкны инкяр итүгә якынаю һәм бер дәрәҗәдә бераллалык сурәтенә кертү максаты белән булган иде. Ләкин хатын-кыз вәкилләр фәкать беренче җөмләне халыкка игълан итеп, мөхтәсиб аркылы имамнарга боерылган җентекләп аңлатуларны халыкка игълан итү, дип тәмам аңлашылып җитмәгәнгә күрә, халыкның шикләнүләре фетнәгә сәбәп булып, Нәзарәткә үпкәләбрәк, бу гомуми приговорларында көчлерәк сүзләр язганнар.

Хатыннарның гаризаларында, җәмәгать намазы дип тавыш чыгарган, Уфага вәкаләт белән килеп йөргән хатыннар турында, намаз

укымыйлар, тәһарәт һәм чисталыкта игътибар итмиләр, кебек кабәхәт сүзләрне дә кушканнар. Низаг һәм дәгъва кузгалгач, тыштагы кузгатучы һәм кайбер бозыклыкларны уятучы белән һәртөрле төркем катышып китә. Үз сүзен өстен итү теләге һәр кешедә яшерелгән, фиргавенлек холкыннан бер әсәр. Бик олы дини тәрбия һәм уку кадере белән генә бу холыкны пәрдә астында яшереп асрый ала.

19 июльдә боларның приговорлары каралды. Кабат фәтва язып игълан итү тиешле күрелмәде: «Мөфтинең элек биргән фәтвасе белән Дини́я нәзарәте фәтвасе арасында мәгънә ягыннан аерма юк, шунлыктан мөфти тарафыннан бары [тик] һәр мәхәлләгә аерым вәгазь җибәрелер», – дип карар бирелде. Минем тарафымнан бу нөсхә вәгазь сурәтендә һәркайсы мәхәлләгә игълан итү өчен мөхтәсиб Рәсүли әфәндегә күндерелде.

## Троицки Мөхәммәд хәлфә

Троицкиның 5 нче мәхәлләдә Габдрахман мәхдүм Рәсүли кыска фикер белән генә үз янына хәлфәләреннән Мөхәммәд бине Мөхәммәдҗан Кәнҗәне имам иткән иде. Ике ел эчендә араларында һәм мәхәллә халкы белән Мөхәммәд хәлфә арасында салкынлык хасил булып, мәхәллә халкы бердәм рәвештә искә алынган затның хезмәттән алынуын таләп итәләр. Халык сөймәве гозере белән шәригатьтә дөрес булган сәбәптән башка Диния нәзарәтендә хезмәттән алу нормасы юк. Шунлыктан ике тараф өчен дә хәерле булыр, дип, югарыда искә алынган затка бу хатны яздым:

«Мулла Мөхәммәд хәлфә (сәламнәрдән соң)! Ике арабызда борчылусыз күп заманнан бирле дустанә мөнәсәбәт дәвам итеп килә. Бу соңгы көннәрдә, ни сәбәпледер, шәхесегезгә карата барлыкка килгән хәрәкәт миңа теләмәгән тәэсир бирде. Әлбәттә, үзегезгә бигрәк тәэсир иткәндер. Мәхкәмәи шәргыя сезнең намусыгызны таптарга теләми. Хәзер эш чираты сезнең эштән алынуыгызга ахыргы чик булып тора. Минем хәерлек теләгән карашымча, халыкның хәрәкәтенә чыдамыйча, намусыгызны саклап, үзегез бу халыкка: «Хезмәт итмим», – дип хезмәттән азат итүләрен сорасагыз, намусыгыз һәм киләчәгегез өчен яхшырак булыр иде. 21 июль (зөлкагдә)».

* * *

20 июльдә Кабак авылыннан печәнче башкорт Гыймадетдин бине Мөхәммәдтән бер кибән печән алдым. 1200000 сумга ун арба-

га төяп китерделәр. Китерү өчен һәр арбага 35000 сум бирелде. Ара 20 чакрым булыр-булмас дәрәҗәдәдер. Һәр йөге 15 пот кадәр бар. Үзләре: «18 пот», – диделәр. Димәк, һәр йөге 150000 сум булды. Печәне яхшы, кәҗәгә дә яраклы. Аллаһ бәрәкәт бирсен.

* * *

Мәркәздә белемлекне раслау, сәүдә хөррияте, хезмәт хөррияте маддәләре буенча фикер алышынып, мәҗбүри исбат ителгән хәбәре коммунистлар тарафыннан ишетелеп тора. Кайберләре өчъеллык хезмәт һәм михнәтебез әрәм булды, Карл Маркс нигезе җимерелде, дип кайгыралар икән. Аллаһ Тәгалә тиз көннән хаклыкны хаклык, ялганны ялган итеп, галәмне низамга һәм хәрәкәт юлына куйса иде. Бу кадәрле күрелгән һәм татылган михнәтләрне бөтен халыкка гыйбрәт итсә иде, гөнаһлар һәм хаталанулар җәзасы итмәсә иде. Гөнаһлар һәм хаталануларның күплегенә күрә, җәзаның да иге-чиге тиз булмавы ихтимал. Аллаһ сакласын.

Вабаның таралуы һәм тәэсире һәр җирдә ишетелә. Казанда зур фаҗигале тәэсире булган Зариф Әмирхан хәзрәтләренең вафаты язылган иде. Бүген 27 июльдә мосафирлар Казанда мулла Шакир бине Габделҗаббар Күләйнең (Колыйның)[44], Чистай имамы мулла Нәҗип бине дамелла Хөсәен Әмирханның, Казанның 17 нче мәхәлләсе зират мәчетендә имам Сафаның вафат булу хәбәрләрен ирештерделәр. Һәркайсы ваба авыруы белән күчкәннәр. Мулла Нәҗип, агасы мулла Зариф вафатыннан соң, туганнарын юату өчен Чистайдан Казанга килгән. Эшен бетергәннән соң, кайтыр өчен пристаньгә төшкәч, хасталыгы беленеп, янә Яңа бистәгә кайтып, хасталанып, туган йортында вафат булган.

## Казаннан Шакир хәзрәт

Мулла Шакир бине Габделҗаббар бине Габдрахман Буавиның тумышы Буа шәһәрендә. Башлангыч белемне һәм гарәп теленең төп нигезләрен дамелла Габденнасыйр бине Әмин мәдрәсәсендә, соңра бераз Казанда 4 нче мәхәллә мәдрәсәсендә дамелла Гыяс бине Хәбиб янында, соңра Бохарада казый дамелла Габдешшәкүр, дамелла Габдулла мөфти Саратави янында рәсми укуларда булып, [һиҗри] 1297 елда Казанга кайтып, атасы мәрхүмнең дәлилләве белән 3 нче Борнаев мәчете мәхәлләсенә имам булган иде. 42 елдан

[44] Шакир хәзрәт 1339 елда (1921 елның 5 июлендә) 73 яшендә вафат.

артыграк имам булып, дөньяда 73 ел торганнан соң, асыл ватанына кайтты. Бохарада дәресханә дәресләрендә иптәш булдык. Өйрәнүе бар иде, дәресләрен бер дәрәҗәдә аңлап укыды. Зирәклеге зәгыйфь булса да, тырышлыгы, диндә нык торуы белән өйрәнү куәте хасил итте. Бәян итүе һәм аңлатып сөйләве ким, каләм куәте яхшырак иде. Төркичә язган кайбер җыентыклары бар. Әбел-Фарук исеме белән нәшер иткәләде. Матур язуы бар, аз-маз шагыйрьлеге яки шигырь төзүе дә юк түгел иде. Динле, сәламәт йөрәкле, гади кеше иде. Норлати дамелла Фәхретдин бине Мостай янында, яшьлек вакытларында Коръәнне дөрес укуын бер дәрәҗәдә яхшырткан, халык тыңларлык яхшы үтәве һәм тавышы бар иде. Элекке хатыны – остазы Габденнасыйр Буави кызы. Элекке уллары Фарук, Габделхаликъ, Заһид шул хатыныннан. Янә ике мәртәбә өйләнеп, соңгы 10–15 елда ике хатыны һәм күп балалары белән кайгыга дучар булып, авырлык белән яшәде. Идарәсе ким, гаиләсе эчендә алып баруы җитәрлек түгел, бер хатынны да тотарлык хәлдән буш икән, ике хатын белән үз өстенә күп авырлыклар йөкләп, көн кичерде. Олы улы Фарук «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә, Буада, «Рәсүлия» [мәдрәсәсендә], соңра Бохарада гыйлем алу юлында булып, үз янына имам иткән иде. Габделхаликъ исемле улы Казанда Суконный мәхәлләсендә (19 нчы мәхәлләдә) мөгаллим һәм мөәзин булып тора. Заһиде вафат булды. Яшь балаларының санын үзе белсә белгәндер.

Быел язында язган соңгы хатында бик моңаеп, сынык күңелле булып каләм йөрткән иде. Каты күңеленнән, күзеннән яшь чыкмавыннан шикаять итеп, хәзер икмәкләре шөбһәле булганлыктан булса кирәк «Ашамасаң, карын ач, җитәрлек керемнәр юк, Аллаһ янына ничек барырбыз, хәер-догада була күр» дигән кебек эчтәлектә язган иде. Бик сагынып бер хат язуны сораса да, тиз яза алмыйча, соңгы хак бәйләнешен үти алмадым. Соңгы хатының үз нөсхәсеннән бу җирдә язам:

«Аллаһ исеме белән. Үзеннән соң искә алырлык берни дә эшләмәгән тыңлаусыз, надан, гафил кол Мөхәммәдшакирдән.

Бөтен халыкка чыганак булган мөселманнарның мөфтие иптәшҗан хәзрәтләренә сәламнәребезне тапшырдык, Аллаһ аны озын гомер, сәламәтлек, саулык белән ризыкландырсын, бөтен начарлыктан, төрле бәладән сакласын. Тарафыбыз исә, Аллаһка мактау булсын, сәламәтлектә. Ләкин хәлләребез исә гаять тарлыкта һәм кысанлыкта. Чөнки хәзерге заманда арыш онының поты исә 70 тәңкә, [...].

Акыллы балам Заһид бичара вафат булды, Фарук һәм Габделхаликъ сәламәт. Фарук исә ике айлап авырды, хәзер сәламәтләнеп килә. Габделхаликъның тормыш иптәше вафат булды...

Әй, мөфти хәзрәт, безне дә хәтерегезгә китер, онытма. Үткән заманыгыз белән танышлыгыбыз бар иде. Безне оныттыгыз. Вакыт тапсаң, хатыгыз белән шатландыр һ.б. Зур хөрмәтле казый Ризаэтдин әфәндебездән сәлам әйтегез, сораганнарга да, ләкин булсас, кем сорасын безне?! Кичке сәгать 11 дә йоклый-йоклый төгәллибез... Моны язды Аллаһның зәгыйфь колы Әбел-Фарук 1921 елның 27 мартында».

Бохарада вакытта дамелла Йосыф Кондызи исемле бер билгесез шәехтән тарикать алган иде, Чистайдан шәех Закиргә дә мәхәббәт белән дуслык тотты. Ахырдан, Троицкидан шәех Зәйнулла хәзрәтләренә очрады. Хәрәкәте, нияте, үзенчә, буш түгел иде, зикере һәм фикере бар иде.

Мәчете Казанда өченче мәчет буларак 2 нче мәхәллә мәдрәсәсенең җирендә шәкертләр өчен ачылса да, дамелла Исхак бине Сәгыйдь мәдрәсәне үз йортыннан бер өлешен багышлап, күл ярына күчергәннән соң, бу соңгы елларгача ул мәхәллә мәдрәсәсез һәм мәктәпсез булып яшәде. Исхак бине Габделмәҗид Арслан васыяте белән бер мәдрәсә торгызсалар да, тар даирәдә фанатик, аңсыз байгуралар күзәтүе астында кайбер башлангыч сабаклар үтәлеп, яшь мулла Фарук белән мөәзиннәре Габдулла бине Мөхәммәдгали (Мәмдәли) укытуларыннан югарыга ихтыяҗ булмады.

## Нәҗип хәзрәт Әмирхан

Мулла Нәҗиб бине Хөсәен бине Әмирхан [һиҗри] 1277 елларда туып, башлангыч һәм урта белем укуын атасы мәдрәсәсендә үткәреп, соңра укуын Кышкари остаз дамелла Исмәгыйль бине Муса бине Габдулла Үтәмишев янында дәвам итте. [Һиҗри] 1300 елларда Казанга атасы җиренә – Яңа бистәнең 6 нчы мәхәлләсенә – имам һәм мөдәррис булып, ике ел үткәч, 1309 елда Чистай шәех Закир бине Габделваһһап хәзрәтләре, үзенә кияү итеп, җиренә имам һәм мөдәррис итеп күчерде. Бу көнгәчә утыз ел кадәр Чистайда дин, укыту, гыйлем хезмәте белән мәшгуль булып, быел 1339 елның 8 зөлкагъдәсендә, туганы вафатыннан соң ике атнадан, туганы балаларын юату максаты белән Казанга килүендә ваба белән хастала-

нып, 64 яшендә вафат булды. Бу кеше[45] галим, хөрмәтле, ихласлы, гамәлле, диндар, туры сүзле, һәр эшендә хаклык тарафлы, фикерендә нык, кеше битәрләвеннән тәэсирләнми, фикере ирешкән кадәр хаклыктан аерылмый, белгәнен тикшереп, эзләнеп белүче, мисалы сирәк, газиз, имам, Аллаһтан куркучы, нәкышбәнди мәсләгендәге суфый иде. Олы абыйсы Зариф әфәнде кебек минем хакта алдаудан һәм ялганлаудан азат, дус һәм яр иде. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Кышкар тармагы Курсави һәм Мәрҗани юнәлешләренә бөтенләй башка, дәрес гыйлемнәреннән башка фәннәргә каршы икән. Бу зат бөтенләй Мәрҗаниләр кебек Коръән һәм хәдис яратучы, чын гарәп һәм дин фәннәренә тарафдар иде. Бу фикере минем белән дустанә, хәтта мәхәббәт һәм ихлас белән яшәүгә сәбәп булган иде.

Кыскасы, бу кешенең ахирәткә күчүе – калган мөселманнар өчен зур кайгы. Ишетелүенә күрә, хасталыгына һич кайгырмаган, сабырлык белән каршылаган, хәтта шатланып, авырып вафат булган. Тормыш юлы һәм хәлләренә караудa, шундый яхшы хәлен һәм күркәм гомер ахырын өметләндерә иде. Аллаһ аны ярлыкасын һәм үз рәхмәтенә алсын. Биш улы, ике кызы һәм хатыны калды. Аллаһ аларга күркәм тормыш һәм яхшы тәрбия насыйп итсә иде.

Мулла Нәҗиб мәрхүмнең кыскача фикерләре: милләт дөрес укытуга мохтаҗ, мәктәпләрне яхшырту зарур, Коръән һәм хәдис гыйлемнәренә әһәмият биреп уку тиешле. Хәтта әхлак китапларын укытудан канәгатьләнү хасил булырлык булсын. Дин гыйлемнәре мәдрәсәсенә тиешле һәм яхшы булса да, фәннәрне катыштырмыйча, һәр ике төр дәресләрнең дәресханәләре һәм мөдәррисләре аерым булырга тиеш.

Мәдрәсәләрнең тәрбияләре, гамәли әхлак өйрәтүләре ким, алда да өметле түгел, шунлыктан гаиләләрне төзәтү тиешле. Моның өчен мәчет дәресләре, михраб һәм минбәр вәгазьләре бик әһәмиятле һәм җитди булырга тиеш. Гаиләне төзәтү белән генә балалар төзәлеп, милләтнең төзәлү юлы ачылыр. Бозык гаилә эчендә үсә торган балага, мәктәп никадәр хезмәт итсә дә, яхшы тәсире өметле түгел. Гыйлем – күп белү белән түгел, гамәл белән һәм эшкә яраў белән. Һөнәр һәм өстенлек тә – фәкать бу эшкә алып барган һәм аңа янәшә булган бәрәкәтле гыйлем, базар малы булган күп мәгълүмат түгел.

[45] Нәҗиб хәзрәт 1339 елның 10 зөлкагъдәсендә (1921 елның 12 июлендә вафат булды).

Русия хөкүмәтенең сәясәтенә кызгылт күз белән карар, ныклык белән халыкны дини һәм милли файдалар өчен туры өндәр иде. Элек икенче Дума алдында Чистай төрмәсендә озак вакыт утырып үткәрде. Сайлау тәмамлангач кына азат ителде. Соңгы инкыйлабларда да хөкүмәтнең куркытуларына дучар булып, Чистайны алганда шәһәрдән чыгып торуны сайлады. 1919 елда соңгы алуларында чыгып, Уфага кадәр килгән иде. Рамазанда ирешеп, Уфадан үткәрмәдек, үзе дә сабырлык тиешлерәк дип, өебездә яшәп, Уфаны басып алгач, минем өчен бик куркыныч көн һәм сәгатьләрне бергә үткәрдек. Авыр көннәребездә безгә яхшы юлдаш булган иде. Кызыллар урнашып җиткәч, йөрүчеләр белән арбада Чистайга кайтып, аз-маз гына җавап алулардан соң, яшьләр тарафыннан якланып, тынычлыкта калды.

Дамелла Нәҗип дини һәм гарәп теле гыйлемнәренә бирелгән, артык акыл белемнәреннән ерак булса да, элек укыган шул белемнәргә (аеруча Мирза Һәдһәрәви һәм казый Күфамуи әсәрләренә сарыф иткән гомерләре өчен үкенми иде: «Тикшерү сәләтен, бераллалыкны исбат итүне арттыра», – дип әйтә иде.

Ул үзе йомшак, дәрәҗәле иде. Хакны ачу, ялганны җимерү эшендә чигенмәс булганга, кайбер кыска уйлы кешеләр тарафыннан кызулык һәм холыксызлык белән гаепләнә иде. Аллаһ дөреслекне белүчерәк. Аз сүзле булса да, вәгазь сөйләве һәм нотыгы бик тәэсирле иде, чынлап ышанып, төп йөрәгеннән һәм камил иманыннан туган сүзләрне китерүчән булганга күрә, нотыклары үзенең ишетүчеләренең күз яшьләрен кузгата иде. Чистайларда Исхак Килдешев: «Безнең дамелланың нотыгына һәм хөтбәсенә, Европада булса, бик бөек бәя куярлар иде», – ди.

Түбәнчелекле иде. Гыйлем һәм хак мәсьәләсендә ияләренә артык түбәнчелек белән мөгамәлә кыла иде. Бөтен галимнәр, бигрәк тә күпчелек кышкарилар кебек үзен гыйлемнән тук [дип] уйлап, камиллек көтмәү хыялында түгел иде. Һәркемнән файда ала, һич авырысынмас иде. Егерме еллар элек Троицкида шәех Зәйнулла хәзрәт янында очрашкач, тоташу чылбырын алу өчен, минем фикерләремә карамастан, балалар кебек алдымда тезләнеп, камил әдәп белән «Сахих Бохари»дан кайбер хәдисләрне укыган иде. Чистай кызыллар кулында булган чакта безнең өйдә дә күп файда алу юлында булды, төрле өлкәләрдә тоташу чылбыры алды. Шәех Габделгазыйм әл-Мөнзиринең «Әт-тәргыйб вәт-тәрһиб» китабында Тирмизи риваяте белән Коръән ятлау хакында килгән намаз һәм доганы күреп,

бик теләп күчереп, Коръән ятлауга теләген күрсәткән иде. Бәлки, элек тә ятлаганнары байтак булгандыр. Мәдрәсәдән Казанга кайтып, имам булганда, имамнарның гадәтләренә каршы булып, Яңа бистәдән Иске бистәгә йөреп, мәшһүр Коръән укытучы шәех Камал кари әфәнде мәрхүмнән Коръәнне дөрес уку фәнен алган иде. Указ алган имамнар, күбесенчә, бер як белән дә үзләрен төзәтү теләгендә, гыйлем арттыру дәртендә булмыйлар. Бер кешедән гыйлем алу, файда күрүгә үзләрен лаек күрмиләр. Бу эш – зур афәт. Хәтта Хиҗаз сәфәрендә булганнары, зур ихтыяҗлары була торып, Коръәнне дөрес уку эшенә керешмиләр. Зур ваемсызлык.

Тарикатьтә элек остазы шәех Закир Чистави хәзрәтләрендә булып, аның вафатыннан соң Троицкидан шәех Зәйнулла хәзрәтләрендә булды. Йөрәк пакьләвендә байтак тырышлык күрсәткән, күп кенә файда алган, ләззәт белән гыйбадәт кылу дәрәҗәсенә килгән иде. Аллаһның рәхмәтендә булса иде.

## Сафа мулла

Сафа бине Таҗеррижәл, Казандагы завод мәхәлләсендә 6 нчы мәхәллә мулласы Габделвәли мулла Габделгаффарда укып, Спас ягында Баллы Күл исемле авылда имам булып, соңра имамлыкны ташлап, Яңа бистәдән мулла Салихҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди мәдрәсәсенә килеп, кайбер дәресләр тыңлап, аз-маз бала-чага укыткалап, халык белән танышып, иске зиратны төрле эшләргә һәм биналарга алудан саклау өчен, мәчет салу тиешле күрелеп, мәчет эшен администрациядән чыгартуда бу кеше тырышып йөргәнлектән, мәчет салучы Салих бине Сабит һәм мәхәллә халкы тарафыннан лаеклы күрелеп, алынган, Салих балаларының мөгаллиме Мөбарәкҗан иптәшлегенә, гыйлем ягыннан лаеклы булмаса да, икенче имам ителгән иде. 18 ел кадәр имам булып торды, 1916 елның 26 маенда Мөбарәкҗан вафатыннан соң ялгызы имам булып калып торды. Гыйлеме һәм фикере, кешелеклелеге ким иде. Аллаһ ярлыкасын, вафаты 1921 елның җиденче июлендә ([һижри] 1339 елның зөлкагъдәсендә).

* * *

Уфа шәһәрендә июль ахырларында ваба авыруы шактый кимеде. Ләкин читкә җәелгән. Кырмыскалы, Кыешкы авылларында каты хөкем сөрә иде. Һәркөн 15–20 кеше күмелә, хәтта һәркемгә кабер өлгерми, бер чокырга күп кешене күмәләр икән. Иген туплау вакы-

ты килсә дә, тупларга нәрсә юк, диләр. Алай-болай җыелып, бер арбага тупланган арыш көлтәсеннән бер пот, ике пот чамалы орлык алалар икән. Бодай шулай ук өметле түгел. Булса, соңгы яңгырлар белән тары, карабодай, бәрәңге, борай кебек затларда бераз өмет булыр, диделәр. Аллаһ колларын күрүче.

## Аештан мулла Шакир

31 нче июльдә алган вәхши хәбәр әсәре:

Минзәлә өязе Аеш авылында имам мулла Шакир бине Мөхәммәдҗанның вафат хәбәре иреште. Ваба чире белән [һиҗри] 1339 елның 17 зөлкагъдәсендә (1921 елның 22 июлендә) берәр көн генә җиңел рәвештә хасталанып, 68 яшендә вафат булган. Ул Тазлардан мөдәррис шәех Ногман янында гыйльми һәм дини [яктан] тәрбияләнеп иске Әлем авылында Габид хәзрәттән тарикать рөхсәте алып, байтак зикер һәм гыйбадәт белән шөгыльләнгән адәм иде. Бу соңгы елларда «Сахих Бохари», «Шәрхе Гайни» өйрәнүенә мәхәббәт итеп, хәдискә байтак сәләт һәм ияләшү хасил иткән, туры фикерле, яхшы әхлаклы, диндар, яхшы адәм иде. Аллаһның рәхмәтенә барган булса иде. Мөгаллимнәр арасында яхшы көч белән танылган Закир, Әбелкәрәм һәм башкаларның аталары, сигез улы һәм бер кызы калган. Яхшы инженер улы һәм хәзер университетка мөнәсәбәтле уллары да бар. Дусларның үлүләре һәм мәйданнан югалулары Дарими вакытында Бохариның әйткән шигырен хәтергә китерә. Хафиз һәм «Мөснәд» авторы имам Габдулла бине Габдрахман әд-Дарими вафаты имам Бохарига хәбәр ителгәч, әйткән: [...].

## Әдәп гүзәллеге

Коръән сүрәләренең башларында искә алынган өлешләрнең кабатланмаган ундүрт «кәф» («әлиф», «ләм», «сад», «ра» – 361, «кәф», «һә», «йә», «гайн», «син» – 165, «ха», «каф», «нүн», «та» – 167 = 693). Фал ачучылар һәм хәрефләр серләре бу санда Госман дәүләтенең барлыкка килүе [елын] аңлаганнар. Моның мисалы шәех Мөхеддин Ибне Гарәби хәзрәтләренә нисбәт ителә:

[...][46].

[46] Дарими [һиҗри] 255 елда, Бохари [һиҗри] 256 елда вафат.

**Икенче гүзәллек**. Искә алынган гыйлем ияләреннән «әлиф», «дад», «мим», «хә», «ләм», «әлиф», «ләм», «каф», «вау», «мим», «ра», «вау», «син» төзелешендә чынга ашу эчтәлеген көтеп, милади 1905 елда («әлиф», «дад», «мим», «хә», «ләм», «әлиф», «ләм» – 911, «каф», «вау», «мим» – 146, «ра», «вау», «син» – 266 = 1322 һиҗри елда) булган япон-рус сугышы нәтиҗәсендә [Госман дәүләте] җимерелүен укыганнар. Гүзәллекләр!

Гүзәллекләрдән соң бу гүзәллекне языйм ки: июльнең беренче атнасы эчендә 24 арба чүп түктерелде. Һәр арбасына 14000 сумнан 336000 сум түләнде. Тыныч заманнарда һәр арбасы 40–50 тиен булыр иде.

## Икътисади хәлләр хакында
## Нәзарәтнең хәлне бәян итүе һәм тәгълиматы

Диния нәзарәтенең икътисади эшләре хәтәр булганлыктан, [һиҗри] 1339 елның 5 зөлхиҗҗәсендә мөхтәсибләр аркылы мондый кәгазьне тараттым. Һәркайсы мөхтәсибнең моңа туры килгәнчә хәрәкәте өмет ителде:

«Мөхтәсиб ..., хөрмәтле имамнар артыннан баручы һәм ихтирам иясе булган хәзрәтләренә белдерелә ки, Диния нәзарәтенең барышы, икътисадча, бу кышта авыр хәлдә калуы күренә. Бөтенләй тукталуы да ихтималы читтә түгел. Съезд тарафыннан билгеләнгән айлыклар [хезмәт хаклары], сезгә мәгълүмдер ки, хәзер 2–3 көнлек кенә. Кулга кергән ихтыяри иганәләр арттыруны күтәрерлек түгел. Бары бер чара күренә ки, мөмкин кадәр һәр җирдә ашлык белән иганә бирсәләр, бу эшне соңга калмыйча, Нәзарәткә белдерсәләр, Нәзарәт төрле фикерләрдән кайтып, тынычлык белән карарланып, мөмкин кадәр эшендә дәвам итәр иде.

Мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди».

Янә мондый язуны тараттым:

«Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Мөхтәсиб мулла ... әфәнде!

Төрле тарафлардан алынган хәбәрләргә һәм кылынган шикаятьләргә күрә, имамнарның тормышлары артык авырайган. Байтак җирләрдә михрабларның буш калулары ишетелә. Бу хәл – безнең ислам дәүләтләребез өчен дингә куркыныч һәм тормыш гарьлеге. Дөрес, милләт үзе дә авыр хәлдә, бу да мәгълүм. Шулай булса да, көчләре кадәр имамнарга яшәү өчен кирәк булган акчаларны шәригать һәм әдәп бурычлары, тәэмин итүләрен йөкләнгән вазыйфалары

[дип] санап, гайрәт һәм дәрт күрсәтүләре никадәр авыр булса да, имамнарны сакларга һәм бетү хәленә төшермәскә тырышулары тиешле күрелә. Шуңа күрә бу киңәш һәм кисәтү кәгазен районыгызда булган дин карендәшләребезгә яраклы юллары белән ирештерүегез өчен сезгә җиткерелә.

[Һиҗри] 1339 елның 5 зөлхиҗҗәсе. Моны язды: мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди».

## Уфа епископының үтерелүе

18 августта Уфа епископы (архиерей) кич белән чиркәүдән кайтканда, урамда билгесез адәмнәр тарафыннан атылып үтерелгән. Җирләү өчен Златоуст һәм Самара епископлары чакырылсалар да, килмәгәннәр. Якшәмбе көн 21 августта Собор чиркәве эченә күмделәр. Берәр атна элек халкына вәгазь арасында әйткән икән: «Христианнар үз руханиларын яклый алмадылар, мөселманнарның Диния нәзарәтләре саклаңган, дәвам итә. Консистория тәмам җимерелгән. Христианнар саклый алмаганнар» дигән эчтәлектә байтак сүз сөйләп, яһүдиләргә байтак кына ризасызлык белдергән икән. Кайбер риваятьләргә күрә, яһүдиләр (мәгълүм төркем) тарафыннан үтерелгән икән. Дөресен Аллаһ белүчерәк. Каны буш, эзләүче булмады һәм булмастыр.

## Уфада ачлык дәһшәтләре

Уфада ачлык сәбәпле, тирә-яктан килгән һәм тупланган ир-хатын, бала-чага бик күбәйде. Ата улны, ана кызны белми, ташлый алган җирендә ташлап китә, адаштыра алса, адаштыра. «Ул көндә [Кыямәт көнендә] кеше карендәшләреннән, анасыннан, атасыннан, хатыныннан һәм балаларыннан качар» [Коръән, 80:34–36] дигән хәлгә бер кечкенә генә мисал диярлек дәрәҗәдә дәһшәтле хәл. Хөкүмәт идарәсе балаларны җыеп, тәрбия йортына куя. Ул тәрбия йорты гаять тар, шакшы, тиешенчә күзәтү юк, йөз балалык җирдә бишйөз кадәр бала куелган. Аларда да ачлык, төрле йогышлы авырулар таралган. Тәүлеккә фәкать чирек кадак икмәк билгеләнсә дә, хыянәт катышып, кими икән. Бу тәрбия йорты исемендә булган өйдә вафат булганнарны эт һәм дуңгыз үләксәсе дәрәҗәсендә тотып, арбага 10–15 не төяп, бер олы чокырга салалар. Ничә көннәрдән соң чокыр тулгач, күмәләр икән. Ышанычлы кешеләрдән

мулла хаҗи Гали Мәхмүд шәфкатьлелеге һәм миһербанлылыгы сәбәпле, юлда егылган, хәлдән таеп калган балаларны искә алынган тәрбия йортына илткәндә, бу вафат булган балаларның бер кулыннан һәм бер аягыннан тотып арбага ыргыту рәвешенчә тутырылганнарын күреп, хәйран булып кайткан иде.

Урамнарда калганнары түгелгән чүп-чарларны, җирәнгеч яшелчә кабыкларын, базарда булса, урлый алганы урлап, кайберләре тотылып, төрле әшәкелек күрәләр. Бу ач төркемнең күпчелеге, йөздән җитмеше-сиксәне мөселманнар. Урамда егылып калган, хәлсез хатыннарга, күп булып күренгән балаларга шәфкатьлелек күзе белән караручы – гаҗизлек һәм зәгыйфьлекне күреп торган адәмнәр. Кызганучы бик аз, булса, христиан халкыннан, марҗалардан булгалый икән. Мөселманнардан азрак икән.

## Ачларга ярдәм комитетлары

Мәскәүдә гомум ачларга ярдәм өчен һәртөрле халыктан, күбрәге халыкка шәфкатьлелек күзе белән караручы, кеше җенесенә ерткыч хайванча карамаучы төркемнәрдән бер зур комитет төзелгән. Шул арада мөселманнарга махсус мөселманнардан да бер комитет төзелгән. Беренче комитет хөкүмәт тарафыннан расланган. Икенче комитет расланырмы, юкмы – шаять, расланыр. Бу икенче комитетны төзүчеләр: 1) Ибраһим Әхтәмов Уфави, 2) Рәсүлзадә Мөхәммәдәмин Кавкази, 3) Гобәйдуллахуҗа Ташкенди, 4) Ильяс Алкин Казани, 5) Госман Токымбитов, 6) Сабирҗан Шәмголов Уфави. Тәмам комитет егерме адәмнән гыйбарәт булып, тирәяктагы җирләрендә хезмәт итү өчен, 14 кешене әгъзадан хисаплаганнар. Алар болар: 1) мөфти Галимҗан Баруди, 2) Габдеррәшид Ибраһим, 3) Муса бине Җарулла Бигиев, 4) Фатих Кәримов, 5) Әхмәдбик Салихов Кавкази, 6) Мөхәммәдриза Вәкилев Кавкази, 7) Хәсән Сабри Айвазов Кырыми, 8) Сәлимгәрәй Җантурин, 9) Бинеямин Әхтәмов, 10) Галим Акчурин Петропавел, 11) Галихан Бүкәйханов казакъ, 12) Әхмәд бай Турсунов казакъ, 13) Габделбари Госманов, 14) Сара Шакулова.

Искә алынган комитеттан радио аша минем исемемә Корбан гаетендә иганә җыю турында хәбәр килгән булса да, Уфа вилаяте исполкомы тарафыннан миңа бары [тик] 21 августта гает тәмамланганчы бер атна соң тапшырдылар. Ни сәбәпле кичеккәндер – сәбәбен сорап, исполкомга мөрәҗәгать ителде. Кичегүе эшкә зур

зарар итте. Шулай да, 22 августта Уфа имамнарына вакыйгадан хәбәр бирелде. Кайбер мәхәлләләрдә гаеттә ачларга ярдәм өчен җыелган акча бар икән.

Бу көннәрдә Уфа губернасы исеменнән дә ачларга ярдәм комитеты төзелеп, аның өстенә, мөселманнарга махсус бер кечкенә комитет төзелгән. Аңа 6 нчы мәхәллә имамы Хәбибулла Әхтәмов рәис, мөәзине Сөләйман сәркятип [итеп] билгеләнгән. Мөфтияткә болар тарафыннан да бу мәсьәләдә халыктан иганә сорап, искә алынган комитетка җибәрүләрен сорап, бер мөрәҗәгать кәгазен нәшер итүне үтенеп, бер рәсми кәгазь килгән иде. Мөрәҗәгать кәгазе язылса, Мәркәздә булган комитет мөһимрәк, Мөфтиятнең бөтен халыкка, вилаятькә мөнәсәбәте тигез булганлыктан, гомуми сурәттә бөтен Русия мөселманнарына мөрәҗәгать итү тиешле булыр кебек күренә.

Мәркәздә оешкан беренче гомуми комитетта кызык бер мәсьәлә бар: әгъзаларының барчасы элек эш кешесе, мәмләкәт төзеклеген кирәксенгән, хәзерге хөкүмәт тарафыннан сөелмәгән, куып чыгарылган кадет һәм аларга охшаган төркемнәрдән. Хөкүмәтнең иң зур ышанычы Америка һәм Европа иганәләре булганлыктан, бу мәсьәләдә үзен битараф итеп, искә алынган мәмләкәтләрдә яхшы төзеклек һәм тормыш яхшырту ияләре булып танылган адәмнәргә ихтыяр биргән. Һәммә әгъзасы мөселманнардан булган икенче комитет әгъзалары да шул рәвештә. Бу эш – хөкүмәтнең бер яхшы идарәсе, үз көченнән читтә булган эштә кыланмыйча һәм икейөзләнмичә эшне ияләренә тапшыруы. Ләкин искә алынган дәүләтләр иганә итәләрме, юкмы – зур мәсьәлә шунда. Кайбер газеталарның хәбәрләренә күрә, салкын рәвештә карыйлар икән. Сәбәбе: бирелгән иганәләрнең тиешле урыннарына ирешмәвен ихтимал тоталар. Шунлыктан үзләренең яклавы һәм күзәтүләре астында ачларга, фәкыйрьләргә бүлеп бирмәкче булалар икән. Бу рәвеш исә Шура хөкүмәтенең хөрмәтенә һәм сәясәтенә каршы, ахырында хәвефле. Шунлыктан бу рәвешне хөкүмәт кабул итә алмастыр. Күрше дәүләтләр Шура дәүләтенең дәвам итүенә риза түгел. Ачлык хөкүмәтнең гаҗиз булуына бер юл булып, шул юл белән хөкүмәтнең төшүен ихтимал тоталар. Шундый сәбәпләрдән, Европа һәм Американың иганәләре бик үк өметле түгел икән. Дөресен Аллаһ белүчерәк.

## Мөфти-казыйлар мәҗлесе, мөселманнарда шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек хакында фикер алышу

19 зөлхиҗҗәдәге 3–4 әгъзадан гыйбарәт [булган] бер чәй мәҗлесендә: «Ачлык сәбәпле урамда калган мөселман бала-чагаларга христиан хатыннарының шәфкатьлелекләре күбрәк күренә, мөселман ир-хатыннарының мәрхәмәтлелекләре азрак була, бу эш нинди сәбәптән?» – дип, бу мәсьәләдә фикер алышынды. Һәркем үзе белгәнчә сөйләде, фикерен мәҗлескә куйды. Ләкин башка мәҗлесләр кебек, монда да хакыйкать белән гыйлем таләп итү һәм хаклык эзләү юлынча булмыйча, һәркем үз фикеренә башкаларны чакыру рәвешен күрсәтә иде. Сүзләренең нәтиҗәләре языла:

Җиһангир бине Тальхә Абызгилдин: «Дин шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек белән боерса да, имамнар халыкны яхшы тәрбияләмәгәннәр, шул шәфкатьлелек рухын бирә алмаганнар. Поплар исә бу мәсьәләдә бик тырыш, дини вәгазьләре тәэсирле була. Мөселманнар иҗтимагый эштә фикер йөртмәгәннәр, иҗтимагый эшләр эшләп өйрәнмәгәннәр», – диде.

Казый Сабир бине Мөхәммәдҗан Хәсән: «Пәйгамбәр тормыш юлын язучыларның барысы сугышлар хакында язып, мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелек мәсьәләләренә җиңел караганнар, динне көчлелек дине итеп күрсәткәннәр. Тәсаувыф ияләре [суфилар] кебек мәрхәмәтлелек юлын күбрәк күрсәткән булсалар, халык арасында тәсаувыф ияләре күбәйсә, мәрхәмәтлелек һәм шәфкатьлелек күбәер иде. Имамнар күбрәк шул юл белән вәгазь-нәсыйхәттә булырлар иде», – диде.

Кәшшаф казый «Галимнәр электән үк гыйбадәт рәвешләрен яхшы бәян иткәннәр. Ләкин эчке әдәбендә йомшак күңеллелекне һәм шәфкатьлелекне җәлеп итү кебек мәсьәләләрдә кыскартканнар. Шунлыктан халык шәфкатьлелек мәсьәләсендә игътибарсызрак булып киләләр» дигән эчтәлектә бәян итте[47].

[47] Минем фикеремчә, һәр әхлакның бәян итү урыны бар. Мәсәлән, намазның тышкы әдәпләре фикыһта бәян ителә, вазыйфасы да шул. Бирелеп уку, йомшак күңеллелек, йомшау әхлак китапларында бәян ителә, Коръәннең кыскача зикерләре аңлатыла һәм бу кадәр чиксез хәдисләр бәян ителә. Шунлыктан шәфкатьлелек һәм мәрхәмәтлелек бәян итүендә ни әүвәлге галимнәрнең бәян итүендә, ни дин һәм шәригатьтә – һичкайсында кимчелек юк. [...].

Риза казый: «Ислам дине халыкка башка төрле аңлатылган. Тәсаувыф ияләре [суфилар] туганнан бирле исламны бозганнар. Шуларның бидгатьләре таралып, халыкны исламнан ераклаштырып, Браһма мәзһәбенә якынлаштырганнар. Тәсаувыф ияләре арасында Кәгъбәтулладан Кара ташны куптарып алып китүчеләр булды».

Элекке сүзен дә тәмам авырлык белән генә күтәргәнлектән, бу соңгы сүзенә түзә алмыйча, өч мәртәбә: «Әстәгъфирулла», – дидем. «Динсезләрнең эшләрен тәсаувыф ияләренә нисбәт итәсең, Кара ташны куптаручы кәррамит [кәррамия сектасына иярүче] иде. Боларга тәсаувыф ияләре булу кая, ислам нигезеннән чыккан динсезләр иделәр», – дидем. Моңа каршы артык кызып, сүземне дә хаталы аңлап, гүя ки мин үзен динсез дигән кебек кабул итеп: «Мин динсез түгел, мөселман. Бер кешегә дә динсез димим. Әгәр берәүгә динсез дисәм, (Халид Нәкышбәндине күздә тотып) Халидне динсез дияр идем, хәзрәти Йосыф хакында начар сүз тапшырган. Син шуны бастырып, тараттың», – диде. Мин: «Сине динсез димим, кәррамитне әйттем, тәсаувыф иясе түгел, динсез дидем», – дигәч, башкалар да сүземне дөрес дип, аның кызулык белән ялгыш аңлаганын белдерделәр.

Янә тарикать ияләре турында һөҗүм һәм кызулыкта дәвам итеп: «Газали, Кушайри, «Әл-Гавариф» авторы [Сүһрәвәрди булса кирәк] ислам галәмен харап иттеләр. Суфичылыкларын катыштырып, ислам динен җимерделәр», – диде. Минем Аллаһтан гафу үтенүем һәм инкяр итүемә каршы: «Бу сүзләремне шөбһәләнми әйтәм, Гарәфәт тавына менеп, кычкырам», – диде. Миндә артык хәйранлык туды. Сүз белән каршы торуның файдасы булачак түгел, җавап бирелсә дә, файдасыз икәне кабат тәҗрибә ителгән. Зарурлык белән, өстебезгә килгән икенде [намазы] вакытының ахыры якынлашканлыктан, кузгалдым. Артык колак салмадым, озакламый сүз дә киселде.

Бу кешенең тәсаувыф ияләре, хәтта тарикать имамнары хакында начар ышануы электән үк мәгълүм. Аз гына мөнәсәбәт килгәндә, «Асар»ында болар хакында, аңлавына күрә, әдәпсезлекләре күп. Болар хакында мин каршылык күрсәтмәдем, файдасызлыгын кабат тәҗрибә иттем. Алар өчен җавап бирү Аллаһка һәм әүлиясенә тапшырылган. Бары минем ике ноктага карашым бар:

Берсе – милләттә шәфкатьлелек азаюның сәбәбен тикшерүдә тәсаувыф мәсьәләсе бөтенләй мөнәсәбәтсез. Тәсаувыф ияләрендә,

хәтта, аның әйтүенчә, хаталы мәсьәләләр, хаталы юллар булса да, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек, юмартлану, кулларында булганны уртаклашу дәрәҗәсенә якын юмартлык башкаларга караганда аларда артык икәне – дуслары һәм шундыйлары тарафыннан расланган ачык мәсьәлә. Шунлыктан бу мәсьәләдә аларга кагылу бөтенләй урынсыз һәм мөнәсәбәтсез.

Икенче нокта – минем белән һәҗүм иясе бу мәсьәләдә капма-каршы тарафта. Мин исә тәсаувыф ияләрен исламның формасын һәм рухын саклаучылар, беренче дәресләрдә үк һәр мәсьәләдә Сөннәткә ияргү, бидгатьтән саклану, гыйлем һәм гамәл ягыннан шул дәресне саклаудан гыйбарәт дип беләм. Моны мәшһүр китапларын укып, бары начар күрү, гаеп эзләү карашы белән түгел, ияләре белән аралашып, күреп беләмен һәм аларга, рәсми булса да, бәйләнешем бар. Шунлыктан аларны сөюче һәм, хакыйкатьтә, Рәсүлуллаһка (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) ияргүче дип ышануым бар һәм бу ышануым иптәшебезгә бик мәгълүм. Егерме-утыз еллык гыйльми мәсләктә, дустанә мөгамәлә һәм аралашуыбыз өстенә, хәзерге көндә бер идарәдә милли һәм дини хезмәттә катнашып эшләү һәм сөйләшеп утыруыбыз бар. Бу мәҗлес әлеге мәсьәләне тикшерү өчен ясалмаган. Бер нәкышбәнди тарикатен сөюче тарафыннан бәйрәм чәе исемендә генә корылган. Шунлыктан бу мәсьәләдә иптәшебезнең мондый һөҗүме мине кәефсез итте. Иптәшлек һәм бергә эшләү әдәпләре, хөрмәте сөйләшеп утыруыбызны кайгыртмау белән, шәхси хокук, әхлак һәм әдәп карашынча, мәҗлес әдәпләреннән чыкты.

Пәрваз мулла (Зыя Камали) бу мәсләктә һәм бу мәсьәләдә ачык язган, фикерен игълан иткән, башка яңалыклары арасында матбугатта нәшер иткән булса да, аңа башкача карала. Ләкин бу кеше [Риза казый] аның белән чагыштырылмас, дини әдәпләрне кайгыртучы, фарыз-важибләрне үтәүче, хәрамнан саклаучы, диндар кеше. Бу күңелсез хәлгә төшүе – аяныч хәл.

[...].

## Риза казыйның китапханәсе хакында Нәзарәткә мөрәҗәгатьләр

23 августта мондый гаризага юлыктым. Гариза казый Ризаэтдин бине Фәхретдин тарафыннан бирелгән. Әйтә:

«Китапханәмне сату ниятендә мин. Әгәр дә алса, минем өчен Диния нәзарәте китапханәсе өчен сатылып алынуы һәм дә таралмый бер урынга җыелып калуы таләп ителгән нәрсә иде. Диния нәзарәте китапларны кирәксенәме, байлыгы мөмкинлек бирәме? Алачак булса да, булмаса да, миңа белдерсен иде. Җавапның кичекмәве таләп ителә.

Казый Ризаэтдин бине Фәхретдин, 1921 елның 21 августы».

Менә хәл ничек! Искә алынган казый 30–40 ел кадәр гыйлемне сөюе сәбәпле, дөнья ләззәтләренә карамыйча, юк акчасын бар итеп, ерак җирләрдән төрле мәшәкатьләр белән, акрынлап җаны бәрабәрендә күргән китапларын тамак өчен сатарга мәҗбүрлек күрә. Ничә еллардан бирле иң мөһим вакытлары, рәсми һәм рәсми булмаган дини һәм милли хезмәтләргә сарыф ителгән, бу елларда Диния нәзарәтенә казый булып, милләтнең (кирәк 1917 елдагы Милләт мәҗлесендә, кирәк 1920 елның сентябре съездында) зур ихтирам һәм үтенү белән сайлаган могтәбәр казые, мөфти кебек таланганлыктан, кабат конфискацияләрдән калган, поскан, чынлап та, сатып ашарга милке юк, башка казыйлар кебек арттырырлык әсбабы һәм җиһазы юк яки файдасын да күрерлек мәхәлләсе юк, милләт тарафыннан уйламыйчарак билгеләнгән, хәзерге көндә өч көн тормыш итүдән артмаслык 40000 сумнан башка кереме юк кеше. Актык китапларын сатып, хезмәтендә дәвам итмәкче була. Югарыда искә алынган затның гаризасына яраклы хәрәкәт итү, көч җиткән кадәр булышуда булу Диния нәзарәтенә тиешле. Милләт бушка тормышын тәэмин итә алмаса да, китапларын яраклы бәһа белән алып, Нәзарәтнең китапханәсенә тапшыру, хезмәте дәвам иткәнчә югарыда искә алынган затның үз идарәсендә һәм файдалануында калдыру тиешле. Аллаһ ярдәм бирсен. Нәзарәт, иншалла, моның чарасына керешер.

23 августта казыйлар белән киңәшләшкәннән соң, мондый җавап яздым:

«Ризаэтдин хәзрәт! Китапханәгез турындагы гаризагыз Нәзарәттә укылды. Сезнең мәҗбүр булуыгыз өчен кайгырганнан соң, китапларыгызның исемлеген, хәзерге хәлгә туры килгән гадел

бәһасен белгәннән соң, алу фикеренә яраклы эшкә керешүгә карар бирде. Мөмкин кадәр тиз заманда [югарыда язылган] ике маддәне белдерсәгез иде. Мөфти Галимҗан Баруди.

## Күренгән ачлык хакында Мәркәзгә хәлне бәян итү

26 августта (22 зөлхиҗҗәдә) июль эчендә Бәләбәй, Эстәрле өлкәләренә кылган сәяхәтемдә күргәннәремнең әсәре булган халык тормышыннан Мәскәүдәге рәисләр Ленин, Сталин, Калинин, Сурупага махсус хат итеп, хәлне бәян итеп, җибәрдем.

Эчтәлеге:

«Мөселманнар артык авыр хәлдә, ачлык, ялангачлык һәм хасталык һөҗүмнәренә дучар булганнар, күп адәм үлән тамырларын ашап, җан сакларга тырышалар, ул аз. Ваба авыруы байтак авылларда барлыкка килеп, күренеп тора. Авыллардан, ташлап, күченеп китүчеләрдән юлда, вокзал буйларында үлеп ятучылар, үлеп, күмелми ятучылар күп күренә, ишетелә. Бу хәлләр күбрәк мөселманнарда күренә. Моның сәбәбе – боларның электән үк запасларының, саклык игеннәренең азлыгы, азык җыйган вакытта җирле идарәләрнең боларның барлык игеннәрен, хәтта орлык өлешләрен алып бетерүләре, гаделлек һәм тигезлек ниятендә булган Шура хөкүмәтенә бер дә мөнәсәбәтсез рәвештә катылык күрүләре. Мөселманнар электән үк хөкүмәт тарафыннан төрле һөҗүмнәргә һәм кагуларга дучар булып, куркучан булып килүләре, хәзер дә хөкүмәт адәмнәреннән артык куркып, бер рәвеш белән җан сакларлык игеннәрен алып кала алмаулары сәбәп булган. Аның өстенә, быел иген уңмады (урожай булмады), курку һәм дәһшәтләрен бигрәк арттырган. Бу сәбәпле, хөкүмәтнең мөселманнар хакында яхшы мөгамәләсен көтеп, аларның дуслыкларына, юашлыкларына, икътисади һәм мәгариф эшләрендә кимлекләренә яраклы идарә һәм яхшы тәрбияләрен тотуын өмет итеп, хәерлек теләп, бу кәгазь язылды».

28 августта Уфада вилаять өчен ачларга ярдәм комитеты сайланды. Рәислеккә чуаш, рус (поп), татардан дүрт адәм сайланып, вилаять идарәсеннән рәисне сайлаусыз игълан ителде. Комитетына мөфти, казыйлардан Кәшшаф, Сабир, Зыя Камали, Җиһангир Абызгилдин, Хәбибулла Әхтәм, сәүдәгәрләрдән байтак адәмнәр билгеләнде. Уфа вилаятендә ачлык гадәттән тыш куәтле булганлыктан, җитди рәвештә хәрәкәт тиешле була. Безнең мөфтияткә исә

һәркайсы ач вилаять өчен ярдәм итәргә тырышу, халыкта теләк һәм кызыксыну уяту тиешле булыр. Аллаһ ярдәм бирсен.

* * *

27 августта Риза казыйдан мондый кәгазь алынды:

«Хөрмәтле мөфти хәзрәтләренә. Әмерегезгә таянып, бу язу белән китапханәмнең исемлеген, хакларын күрсәткән җәдвәлне тапшырамын. Бүләк итеп бирү фикере булганлыктан, ата-бабам тарафыннан язылган нөсхәләр һәм үзем язган нәрсәләр монда кермәделәр. Нәзарәт өчен аларның әһәмиятләре дә юктыр. Якынча 570 данә кадәр китап булып, суммасы 21062 сум тирәсендә, хаклары уртача булса кирәк. Кинәт авыр булу ихтималы күренсә, шушы суммадан 1 сум башына 30 тиен киметүгә риза булам. Имза».

Китапларның исемлеге башында [күрсәтелгән] кыйммәтләләрен алтын бәһасе белән [сатарга] дип шарт иткән иде. Алтын исә бу көннәрдә Уфада ун сумлыгы 150000 сум чамалы (1 сумы 15000сум була). Бу хисаптан китапханәнең кыйммәте 32430000. Бу кадәр бәһа белән Нәзарәт артык кыйммәтлеге һәм финанс куәтенә яраклы булмауны күреп, алудан гаҗизлеген күрсәтеп, югарыда искә алынган затка мондый язуны язды:

«Ризаэтдин хәзрәт! Бу мәсьәләне мәҗлес карады. Алтын хисабын язусыз, махсус рәвештә бу көндәге кыйммәтчелек [аркасында] Мәхкәмәи шәргыянең күтәрә алмавын күрде.

Мөфти Галимҗан Баруди, 29 август».

## Янә ваба фаҗигасы

Бүген 31 августта Бәләбәйнең Чакмагыш авылы 3 нче мәхәллә имамы мулла Хөсәен бине Яхъядан алынган хатта, 3 августта чәршәмбе көн Чакмагыш имамы һәм өлкәнең мөхтәсибе мулла Шәех бине Яхъя бине Хисам бине Мөхсиннең ваба белән вафат булуын язган. Аллаһ аны кичерсен. Җеназасы зур җәмәгать белән пәнҗешәмбе көн мулла Бәдретдин бине Исмәгыйль имамлыгы белән укылып, җирләнгән. Мәрхүм мулла Шәех 46 яшендә Томытыктан Әхмәдлатыйф бине Габделлатыйфта укыган, хөрмәтле һәм гыйлем сөюче гадел адәм иде. Тормышында милләт өчен өмет ителерлек, диндә нык торучы кеше иде. Коръән һәм хәдис гыйлеме белән шөгыльләнә, кайбер гарәп әдәбиятында язган һәм җыйган яхшы әсәре дә бар. Бу вилаятьнең күзгә күренерлек, галимнәр җөмләсеннән санарлык, эшлекле адәм иде. Дүрт улы, бер кызы һәм

хатыны калган. Васыятендә балаларын укыту мәсьәләсендә расланган васыять биргән. Аллаһ Тәгалә үзен рәхим кылган булса иде. Балаларына хәерле гомер, файдалы гыйлем һәм яхшы тормыш насыйп итсә иде.

## Мәскәүдә ачларга ярдәм комитеты ябылган

Мәскәүдән радио белән хәбәр ителүенә күрә, андагы төрле фиркадан (байтагы кадетлардан) оешкан ачларга ярдәм өчен булган комитет ябылган. Бу комитет алтмыштан артыграк адәмнән оешкан, Европа, Америкадан азык китерү өчен коммунистлардан [кала] башкаларны катыштырып төзелгән һәм байтак куәт бирелгән комитет иде. Ни булгандыр, бәлки, Европа белән артыграк якынлашып, сәяси мәсьәләләрдә дә сүзләре булып, хөкүмәтнең шөбһәсенә сәбәпче булып, ябылгандыр. Ач вилаятьләр өчен бер өмет шул капкада иде. Элегрәк ишетелгән иде: күрше дәүләтләр иганә итмәкче булсалар да, үз гаскәрләре саклавы астында ачларга бүләчәк, коммунистларның күп эшләрдә фиркадашларына яхшы карап, башкаларны күп кайгыртмаулары бу фикерне кузгаткандыр. Бу фикер исә, әлбәттә, хөкүмәтнең зур шәбһәсен җәлеп итәчәк, ахырдан, эш кулларыннан ычкынуга сәбәп булуы бик ихтимал булачак. Шунлыктан бу мәсьәләдә төрле ихтималлар, төрле сәясәтләр булып, читтән ризык китерү бөтенләй тукталып, ачларның ачлыкта һәлак булулары мөмкин. Күрше дәүләтләр исә, бу зәгыйфьлек һәм бу һәлакәтне Шура хөкүмәтенең җимерелү һәм бетүенә бер юл [итеп] күреп, халыкның кырылуына салкын кан белән карап, ахырында гомуми хәерлек булыр, дип көтүләре ихтимал. Хуҗа [Аллаһ], ниләр, ниләр күрербез.

Бу көннәрдә Румыниянең Русиягә каршы гаскәр туплавы, Сәфәр берлеген игълан итүе ишетелде. Моңа каршы Сибириядә Сәфәр берлеге игълан ителү хәбәре бар. Эчке Русиядә дә бер-ике еллык өчен игълан ителәчәк икән. Азык, кодрәт ничек булыр – мөмкин булса, булмаса да, хәрәкәт итми хәл юк. Ахыры хәерле булсын.

Ихтимал, Румыния аркасында Маҗар, Франция һәм башка кечкенә дус дәүләтләр – «Малая Антанта» – булуы, каршы төшүе һәм фәләне байтактан ишетелә иде. Бу кадәр кыйммәтчелек, ачлык, ваба һәм башка авырулар өстенә, Русия башына янә нинди бәлаләр туар? Коллар – Аллаһ коллары, илләр – Аллаһ илләре, аларда ни

тели – шуны ачыклый. Кемне тели – гафу итә, кемне тели – газаплый. Аллаһ – Кичерүче, Рәхимле.

## Мәдинә мәчетенең планы

Диварыма аскан Мәдинә мәчетенең планы яхшы истәлек булып тора. Бу план Чистайлы мөһаҗир Хөсни Әбү Хәлил тарафыннан Германиядә эшләтелгән. Рәсүлуллаһның (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) үз нигезе күрсәтелгән һәм хәзрәти Гомәрнең, хәзрәти Госманның, Вәлид бине Габделмәликнең, Мәһди Габбасиның, Солтан Каетбайның, солтан Габделмәҗид Госманиның арттырганнарының барысы да аерым буяулар һәм язулар белән күрсәтелгән. Мәйданнары һәм аралары үлчәм һәм үлчәм берәмлекләре белән күрсәтелгән. Гомум мәчетнең үлчәме: кыйбла тарафына төньяктан көньякка таба буе – 140 метр, көньяктагы киңлеге – 82, төньяктагысы – 67 метр. Пәйгамбәр нигезенең көньякка сузылуы – 38 метр, көнчыгыштан көнбатышка – 40 метр. «Минем йортым һәм нурым арасында җәннәт бакчаларыннан бер бакча» дигән мәшһүр хәдискә күрә, пакь бакча дип хисаплана торган җир – «бәйте шәриф»нең тәрәзәсеннән минбәргә хәтле – 20 метр, кыйбладан төньякка – 12 метр кадәрлегә «бакча» дип игътибар итәләр. Бу «бакча» микъдарына планда билге белән билгеләнгән. Йә Аллаһ, миңа Үзеңнең рәхимлегең һәм юмартлыгың белән, Мәккә-Мәдинә мәчетләренә әйләнеп кайтырга, анда басып торырга һәм аларның берәрсендә үләргә насыйп ит. Йә Рәхимлеләрнең Рәхимлесе. [Һиҗри] 1340 елның 5 мөхәррәме.

Касәм бине Хәбия әйткән: «Төннәр һәм иртәләр үтәләр, яшьләр үсәләр, картлар бетү хәленә килә, гомерләр үтә, Кыямәт якынлаша. Гыйбрәт күп, ләкин игътибар юк». Әлеге шагыйрь Касәмнең шигырьләрендә байтак гыйбрәт һәм киңәшләр язылган. Искә алынган шигырьдән соңгылары:

[...].

Бу биттә булган шигырьләр Зиһни әфәнденең «Әл-каүл әл-җәдид» исемле әсәреннән күчерелде.

Бу көннәрдә ислам тарихы яңарды. Һиҗри 1340 ел туды. Бу елның миңа мөнәсәбәте: 1273 елда тууымнан [соң] 66 ел һәм якынча 8 ай үткән. Бохарадан кайтып, имамлык һәм мөгаллимлек өчен 1300 ел мөхәррәме башында ярлык [указ] алуыма тәмам 40 ел үткән. Гыйлем юлына кереп, хөрмәтле мәдрәсәдә «әлифба» дәресен

башлавымнан тәмам 62 ел үткән – 1278 ел ахырында, 1862 елның маенда. Мәктәп иптәшләре, бигрәк [тә] дуслар аз иде. Куәтләр зәгыйфьләнде, төкләр агарды, вакыйгалар моңа бигрәк тәэсир итте. Бәндәлек вазыйфалары йөз кимчелек һәм җитешсезлек белән үтәлә. Гыйлем һәм казыйлык дәрәҗәсе, мөфтилек вазыйфалары шулай ук. Аллаһ Тәгалә хәерле хәл һәм яхшы ахыр насыйп итсә иде.

## Габдулла Үтәмишев вафаты

Казан почтасыннан алган хәбәргә күрә, 15 зөлхиҗҗәдә (19 августта) Әбү Әхмәд Габдулла бине Исхак бине Муса бине Габдулла Үтәмишев вафат булып, иртән җирләнгән. Беренче хатыным Маһруй бинте Исхакның туганы иде. Яшьлектән үк акылы камил түгел иде. Укыр-язар дәрәҗәдә укыган, дөньяның рәвешеннән икътисади хәлләреннән хәбәрсез, утыз елдан артыграк туганы һәм минем карамак астында, соңгы 3–4 елдан бирле кече туганы Нәгыймә һәм аның ире мулла Салихҗан Барудиның күзәтү һәм тәрбияләрендә тормыш итә иде. Соңгы заманда юләрләр шифаханәсенә куелып, 15 көн кадәр анда тәрбияләнсә дә, шифа тапмыйча, вафат булган. Ике улы, дүрт кызы калды. Атасыннан калган байлыгы, кирәк үзе, кирәк гаиләсе икътисад кайгыртуына җиңел карасалар да, анасы Гайшә бинте Мөхәммәдшәриф идарәсендә һәм минем күзәтүем астында сакланды. Казандагы йорты [һиҗри] 1338 елның язындагы зур янгында янып, гаиләсе бер таш өлешен төзәттереп, торырлык хәлгә китерделәр. Печән базарында Казаков бинасы, яхшы сарае һәм «сарай» исеме белән билгеле магазин һәм номерларда яртысына якын өлеш күчемсез милке, Малмыж өязендәге 500 дисәтинәгә якын печән җире калды. Хәзерге көндә йортлары хөкүмәт тарафыннан, печәнлеге күршеләре рус һәм чирешләр тарафыннан алынса да, замана тынычлану белән кайтарылулары өметле. Аллаһ Тәгалә вафат булучыны рәхим кылган булса иде. Вакытында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә байтак иганәләре булды. Вәҗиб сәдакаларыннан файдасы иреште. Малмыж тарафында һәм башка тарафларда мәчет һәм мәктәпләр төзү юлында анасы Гайшә бинте Мөхәммәдшәрифнең яхшы идарәсе астында байтак файдалы ярдәмнәре булды. Аллаһ аңа хәерле әҗерен бирсен. 1340 елның 6 мөхәррәме (1921 елның 8 сентябре).

## Нәзарәткә Мәркәздән махсус комиссия килү

13 сентябрьдә Мәскәүдән Уфага Диния нәзарәте белән җирле Архив оешмасы һәм ЗАГС арасында булган кайбер мәсьәләләрне хәл итү өчен бер комиссия килде. Әгъзалары: Габдулла Гыйсмәти (рәис), Петроград имамы Лотфулла Исхак, Архив оешмасыннан рус Узумов, сәркятип Мирзамөхәммәд бине Әхмәд Ирзин. Бу комиссиянең килүе җирле идарәләрнең кәефләрен бозды, бераз дулкынлануга төшерде.

15 сентябрьдә Нәзарәт бүлмәсендә җирле идарәләрдән хокук вәкиле, вилаять идарәсеннән бер адәм, Нәзарәттән казый Тәрҗемани составында катнаш мәҗлестә эшләрне тикшерү булырга тиеш иде. Җирле хокук вәкиле килмәгәнлектән, мәҗлес таралып, кичәсендә Нәзарәт вәкиленнән әзерләнгән тәкъдимне һәм аңлатманы тыңладылар.

16 сентябрьдә җирле идарәдә аерым мәҗлес ясап, алардан җавап алып, соңра җирле идарә әгъзалары белән мондый карарга килделәр: Архив бөтенләй барлык бүлекләре белән Диния нәзарәте әгъзаларына тапшырылачак, Уфа хөкүмәте һәм ЗАГС идарәсе тыкшынмаячак. Тик Нәзарәт рәсми идарә буларак танылмаганлыктан, дәфтәрләрдән бирелгән справкаларын рәсми идарәләрдә кабул иттерү өчен Мәркәз (Мәскәү) тарафыннан рәсми балтаураклы мөһер бирелеп, эшкә җиңеллек биреләчәк. Мөһер куючы Нәзарәтнең күрсәткән адәме булып, айлык хезмәт хакы хөкүмәт тарафыннан биреләчәк. Архив дәфтәрләре турысында Нәзарәткә җирле идарәләр тыкшынмый, бәлки Мәркәз белән генә мөгамәлә күреләчәк. Хәзер бу рәвеш яхшы күренә. Аллаһ ахырын хәерле итсә иде.

## Петроград мәхәлләләре

16 сентябрьдә искә алынган комиссия белән Петроград мәхәлләләре һәм яңа җамигъ мәчете турында фикер алышу булды. Нигездә, Петроградта өч мәхәллә булып, беренчесендә имам Муса бине Җарулла Биги, Лотфулла бине Исхак, икенчесендә Фатих бине Хәсән Дивликамов, икенчесендә Камал Басыйров иделәр. 1920 елның маенда беркадәр адәмнәр белән яңа җамигъ мәчетне бер рәсми ачу өчен тупланган яшьләр (коммунист, студент, курсист кебекләр), яннарында мәхәлләләрдән байтак адәмнәр белән ачып,

башка мәхәлләләрнең бетерелүен игълан иткәннәр. Ләкин мәхәллә халыклары тарафыннан бу эшкә ризалыклары мәгълүм түгел иде. 2, 3 нче мәхәллә имамнары һаман мәхәлләләренең дәвам итүен телиләр. Шунлыктан Диния нәзарәте бу мәсьәләдә, байтак игътибар белән карау һәм киңәшләшүдән соң, бер карар чыгарды. Шундый ки, Петроградта бик кыйммәт төшкән, хәзер совет акчасына 10 миллион сумнан артык чыгымга мохтаҗ булган бер яңа җамигъ мәчет бар. Моның тәрбиясе халкы өстендә. Хөкүмәттән, әлбәттә, бер тиен юк. Шундыктан халыкны бер җамигъ мәчеткә туплау тиешле күрелде. Икенчедән, электән мәхәллә булып килгән өч мәхәлләнең бетерелүе мәхәллә халыклары тарафыннан игълан ителмәгән, бәлки аларның дәвам ителүен теләүләре беленә. Нигездә, Петроград кебек зур шәһәрдә бер дәфтәр һәм бер имам идарә итә алмый. Шунлыктан Диния нәзарәте ике тарафны да кайгыртып, бу карарны чыгарган иде. Җомга һәм гает [намазлары] бөтен халык өчен тик бер җамигъ мәчеттә үтәлер. Искә алынган җамигъ мәчет һәркайсы мәхәллә халыклары өчен җомга [намазы] уку мәчете булыр. Ләкин өч мәхәлләдә дәфтәр булып, аларның вазыйфаларын (исем кушу, җеназа, никах, талак эшләрен) элекке имамнары үтәр. Шул имамнар җомга һәм гает [намазлары] өчен җамигъ имамнары булып танылырлар, чират белән намазны үтәрләр. Өч мәхәллә эчендә җомга һәм гает [намазлары] укырга рөхсәт ителмәс. Укысалар, бишвакыт [намазны] укырлар. Бу карар иң файдалы рәвеш [булып] күренде. Ләкин искә алынган комиссия, аеруча Лотфый электән үк 3 нче мәхәлләгә имам куюга бик каршы булганлыктан, бу карарга һаман ризалык күрсәтмәде. Габдулла Гыйсмәти дә аның белән килеште, шуны да өстәде: «Муса әфәнде имам булса да, вазыйфаларын үтәми, читтә йөри, Мәхкәмә әдәпкә өйрәтсен. Шулай ук Фатих Дивликамов хезмәтендә түгел, ике елдан бирле читтә сәүдә итеп йөри, урыныннан алынырга тиеш». Мәхкәмә яңадан бу эшне караячак булды.

Лотыф Исхакый Нәзарәтнең карарыннан риза булмавында нык торды. Соңра мөхтәсиблегеннән һәм имамлыгыннан алуны тәкъдим итте. «Бөтен җамигъ мәчетнең эшләрен башкаручылар эшеннән азат итәчәк» дигән эчтәлектәге сүзне дә эштән алыну кәгазенә язды. Минемчә, эшеннән алынуны кабул итү, Нәзарәтнең элекке фикерендә нык торуы хәвефле түгел иде. Югарыда искә алынган зат та яхшы һәм начар тәэсир итү куәте булса да, Петроградтагы күпчелек аңа караячак түгел, шаять, аннан башка да җамигъны

сакларлар иде. Ләкин төрлечә фикер алышудан соң, хөкүмәт вәкиле Гыйсмәтинең фикере дә ят күренмәде. Соңра бу карарга килдек: «Мәхәлләләрнең җомга һәм гает [намазлары] туктатыла. Муса белән Лотфи җамигъ мәчеттә вәгазь сөйләүче, Камал Басыйри, Ягъкуб Габделхаликъ имам булып хисапланыр. Җамигъ мәчетнең халкы мәхәллә яки район булып бүленеп, имамнар идарәсенә биреләләр. Бу рәвешкә дә Лотфи мөхтәсиб риза булмаса да, күп тавышланмый гына рәсми кәгазьләрне алып китте. Ахыры хәерле булсын.

## Госман Коръәнен Төркестанга тапшыру мәсьәләсе

17 сентябрьдә искә алынган комиссия белән, Төркестаннан (Сәмәркандтан) алынып, Петроградка куелып, соңра 1918 ел башында безгә Диния нәзарәтенә тапшырылган Госман (Аллаһ аннан риза булсын) нөсхәсе дип мәшһүр Коръән шәриф турында фикер алышу булды. Мәсьәлә шул: Төркестан вәкиле бу Коръән китабының Төркестанга кайтарылуын сорап, Мәркәзгә (Мәскәүгә) Наркомнацка гариза тәкъдим иткән, Наркомнац бирүне һәм кайтаруны тиешле күреп, ЦИга (центральный исполкомга) тәкъдим иткән. ЦИ Диния нәзарәтеннән бу мәсьәләдәге фикерен сорады. Нәзарәт, бу Коръән китабы бөтен Эчке Русия һәм Сибириягә тапшырылганлыктан, бер махсус съездсыз кайтару хакына ия түгеллеген белдерде. Менә бу маддәдә искә алынган комиссия (Гыйсмәти бу Наркомда бер әгъза, Лотфи исә аларны яклау нияте белән) төркестанлыларның тарафын тотып, кайтаруны тәкъдим иттеләр. Төрле ысуллар торгызып, таләп итүләрендә нык тордылар.

Болар сүзләренең йомгагы: Коръән шәриф китабы – Сәмәрканд малы. Элек алардан тартып алынган, хәзер һәр милләткә үзенең милке кайтарыла. Шунлыктан бу Диния нәзарәтенә вакытлы сурәттә куелган әманәтне урынына тапшыру, Төркестан җөмһүриятенә кайтару тиешле.

Болар бу мәҗлескә, хаклары булмаса да, үз тарафларыннан тавыш бирү өчен Уфа имамнарыннан Җиһангир Абызгилдин, Зыя Камали әфәнделәрне китергәннәр иде. Ярдәм сорагач, тыймадык, мәҗлестә булдылар. Болар да комиссиягә сүз биргәнлекләреннәнме, нидәнме, аларның дәгъваларын куәтләделәр, Коръән китабын Төркестанга бирүне өстен күрделәр.

Җиһангир: «Кәферләр белән чолганып алынган җирдә торуы хәвефле, әрәм булу ихтималы бар. Ислам җиренә – Төркестанга – кайтарылсын», – диде.

Зыя: «Коръән китабы Төркестаннан тартып алынган, Нәзарәткә вакытлы сурәттә әманәт ителгән. Русия (Уфа) мөселманнары кимүдә, хәвеф-хәтәрдә, Төркестан ише исә парлак, яхшы вакытта әманәтне үзләренә тапшыру тиешле. Рус эчендә, бездә, әрәм булуы ихтималы да юк түгел», – диде.

Бу ике имамның элек искә алынган Коръән китабын Уфада саклау фикерләре, Диния нәзарәтенең фикерләрен яклау вазыйфалары булса да, бүген киресенчә хәрәкәт иттеләр. Зыя Камалиның хәрәкәтләрендә ят эш юк. Җиһангир әфәнденең фикере алдарга теләү кебек укылды.

Сабир казый, хәлендә тәҗрибә ителеп килгәнчә, төрлечә булуын югалтмады, икейөзлерәк сүз сөйләде. «Асыл Төркестан малы булганлыктан, үзләре җөмһүрият тәшкил иткәнлектән, Коръән китабы аларга кайтарылырга тиеш булса да, съезд карарыннан башка кайтару халык тарафыннан җаваплылык астында калуга сәбәп булганлыктан, Нәзарәт кайтара алмый», – диде.

Казый Риза җитди, тулы итеп аңлатып, кайтарылырга тиеш түгел икәнен бәян итте. «Кайтарылуны таләп итү тиешле булса, халык тарафыннан булырга тиеш, хөкүмәт әгъзасының вазыйфасы түгел. Хәзерге урыны имин, халыкның төрле рәвештә файдалануында булып, Төркестан мөселманнары килсәләр, үзләре дә монда торуына риза булулары өметле», – диде.

Кәшшаф казый: «Төркестанлылар кайтаруны сорасалар да, элекке хәлләреннән аңлашылуына күрә, сакларга көчләре булырмы? Элек яхшы саклый алмаганнар, яртысына якыны әрәм булган, кайбер сүрәләре бөтенләй, кайбер сүрәләренең кайбер җирләре әрәм булган. Нәзарәткә вакытлы тапшырылу мәгънәсе һичкайсы кәгазьдән мәгълүм түгел», – диде.

Ахыргы мәҗлестә рәис сыйфаты белән әйттем: «Һәр тарафтан сүзләр ишетелде, фикерләр аңлашылды. Нәзарәт бу мәсьәләдә янә уйлар, тиешле тапса, төзәтер. Тик төркестанлылар ашыгып сораганнар, чөнки анда саклардай бер дини басмаханәләре юк, казыйлар өчен бер казыйханә, мөфтиләр өчен бер фәтваханә Төркестанның бер җирендә дә торгызылмаган. Һәркайсылары махсус урыннарында рәсми эшләрне үтиләр. Бу кадәр иске китапханәләре сакланмаган, китапларының барысы да әрәм булган, ышанычлы

дини идарәләр, яхшы биналар торгызылгач, мөрәҗәгать итсәләр, бу мәсьәләнең яхшырак хәл ителүе өметле».

Йомгак: Коръән шәриф китабы, мәшһүр сүзгә күрә, Төркестан эше түгел, Мәдинә хезмәте. Бу эш нык булып җитмәсә дә, Төркестан хезмәте булмыйча, Гыйрак тарафыннан килгән, дип уйланыла. Бу Коръән китабы Хуҗа Гобәйдулла гаиләсендә булып, ул Ташкенттан Сәмәркандка күчкәндә булса кирәк, Сәмәркандка урнаштырылган. Русия гаскәре Сәмәркандны яулап алгач – Коръән китабы өчен җаваплы кешеләрнең түрәләргә сатып бирүләре дөресме яки гаскәри яулап алу хөкеме беләнме – Петроградтагы император китапханәсенә күчерелгән.

Шәригать мәсьәләсе: кәферләр ислам дәүләтенә хуҗа булсалар, мөселманнарның мал һәм милкен мәмләкәтләренә чыгару һәм күчерүгә ия булалар, бары [тик] үзләренә ия булмыйлар. Шунлыктан, Уфа имамнарының әйтүләренчә, Коръән шәриф китабы Төркестан малы һәм хакы булса да, яулап алыну һәм малларына ия булу белән аларның милекләреннән чыгып, Русия дәүләте милкенә кергән. Дәүләт исә үз милкенә кергән бу Коръән китабын Русия мөселманнарының гомуми вәкаләтен тәшкил иткән Диния нәзарәтенә Петроградтагы рәсми идарәләре арадашчылыгы белән биргән һәм тапшырган. Шунлыктан икейөзлелек белән карамыйча, шәригатьтчә дөрес булган ихлас караш белән каралса, Коръән шәриф китабы Төркестаннан киселгән, Эчке Русия мөселманнарының милекләренә кергән. Вәс-сәлам.

* * *

17 мөхәррәмдә дүшәмбе кичәсендә «Сөнән Әби Дауд» китабын укып һәм төзәтеп тәмамладым. [Һиҗри] 1339 елның 15 рабигыль-әүвәлендә укый башлаган идем. Нөсхәсе [һиҗри] 1283 елда Һиндстанда басылган, китап читләрендә «Миркать әс-сугуд», «Фәтх әл-вүдүд» исемле ике хезмәтеннән байтак язмалар, кайвакыт «Миркать»тән күчермәләр булган нөсхә. Бу нөсхәне остаз мулла Сәлахетдин Исхак хәзрәтләре Хиҗаздан китергән, башка китаплары рәтендә, мөселманнарга бүләк итеп, минем күзәтүемә һәм саклавыма тапшырган иде. Китапның язуы күркәм булса да, хатасы күп, аеруча хәрәкә һәм нокталарында бозык хаталары чиксез. Моның сәбәбе – Һиндстанда китапчылар һәм язучылар арасында гади адәмнәрнең булулары, боларның кәсеп нияте белән үзләре аңламаган нөсхәләрне күчерүләре. Бу китапның кайбер битләрендә

40–50 кадәр урында төзәтү булды. Инде китапта хата калса да, бик аз калгандыр, байтагын игътибар белән төзәттем. Кайвакыт китап читендә булган хаталарны төзәтү өчен вакытым мөмкинлек бирмәде. «Сөнән Әби Дауд»ның, элек хәҗәт вакытта мөрәҗәгать ителеп, күп җирләре укылса да, ләкин тәртип белән укып, өйрәнеп чыкканым юк иде. Инде Аллаһның ярдәме белән быел насыйп булды. Бу китап өчен күп шәехләрдән алган тоташу чылбырлары «бәрнамиҗ»[48] («Сәбәт») китабында язылып беркетелгән. Кыскача бер тоташу чылбыры, керешү тарихын язганда, 53 нче биттә язылган.

19 мөхәррәм кичәсендә имам Тирмизи Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Сүраның «Сөнән» китабын укырга керештем. Аллаһ Тәгалә тәмамларга һәм файда күрергә насыйп итсен.

## Ләбибә ханым вафаты

Чынлыкта, без барыбыз да Аллаһныкы һәм, чынлыкта, Аллаһка кайтачакбыз. Йә Аллаһ, безгә кайгыларыбыз өчен әҗер бир һәм аның урынына аннан да хәерлесен бир. Әҗерсез калдырма, бетермә. Әмин.

Казаннан 11 сентябрьдә язылып, Уфага килгән бер хатта зур фаҗигале бер хәбәр: Казан шәһәренең һәм вилаятенең зур остазы, мәшһүр кари Җамалетдин бине Шәйхетдин Хөсәеновның тормыш иптәше Ләбибә бинте мулла Һади ханым тиф авыруы белән дөньядан кайткан. Аллаһ аны кичерсен һәм рәхим кылсын. 1921 елның 8 сентябрендә вафат булып, 9 сентябрендә җомга көн Казанның олы мәйданында зур җәмәгать белән җеназа намазы үтәлгән. Җеназасында күп адәмнәрнең күзләреннән яшьләр аккан, хәтта аваз белән елаучылар да булган. Еларлар – хезмәте танылган, кадер-хөрмәте беленгән, зур яхшы тәэсире мәйданда күренгән иде.

Вафат булучы яшьлегендә атасы тәрбиясе һәм укытуында гарәп морфологиясе һәм синтаксисына яхшы сәләт хасил итеп, «Исагуҗи»дан хәбәрдар булып, 1896–1897 елларда минем йортымда хатыным Маһруй ханым тарафыннан ысуле җәдит белән иң беренче мәртәбә буларак төзелгән кызлар мәктәбенә 13–14 яшендә мөгаллимә ярдәмчесе итеп җәлеп ителде. Шул йорттагы мәктәптә

[48] «Бәрнамиҗ» дип бер кешенең остазларын һәм тоташу чылбырларын искә алган җыентыкка әйтәләр.

яшәп, Маһруй остазбикә тәрбиясендә гыйльми әдәбият һәм тәрбия ысуллары, өй һәм кызлар мәсьәләләрендә камилләшеп, мәктәпнең бер өлешен тәшкил итеп, мөгаллимнәр бүлегендәге күзәтүлек хезмәтен үтәде.

Шул арада Чиләбедә имам, мөгаллим булып, яшьли вафат булган олы бертуганы Мөнир әфәндедән байтак гарәп телен укып, гарәп телен белү куәтен арттырган иде. 1903 елда мәшһүр кари Җамалетдин бине Шәйхетдин Хөсәен белән никахлашып, Маһруй ханымның авыруы озак булганлыктан, мәктәпнең идарәсе һәм укытуы аның ихтыярына калып, остазбикәмнең вафатыннан соң кызлар мәктәбен 1905 елда үз йортына күчергән, мәктәп байтак зурайган, башлангыч, урта, бераз югары бүлекләрдән торган мәктәбендә 200 дән артык кыз укыдылар.

**Үзенең шәхси хәле:**

Гарәп телен белүе яхшы, дини гыйлемнәрдән хәбәрдар, шәкертләренә дөрес укыту һәм практика белән «Мишкәт әл-мәсабих» кебек мөбарәк китапны укытыр дәрәҗәгә ирешкән иде. Гарәпчә укуында зур мөгаллимнәр кебек хатасыз, гарәп морфологиясе һәм синтаксисы кагыйдәләренә туры килгән рәвештә укыр иде. Коръән укуы бик дөрес, хатын-кыз укуына нисбәт белән генә түгел, бәлки галимнәр һәм имамнарның укулары үлчәве белән дә яхшы иде. Дине куәтле, яхшы диндар, шәкертләрен дин рухында тәрбияли иде. Гаять тырыш, түзем, нык, дәртле иде. Укытуында бик күпкырлы итеп укытыр, осталык белән аңлатыр, сай дәрес бирү белән канәгатьләнмәс, аңлатыр, белдерер иде. Шәкертләреннән байтак кызлар һәм кайбер хатыннар Коръәнне дөрес һәм яхшы укуга осталык хасил иттеләр, яхшы практикага ия булган рәвештә гарәп морфологиясе һәм синтаксисын өйрәнделәр, гарәпчә гыйбарәләрне дөрес укып, туры аңлау осталыгына яраклы булдылар. Савабы үлгәч тә килеп тора торган байтак сәдака калдырды. Кырык яшен тутырыр-тутырмас ирен, дүрт баласын, атасы урынында торган сөекле остазын калдырып, ахирәткә сәфәргә китте. Аллаһ сәфәрен мөбарәк итсен, рәхмәтенә ирештерсен, безнең өчен һәм варислары өчен күп савап запасы итсен. Ире Җамалетдин кари – икътисади эшләрдә вәкилебез. Ул да байтак авыр хаста икән. Аллаһ аңа хәерле сихәт бирсә иде. [Һиҗри] 1340 елның 21 мөхәррәме, җомга көн. Соңгы хәбәрләргә күрә, ире савыгу юлында икән.

## Төркиянең Грецияне җиңүе

17 сентябрь көннәрендә телеграмма Төркиянең Грецияне көчле җиңүен, Греция гаскәренең артык тар-мар ителгәнен хәбәр итте. Августта Грециянең җиңүче булуы, иске шәһәрдән ары хөкүмәтнең пайтәхете булган Анкара шәһәренә якынлашуы ишетелгән иде. Хәтта Анкарадан күченә башлаулары газеталарда күренә иде. Бу сентябрь урталарында төрекләр көчле һөҗүм иткәннәр, ун көннән артык канлы сугыш һәм үтерештән соң, төрекләр җиңгәннәр. Греклар әсбапларын, яралыларын, хәзинәләрен ташлап, таркалып качарга мәҗбүр булганнар. Бу шатлыклы хәбәр сәбәпле, Истанбулда зур шатлык булып, җамигъ мәчетләрдә зур-зур җәмәгатьләр белән шөкранә догасы укылган. Грециянең яклаучысы, ярдәмчесе булган инглиз хәвеф һәм борчылуга төшеп, 3–4 диңгез көймәләре керткән. Төркестан һәм башка шәһәрләрдән хәлләр һәм хәбәрләрдән мәгълүмат алу өчен чыккан, Анкара депутатлары мәҗлесе җөмләсеннән, истанбуллылар бу көннәрдә Русия эчендә сәяхәттә, очраклы рәвештә Уфада булып, өстенлекле кунак итү ясап, мөфти-казыйлар һәм кайбер имамнарны чакырып, бер мәҗлес корды.

22 сентябрьдә Мәскәүдә булган Төркия илчесе Гали Фуад пашага, Анкара депутатлары мәҗлесенә ирештерү өчен, Русия галимнәрен һәм башкаларны колачлау белән, бу тәбрикләү һәм дога телеграммасын бирдем:

«Русия мөселманнары төрек гаскәрләренең туфракларына золымлык итү рәвешендә кергән, хыянәтче дошманнары булган греклардан өстен чыгуларына чын күңелдән шатланалар, төрек гаскәрен тәбрик итәләр. Якын вакытта дошманны катгый җиңеп, төрек җиреннән куу хакында руханилар һәм халкы ихласлык белән догалар кылалар».

Соңгы хәбәрләргә күрә, Греция гаскәре көчле рәвештә җиңелеп, төрекләр әһәмиятле рәвештә өстенлек тапканнар.

Янә соңгы хәбәр: Греция хөкүмәте гаскәрен Анатолиядән алачак икән. Хәерле рәвештә мөселманнарның үз җирләре, үз мәмләкәтләре үзләренә кайтарылса иде.

Җир йөзендә калган бер ислам хөкүмәте бөтен мөселманнар өчен дини мәркәз урынында калган. Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә рәхмәте һәм юмартлыгы белән искә алынган Төркия мөселман хөкүмәтенә өстенлек биреп, дин һәм сәясәт мәсьәләләрендә

урталыкта булып яшәсә иде. Дин һәм милләт өчен файдалар тудырса иде.

3 октябрьдә Мәскәүдән Төркия илчесеннән алынган телеграмма нөсхәсенең тәрҗемәсе:

«Русия мөселманнары мөфтие Галимҗан әфәндегә.

Анатолиядә өстен чыгу мөнәсәбәте белән сезнең тәбрикләү телеграммагызны алдым һәм Анкарага җибәрдем. Бөтен ислам гәләменең мәгънәви ярдәме безнең дошманнан тулы өстен чыгуыбыз өчен иң яхшы ышаныч күрсәтүче булып чыгабыз. Төркия хөкүмәте исеменнән мин сезгә һәм барча мөселманнарга шатлыклы хисләрен белдергәннәре өчен үземнең самими рәхмәтемне җиткерәм.

Мәскәүдәге Төркиянең гадәттән тыш хәлләр илчесе Гали Фуад».

* * *

Обсерваторияләрнең хәбәрләренә күрә, бу [һиҗри] 1340 елның сәфәр ае шимбә көн 1 октябрьдә көндезге 2 сәгать 26 минутта туа. Ул кичәдә күренерлек дәрәҗәгә җитешә алмаганлыктан, фәкать дүшәмбе көн – 1 сәфәр [дип] игътибар ителү мөмкин. Диния нәзарәте Мәгариф бүлегенең игътибары һәм календаре дә дүшәмбе көнгә.

Бу октябрь башында яңа хезмәтебезгә тулы айлар игътибары белән бер ел тулды. Өч елның өчтән бере үтте. Быел зур афәт күрмичә, гади эшләр белән үткәрелде. Тик архив мәсьәләсе зур дулкынлану булды. Үткән ел ноябрендә метрика дәфтәрләре хөкүмәт кулына алыну тиешле, дигән Декретка таянып, дәфтәрләр торган архивны ЗАГС оешмасы алып, бөтен идарәсен Нәзарәтнең элекке архивисты Арслангәрәй Еникиев кулына тапшырган. Ул исә куркаклыгы сәбәпле, Нәзарәттән архивны кисеп, ЗАГСка хезмәт итеп килде. Бөтен метрический справкаларны ЗАГС исеменнән үтәп килде. Кабат мөрәҗәгатьләребездән соң гына Мәркәздән бер комиссия килеп, җирле идарә әгъзалары да катнашкан мәҗлестә бер карарга килеп, Мәркәздән хәбәр җибәрәчәк булып китте. Бу мәсьәлә үткәч тә, сентябрьдә яки аз гына элегрәк Бөре өязенең 5 нче район мөхтәсибе мулла Фәезхан Дауди ваба белән вафат булган. Вафат булучы Оренбургның Кәрвансарай мәчете имамы Сөләйман ахунда, Кышкарда яхшы укыган. Төркиядә дә булган укуы аңлы, диндар кеше, каләме һәм язуы да дөрес иде. Оренбургта «Дин вә мәгыйшәт» журналында байтак еллар дини-гыйльми һәм каләм

куәте белән хезмәт итте. Соңра мөхтәсиблек хезмәтенә сайланып, тирә-ягында игътибар казанып тормыш итүдә иде. Кыскасы, бу заман өчен тирә-ягында ганимәт [буларак] беленерлек кеше иде. Яше алтмыштан үтәр-үтмәс дөньядан кайтты. Аллаһ аны кичерсен һәм рәхим кылсын.

Октябрь ахырларына кадәр Уфа базарында бәяләр: арыш онының поты – 100000 сум, бодай – 240000 сум, печән поты – 20000–25000 сум, кишер, чөгендер, шалкан – 25000–30000 сум, бәрәңге 30000–35000 сум, алабута оны – 40000–50000 сум кадәр, утын колачы – 100000–120000 сум, йомырканың данәсе – 1000 сум, бер шешә сөт – 10000–12000 сум, итнең кадак хисабы – 3000–3500 сум, бал – 15000, май – 15000 сум, сары май – 15000–20000 сум кадәр, гади елкы малы – 800000 сум, гади сыер – 1500000 сум һ.б. Иң арзан нәрсә – хәзерге хөкүмәтнең акчасы. Алтын акчага 36000 сумы – 1 сум. 10 сумны 360000 гә алыштыралар. Мәскәүдә 400000 нән югары икән. 40000 сумы 1 сум була.

## Янә ЧКга чакыру

20 октябрьдә ЧКга чакырылдым. Боларның чакырулары хәвеф-хәтәрлерәк булганлыктан, Аллаһка сыеныбрак барсам да, яхшы мөгамәлә күрсәттеләр. Китапчы Нургали бине Сәйфулла Хәсән үзе тоткарлангач һәм сәүдә китаплары конфискацияләнгәч, Диния нәзарәтеннән алган элекке мөфти Сафа Баязидов бастырган «Бәдьэл-мәгариф», Әзкәрес-саләһ» эчтәлекләрен үз эченә алган «Тәзкирә» исемле китапларны да конфискацияләгәннәр. Боларның бер өлеше Нәзарәтнең үз малы иде. Трибунал мәхкәмәсендә каралып, Нургали һәм әйберләре кайтарылгач, искә алынган «Тәзкирә» кайтарылмады. Нургали әфәнде Уфадан бөтенләй күчеп, Перьм вилаятенә имам булу өчен киткәч, ЧКда калган «Тәзкирә» китаплары хакында: «Ала алсагыз, Нәзарәткә булсын, алыгыз», – дип киткән иде. Шуңа күрә Нәзарәт хакы булганын һәм Нургалинең багышлаган өлешен катыштырып, искә алынган китапларны сорап, ЧКга мөрәҗәгать иткән идем. Бу мөрәҗәгатем бер өмет белән түгел иде, халык мәкаленчә «Ятып калганчы атып кал» дигән эчтәлегенчә бер эш иде. Ни сәбәпледер ЧК түрәсе мөрәҗәгатемне игътибарга алып, китапның тик дини китап икәнен тикшерә: «Әгәр дини китап булса, сораганың буенча китапларны кайтардым», – ди. Мин

яңадан, дини һәм рухани китап икәнен тел белән бәян итсәм дә, язып җибәрүне сорады. «Яхшы», – дидем.

Кузгала башлагач, иң мөһим бер мәсьәләне кузгатты ки, июнь аеннан бирле хөкүмәтнең финанс бүлеге үзләре аркылы безгә җибәрелгән акчаларны безгә тапшырмый тора. Мәсьәләсе үткәндә язылды. Бу турыда үзләренә кабат мөрәҗәгать ителде. Мәркәзгә дә шикаять ителде. Акча саклау, акча йөртү турында булган соңгы Декретлар каршы булып, Мәркәздән килгән бер телеграмма хәбәренә таянып, бикләп тоталар иде. Бу мәсьәлә Мәркәздән килгән Гыйсмәти әфәнде рәислегендә булган тикшерү комиссиясенә дә аңлатылган иде.

Инде ЧК түрәсе бу турыда җирле исполкомга биргән мөрәҗәгать кәгаземне тотып: «Акчалар хакында хөкүмәтнең (финанс комиссариатының) карары дөресме, нөсхәсен миңа җибәрсәгез, финанс бүлегенә язармын, банк акчагызны тапшырыр», – диде.

**Бу мәсьәләдәге өйрәнү.** Акча турында боларга кисәтү булган. Безгә тапшыру өчен бер сылтау эзләп, миңа хәбәр бирә, туры, ачык белдерми. Кечерәк кенә булган китап мәсьәләсен сүз башы итеп, бу мәсьәләне сүз арасында гына искә ала. Өмет ки, бу өйрәнү дөреслеккә чыгар, китапларны һәм акчаларны, үзе әйткәнчә, кайтарыр.

## Татарстанның Мәркәздәге вәкиле белән әңгәмә

22 октябрьдә Мәркәздә Казан хөкүмәтенең вәкиле булып торучы Шаһиәхмәдов Мәхмүт иптәш юлыкты. Бүлмәмдә озак сөйләшеп утырдык. Казан һәм Башкортстан хөкүмәтләре идарәләрендәге һәм башка шәркый эшләрдәге хәлләрдән хәбәр алу өчен, Мәркәздән җибәрелгәне аңлашыла, хөкүмәтнең байтак уңлашканын белдерә. Безнең Нәзарәтнең ни яклардан тарлык күрүен һәм ни хәҗәтләре һәм таләпләре барлыгын сораша, кирәк була калса, хәбәрдар булуым тиешле», – дип кенә сораса да, «Мәркәздән үк шундый хөкүмәтләрдән боерылмадымы икән» дигән караштa булдым.

Кыскасы: хәлләр һәм мөгамәләләрдән аңлашылуына күрә, хөкүмәтнең уңлашуы шактый ук булган. Шунлыктан Диния нәзарәтенә карашы да байтак яхшыланган кебек сизелә. Бөек һәм Олуг Аллаһ ахырыбызны хәерле итсен.

22 октябрьдә шимбә көн ЧКга искә алынган ике маддә турында, таләп ителгәнчә, язу җибәрелде. Нәтиҗәсе нинди булыр? Иншалла, хәерле булыр.

Нәзарәткә иганә мәсьәләсендә ризыклар белән иганәне яраклы күреп, мөхтәсибләргә мөрәҗәгатебезгә күрә, яхшы хәрәкәт сизелә башлады. Төрле яктан хәрәкәтләре ишетелә һәм аз-маз килә дә башлады. Акчаның хөкүмәт тарафыннан туктатылуына очравы тирә-якка ишетелгәнлектән, акча җибәрүләре азайды. Тик почта аркылы сирәк кенә килә. Якын җирләрдән ризык иганәсе, шаять, яхшы булса кирәк. Шаять, вазыйфаларны да азык белән, уртача кыйммәте белән бирелә башлар. (Азыкның чыккан җирендәге бәһасенә юл чыгымнарын кушуны уртача бәһа [итеп] хисаплап торабыз).

## Риза казыйның Богырслан сәфәренә әзерлеге

Октябрьдә бер мөһим вакыйга – Риза казыйның Богырсланга бару мәсьәләсе – булды. Югарыда искә алынган затның икътисади хәлләре зәгыйфь, барлык дәртен каләмгә биргәнлектән, икътисад тарафына карау өчен башында өлеш тә калмаган, калса да, бик аз. Китаптан башка мөлкәт хасил итмәгән, канәгатьлек белән, булганча, юмартлык белән тормыш сөрергә өйрәнгән. Шунлыктан хәзерге хәлләр югарыда искә алынган затка авыр тәэсир итте, байтак бурычлы булды. Бүген 1 миллион кадәр бурычы бар, үтәве күренми.

Богырслан өлкәсе халкы бер дини мәдрәсә ачып, дәвам иттерү фикерендә булып, казый җәнапләренең хәлләрен белүче таныш-белешләре 4–5 айлык мөгаллимлек хезмәтенә чакырдылар. Айлык [хезмәт хакы итеп] ике поттан артык азык һәм 20000 сум акча бирмәкче булдылар. Казый әфәнде һәрвакытта дәрес хезмәтеннән сакланып килеп, хәтта үткән кышта Диния нәзарәте ачкан курсларда мөгаллимгә бик көчле ихтыяҗ хәленә килгәндә дә, кабул итмәгән иде. Ләкин быел Богырсланга баруга күңел куйды. Башта бөтенләй казыйлыктан китү фикерендә булып, соңра дөресрәк фикерләп, гаиләсен калдырып, вакытлыча үзе генә бару фикеренә килгән һәм Нәзарәткә рөхсәт сорау гаризасын тәкъдим иткән иде. Богырслан мөхтәсибеннән дә курслар ачулары һәм казый әфәндене вакытлыча мөгаллим итеп җибәрү турында язулар килгән иде. Нәзарәт бу мәсьәләдә озак фикергә дә хаҗәт күрмичә, мөмкинлек

бирмәде. Мондый сәбәпләрдән: 1) ноябрьдә минем (мөфтинең) һәм Кәшшаф казыйның Мәскәү сәфәре сәбәпле, Нәзарәттә булмавыбыз күренеп тора; 2) Нәзарәттә мөһим әгъза була торып, икътисади даирә сәбәпле, читкә чыгуы Нәзарәт һәм милләт өчен бер кимчелек [булып] күренә.

Икътисади хәлләре өчен зур иганә, аерым игътибар ителү мөмкин булмаса да, һәр айда пот ярым кадәр он, чиктән тыш өстенлекле буларак иганә итүне Нәзарәт йөкләде. Башкаларга сентябрьдән башлап 80000 сум акча һәм бер пот ризык билгеләнеп, югарыда искә алынган зат җәнапләренә 1,5 пот биреләчәк булды. Шулкадәрлегә канәгатьләнеп, Богырсланга бару фикереннән кайтты. Бу кадәр белән генә тәмам юмартлык хасил булмаса да, яхшыртылды.

Богырсланга бару белән дә шулкадәрдән артык җиңеллек булуы ерак иде. Гаиләсен калдырып китсә дә, ике җирдәге чыгымнар, әлбәттә, бәрәкәтсезлек китерәчәк иде. Икенчедән, 4–5 айлык аерым хезмәткә китеп тә, Нәзарәттән айлык хезмәт хакы алып торуы вөҗданча авыр эш иде. Ахыры хәерле булсын.

## Мәскәү сәфәре

Байтак вакытлардан бирле Нәзарәт тарафыннан Мәскәү сәфәре зарури [булып] күренеп килә, Мәхкәмәнең күп эшләре өчен Мәркәзгә мөрәҗәгать [итү] тиешле иде. Моның өстенә, Русия эчендә 4–5 вилаятьне каплап, ничә миллион кадәр халыкны, аеруча мөселманнарны каплаган ачлык Мәхкәмәнең һәм Мөфтиятнең кайгыртулы рәвештә хәрәкәтен, өметле булган тарафлардан иганә җәлеп итүгә тырышлыгын тиешле итә иде. Бу икенче максат (ачлык) өчен дә Мәркәзгә барып, рәисләр белән очрашу һәм сөйләшү тиешле, андагы күрше ислам мәмләкәтләренең вәкилләре белән сөйләшеп, артык мохтаҗлык эчендә калган мөселманнарның хәлләрен белдерү тиешле иде. Мәркәздән килгән комиссия һәм башка рәсми адәмнәр дә бу максат һәм тәкъдим өчен искә алынган сәфәрне тиешле күрәләр иде. Шунлыктан бу 1921 елның ноябрь башларында әлеге сәфәр ниятләнә. Мин һәм юлдашым да казый Кәшшаф Тәрҗемани булып сәфәр ителсә кирәк. Мәхкәмәнең икътисади хәлләре бик яхшы булмаса да, мондый заруриятлар өчен, авырлык белән булса да, чыгымнар кылмый чара күренми. Ачларга ярдәм турында хәрәкәт иткәннәргә хөкүмәт тарафыннан юл

чыгымнары бирелсә дә, безнең идарәнең бу хезмәте хәзергәчә танылмаганлыктан, файдалану юлы күренми. Шаять, Мәркәз хөкүмәте белән танышканнан соң юл ачылса кирәк.

30 октябрьдә Мәскәү сәфәре турында бу рәвешле карар ителде. Карар кәгазе сурәте:

«Диния нәзарәтенең кайбер рәсми хәҗәтләрен булдыру өчен байтактан Мәркәзгә мөфтинең сәфәрен Нәзарәт тиешле күрә иде. Мәмләкәттә 4–5 вилаятьне каплаган көчле ачлык һәм кыйммәтчелек, иң авыры мөселманнарда булган хәлдә, Нәзарәтнең һәм мөфтиятнең бу мәсьәләдә кайгыртулы хәрәкәтен, мөмкин кадәр тырышлык куюын кабул итә. Бу тәкъдим өчен дә Мәркәз сәфәре иң беренче тиешле адым һәм мәҗбүри эш башы иде. Шуңа күрә бу ноябрь башыннан калмыйча, мөфтинең һәм аңа ярдәмче иптәш буларак байтак идарәләрдә танышлыгы булган казый Кәшшаф Тәрҗеман белән бергә Мәскәүгә сәфәрләрен Диния нәзарәте билгели һәм карар кыла. Кассада тарлык булганлыктан, тик 1000000 сум юллык [акча] билгели. Җитмәгән микъдарын, хисаплаганнан соң, Нәзарәт үтәячәк була.

Мөфти Галимҗан бине Мөхәммәдҗан Баруди. Казыйлар: Ризаэтдин бине Фәхретдин, Кәшшафетдин Тәрҗемани.

Нигездә, бер кеше баруга риза булып, берьюлы комитетның ике әгъзасын командировать итүдә аерым фикердә калып, имза куйдым Мөхәммәдсабир Хәсәни, Мөхлиса Буби».

Кыскасы, Мәскәүгә ике адәм баруның сәбәбе карар мәҗлесендә, аннан элек кабат фикер алышынган һәм Мәскәүдән килгән комиссия дә шулай кирәксенгән иде. Сәбәбе: рәисләрне, төрле дәүләтләрнең вәкилләрен күрү, тиеш булса, вәкилләре аркылы дәүләтләренә язу белән мөрәҗәгать итү өчен, әлбәттә, минем (мөфтинең) үземнең сәфәр зарур күрелә. Бу эшкә исем, абруй һәм шөһрәт, әлбәттә, тәэсир итә. Юлларның кулайсызлыгы, көз көннәрендә сәфәрнең авырлыгы, Мәскәүдә дә 15 көн – 3 атна булса да тәрбиясез ят тормыш, картлык вакытына яраклы хәлләрдән түгел. Шулай да бер тарафтан Диния нәзарәтенең йомышлары, икенче тарафтан гомум мөселманнарны каплаган ачлык бәласе бу сәфәрне тиешле итә. Шунлыктан милләт тә бу эшне тели. Янә андагы Төркия, Иран, Әфганстан илчеләре, Төркестан, Хива вәкилләре белән танышу һәм ачлар турында фикер алышу хөкүмәт күзендә Нәзарәтнең әһәмиятен арттыра, кадер-хөрмәтен белдерә торган хәл булса кирәк. Шунлыктан иганә максаты кулга керәме,

юкмы, Нәзарәт өчен булган бу теләкләр һәм өметләр бөтенләй бушка чыкмаса кирәк. Минем олыларга мөрәҗәгать итеп, бер дәрәҗәдә колакларын һәм карашларын җәлеп итү өчен мөфти сыйфаты һәм исеме белән булып, кечкенә йомышлар өчен азрак юл белгән, андагы кайбер түрәләр белән таныш, рус каләмен [язуын] һәм телен белгән бер иптәшнең тиешлеге шөбһәсез бер мәсьәлә [булып] күренә. Бөтен Казакъстан, Эчке Русия һәм Сибириянең 65 яшьлек мөфтие мондый вакытта мондый олы йомышлар белән барсын да, үзе генә барсын, дип әйтү – мөфтилек дәрәҗәсен танымау өстенә, эшне аңларга теләмәү, дип уйларга мәҗбүр итә. Сабир казыйның кабат фикер алышудан соң да, аерым фикердә калып: «Бер генә адәм барса, җитә», – дип әйтүе бер аңлашылмаслык табышмак [булып] тоела. Аеруча 10 сентябрьдә Мәскәү комиссиясе белән катыш мәҗлесебездә әлеге ике адәмнең сәфәрләренә карар бирелеп, югарыда искә алынган зат шартсыз имза куйган иде. Берьюлы ике әгъзаның вакытлыча әзер булмавыннан Мәхкәмәнең эшләренә зыян киләчәк түгел. Өч әгъза тәмам һәр хезмәтне үтәр өчен җитә. Шәригатькә һәм уставка яраклы [итеп] үтәячәкләр. Аллаһ Тәгалә ярдәме белән. Бер кимчелек булса – чыгымнарның күплеге, кассаның кысынкылыгы. Эшнең әһәмиятенә күрә, моның да тәэсире юк [дип] хисапланырга тиеш. Милләт үз өстенә алачак. Үз өсләренә алып та торалар. Аң ияләреннән бер адәм дә авырсыну күрсәтмәсә кирәк, иншалла.

Рабигыль-әүвәлдә, ноябрь башында сишәмбе көн төштән соң 19 мөхәррәмдә өйрәнүенә керешкән «Сөнән Тирмизи»нең беренче яртсын тәмамладым. Диния нәзарәте китапханәсе нөсхәсеннән укып, кайбер җирләрен дөресләдем, кайбер җирләренә аңлатмалар теркәп куйдым. Шул сәгатьтә ахыргы яртысын башладым. Моның өчен Аллаһка мактау.

*БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ*

[Һижри] 1340 елның рабигыль-әүвәлендә (1921 елның 7 ноябрендә) дүшәмбе көн иртәнге сәгать 10 да иптәшем казый мулла Кәшшафетдин бине Кауваметдин Тәрҗеман белән йортыбыз булган Диния нәзарәте бинасыннан, гади эш чанасына утырып, Мәскәүгә бару нияте белән вокзалга юнәлдек. Кадерле тормыш иптәшем Гайшә хатын «Хәерле сәфәр, сәламәт кайту» догасын укып, капкага кадәр килеп, тилмереп, озатып калды. Мин дә капкада борылып, күзләремне тутырып ачып карап, саубуллашу сәламемне әйтеп, аерылдым. Аллаһ безне иминлектә һәм уңышта җыйсын.

**Бу уңайсыз вакытта авыр сәфәр ник кирәк булды?**

1. Бу 1921 елда 11–12 вилаятьтә ачлык һәм кыйммәтчелек хөкем сөрә. Бу афәт иген булмау һәм уңмау сәбәпле булса да, ләкин үткән елдагы җирле хөкүмәтләрнең алык-салыклары үлчәүсез, бәлки тапканны себереп алу юлынча булганлыктан, халыкның байтагында булган берәр еллык саклык кибәннәре беткән, хәтта 1921 ел сабаны өчен орлык өлеше дә калдырылмаган иде.

Руслар бу мәсьәләдә бердәмлек белән булып, байтак азык яшереп калдыра алсалар да, мөселманнар яраклы була алмаганнар. Араларындагы таркаулык, доносլардан, үзләренең элеккедән бирле хөкүмәттән золымлык күреп, куркак булып килгәнлектән, барлык нәрсәләреннән аерылганнар иде. Шунлыктан бу ачлыкның артыграк начар тәэсире мөселманнарга булды. Мөселманнарны төрле рәвеш белән һәлак итте. Ачлык һәм, шул сәбәпле, ваба, тиф таралуы, күченеп китү юлына кереп, максатларына җитә алмыйча, юлларда әрәм булу кебек афәтләр бик күп зарар итте. Бу гомуми ачлыкның аеруча мөселманнарда булган таралуы гаять фаҗигале булганга, Мөфтият тарафыннан да бу мәсьәләдә хәрәкәт итү, мөмкин булган кадәр азык белән иганә итү зарур күрелде. Мәскәүдә булган рәисләр белән фикер алышып, иганәләр җәлеп итү юлларын җиңеләйтү, мөмкин булса, Сибириядән, Төркестан, Хәрәзем һәм башка күрше җирләрдән ярдәм сорау, әсбапларында киңәшләшү тиешле күрелде. Бу мәсьәләдә төрле җирдән фикер бирүчеләр, бу хәрәкәтнең тиешлеген бәян итүчеләр дә күп булды.

2. Икенче сәбәп – Диния нәзарәтенең байтак мәсьәләләре[49]. Уфада торып, җирле идарәләрдә, хатлар һәм гаризалар белән Мәркәздән хәл ителми. Шунлыктан Мәхкәмәгә байтак уңайсызлыклар туа. Мәркәзнең үзенә барып, хосусый телдән мөрәҗәгать тәэсирсез булмый. 1920 елдагы сәфәрем дә, 1921 ел кышындагы Кәшшаф казыйның сәфәре байтак файдалы булган иде.

Шушы ике сәбәпле, юлның авырлыгына карамыйча, чыгымнарның артык күп булуына игътибар итмичә, бу сәфәр өскә йөкләнде. Аллаһ Тәгалә хәерле нәтиҗәләр бирсә иде.

**Төп чыгымнар.** Йорттан вокзалга төшергән өчен – 35000 сум, әйберләрне вокзалга урнаштыру өчен йөк ташучыга – 30000 сум, юл азыклары – 139750 сум, Мәскәүдә торачак йорт хуҗасына бүләккә бал (10 кадак), май (5 кадак) – 280000 сум. [Барлыгы] була – 806750 сум. Бу микъдар белән юлга чыгылды. Саклык парәсе булып, кайтыр өчен дә хисапланып 1000000 сум алынды.

Көндезге сәгать 12 дә киләчәк поезд вакытыннан бер сәгать кичегеп килде. Бер сәгать вокзалда торды. Петроградлы Хөсәен Кәримов исемле егетнең тырышлыгы, яхшы хезмәте сәбәпле, билетларыбыз белән икебез бер диванга урнаштык. Бу да бер баш

[49] Мәскәүдә фикер алышу тиешле таләпләр, Нәзарәт хәҗәтләре: 1) мал эшләрен тәэмин итү, күрәлмауны җиңеләйтү, 2) архив турындагы тапшыру, рәсми рәвештә Нәзарәткә кайтару, 3) дини мәктәпләрне милләткә кайтару, хөкүмәтнең конфискацияләвеннән котылу, 4) имамнарны һәм дини мөгаллимнәрне гаскәри хезмәттән һәм башкалардан азат итү, 5) ихтыярлы иганәнең милләт ихтыярында калдырылуы, 6) типография ачарга мөмкинлек бирү, хосусый типография ачылганчы, хөкүмәт типографияләреннән файдалануны сорау, 7) һәр җирдән иганә юлы белән Нәзарәткә багышланган ризыкларны күчерү, 8) дини укытуларга (мәктәп, мәдрәсә, вакытлы курсларда) мөмкинлек бирү, 9) варисларның ризалыклары белән мирасларның шәригатьчә бүленүе, ачлык турында рәисләр белән фикер алышу, Азык-төлек идарәсе белән.

Төркестан вәкиллегенә мөрәҗәгать: 1) ризыклар белән ярдәм итүләре, 2) Эчке Русиядән Төркестанга мөһаҗир мөселманнарны урнаштыру. Хәрәзем вәкиллеге белән фикер алышу ачлык, мөһаҗирлек мәсьәләләрендә. Әфган вәкиллегенә мөрәҗәгать. Иран илчелегенә мөрәҗәгать. Төркия илчелегендә: 1) ачлык турында фикер алышу, 2) Анатолиягә мөселман мөһаҗирләрен күчерү мәсьәләсе. Бу турыда вакыт булу мөмкинлеге белән хөкүмәт белән фикер алышып, рәсми ярдәм һәм булышу хасил ителер. Америка вәкиллеге: мөселманнарның аерым көчле ачлык, фәкыйрьлек һәм мохтаҗлыкта калулары бәян ителер.

уңыш булды. Билет алып та урнаша алмаган кешеләр күп булды. Мәшәкать белән вокзал хезмәткәрләре аркылы кассирның кәефен табып, билет алганнан соң, билетка вагон номерын яздырыр өчен янә бер җәфа чигү тиешле иде. Безнең Хөсәен юлдашның поезд түрәләре белән яхшы танышлыгы булганлыктан, безнең бу эшләребез җиңел үтәлде, Аллаһка мактау булсын. 2 сәгатьтән соң поездыбыз хәрәкәт итте, Аллаһка тапшырдык.

## Сәфәр – җәһәннәмнең бер өлеше

Бу мәшһүр мәкаль хәдис булып җитмәсә дә, зур арттырулы сүз булса да, сәфәрнең мәшәкать булып, гади һәм гади булмаган җәфаларга сәбәпче булуын аңлата. Күп тәҗрибә белән әйтелгән сүз. Мин сәфәрләрдә күп йөрдем. Шәригать, бәндәләргә мәрхәмәт итеп, гади мәшәкатьләрне мәшәкать [дип] игътибар итеп, мосафирга уразаны кичектерү, намазны кыска уку кебек җиңеллекләр белән булышкан. Хәдис белгечләренең күпчелеге, фәкыйһләрнең кайберләре фикеренчә, иртәнге намаздан [кала] башка сөннәт [намазларның] сәфәрдә калдырылуы шәригатьттә дөрес күрелгән.

Ләкин кайбер табигатьләргә күрә, гади эшләр дә авыр була, чикләнүчелек дәрәҗәсенә ирешә. Җөмләдән, мин яшь һәм сабый вакытымнан бирле кешеләр җыелган урында һәм гомуми бәдрәфләрдә тәһарәт боза [йомышны үти] алмыйм, оялу җиңә һәм үзенең тәэсирен йөртә. Сабыйлыгымда мәктәп һәм мәдрәсәдә тәһарәт бозу бик мөшкел хәл була иде. Олы йомыш исә бик сирәк мөмкин була иде. Бу хәл һаман бар. Бик тыныч һәм аулак булмаган җирләрдә гаҗизмен, рәхәт бушана алмыйм. Ут көймәләрендә (поездларда) элекке заманнарда бик кулай, киртәсез булса да, бик авырлык белән бушана идем. Тимер юл вагоннарында хәлем бик мөшкел була иде. Бушату, бәвел агызуга кадәр мәшәкатьле булып, эчемдә мәҗбүри тоту бәласе туа иде. Бәдрәфләрнең бер дәрәҗәдә чисталыклары була торып, шул бәлага дучар була идем. Инде табигать нәфрәтләнерлек сәбәпләр хәзерге заман вагоннарында күп арткан. Шакшылык, сусызлык, гади юлчылар өчен урыннарның барысы да өченче дәрәҗәдә булганга, тыгызлык, ишектә бик күп көтеп тору кебекләр. Бу сәбәпле, минем өчен тәһарәт бозу мәсьәләсе бер гади булмаган чикләнүчелек, бер авыр мәшәкать булды. Дүшәмбе, сишәмбе көннәрдә бик өлешчә микъдарда

тамчыдан артык, ял итәр дәрәҗәдә, бушана алмадым. Тыелып, кәефсез килдем. Эчем исә (бу сәгатьтә өйдән чыкканыбызга 54 сәгать үтте) бөтен бу вазыйфасын оныткан дәрәҗәсендә. Сишәмбе көн, чәршәмбегә каршы төндә һәм чәршәмбе көндезендә, Аллаһка мактау булсын, табигать бераз гадәти булдымы (хәер, Самарада бәдрәфне бераз чистарттылар), бәвелне яхшы бушата башладым. Кыскасы, һәркемгә сәфәрнең җәһәннәм төре бар. Рәсүлуллаһ (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) «Сәфәрдә эшегез бетсә, тизрәк кайтыгыз. Мосафирның кеше хәҗәтләре вакыты алмашына, гадәти булмаган эшләргә очрый» дигән эчтәлегенә якын хәдис сөйләгән.

## Тимер юлда тәяммүм

Вагондагы юынгычларда (уборныйда) су булмавы мөшкел булды. Җирләр пычрак, һава бозык, вокзал тирәсендә су юк иде. Кайберләрендә кайнар су булса да, алып, суытып әзерләү өчен янә күп вакыт хәҗәт була. Шунлыктан зарурлык белән берничә намазны тәяммүм [тузан белән тәһарәт алу] белән урыныбызда утырып үтәдек.

Тәяммүм зарурлыгы маддәләрендә фәкыйһләрнең искә алган сәбәпләре, чикләү өчен булмыйча, охшату юлы белән булса кирәк. Коръән: «Әгәр су тапмасагыз, чиста җирдә тәяммүм алыгыз» [Коръән, 4:43, 5:6], – ди. Тышкы ягына күрә, су булмаган тәкъдирдә генә рөхсәт ителә һәм дөрес була, дип аңлашылса да, мәсьәләнең рухына һәм фәлсәфәсенә күрә, ысуллар гыйлеме галимнәре бәян иткәнчә, текстның дәлиленә күрә, суны куллануда гаҗизлек нияте булуы билгеләнгән булганлыктан, фәкыйһләр әйткән нәрсәләргә кермәгән маддәдә дә бер төр гаҗизлек шиксез булса, тәяммүм дөрес булса кирәк. Безнең мәсьәләдә: кайнар чәй суы кайбер вакытларда табыла, ләкин суытырлык вакыт яки савыт юк яки тәһарәт алырлык урын юк, булса да, мәшәкать белән генә була. Шунлыктан су куллануда гаҗизлек пәйда булып, казый мулла Кәшшаф Тәрҗеман белән киңәшләшкәч, кайбер нәрсәләргә кунган тузан белән тәяммүм алып, берничә намаз укыдык. Әйберләргә кунган тузан белән тәяммүм, хәнәфи фәкыйһләре фикеренчә, дөрес булса да, аятькә туры килүе бик ачык булмаганлыктан, зәгыйфьлектән азат түгел. Мөмкин булган тәкъдирдә, «... чиста җирдә тәяммүм алыгыз» дигән аятьнең тышкы ягынча җир заты белән тәяммүм тиешле. Ләкин

сәфәрләрдә бөтенләй саклык юлын кайгыртып булмый. Мәзһәбләр арасыннан сайлап алу беренчерәк һәм яхшырак булса да, кайвакыт читен була, аеруча безнең бу сәфәребездә җирне пычрак каплаган яки ап-ак кар каплаган. Шунлыктан җирне ниятләү авыр.

## Мөнәсәбәт белән янә бер мәсьәлә

Элек миннән кар белән тәһарәт [алу] дөреслеге турында сораулар булган иде. Мин фәтвадә куркак булганлыктан, дөреслеген китапта ачык күрмәгәнлектән, фәтва бирә алганым юк, ләкин кайвакыт үзем гамәл кылгаладым. Уфада шәригать һәм низам белән дөрес булмаган рәвештә тоткын булганда су бирмәгәнлектән, галимнәрдән гыйбарәт [булган] иптәшләрем казый Ризаэтдин, казый Кәшшафетдин һәм элекке казый Гыйнаять Кабкай белән ишегалдында кар белән тәһарәт алган идек. Ләкин март көннәре булганлыктан, юешләнгән кар иде. Гәүдәгә ирешкәч, суланып тамчылана иде. Мондый карда күп шөбһә дә булмаска тиеш, дөрес булса кирәк. Инде суык көннәрдә тәнгә ирешү белән суланмаса, ничек булыр? Пычраклыкны җибәрүдә, әлбәттә, кар җитәрлек түгел, сыек булмаганлыктан, бетерми. Кирәк тәннән, кирәк киемнән пычраклыкны бетерә алмый. Тәһарәтсезлекнең пычраклыгы мәгънәви, мәгънәдә тәһарәт гыйбадәттән гыйбарәт булганлыктан, билгеле су булмаса да, ул булмаганда хакыйкый су булганлыктан, карны куллану җитәрлек булса кирәк, дип өмет ителә. Җентекләп аңлатканда мондый яклары искә алыныр:

1. Кар – хакыйкатьтә, су. Салкын һава ирешү белән су сурәтен үзенә алганча, парлар туңган кар сурәтен алган. Хәтта табигатьнең хикмәт ияләре бәян итүенчә, суның табигый сурәте туңган сурәт булып, эссе һаваның тәэсире сәбәпле, сыек сурәткә әйләнгән.

2. Кайбер хәнәфиләрнең бәян итүенә күрә, суның тәһарәтсезлекне бетерүдә тәэсире дә чыгаручы сыйфаты булуыннан. Карда пычраклыкны җибәрерлек чыгару сыйфаты булмаса да, тышкы якта булган пычракны бетерә. Шул сәбәпле, кайбер шайтан әсәрләрен гәүдәдән чыгарып, йөрәккә тәэсир итә. Бу да билгеле суга мөнәсәбәтле һәм аңа бер яктан алыштыру булырга мөмкин.

3. Тәһарәтнең намазга һәм гыйбадәткә тәэсире, хакыйкатьтә, Аллаһның әмеренә буйсынып, бер дәрәҗәдә чикләнүчелек һәм мәшәкать йөкләп, гыйбадәт кылу рәвешенчә. Затында су булган

карны кулланууда искә алынган гыйбадәтнең үз сурәте булмаса да, гыйбадәт кылып, бер төр чыгаручыны куллану була. Шунлыктан тәһарәт хөкемен алса кирәк. Бу уй – мин язучы Галимҗан Барудиның күп еллар фикерләүдән һәм өйрәнүдән соң җыңгән уе. Дөреслеккә ирешкән булсам – Аллаһның рәхмәте һәм туры юлы, хата кылган булсам – үземнең гаҗиз кимчелегем. Аллаһ – дөреслеген белүчерәк. Иптәшем казый Кәшшаф бине Каувам Тәрҗеман да бу фикер белән килеште.

## Икенче мәсьәлә

**Вагонда намаз уку мәсьәләсе.** Поезд туктаган вакытта бер шөбһә дә юк, әлбәттә, дөрес. Әмма барган вакытта уку фәкыйһләрнең арбада барган вакытта хайван өстендә укуга охшаган булып, хата булырмы яки бара торган көймәгә охшаган булып, дөрес булырмы? Кайбер галимнәр бара торган хайван һәм арба өстендә уку кебек, дөрес түгел диләр, сәҗдә җирдә яки җиргә караган нәрсәдә булу тиешле, диләр. Кайбер фәкыйһләрнең су буенда булган көймәдә намаз уку дөрес түгел, җиргә чыгып уку тиешле дип әйтүләре бу җиргә карауның шарт күрелмәвенә күрә. Хәтта кайберәүләр, яр буенда сәҗдәдән тыярлык пычрак булса, ишарә белән шунда уку тиешле, көймәдә уку дөрес түгел, дигән. «Һидая» һәм шәрехләрендә искә алына. Бу фикер «Гумбәтер-риваять», «Изах»та китерелә. Ләкин «Һидая» һәм шәрехләренә күрә, су буена бәйләнеп куелган көйменең эчендә намаз уку дөрес. Җиргә карау мәсьәләсенә керүдән башка дөрес икәнен искә алганнар, бары аягүрә укуның тиешлеген бәян иткәннәр. Безнең тимер юл вагоннары тыштан арба җенесеннән күрелсә дә, намаз хакында. арба хөкемендә булмыйча, көймә хөкемендә булуы ачыграк. Шушы сәбәпле:

1. Тимер юл вагоннарында йөрү һәм сәяхәт бик гомумиләшкәнлектән, тышка чыгып уку мәшәкатьсез булмаганлыктан, барган вакытта вагонда уку дөрес булмаса, намазны калдыруга киртә булыр дәрәҗәдә мәшәкать булачак. Намаз – һәр мөэмингә Китап белән вакыты билгеләнгән булып, кичектерүе дөрес булмаган ислам фарызы. Шунлыктан кичектерүсез, мәшәкатьне йөкләмичә, барган хәлдә булса да, укуны дөрес күрү тиешле. Ничек булса да, бу изге гыйбадәтне вакытында үтәү мәҗбүри.

2. Вагонның бары бер-ике адәмне сыйдырырлык арбага мөнәсәбәте һәм охшавы игътибар ителмәскә тиешле. Ничә гаиләне сыйдырырлык һәм торуларына мөмкинлек бирерлек бер гади йөк көймәсе кадәр зур, бәлки үзенең байтак яхшылыкларын эченә алган, күп өйләре булган бер йорт кебек. Димәк, моның, арба хөкемендә булмыйча, көймә хөкемендә булуы тиешле.

3. Вагон зур көймә кебек вакытлы бер урын. Тәһарәт һәм аны бозу, йокы һәм уяулык, хәрәкәт һәм туктап тору, ашау һәм эчү, кыскасы, билгеләнгән бөтен тормыш хәҗәтләрен күтәрүче бер урын. Ут көймәләре (пароходлар) дә шулай. Хайван һәм аңа таккан кечкенә арбаларга мөнәсәбәте юк. Боларда (вагоннарда) барган хәлдә уку намаз укучының йөреп торгандагы укуына охшаш. Шунлыктан боларда җиргә карау игътибар ителмәве тиешле. Намаз укучы, хакыйкатьтә һәм хөкем белән, җиргә караган хәлдә укыган булсын. Әмма вагон зур булганлыктан, аның хәрәкәте һәм йөреше хайван өстендәге кешенең хәрәкәте һәм йөреше хөкемендә түгел. Бәлки баручы өчен көймәдәге кебек үзенә махсус һәртөрле хәрәкәтләр мөмкин. Шунлыктан вагонның көймә хөкемендә булуы ачык була.

Күп еллардан бирле, Аллаһка тапшырып, искә алынган язмаларга күрә, шул рәвешле гамәл кылып киләбез. Остазлардан шәех Шиһабетдин Мәрҗани, шәех Зәйнулла Рәсүли һәм башкалар да бу фикердә булдылар. [Һиҗри] 1335 елда Әндиҗан шәһәрендә мулла Сөләйманколый исемле аңлы галим бу мәсьәләне сорагач, фикеремне һәм гамәлемне суйләгәннән соң, канәгать булып һәм рәхмәт әйтеп: «Әбел-Хәсәнәт мәүляви Габделхәй әл-Лүкнәви дә шулай фәтва биргән», – дип, фәтваләр җыентыгын күрсәткән иде. Әйткәненчә дөреслеген язган иде. Шулар белән бергә, саклану булса, барганда укылмыйча, туктаганда яки тышка чыгып, җирдә укылса, әлбәттә, шөбһәдән ераграк була. Бу – миндә булган нәрсә һәм Аллаһка мактау булсын.

## Самара, Сызрань, билет җәфалары

8 ноябрьдә сишәмбе көн көндезге 1 сәгать 40 минутта Самара вокзалына ирештек. Һава юеш, кар эрегән, халык күп, вагоннарга утырыр өчен зарланалар. Һәр җирдә вагон билетын алулар бик мөшкел, асыл билет бәһасе өстенә, арадашчыларга билет бәһасенең

яртысы кадәр чәйлек бирергә кирәк. Билет алганнан соң, вагонга керү өчен янә күп мәшәкатьләр кирәк икән. Кыскасы, төрле рәвешләр, төрле авырлыклар сәфәр юлларын авыр итә, йөрешләрне кисә, шул юл белән сәүдә мөгамәләсен туктата. Сәүдә иткән кешеләр дә зарурлык белән бозык ялганны үзләренә йөклиләр. Әйбер бәяләре көннән-көн арта бара. Бу тормыш нигә барып терәлер, ахыры ни булыр? Аллаһ ахырын хәерле итсен.

Ике сәгать микъдары Самарада юаныпр, Сызраньгә юнәлдек. Төнге сәгать уннарда аңа ирешеп, сәгать 12 чорларында хәрәкәт иттек. Самара, Сызрань вокзаллары начар вакыйгаларны, рәхимсез идарәләрне күрсәтүдә иде. Вокзал ачлыктан йорт-җирләрен ташлаган халык белән тулы, гаиләләре, яшь балалары белән атна-ун көннән бирле вагон чираты көтеп яталар. Кыйммәтчелектән ачыгып, барлык нәрсәләрен сатарга мәҗбүр булып, поездан өмет өзеп һәм кире кагылып, идарәгә рәнҗеп, аны кәһарләп, тилмереп калалар. Кычкырып елап калган марҗалар да булгалый икән. Көчле адәмнәр, кулларында билетлары булган хәлдә, вагонга кабул ителмичә, өметсез булып калгалыйлар. Чөнки билетта вагон номеры язылу шарт булганлыктан, күп адәмнәргә насыйп булмый.

Кичен яхшы ял иттек. Диваныбыз миңа калып, иптәшем өченче рәткә менеп, ял итте.

## Акчурин вокзалы

Чәршәмбе көн иртәнге сәгать 10 да Акчурин вокзалыннан (Гурьевкадан) үттек. Акчуриннарның өйләре һәм фабрикалары Имру әл-Кайс шигыренең башы булган [...] шигырен хәтергә төшерерлек хәлдә күренеп калдылар. Маңгай тирләрен чыгарып, кул көчләре белән эшләп, халык өчен киемлек җитештергән, йөзләп-меңләп хезмәтче һәм эшчеләрне туйдырган, эзлексез килеп-китеп торган кунакларга кунак итү һәм хөрмәт биреп килгән хуҗалардан һичкем калмаган, коры бина һәм корылмаларыннан башка исем һәм даннары тәмам беткән хәлдә, матәм хәле кебек яки онытылган каберләр кебек еларлык хәлгә килеп күренәләр. Хуҗалары, 50–60 ел нигъмәт биргән эшчеләреннән һич яклау һәм саклау күрмичә, Кызыл гаскәр басып алу вакытында гомерләрен саклау нияте белән, төрле куркыныч авырлыкларны йөкләп, Сибириягә качканнар. Читтә төрле җәфалар һәм михнәтләр күреп,

бу көнгәчә сәламәт яшиләр. Йортларын баш-күзләре белән еракан гына булса да күрүдән гаҗиз, ата-бабаларының каберләренә бер мәртәбә сәлам бирүдән, бер мәртәбә булсын, «Фатиха» сүрәсен укудан тыелганнар. Күп елларда кабат кунак булып, хөрмәт күреп йөрүебез бу йортларны еракан вагон тәрәзәсеннән күреп, ятимлек хәлендә калган биналарның хәлләренә шәфкать итеп, хуҗаларының сәламәт кайтып, дөнья һәм ахирәтләренә файдалы рәвешле эшләрен яңартып, идарә итеп, кайгылы хәлләре яхшы якка үзгәрүе турында дога һәм «Фатиха» укып үттем. Аллаһ аларның хәлләрен яхшыртсын, кайгыларыннан файда бирсен. Чынлыкта, монда акыл ияләре өчен гыйбрәт бар.

* * *

Рязаньгә җитәрәк, бер вокзалга чыктым, бер бай рус авылы янында идек. Берничә данә тере каз чыгарганнар, 70000–75000 сум сорап торалар. Кайбер адәмнәр Мәскәүгә алып китәләр икән. Мин дә бер кадак микъдары эремчек алып, 7000 сум түләдем. Бер кабарлык каймакны 500 сумнан саталар иде. Рязаньгә җиткәндә, куәтле кар яуды, бер чарик кадәр яхшы кар иде. Мәскәүгә җиткәндә, җирдә һич кар әсәре күренмәде. Коры, салкын җир туңган иде.

## Мәскәүгә ирешү

Төнге сәгать 2 дә Мәскәү вокзалына ирештек. Әйберләребез байтак булганлыктан, өч кисәген йөк ташучыга, 25000 сум бәрабәренә сатулашып, күтәрттек. Башкаларын үзебез һәм кайбер дуслар күтәрештеләр. Вокзалдан чыкканда, фаэтончылар үзләрен тәкъдим итә башладылар. Вакыт соң булса да, үзләре күп иде. «Икенче мәчет ишегалдына нинди хак белән илтәсез», – дип әйтүебезгә: «Бер ярым», – диделәр. Бер – 100000, бер ярым – 150000 [сум] икән. Ике чакрым чамасы юлга шул кадәр бәһа сорадылар. Вакытның соңлыгы да тәэсир итәдер. Соңра 75000 [сум] бәрабәренә ялладык. Ике адәм 5 пот кадәр йөгебез белән утырып, сәгать 4 тә Дүртенче Мещанскийда, Выползовский тыкрыгында, 5 нче номерлы йортта, Икенче мәчет ишегалдына кереп, мөхтәсиб мулла Габделвәдүд ахунга ишек кактык. Ул да ял итәргә ятып җитмәгәнлектән, тиз үк кабул итеп, җылы, яхшы йортына урнаштык. Чәй

эчеп, тәһарәтләр яңартканчы таң атты. Аз гына көтеп, иртәнге намазны үтәп, ял иттек.

Дөньяның үзендә бер карар ләззәт һәм кыйммәт юк. Һәрнәрсәнең ләззәте һәм кыйммәте фәкать башка нәрсәгә карап. Бер гади һәм бик гади мисал: иске, салкын, һава-җил узып торган бәдрәфләрне зарарлы күреп, җылы, яхшы тәртиптәге, яңа ысуллы бәдрәфләр чыгарылган иде. Без дә бу төр бәдрәфләр өчен чыгымнар тоткан идек. Югарыда язылганча, Уфадан чыгудан бирле бушануым бик авыр һәм читен, авыр һәм һич юк иде. Дүрт тәүлек һәм ике сәгать тыелып, тотып килдем. Ничә мәртәбә ниятләсәм дә, вагонның бәдрәфеннән табигатем нәфрәтләнде, тәнем тартынды. Кире этәрү куәте җиңүче булып, гамәл кылмады. Габделвәдүд ахун йортында, салкын җил өреп торган бәдрәфендә, Аллаһка мактау булсын, тәмам рәхәтлек һәм ләззәт белән бушандым. Зарурлык башканы кирәсенмәде, булуына канәгатьләнде. Кылану юлына кермәгәндә, һәрнәрсәнең зарур кадәрлесе белән канәгать булу мөмкин, икътисади бер урталык, исрафтан саклану булачак.

## Җомга һәм мәүлид

11 ноябрьдә җомга [намазы] уку миңа тапшырылганлыктан, сәфәр авырлыгы бетеп җитмәсә дә, кабул иттем. Җомга хөтбәсеннән элек вәгазь сөйләү, кабат хөтбәгә кайтканлыктан, бер төр Сөннәткә каршы нәрсә урынында күрелсә дә, халык шәригатьтә дөрес булган хөтбә эчендәге вәгазьне аңлап җитмиләр, дип, элек кыскача бер нотык сурәтендә берәр нәрсә сөйләвемне сораганлыктан, мәүлид мөнәсәбәте белән «Мөхәммәд – Аллаһның илчесе, ул рәсүл белән бергә булган хак мөэминнәр кәферләргә каты торалар, үз араларында бер-берсенә шәфкатьле булалар» [48:29] җөмләсен тәфсир итеп һәм аңлатып, бер кыска хөтбә белән җомга [намазы] укыттым. Намаздан соң халык күрешеп, сәгать ике тирәсендә намаздан чыктык.

Бу җомга көн ястү намазыннан соң әлеге Икенче мәчеттә мәүлид мәҗлесе булды. Халык күп тупланган, мәчет тула язган иде. Ахун кыскача ачу нотыгын сөйләп, мин «Аллаһ Үзенең илчесе Мөхәммәдне туры юлны өйрәтүче, күрсәтүче Коръән һәм Ислам дине белән җибәрде, ул китергән Ислам дине хаклыгы белән барча диннәрдән өстен булсын өчен, мөшрикләр ислам диненең өстен

булганын сөймәсәләр дә» [Коръән, 9:33, 61:9] дигән хөрмәтле аятен укып, аңлаттым. Бөтен диннәрдән өстен булу маддәсендә бераз аңлатылды. Бераз Кәшшаф казый Мөхәммәд пәйгамбәр миссиясенең дөнья һәм ахирәт бәхетенә сәбәпче булуы турында, аятьләргә һәм хәдисләргә таянып, яхшы хөтбә сөйләде. Балалар, 5–10 тавыш кушылып, шигъри тасвирлау һәм тәбрикләү укып, соңра ахун Коръән һәм Бәрзәнҗи «Мәүлид»ен укыды. Мәҗлес ахырында аваз белән төркичә дога кылып, тәмамланды. Халыкның теләге яхшы гына, караңгы кичәдә, салкын һавада салкын мәчеткә ерак җирләрдән дин мәхәббәте белән тупланганнар. Мәхәббәт белән вәгазьләрне тыңладылар, яхшы ганимәт хәл. Ләкин гарәпчә булган Бәрзәнҗи «Мәүлид»еннән гади халык дөрес бер сүз аңлый алмадылар. Төркичә укылса, яхшырак аңларлар иде. Истанбулда халык байтак гарәпчәгә әһәмиятле булсалар да, электән бирле илебездә һәм Төркиядә билгеле булган төркичә Сөләйман Дәдә «Мәүлид»ен укыйлар. [Һиҗри] Мисырда 1304 ел рамазанының 27 нче кичәсендә, кальга эчендә, Мөхәммәдгали пашаның җамигъ мәчетендә галимнәр һәм әмирләр җыелган мәүлид мәҗлесе булды. Мәҗлестәгеләрнең барысы да гарәпчәне аңлаучы булган хәлдә, искә алынган Сөләйман Дәдәнең төркичә «Мәүлид»ен укыганнар иде.

## Бүлек

«Бөтен диннәрдән өстен булу өчен...» [Коръән, 9:33, 61:9] аятенең тәфсирендә кайбер фикер ияләре, уйламыйчамы, уйлапмы, өстенлекне сәяси һәм сәяси җиңүгә йөкләп, элекке гасырларда булган өстенлек һәм җиңүгә йөкләү белән канәгатьләнмичә: «Ахыргы гасырларда Кыямәт көненә хәтле өстен булачак, һәммә дәүләтләр өстенә ислам җиңүче һәм өстен булачак», – диләр. Хәтта Ризаэтдин казый җәнапләре бу фикерне һәм өйрәтмәне ислам философы, мәшһүр галим шәех Җамалетдин әл-Әфганидән күчерә.

Мин бу фикерне дөрес димим, күпчелек тәфсирчеләрнең «Дәлил китерү белән өстен итү өчен, көч һәм хакимлек белән түгел» дип әйтүләрен туры һәм дөрес күрәм.

1. Туры юл һәм хак дин белән Рәсүл җибәрүенә дөньяви мәнфәгать, вакытлы көч һәм гәүдә файдаларының максат һәм нәтиҗә ителүе дөрес һәм яраклы түгел. Бөтен күктән иңгән диннәр дә хикмәт ияләренең фәлсәфәсе, акыл ияләренең хикмәте белән

исбат ителгән һәм бәян ителгән, дөньяви файдаларның һичбер хөкемендә, игътибарга лаек булуына каршы. Бу – кыска, фани тормышта яхшы ашау-эчүне, киенүне һәм бизәкләр эчендә тормыш итүне, ләззәт һәм зиннәт белән гәүдә асрауны, ләззәт һәм зиннәтне максат итеп тоту дәрәҗәсендә күргән адәмнәрнең карашына туры килә. Бар караш һәм дәртне бу вакытлы яшәү бәхетенә чолганган Европаның бозык мәдәниятенә, шәһвәт тормышына сөенүдән туган бер фикер, нәтиҗә. Раббының туры юлы белән Рәсүл җибәрүенә бу нәтиҗәне төзелгән максат итү – Раббының туры юлын түбәнәйтү һәм җиңеләйтү дәрәҗәсендә мөнәсәбәтсез.

2. «Бөтен диннәрдән өстен булу өчен...»дә булган «ләм» аңлату өчен булуы яраклы түгел. Аллаһ эшләренең сәбәпләре белән аңлату булмавы өстенә, әйберләрне үзе белән аңлату булганлыктан, яхшы бәйләнеш булмый. Бәлки Коръәндәге күбрәк «ләм»нәр кебек «ләм» ахыры булырга тиеш, ягъни Рәсүл җибәрелү һәм игълан итү диннең яхшы ахыры. Дин [ислам дине] башка диннәрдән өстен булачак. Бу эш исә, вакытлы гына булмыйча, даими рәвештә булырга тиеш. Исламның сәяси җиңүе исә берничә гасырлар дәвам иткән булса да, күп заманнардан бирле сәяси җиңүен югалтты. Моннан соң да өмет аз. Әмма дәлил китерү белән өстенлеге һичвакытта кимчелеккә һәм бетүгә очрамаячак, бәлки бүгенгәчә һәммә диннәргә нисбәт белән, һәммә хәлләре һәм хөкемнәре белән тумыштан булган үзенчәлеккә яраклы, кирәкле фәлсәфә һәм хикмәт булган кебек, соңгы заманнарда да табигый дин һәм тумыштан булган өйрәтмә булып яшәячәк. Аллаһ тарафыннан камиллеге, тулылыгы һәм ризалыгы хәбәр бирелгәнгә, үзгәртүдән сәламәт булганлыктан, һичвакытта акыл һәм вөҗдан ияләре тарафыннан шик-шөбһәгә дучар булмаячак, динсезләр, каршылык күрсәтүчеләр һәм ияручеләрдән [кала] башка кешеләрнең инкяр итүенә лаек булмаячак.

## Төркия илчелегенә бару

13 рабигыль-әүвәлдә (ноябрьдә) якшәмбе көн Төркия илчелегенә бардык. Илче Гали Фуад паша исемле 40 яшь чамалы яшь адәм, бәлки батыр гаскәри түрә, генерал дәрәҗәсендә булып, сугышларда байтак яраклык эш күрсәткән адәм икән. Бу бару бары танышлык өчен генә булганлыктан, ачларга ярдәм турында сөйләшү ачмадык. Хәзерге төрек-грек сугышыннан, төрек-Франция

килешүеннән бераз сүз булып, Төркиянең сәясәте яхшы гына барганын, газеталарда язылганча, искә алынган сугышта һәм килешүдә Төркия байтак уңыш казанганын раслады һәм сөйләде. Искә алынган илче сүзгә юмарт адәм [булып] күренде. Җомга көн җомга намазына киләчәк, намаздан соң безгә киләчәк булып, түбәнчелек күрсәтеп, озатып калды.

## Әфган илчелегенә бару һәм Әфганстан

14 рабигыль-әүвәлдә (ноябрьдә) дүшәмбе көн Әфганстан илчесе Мирза Мөхәммәдхан җәнапләренә бардык. Бу кеше белән үткән елда Әфганстан вәзире Вәлихан җәнапләре белән берлектә ахун Габделвәдүд йортында танышкан идек. Галимнәрдән, хуш мәҗлесле, хуш сүзле адәм. Озак сөйләшеп утырдык. Фарсы телендә сәгать ярымнан артыграк сөйләштек. Ачлар мәсьәләсенә сүз мөнәсәбәте килеп, яхшы чыгымнарына сарыф ителсә һәм таратылса, Әфганстаннан иганә мөмкин икәнен сөйләде. Бу турыда хөкүмәт белән сөйләшүебез беренчерәк булганга, һаман хөкүмәт фикере аңлашылмаганлыктан, артык кирәгенчә сөйләшүне икенче вакытка калдырып, саубуллаштык.

Әфганстан байтак алга китү һәм яхшыру юлына кергән, Төркия кебек Европа идарә һәм гаскәр ысулы юлына төшеп бара икән. Төрле газеталар һәм журналлар нәшер итәләр, Европаның зур шәһәрләрендә вәкиллекләр тәшкил итәләр икән. Күргән матбугат: «Әмане Әфганстан» [исемле] атналык журнал, Кабулда «Иттифакы ислам» – атналык, Һиратта «Иттихад мәшрикый» газетасы – атнага ике тапкыр [чыга], Җәлалабадта «Тулүгы Әфган» – атналык [газета], Кандәһарда «Азади шәриф» журналы 15 көнгә бер мәртәбә Берлинда басыла һәм нәшер ителә. Башка басылган кәгазьләре булса да, илчелектә очраганнары болар. Берлинда басыла торган «Азади шәриф» зур кәгазьдә гарәп, фарсы, һинд, немец телләрендә алты биттә гүзәл хәрефләр белән басыла. Баш битендә шәрыкта Европа әсирлегенә дучар булган сигез сыйныф халыктан берәр үрнәк төшергән, шәех Сәгъдинең мондый өч шигырен язган: [...].

Бу журналда мисырлылар, һиндлар, әфганилар катнашканнар.

Искә алынган илченең бәян итүенә күрә, Һидстанда инглиз зарарына хәрәкәт байтак куәт ксеп иткән. Хәтта инглиз бер төр автономия бирергә булса да, халык риза булмыйча, тулы бәйсезлек

таләп итүдә нык торалар икән. Индуслар (һинд мәҗүсиләре) белән мөселманнар бердәмлек белән хәрәкәт итәләр, хөкүмәт гаскәрендә булган җирле халык хезмәтләрен ташлаганнар, хөкүмәт белән яхшы мөгамәләне кискәннәр, ватан хисләре тәмам уянган икән. Аллаһ бирсен, яхшы тәмамлануга ирешсеннәр, инглизгә әсирлектән һәм аның золымлы хакимлегеннән арыну табып, уртача хөррият һәм туры идарәгә ирешсеннәр.

## Ачларга ярдәм турында чаралар

Дүшәмбе көн кичәсендә йортыбызда уфалы дәгъва вәкиле Ибраһим бине Әбес-Сөгуд Әхтәмов белән сөйләшеп утырдык. Ачларга ярдәм турында хәрәкәтләрнең зарурлыгын, моның өчен элек Наркомнац рәисе Сталин белән сөйләшеп, аның ризалыгы аңлашылганда, яхшы проект әзерләп, башка рәисләргә бирүне тәкъдим итте. Элек махсус сайланган комитетларга һәм христианнарның руханилар рәисенә (патриарх) ярдәм итсәләр дә, бу соңгы бер ай эчендә хөкүмәтнең сәясәте байтак уңлашуы мөнәсәбәте белән ярдәмнәре ихтимал булганын сөйләде.

Нәзарәт иганә туплау өчен мөмкинлек алса, үз вәкилләре аркылы эш күрәчәк. Кирәк иганәне туплауда, кирәк тиешле урыннарга китерүдә, кирәк тиешле урыннарына бүлү һәм таратуда хөкүмәт тарафыннан тик күзәтү вәкиле катыштырып, үз вәкилләре белән идарә итәчәк. Киресенчә булганда, халыкның начар карашына сәбәпче һәм сәбәп булып, артык әһәмиятле рәвештә иганә тупланмаячак. Мондый шартлар хөкүмәтнең сәяси намусына, деспотизмына яраклы күрелмәве ихтимал. Ләкин яхшы сәясәт һәм чын чара – ач калган бу кадәр миллион халыкның файдаларына каралса, әлбәттә, вак сәясәтләрдән китеп, бу безнең шартларыбызга риза булуы тиешле. 15 ноябрьдә Наркомнац әгъзасы Мирсәет Солтангалиев йортында булып, югары таләп турында сөйләшенде. Карар: кыска бер гариза язып, искә алынган идарә рәисе Сталинга бирелер, соңра таләп ителгән хәлгә күрә эш күрелер. Искә алынган Мирсәет һәм Габдулла Гыйсмәти, рәсми рәвештә коммунист булсалар да, мөселманнарның эшләренә, аеруча Диния нәзарәтенә яхшы күз белән карыйлар. Мирсәет, дошманнарыннан куркып, үзен битараф тотып хәрәкәт итә, ләкин кулыннан килгән кадәр ярдәмен ирештерә.

## Мәүлид мәҗлесендә Төркия вәкилләре

16 ноябрьдә чәршәмбе көн Сабир Шәмгун йортындагы кунак мәҗлесендә Төркия пашаларыннан Җамал паша белән очрашу булды. Бу адәм соңгы рус-Герман сугышында зур эш күргән, Сүриядә инглизгә каршы сугышкан каһарман. Анатолиядән Русиягә килеп, аннан Төркестан һәм Әфганстанга барып, анда тәшкил иткән гаскәрдә байтак яхшы хезмәт күрсәткән икән. Яше 40–50 арасында, куәтле, нык, батыр адәм. Ишетелгәнгә күрә, Берлинда булган гаиләсе янына барып, янә Әфганстанга кайтачак икән. Әфган дәүләте яңа яхшыру юлына кергән, гайрәтле дәүләт булганлыктан, файдалы адәмнәрне җыя, гаскәр һәм милек эшләрендә яхшы уйлап эш итүче адәмнәрдән файдалана. Прогресс һәм яхшыру юлына кергән адәм һәм дәүләт өчен бу юл һәм бу фикер иң беренче дәрәҗәдә мәҗбүри эшләрдән. Үз фикере белән канәгатьләнгән, үз гыйлеменә алданган зат – кирәк шәхес, кирәк дәүләт булсын – һичвакытта бәхетле була алмый, җиңү һәм уңышка ирешә алмый. Гыйлем юлында булган зат, һәрвакытта, һәр җирдә, һәркемнән файда алу юлында булса гына, уңыш таба, чын өстенлекле мәртәбәсенә ирешә ала. Шулай ук дәүләтләрдә һәр мәсьәлә өчен читтән аң һәм тәҗрибә ияләрен җәлеп итеп, гаскәр, милек, сәясәт идарәләрен тиешле юлына салырга сәләтле була.

Мәүлид уку вакытына Җамал паша килеп җитмәсә дә, иптәшләреннән табиб Назыйм бәк килгән иде. Мәхәллә имамы Габдулла бине Хәсән Шәмс Бәрзәнҗи «Мәүлид»ен бераз укып, догадан соң, мәҗлестә булучылар аңламаган гарәпчә уку мәсьәләсендә каршы төште, төркичә уку тиешле икәне турында сөйләде. Сүзендә хаклы иде. Паша килгәннән соң, гаҗәпләнгән һәм хәйран калган рәвештә аңа да сөйләде. Мин байтак еллардан бирле Казанда төркичә укылуын киңәш итүдә булсам да, элекке мәүлидчеләр үзләренең ятланган нәрсәләрен файдалану, өйрәнгән базарларын үзгәртмәү һәм төшереп калдырмау өчен кабул итүгә мөмкинлек бирмәсәләр дә, төркичә уку байтак мәйдан алган иде. Элекке мәүлидче Габдулла кари һәм аның ихласлы иярченнәре саклансалар да, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә караганнардан мәшһүр кари Вәли әфәнде яхшы төркичә укый башлаган иде. Мәскәү ахуны исә тиз вакыт белән генә үзгәртүне сорамый, әзерлекләре дә булып җитмәгән. Шаять, моннан соң яхшыртылыр. Мәүлид мәҗлесләре,

мәүлид уку – асылда, Рәсүлуллаһка (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) мәхәббәттән булганлыктан, Гарәбстан һәм Төркиядә таралган, соңра безнең Болгар йортларында да гадәт булган мәҗлесләр. Асыл хәдис белгечләре арасында каршылыклы, ваһһабилар арасында күркәм булмаган, бәлки бидгать булу белән хөкем ителгән гадәт. Кануҗи әсәрләрендә бәян ителгән. Имам Раббани шәех Әхмәд Сиһринди бер хатында «Булмаган җирдә чыгарылмый, булган җирендә тыелмый» дигән мәгънәдә киңәш итә. Байтак галимнәр тарафыннан моның яхшы бидгать булуына авышу күрелгән. Мәҗлестә акыл һәм шәригать ягыннан тыелган нәрсә катышмаганда, укылган мәүлид кыйссасы мәҗлестәгеләргә аңлатылып, Рәсүлуллаһның (Аллаһ аны олыласын һәм сәламләсен) кайбер яхшы хәлләре һәм хөрмәтле әдәпләре искәртелсә, байтак файда итү өметле. Шунлыктан мин дә бу мәүлид мәҗлесләренә инкяр итү күзе белән карамыйча киләм. Шәех Мәрҗани мәрхүм белән дә кайбер кыскача мәүлид кыйссасын тыңлаганыбыз булды. Ләкин иң мөһим маддә – кыйссаның мәҗлестәгеләргә аңлашылуы. Гарәпчә белмәгән гади халык алдында гарәпчә булган Бәрзәнҗи «Мәүлид»ен уку яраклы түгел. Гәрчә искә алынган Бәрзәнҗи «Мәүлид»е гүзәлдер, ләкин гарәпләргә һәм гарәпчәне яхшы белгән адәмнәргә нисбәт белән. Башкаларга исә халыкның белгән тел белән укылуы шарт. Төркиядә укылып килгән, элекке заманнарда Болгар йортларында да укылуы гадәт булган шәех Сөләйман (Сөләйман Дәдә) Брусави хәзрәтнең «Мәүлид»е яхшы. Аннан да яхшырагы туганчы, шул нөсхәне уку бик яраклы. Аллаһ кемне тели – шуны туры юлга күндерә.

## Хикмәт иясе Бруштейнга юлыгу һәм аның мәҗлесе

17 ноябрьдә узган ел Мәскәүдә юлыккан, көндәлек дәфтәремнең беренче томы 141 нче битендә җентекләп язылган хикмәт иясе Ф. Бруштейнга юлыктым. Үземдә булган көчле йөрәк кызуын сөйләдем. Бу авыруым байтак еллардан бирле дәвам итә, эч тулу вакытында аз гына хәрәкәттә моны кузгата, күкрәкне кыса, авырттыра, хәрәкәттән һәм йөрүдән тәмам гаҗиз итә. Ләкин аз гына туктаса, басылып рәхәт бирә, ашамау бу авыруга файда итсә дә, вакытлы була. Элек табибларга мөрәҗәгатемдә, иттән саклану, җәяү күп йөрергә киңәш итәләр иде. Ул рәвешне бераз куллана идем.

Быел җәяү йөрүгә вакыт һәм форсат аз, иттән сакланып булмый, картлык һәм зәгыйфьлек арта бара. Шунлыктан бу авыру да бераз артты. Урамда саклану сәләте азлыктан, җәфасын күргәлим. Адәм баласы һәрвакытта наданлыктан яки гыйлеме белән гамәл кылмаганлыктан, төрле афәтләргә дучар була. Дөньяви һәм дини афәтләрне шул ике сәбәптән таба. Ит мәсьәләсендә дин галимнәренең киңәшләре булуны, хәтта борынгы изге галимнәрнең таләпләре буенча да саклануның (ниһаять, 40 көнне итсез үткәрмәү дәрәҗәсендә генә аз ашауның) файдалы икәнен белә идем. Бу мәсьәләдә медицина җыентыкларында байтак киңәшләр укыган идем. Яшәргә теләгән [кеше] ит ашамас, ашказанын саклаган [кеше] ит аз ашасын, ит – ерткыч хайван азыгы, адәм азыгы түгел, бәлки аның азыгы – үсемлекләр, дигән мәгънәдә күп укыдым. Гомуми хисаплар нәтиҗәләрендә (статистикларда) йөздән артык яшәгәннәрнең тәрбия ысулына һәм азыкларына итнең аз кергәне, күбесенчә, үсемлекләр белән канәгатьләнүләре ишетелә һәм газеталарда укыла иде.

Искә алынган хикмәт иясенең киңәшләре узган ел кәгазьләремдә язылган иде. Бу тапкырда шул киңәшләрен яңартты. Иттән саклануны тиешле күрә, гаилә эчендә бөтенләй саклану мөмкин булмаганда, шулпасын эчеп канәгатьләнүне тиешле күрә. Кайгыртулы киңәше – гөмбә шулпасы. Бу шулпада күп хасият күрә. Кан тамырларында булып, кан юлларына киртә булучы тозларны бетерә, канның табигый йөрешләренә ярдәм итә, диләр. Кул-аякның өшүе, ревматизм, подагра кебек авыруларның куәтле сәбәпчесе һәм сәбәбе тамырларның тоз белән багланып, әгъзаларны җылытучы булган канның яхшы йөри алмавыннан икән. Бу адәм чәйдән, төтеннән саклануны да тиешле күрә. Кәнфит затларын бик зарарлы, аеруча тешләргә зарарлы, саклануы мәҗбүри, аеруча балаларга ашатмаска кирәк, ди. Әлбәттә, кайнатма (варенье) затлары да бу хөкемдә. Бу соңгы заманнарда халык арасында теш авыруының күплеге, шәһәрләрнең күп җирләрендә теш табибы игъланнары, күп адәмнең шул табибларның нервыбозгыч чыгырларыннан җәфа күрүләре, ничә көннәр аларның капкаларында чиратлар көтеп, гомер үткәрүләре, күбрәк, шул кәнфит, кайнатма кебек ябышкак татлылардан туа. Элек халыкның – бай һәм фәкыйрьнең – сыйлануы, исраф итүе, ләззәтләргә чумуы ифрат дәрәҗәгә ирешкән иде. Көнгә 3–4 мәртәбә самавыр кайнатып, чәй янында сәгатьләр

буе гомер үткәреп, бал һәм шикәр татлысы белән генә канәгатьләнмичә, чәйне чәерле кайнатмалар белән, аның да төрлеләре, хәлләре җиткәнчә, иң кыйммәтлеләре белән эчәләр иде. Шул кайнар чәйнең зарары өстенә, кәнфит, кайнатма кебекләр, зарар өстенә зарар булып, адәмнең яхшы яшәве һәм сәламәтлек саклавы өчен мәҗбүри һәм зур шарт булган кыйммәтле тешләрен – Аллаһның зур нигъмәтен – әрәм итәләр икән.

Кыскасы, искә алынган хикмәт иясенең бу мәсьәләдә булган васыятьләрен хикмәткә, сәламәтлек саклауга яраклы күрдем. Бу кешенең итне кую, азыклар ашау мәсьәләсендәге бер сүзе: яңа туган балаларның ашны сеңдерүе зәгыйфь, [бала] чәйнәү коралларыннан мәхрүм булганлыктан, элекке вакытларында фәкать ана сөте белән генә тәрбияләнә, шул сөт азык өчен дә, үсү өчен дә җитә. Бара-бара йомшак ботка затын кабул итә, чәйнәлгән икмәк затларын ашый башлый. Ит ашамавыннан, азык һәм үсү яклары белән зарар һәм житешсезлек күрми, табигый хәл белән үсә, яхшы сәламәтлегендә яши. Тик кайбер уйламыйча эшләүче аналар вакытларыннан элек, ашыгып, кайбер зарарлы нәрсәләр ашатып, көченнән артык авыр нәрсәләр биреп, баланың табигый үсү һәм табигый сәламәтлекләрен бозсалар бозалар.

Бала, теш чыгып, байтак куәт кәсеп иткәннән соң, үзе чәйнәп ашау дәрәҗәсенә килә, соңра зарур булмаса да, ит ашау сәләтенә килә. Бу хәлнең киресе, 45–50 яшьтән соң адәм баласы хайван куәте яклары белән түбән төшә башлап, әүвәлге хәле булган бала һәм сабыйлык хәленә якынлаша, акрынлап сабый кебек бик җиңел нәрсәләр белән генә тукланырга тиешле була. Ит һәм башка авыр ризыклардан саклану мәҗбүри була. Сакланмаса, ашказанын артык көчләп, аны бөтенләй эшеннән һәм көчтән чыгарырга сәбәп булып, гомеренең ахырын якынлаштыра.

## Заһид Шамвилнең ядкяренә мәҗлес

18 ноябрьдә җомга көн кичке сәгать 5 тә үткән ел вафат булган Заһид бине Шафигъ бине Шамвил (Шамил) Дагыстани ядкяренә Мәскәү егетләре мәҗлес ясап, Төркия илчесе, башка Төркия түрәләре, мин, казый Кәшшаф, имамнар һәм башкалардан 80 кадәр адәмнән гыйбарәт мәҗлес булып, Коръән укылып, үлгән Заһид әфәнденең кайбер яхшылыклары хакында нотыклар сөйләнде.

Пылау, чәй, чәй ашлары тәкъдим иттеләр. Бер-ике миллионлык чыгым тотканнар. Бер-ике сәгать сөйләшеп утырып кайттык. Мондый мәҗлесләр, мәетнең кырыгы һәм елы исемле дога мәҗлесе ясаулар фәкыйһләр каршында мактаулы күрелмәгән, бәлки бидгать [итеп] санарлык мәҗлесләр җөмләсеннән. Кайбер шәех гамәлләренчә, дөрес күрелеп, үтәлә. Бу каршылык гыйбадәт һәм саваплы эш [итеп] санау нияте белән булганда. Әмма бу Заһид әфәнде өчен ясалган мәҗлес мондый түгел, бәлки яшьләрнең Европага иярүләреннән туган бер җыелыш әдәпләре, иҗтимагый мәҗлесләре. Хезмәт иткән, милләт эчендә һәм эшендә гайрәт һәм дәрт белән танылган адәмне, башкаларга гыйбрәт һәм кызык-сындыру булсын өчен яшәвендә һәм үлемендә шундый ихтирамнар күрсәтү – сәясәтчә һәм иҗтимагый кагыйдәләрчә, кабул ителгән һәм мактаулы хәрәкәт.

## ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз ........ 3
Диния нәзарәтенең кулланылуы һәм киләчәктә фарыз ителгән чаралары ........ 8
Диния нәзарәте дәвам итсә, аның киләчәге өчен идарә итү рәвеше һәм чара ........ 10
Нәзарәттә яңа комиссиянең эшкә керешүе ........ 19
Шәһәр Шәрәфнең имамлыгы ........ 19
Нәзарәттәге эшләр бүленеше ........ 20
Съездга килгән докладларда игътибар итәрлек нәрсәләр ........ 21
Коръән тәрҗемәсе мәсьәләсе ........ 25
Гыйльми шура мәсьәләсе ........ 28
Нәзарәтне тикшерү комиссиясе ........ 29
Съездның тәмамланмаган эшләре ........ 29
Ибне Габидиннең «Сәбәт» нөсхәсе һәм хәдис гыйлемнәре ........ 29
Муса әфәнденең доклады ........ 30
Съезд хакында Муса әфәнде хаты, Заһид Шамвилнең вафаты ........ 32
Сүзлек иясенең бер вакыйгасы, сәләфләрнең хәдис укулары ........ 35
«Әмин» сүзе хакында ........ 36
Совет-Польша килешүе ........ 36
Килешүләр, бармак хисабы ........ 37
Заһид Шамил тәрҗемәи хәле ........ 39
Татарстан җөмһүрияте рәисе Сәедгалиевкә ату ........ 41
Толстой хакында әңгәмә ........ 43
Совет мәктәпләренә балаларны җибәрү һәм дин дәресләре ........ 45
Кояш-ай тотылу мәсьәләләре ........ 45
Суфьян бине Гуяйнә һәм шәкертләре ........ 46
Нәзарәтнең мөрәҗәгатьнамәсе ........ 47
ГубЧКга чакыру ........ 49
Мирас бүлүдә Нәзарәт кәгазе ........ 51

Нәзарәтнең архивын алулары ........................................................ 51
Остаз, ата, каенаталарны һәм хатынның ирен
исеме белән атавы хакында искәрмә ........................................ 52
Исем кушу рәвешләре хакында искәрмә ........................................ 54
Минзәлә мулласы Шаммазовларның съезды ................................ 56
Намаз укыганда игътибар ителгән сөннәтләр ............................. 57
Кайгылы вакыйга ............................................................................ 59
Борынгы галимнәрнең акыл һәм шәригать
гыйлемнәренә мөнәсәбәтләре һәм акыл
гыйлемнәренең файдасы хакында ........................................ 60
Муллаларның Нәзарәткә мөрәҗәгате ........................................ 62
Мәүлиден-нәби (Аллаһ аны олыласын
һәм сәламләсен) тарихы ........................................................ 62
Вакытлы курслар дәресләре ........................................................ 63
«Сахих Мөслим» китабын уку, Нәвави,
Әбү Дауд, Тирмизи ................................................................ 65
Уфа милләтләр бүлегенең Нәзарәт тәгълиматен
күзәтү хакындагы кәгазе ........................................................ 69
Нәзарәт алдындагы курсларның дәресләре ................................ 69
Намазга керешкәндә тел ниятенең бидгать булуы,
күңел ниятенең әһәмияте ........................................................ 70
Намаз башлау тәкбирендә сөннәткә каршы
булган кыскача бер сүз ............................................................ 71
Эстәрлебашта җамигъ мәчет төзүгә
мөфтинең каршы булуы һәм рәсми хаты ................................ 72
Кәс, чынаякларга язылган гарәпчә шигырьләрнең хаталары.
Сәләх хәзрәтнең искәртүе........................................................ 74
Имам Бохари һәм Рифагыйның кайбер хәлләре............................ 75
Уфа милләтләр бүлегенә Нәзарәт тәгълиматы,
мәртәбәләре һәм архивы хакында мөрәҗәгать ............................ 76
Уфа имамнары белән коммунистлар арасында дини бәхәс.............. 76
Дини бәхәскә әзерлек ...................................................................... 79
Зыя Камалиның дин хакындагы кайбер фикерләре ........................ 81
Икенче мәртәбә дини бәхәс ............................................................ 83
Дин белән фән һәм боларны куллану мәсьәләсе ............................ 84

1920 елда булып киткән имтиханнарның кыскача җәдвәле ............ 86
Вакытлы курсларның һәм мөгаллимнәрнең вазыйфалары .............. 86
Курслар эшендә начар вакыйга ........................................................ 87
Икътисади мәсьәлә ............................................................................ 88
Мәгарри һәм Муса, Зыя әфәнделәр.................................................. 89
Томски Хәмзә ахун китаплары һәм тәрҗемәи хәле ........................ 90
Имамнарга мәҗбүри хезмәт ............................................................. 93
Вакытлы курсларны туктату ............................................................ 93
Фетнә хакында хәдис. Фетнәнең файдалары ................................. 95
Мәхкәмә шәргыянең бер еллык хисабы .......................................... 96
Вакытлы курслар шәкертләре ......................................................... 96
Самарада дин укыту .......................................................................... 96
Очрашу әдәпләре мәсьәләсеннән бер кечкенә,
ләкин әһле аз бер сүз ........................................................................ 97
Янә ГубЧКга чакыру ........................................................................ 100
Башкортларның махсус Нәзарәт төзүләре .................................... 102
Башкорт съездына вәкилләр һәм мөрәҗәгать җибәрү .................. 105
Истанбул, Анкара хөкүмәтенең үзләре
һәм Совет-инглиз мөнәсәбәтләре.................................................. 106
66 яшь тулу мөнәсәбәте белән үткән
гомерләргә гомуми бер караш........................................................ 108
Кыйммәтчелек.................................................................................. 110
18 дән түбәннәргә дин укыту мәсьәләсе........................................ 110
Фәкыһия ........................................................................................... 112
Мәхмүд Әсгадьнең «Ислам дине тарихы» китабы........................ 112
Том обсерваториясеннән алынган җәдвәл ..................................... 113
Җыелган иганәләрне Нәзарәткә тапшырмау
хакында башкорт хөкүмәтенең чарасы ......................................... 114
Ибраһим Акчурин хаты ................................................................... 114
Чулман буендагы хавариҗ җәмәгатенең ябылуы.......................... 115
Мөфти Мансур Халиков хаты һәм
Башкортстан Диния нәзарәте ......................................................... 116
Нәзарәтнең эш хисабы .................................................................... 118
Никах таркату турында фәтва ......................................................... 118

Нәзарәтнең теләкләре Үзәктә кабул ителгән .................................... 118
Совет хөкүмәтенең уңлашуы........................................................... 119
Госман Коръәне хакында............................................................... 120
Яңа имамнарга указларын тапшырганда
сөйләнә торган вәгазем ............................................................. 121
Архив хакында Мәркәзгә мөрәҗәгать ............................................ 123
Иманлы исерек................................................................................ 123
Чимкенттан (Черняевтан) хат.
Бала тәрбиясендә мөһим искәртүләр.......................................... 124
Ай хәбәрләре һәм кояш тотылу....................................................... 128
Архивка угрылар керү...................................................................... 129
Игенчелек мәсьәләсендә мөрәҗәгатьнамә ..................................... 129
Чиләбе тарафларындагы дини мәдрәсә .......................................... 130
Тарихи көн, нәк кырык ел................................................................ 131
Троицки вакыйгасы ......................................................................... 132
Нәзарәтнең бер бинасы алынуы ...................................................... 134
Тәфсир авторы Шәех Мәхмүд әл-Әлүси әл-Багдади ...................... 135
Зәмәхшәри ....................................................................................... 139
Кызык хәл........................................................................................ 140
Икенче кызык хәл ............................................................................ 141
Уразага керү һәм ай башлары.......................................................... 142
Ястүнең вакыты хакында фәтва ....................................................... 143
Хатыннарның җәмәгать намазына йөрүләре хакында...................... 144
«Мөкаддимәи җәзәрия» китабы ........................................................ 153
Бәләбәй өязенә сәфәрем ................................................................... 154
Карамалыда гает һәм вәгазь ............................................................. 159
Карамалыда безнең гает................................................................... 161
Әнәс, Кыргыз-Миякә, Сатый авылларында ..................................... 163
Канбәк, көчләп чукындырылган кешеләр,
Эстәрлебаш тәэсире ................................................................... 166
Мәнәвез ир-хатыннарына вәгазь, милиция рәисе............................ 169
Никифор авыл мәчете һәм имамнары, җомга вәгазе........................ 170
Яңгыр, бер русның рәхмәт әйтүе, гыйбрәт ..................................... 173

Эстәрле тәэсире, Шафигыйның
остазына каршы язуы, кисәтүләр ........................................ 174
Башкортларда кунак итү ысулы ........................................ 176
Күл авылы, Илчегол, язма китаплар ........................................ 177
Чебенле, Нарыстау кыйблалары ........................................ 179
Эстәрлебаш, тарихы, җомга һәм вәгазьләр ........................................ 182
Бу сәфәрдә иҗазәт бирелгән затлар ........................................ 183
Башкорт мөфтие Мансур бине Хатыйб бине
Габделхаликъның килүе ........................................ 185
Хәбибенәҗар хәзрәтнең вафаты, тәрҗемәи хәле ........................................ 189
Яңа Карамалы һәм мөхтәсибне тикшерү ........................................ 190
Исмәгыйль, Карлыман, Фәтхулла ахун җыентыгы ........................................ 192
Юлыккан нәрсәләр ........................................ 194
Йомран, Кабак, Кыешкы, Уфа ........................................ 194
Сәфәрдә күргән хәлләр ........................................ 197
Искә алынган тарафларда гыйльми хәл ........................................ 200
Кайбер дини мәрасимнәре ........................................ 202
Халыкның тормышлары ........................................ 204
Шәйхулла Алкин вафаты ........................................ 205
Зариф хәзрәт Әмирхан ........................................ 207
ГубЧКның финанс идарәсенә катышу ........................................ 209
Янә Троицки вакыйгасы ........................................ 210
Троицки Мөхәммәд хәлфә ........................................ 211
Казаннан Шакир хәзрәт ........................................ 212
Нәҗип хәзрәт Әмирхан ........................................ 214
Сафа мулла ........................................ 217
Аештан мулла Шакир ........................................ 218
Әдәп гүзәллеге ........................................ 218
Икътисади хәлләр хакында Нәзарәтнең хәлне бәян итүе
һәм тәгълиматы ........................................ 219
Уфа епископының үтерелүе ........................................ 220
Уфада ачлык дәһшәтләре ........................................ 220
Ачларга ярдәм комитетлары ........................................ 221

Мөфти-казыйлар мәҗлесе, мөселманнарда шәфкатьлелек
hәм мәрхәмәтлелек хакында фикер алышу ............................... 223
Риза казыйның китапханәсе хакында
Нәзарәткә мөрәҗәгатьләр ........................................................ 226
Күренгән ачлык хакында Мәркәзгә хәлне бәян итү ..................... 227
Янә ваба фаҗигасы ........................................................................ 228
Мәскәүдә ачларга ярдәм комитеты ябылган ................................ 229
Мәдинә мәчетенең планы ............................................................. 230
Габдулла Үтәмишев вафаты .......................................................... 231
Нәзарәткә Мәркәздән махсус комиссия килү ............................... 232
Петроград мәхәлләләре ................................................................. 232
Госман Коръәнен Төркестанга тапшыру мәсьәләсе ...................... 234
Ләбибә ханым вафаты .................................................................... 237
Төркиянең Грецияне җиңүе ........................................................... 239
Янә ЧКга чакыру ............................................................................. 241
Татарстанның Мәркәздәге вәкиле белән әңгәмә ........................... 242
Риза казыйның Богырслан сәфәренә әзерлеге ............................... 243
Мәскәү сәфәре ................................................................................ 244
Бу уңайсыз вакытта авыр сәфәр ник кирәк булды? ....................... 247
Сәфәр – җәhәннәмнең бер өлеше .................................................. 249
Тимер юлда тәяммүм ..................................................................... 250
Мөнәсәбәт белән янә бер мәсьәлә ................................................. 251
Икенче мәсьәлә .............................................................................. 252
Самара, Сызрань, билет җәфалары ................................................ 253
Акчурин вокзалы ............................................................................ 254
Мәскәүгә ирешү ............................................................................. 255
Җомга hәм мәүлид ......................................................................... 256
Бүлек .............................................................................................. 257
Төркия илчелегенә бару ................................................................ 258
Әфган илчелегенә бару hәм Әфганстан ........................................ 259
Ачларга ярдәм турында чаралар .................................................... 260
Мәүлид мәҗлесендә Төркия вәкилләре ......................................... 261
Хикмәт иясе Бруштейнга юлыгу hәм аның мәҗлесе ..................... 262
Заhид Шамвилнең ядкяренә мәҗлес ............................................. 264

***Галимҗан Баруди***

**ДНЕВНИК ВОСПОМИНАНИЙ:**
**с октября 1920 по ноябрь 1921 г.**

*На татарском языке*

**ХАТИРӘ ДӘФТӘРЕ:**
**1920 елның октябреннән алып 1921 елның ноябренә кадәр**

*Научно-популярное издание*

Басмага әзерләүчеләр – *Айдар Марсил улы Гайнетдинов*
*Руслан Ринат улы Хәбибуллин*

Компьютерная верстка **–** *А.Р. Тухватуллина*
Подписано в печать 13.11.2018 г. Формат 60×84 $^{1}/_{16}$
Печатных листов 17,0. Тираж 200 экз.

Отпечатано с готового оригинал-макета

ИЗДАТЕЛЬСКИЙ ДОМ
*им. академика В.И. Андреева*

420108, г. Казань, ул. Портовая, 25а
Тел./факс: (843) 231-05-46, 231-08-71, 231-04-19
E-mail: citlogos@mail.ru
www.logos-press.ru

**Сайт**
**Института истории**
**Академии наук РТ**
**Татаровед.рф**